# КАЗАН УТЛАРЫ

10. 1992



**КАДЕРЛЕ УКУЧЫЛАР!**

Мөхтәрәм милләттәшләр!

Башка күп кенә газета-журналлар кебек, матди ярдәм алу өчен, без дә **Редакция фонды** оештырдык. Татарстанда, Россиядә, БДБ дәүләтләрендә, чит илләрдә яшәүче милләттәшләребезгә мөрәҗәгать итәбез. Безгә ярдәм итәргә теләүчеләр булса, хәл кадәри акчаларын түбәндәге адрес белән күчерә алалар:

**420066, г. Казань, ул. Декабристов, 1. Волжско-Камский акционерный банк РКЦ ГЦБ. Р/счет 1 700161998/2345114 МФО 265005. Для Фонда Редакции.**

# КАЗАН УТЛАРЫ

АИЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:

ТАТАРСТАН ХӨКҮМӘТЕ, ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

**10**

**(840)**

**1992**

КАЗАН

## *Бу санда*

ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

**Ә. ГАЛИЕВ.** Авылдашлар. *Роман*....3
**М. КАЮМОВ.** Дүртенче. *Поэма*....81
**Ф. САДРИЕВ.** Таң җиле. *Роман*....87
**РАФАИЛ.** Мизгел. *Шигырьләр*....135
**Ф. ГАБДРӘХИМ.** Кораб ясый татар. *Шигырьләр*....139
**С. РӘХМӘТУЛЛА.** Ага сулар. *Шигырьләр*....141

ДӨНЬЯ ӘДӘБИЯТЫ ҮРНӘКЛӘРЕННӘН

**Р. АКӨТӘГАВА.** Чытырманлыкта. *Новелла*....144
**Ж. АМАДУ.** Габриэланың гыйшкы....154

ХӘЕРЛЕ ЮЛ!

**Р. РАХМАН.** Керфекле тәрәзәләр. *Шигырьләр*....150

ПУБЛИЦИСТИКА

Бөтендөнья татарлары конгрессы....173
**В. ГАЙФУЛЛИН:** Татар мәктәбе: алда ниләр көтә....184

ЛАТИН ӘЛИФБАСЫ НИГЕЗЕНДӘ

ТАТАРЧА УКУ КҮНЕКМӘЛӘРЕ

**ДӘРДМӘНД.** Без. *Шигырьләр*....189

Безнең календарь....188
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан....191

*Баш мөхәррир*

**Равил Фәйзуллин**

*Редколлегия*

**Гариф Ахунов**
**Гүзәл Вәлиева-Сөләйманова**
**Тәлгат Галиуллин**
**Аяз Гыйләҗев**
**Салих Маннапов**
**Зиннур Мансуров**
**Рөстәм Мингалимов**
**Фәрвәз Миңнуллин**
**Минтаһир Минһаҗев**
**Мөхәммәт Мәһдиев**
**Ринат Мөхәммәдиев**
**Рашат Низамиев**
***(баш мөхәррир урынбасары)***
**Индус Таһиров**
**Марс Шабаев**
***(җаваплы сәркатип)***
**Тәүфикъ Әйди**
**Марсель Әхмәтҗанов**

Безнең адрес: 420066,
Казан, Декабристлар ур., 2.

Телефоннар:
баш мөхәррир — 53-07-60,
баш мөхәррир урынбасары —
53-07-09,
җаваплы сәркатип — 53-36-12,

*бүлекләр:*

чәчмә әсәрләр, шигърият,
очерк — 53-07-61,
тәнкыйть, фән, сәнгать,
хатлар — 53-07-63,
корректорлар — 53-07-65.

## В НАШЕМ НОМЕРЕ

«Проза и поэзия»: окончание романа **А. ГАЛИЕВА** «Земляки», начало романа **Ф. САДРИЕВА** «Утренний ветерок», поэма **М. КАЮМОВА**, стихи **Р. ГАЗИЗОВА, Ф. ГАБДРАХИМА, С. РАХМАТУЛЛЫ**.
«Из страниц мировой литературы»: новелла **Р. АКУТАГАВА** «В чащобе», отрывок из романа **Ж. АМАДУ** «Любовь Габриэлы».
«В добрый путь!»: стихи **Р. РАХМАН**.
«Публицистика»: материалы из Всемирного конгресса татар, статья **В. ГАЙФУЛЛИНА** о проблемах татарской школы.
Навыки чтения на основе латинской графики.
Наш календарь.
Дневник общественно-политической жизни.
На наших обложках: картина уфимского художника Р. Хасанова «Игры наших дедов»; известный ученый, литературный критик А. Ахмадуллин.

*Мөхәррирләр:* Мансур Вәлиев, Рәдиф Гатауллин, Шамил Маннапов, Кояш Тимбикова, Тәүфикъ Әйди, Рәшит Әхмәтҗанов.
*Техник мөхәррир:* Тәслимә Сибгатуллина.
*Корректорлар:* Гөлзада Моратова, Лилия Гатуллина.

Производствога бирелде 11.08.92 ел. Басарга кул куелды 29.09.92 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70×108 1/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8).
Тираж 23989. Заказ В-413. Бәясе 1 сум 80 тиен.

Татарстан газета һәм журналлар нәшрияты басмаханәсе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1992 ел.

Әнәс Галиев

# АВЫЛДАШЛАР

РОМАН

## XII

Икенче көнне Әлфия райфо мөдире янына барды. Мөдир түгәрәк гәүдәле, боҗыр кебек терчә, гадәттән тыш өче телле кеше икән. Бу кеше сугыш алдыннан гына Әлфия укыган институтны тәмамлаган, бергә укыган иптәшләрен искә алып, аларга мөсхәрәле бәяләр биреп утырды. Янәсе, кызның кылын тартып карый. Кешеләрне таный беләме, янәсе. Ун елга якын мөдирлек чорында байтак хезмәткәрләрне кулы аша үткәргән бу кеше Әлфиягә шикләнебрәк карады. Бусагасын беренче тапкыр атлап кергәннәрнең каушап төшүен, ялагайлануын, ялваруын күтә иде мөдир, шундыйларга күнеккән иде. Болай үзе финанс эшенең бөтенваклыкларын, законнарны яхшы белә мөдир, хәтере дә искиткеч шәп. Закон дигәндә, кәгазь актарып тормый.

Баштарак кыю гына җавап биреп утырган Әлфия бара-тора каушый башлады, буталды, тирләп чыкты. Мөдирнең өздереп карый торган рәхимсез күзләре дә тәэсир итте бугай. Аның соңгы сорауларына рәтле җавап бирә алмады.

— Безнең эш аерата үзенчәлекле, зур өзерлек таләп итә. Эшли алырсыңмы? — диде ул турыдан-туры.

Әлфия, ясалма елмаерга тырышып, күзләрен бер ноктага терәп, тынып калды. Әгәр урнаша алмаса, Мансур абыйсына ни әйтер? Хурлыкка кала ич алай!

— Тырышырмын,— диде ул, кыска гына.

Мөдир елмайгандай итте.

— Ярый. Мансур белмичә генә тәкъдим итмәс. Эшләп кара.

Мөдир, телефон трубкасын кулына алгач, беравык уйланып торды, шуннан соң гына шалтыратты, кемнедер үз янына чакырды. Бер минут та үтмәде, кабинетка Юныс килеп керде. Ул да уңайсызланды ахрысы, бусага аша атлау белән тукталып калды.

— Юныс Гыйльметдинович, сезнең полкка яңа солдат килде. Менә бу яшь иптәшне бер ай сынау шарты белән налог инспекторының ярдәмчесе итеп эшкә алабыз.

Мөдир белән Юныс берничә сүз алыштылар да, икенче көнне сәгать тугызга эшкә килергә кушып, Әлфияне өенә кайтарып җибәрделәр.

Юныс, кабинетына чыккач, озак кына учын-учка ышкып утырды. Эшкә аның кул астына килә икән, бу борыны чөенке кыз да әллә кая

---

Ахыры. Башы 9 нчы санда.

бара алмас, дип уйлады. Әлфия исә юл буе газаплы уйлар тозагында кайтты. «Әллә иртәгә райфога эз дә басмаскамы?» — дип тә уйлады, аннары тагын икеләнеп калды — Мансур абыйсына ни дип аңлатыр? Мансур абыйсын уйлагач, таянычы, яклаучысы булачагына ышанган кыз йодрыгын һавада селкеде: «Кагылып карасын Юныс!.. Күрмәгәнен күрер!»

Финанс оешмаларында налог хезмәтләрен башкаручылар өчен иң кызу көннәр иде. Елга ике мәртәбә — беренче гыйнварда һәм беренче июльдә налог учеты үткәрелә. Бу финансчыларның «урак өсте». Әлфия «июль урагына» туры килде.

Беренче июльдә авыл хуҗалыгы буенча керем чыганаклары исәпкә алынып, бөтен түләүчеләргә налог өр-яңадан исәпләнә. Һәр хуҗалыктагы сыер, дуңгыз, кәҗә-сарык һәм янә дә яшелчә, бәрәңге утырткан җирләр дә исәпкә алына. Аларның һәркайсының доход нормасы бар. Шул нормативларны кулланып, һәр хуҗалыкка өстәмә налог салына. Четерекле һәм җаваплы эш бу.

Әлфиягә эш кәгазьләре белән танышу өчен бер көн вакыт бирелде. Бүтәнчә эшне сузарга ярамый, диделәр аңа. Ул көннең көн буе өстәлгә тау кадәр өелгән кәгазьләрне актарып, баш ватып утырды. Кәгазьләрнең әле берсен, әле икенчесен аңларга тырышты, тырышса да, башы җитмәде. Төшкә кадәр бүлмәдә алар икәү генә утырдылар. Юныс аның ягына әйләнеп тә карамады, сорашмады, булышмады, төштән соң, сүзсез генә чыгып югалды. Әлфия бер башы калды.

Төштән соң мөдир керде, йомшак кына хәл-әхвәл белеште:

— Ничегрәк соң, аңлашыламы? Тырыш, уяу бул, иртәгә менә эшкә ныгытып керешерсең, инспекторың белән участокка чыгарсың. Мөдирнең тавышы бүген йомшак булса да, аның сораштырып йөрүе Әлфиянең гайрәтен тагын да ныграк чигерде. Ул шыпырт кына чыгып сызарга җыенган иде, Мансур абыйсы исенә төшеп, тагын тыелып калды.

Райфо хезмәткәрләре кабинетта утырмыйлар да икән, алар көннәр буе участокта, йорттан йортка йөреп көн үткәрәләр... Әгәр эше барса, атна буе райфода күренмәсә дә сүз әйтүче юк икән. Мөдирдән соң кергән хатын Әлфиягә шуларны аңлатты. Әлфиянең инспекторы кичкә кырын гына кайтып керде. Наилә атлы татар хатыны икән. Наилә, бик эре кыланып, суык кына күреште.

— Минем ярдәмчем син буласыңмы? — дип сорады.

Ул Әлфиядән күпкә өлкән, үтә ябык, йөзе зәңгәрләнеп беткән, өшәнгән хатын иде. Соравына җавап булмагач:

— Әллә үзебезчә аңламыйсыңмы? — диде.

— Аңлыйм, нигә аңламаска.

— Мин сине марҗа кызы дип торам. Толымың гына озын, толымың булмаса, чат марҗа кызы инде син. Ярый, безгә бергә эшләргә туры киләчәк.

Наилә районда гына түгел, шәһәрдә дә иң тәҗрибәле, елгыр инспекторлардан санала. Мансур Әлфияне көчлерәк иптәшкә беркет инде, дип үтенгәнгә күрә, райфо мөдире кызны Наиләгә тапшырырга булды.

— Яңа кеше алдык, эш белән танышлыгы бер дә юк. Өстәвенә юаш күренә. Сиңа тапшырам. Нык кара! — диде ул, Наиләне кабинетына чакырып.

Наилә уйлап-уйлап торды да иртәгесен Әлфияне участокның иң ерак почмагына — Семхозга алып китте. Авыл хуҗалыгы фәнни эзләнүләр институтының тәҗрибә кыры — Семхоз шәһәрдән читтә, ун чакрым чамасы ераклыкта урман эчендә урнашкан иде. Ул якка транспорт йөрми, инспекторларга җәяү барырга туры килде. Наиләнең үзенчә Әлфияне сынавы да иде. Шунда җәяү барып кайтырга чыдамы җитсә — эштә калыр, юк икән — ак юл, дип уйлады. Узган ел да шулай берәүне сынаганы бар иде, ярдәмче итеп билгеләнгән туташ Семхозга барып кайткач, икенче көнне эшкә килмәде.

Иртәнге алтыда, трамвайның актык тукталышында очрашабыз, дип сүз куешканнар иде. Әлфия нәкъ әйтелгән вакытта билгеләнгән урынга барып басты. Наилә үзе шактый соңарды. Иреннән зарланырга тотынды һәм ярты юлны үткәнче зарланды.

— Нишләргә дә белгән юк... Эчә дә кайта, сала да тавыш чыгара...

Наилә иренә хатынын аертып чыккан иде. Аерылган хатын чәпчеп йөрмәде, мәгәр ике җитеп килгән кызлары Наиләнең теңкәсенә тиделәр. Кич җитте исә килеп керәләр дә, телләренә ни килсә, шуны әйтеп сүгәләр тегене.

Әлфия ир-ат халкыннан җизнәсе белән Мансурны гына белгәнгә, исерек ир белән яшәү хикмәтләрен аңламый иде, әлбәттә. Ни уңга, ни сулга аерып сүз әйтмәгәч, Наилә аның хакында, аңгырадыр бу нәрсә, сүзне уртак итә дә белми дип уйлады.

Алар Семхозга барып кергәндә, төш вакыты җитеп килә иде инде. Монда төпләнгәннәр, барысы да дип әйтерлек, колхоз оҗмахыннан качып, яңарак кына авылдан килгән кешеләр иде. Андыйлар йорт сала, йорт белән рәттән хуҗалыгын да ныгыта. Авылдагы ата-бабаларының нигезен бетереп, теш шыкырдатып күченеп киткән крестьяннар монда килүгә тормышны нәкъ авылча диярлек дәвам иттерәләр. Урын гына башка, калганнары үзгәрешсез. Абзар тулы хайван, өй янында иркен бәрәңге бакчасы, агачлар арасында умарталар. Үз сүзләре белән әйткәндә, «Эшләре дә, ашлары да бар». Яратмаганнары мәгълүм, алары — налог инспекторлары.

Әлфия үзенең нинди эшкә тап булганын, кемнәр арасына килеп керәсен күз алдына да китерә алмый иде.

— Безгә әүвәл башлап тамак ялгап алырга кирәк. Теге исерек дуңгыз белән маташып, ашап алырга да өлгермәдем мин,— диде Наилә.

Әлфия аның сүзләрен үзенчә аңлады.

— Тамак ялгарлык ашханә бармы соң монда? — дип сорады.

— Хәзер рәтлибез, бер дус апа бар минем.

Наиләнең бу сүзләре Әлфиягә мәзәк булып тоелды, чөнки кичәгенәк мөдир сүз арасында гына аны кисәтеп үткән иде.

— Участокта эш өстендә берәү белән дә якын мөнәсәбәткә кермәскә, аеруча налог түләүчеләрдән сак булырга, ашап-эчеп утырмаска, дөнья хәлләрен сөйләшмәскә,— дигән иде кырыс мөдир.

Алар урам очындагы кырый йортка барып керделәр. Өйдә балалар гына иде, сорашып, әнкәләренең шәһәргә сөт сатарга китүен аңладылар.

— Булмады,— диде сөмсере коелып Наилә.— Уңмаган юлга чыкканбыз!

Ул түргә узды, өстәл артына кереп утырды, портфеленнән чиста бланклар тартып чыгарды.

— Яхшылап күзәт, өйрән.

Наилә бер графаны бармагы белән төртеп күрсәтте дә бланкны тутыра башлады.

— Аның бер кыенлыгы да юк, икенче хуҗалыкка кергәч, тутырып карарсың.

Ул бланктагы стандарт сорауларга җавап язып бетерде дә, балаларга мөрәҗәгать итеп:

— Әйтегезчә, үскәннәрем, йортта нинди хайваннар асрыйсыз? Карагыз аны, алдашмагыз. Алдашсагыз, милиционер алып китәр.

Балалар бер-берсенә төртә-төртә пырхылдадылар.

— Нәрсәдән көләсез? Ни булды?

Балалар көлешә-көлешә почмак якка шылдылар. Наилә тузынып артларыннан керде дә олырак кызны беләгеннән сөйрәп алып чыкты.

— Син, үскәнем, җитеп беткәнсең, ә үзеңнең бер тиенлек акылың юк. Әйт, нинди хайваннар асрыйсыз?
Кыз тиз үк җитдиләнде.
— Мин берни дә белмим, әни кайткач керерсез,— диде.
— Яхшылык белән әйтмисең икән, әниеңне райфога чакыртып, арт сабагын укытырмын!
Кыз белән бергә Әлфия дә кызарынды, эче чурлап тора иде, ашыйсы килүе дә онытылды. Кыз курка торганнардан түгел икән, башын бер якка кыйгайтты да тын гына басып торды. Наилә бүртенеп-кызарынып бланк тутыра башлаган иде, каләм очы сынды. Ачуы соң чиккә җиткән Наилә икенче каләм белән сыздыйн-быздыйн язу язды да кызга бирде:
— Әниеңә бир, иртәгә үк райфога килсен.
Капкадан чыгып, Әлфия баядан бирле кыҗрап торган сүзләрен әйтергә дә өлгермәде, кыз аларны куып җитте.
— Мә, апа, язуың үзеңә булсын! — дип, кәгазьне җиргә атып бәрде дә йөгереп кереп китте.
Беренче хуҗалыкта ук маңка бер кыздан җиңелеп калгач, Наиләнең ярсуы ташыды, күршедәге капканы аягы белән тибеп ачты да ишегалдына күзен акайтып барып керде. Аларны бозау кадәр ала эт каршы алды. Ажгырып, ыржаеп торган этне күргәч, Наилә әче тавыш белән акырып җибәрде. Бу тавышка эт шып туктады, өй ишегеннән чүмәлә зурлыгы бер ир килеп чыкты.
— Тими ул,— диде, төксе карап.
Хуҗасы килеп муен каешыннан тоткач та әле эт кат-кат ырылдап алды, сырт йоннары кабарды. Наилә хуҗага бәйләнергә тотынды:
— Шундый явыз этне бәйсез тоталармы? — диде.
— Явызларга гына шулай ырылдый ул. Мөгаен, юньлелеккә йөрмисездер әле,— диде ир, йөнтәс кашларын җыерып.
— Милициягә хәбәр итәргә кирәк булыр!
— Янама, янама! — диде ир кызып.— Сезнең ишеләрне күп күргән.
— Кулак калдыклары! Тапкансыз җылы урын! — Наиләнең бу сүзләреннән Әлфия куырылып калды.
— Син эттән түгел, эт синнән курка! Кем ул кулак калдыгы? Авызыңны үлчәп ач!
Тавышка өйдән урта яшьләрдәге хатын килеп чыкты. Керүчеләрнең кемлеген абайлагач, атылып килеп җитте, ирен әрләргә тотынды.
— Кунаклар бар икән, керегез, кер, күптән күренгәнегез юк иде. Ул тозсызга исегез китмәсен, өйгә узыгыз.
Наиләнең беләгенә асылынып өйгә өстерәде, Әлфиягә күзе төшеп, аны чакырырга тотынды.
— Бу кызый да синең беләндер инде? Әйдә, әйдә, түрдән узыгыз.
Хуҗа хатын инспекторларны кыстый-кыстый түргә үк утыртты.
Өй эче буш диярлек, күз төшәрлек бер нәрсә дә юк. «Ә Наилә апа шуларны кулак калдыгы дип сүкте!» — дип борчылды Әлфия. Йорт эчен җентекләбрәк карый башлады. Бер почмакта балта белән юнып ясаган тупас карават куелган. Кырына кызылга ак чәчәк чигелгән чаршау эленгән. Өстәл-урындыклар да бик тупас, өстәл тактасы яхшылап ышкыланмаган. Күренеп тора, хуҗа боларны үзе һәм күптән түгел генә ашык-пошык әмәлләгән. Күзгә карарлык та түгел, почмагы кителгән, пыяласына су тиеп бозылып беткән. Хуҗа хатын өстәлгә тиз генә клеенка җәйде һәм юеш чүпрәк белән сөртеп алды. Үзе әзерли, үзе еш-еш тәрәзәгә күз ташлый, ирем килеп керер дип курка ахрысы, дип уйлады Әлфия.
— Мин хәзер... Сез әз генә утыра торыгыз.
Бер чыгып киткәч, хатын шактый тоткарланды, Наилә белән Әлфия хафалана ук башладылар.

— Әллә бу кулак калдыгы чыгыһ тайдымы? — диде Наилә урыныннан калкынып.

Әлфия җавап бирергә кыймады. Наиләнең кыланышлары аның җанын әрнетә иде. Хуҗа хатын зур чүлмәк күтәреп килеп керде.

— Бәхетле авыз икәнсез, матурларым. Кичә генә сөзмә өзерләгән идем. Телеңне йотарлык булган. Әйдәгез, тамак туйдырып алыгыз.

— Юк, ашап тормыйбыз, ашыгабыз,— диде Наилә.— Тизрәк эшне бетерик тә кузгалыйк.

— Нинди сүз ди ул? Аштан олы булалармы? Гөнаһысын кая куярсыз?

Әлфиянең өзелеп тамагы ачкан иде. Наиләнең карышкан булып маташуын ошатмады.

Әле генә ашап чыгарлык кеше эзләп йөрде, хәзер чыгымчылаган була. Бик ясалма кеше икән бу Наилә!

— Әйдә, сеңлем, ичмасам син авыз ит. Сөзмәсе дә сөзмәсе! Начальнигың ашамаса ашамас. Мондый сөзмә шәһәрдә бик тәтеми ул.

Хуҗа хатын зур агач җамаяк белән Әлфиягә сөзмә бүлеп куйды, өстәл уртасына үзе пешергән ипи телемнәрен өйде. Тик Әлфия Наиләдән алда ризыкка үрелергә базмады. Алар шулай тарткалашып-ялындырып утырганда, баягы ир — хуҗа килеп керде. Хуҗа ханым аңа ябырылды:

— Үпкәләткәнсең кунакларны, телеңне өзеп алырга кирәк синең.

— Үпкәләсәләр, үпкә ашатырбыз. Ризыгыңны тыгынсалар да, барыбер өстеңә язып китәчәкләр!

Хуҗалар да, кунаклар да тын калды, ишегалдындагы этнең ырлаганы гына ишетелеп торды. Хуҗа хатын майдай эрегән тел белән Наиләгә атап эндәште.

— Әхмәтша абыеңа карама. Ачулы чагы. Кичә, эштән кайткан чакта, илле сум акчасын талап алганнар. Юк иде элек мондый хәл, без монда бер-беребезне белеп, туганнарча яши идек. Күбесе авылдашлар! Авылдашны рәнҗетергә ярыймыни? Баксаң, бодай басуына билчән дә килеп кергән икән.

— Ачу килгән чак — кулда пычак, дигәндәй...— Әхмәтша, дәү сынын калкытып, Наилә каршысына килеп басты.— Утырыгыз, сеңел, миңа карамагыз. Сөзмәдән авыз итегез. Гадәтем шул, әйтәм дә кайтам. Ашагыз, сатып алган нәрсә түгел, үзебезнеке.

— Шундый ул, шундый,— дип такмаклады хуҗа хатын.— Кеше барында телеңне тый, дип ни әйтәм, һич өйрәтеп булмый.

Наилә дә артыгын кыстатмады, алдына куелган җамаяктан башта чемченеп, бераздан соң умырып, төмле сөзмәне ура башлады. Әлфия күңеле белән кырыс Әхмәтша ягында иде, тагын ни әйтер икән, дип аның авызына карап, көтеп утырды. Наиләгә каршы сыңар сүз дә әйтә алмый Әлфия, ичмасам шушы тупас, кыргый Әхмәтша сүз әйтеп аны акылга утыртсын иде.

— Шәһәр халкына хайван асрау тыела, дип сөйлиләр. Дөрес хәбәр микән? Әхмәтша бу сүзләрне үз алдына әйтте.

— Тыеп дөрес эшлиләр! — диде Наилә.— Хайван багу — авыл халкы эше. Малны алар асрарга тиеш. Шәһәрдә эшче сыйныф яши. Завод-фабрика кешеләре. Пролетариат. Пролетариат! Безнең партия шуңа таяна. Шәһәрдә мал асраган кеше кем була? Ахыр чиктә ул кулакка әйләнә. Коммунистик идеалларга хыянәтчеләр үсә мал абзарларында!

Әхмәтша чәчү тубалы зурлыгындагы башын чайкады.

— Хайван асрауны тыйсалар, халык сөтке-майга тилмерәчәк. Итне әйткән дә юк.

Наилә сөзмәне сыпырып куйды, шуны гына көтеп торгандай, хуҗа хатын аның җамаягына чөмәкәй итеп тагын сөзмә салды.

— Хәзер колхозлар төмам ныгып җитте,— диде Наилә, кашыгын сөзмәгә батырып.— Кукуруз үстерүне дә җайга салып җибәрсәк, шәһәр

халкын авыл хуҗалыгы продуктлары белән тәэмин итәргә мөмкинлекләр туа. Партия бу эшне тулаем үз кулына алды.

— Ә мондый сөзмә кибетләрдә булачакмы?

— Һичшиксез! Партия шулай ди!

— Белмим, белмим,— дип гөрләде Әхмәтша.— Колхоздан чыгып шәһәргә килеп җиткәнче мең кул аша узган болай ләззәтле булмый ул. Су кушып җанын алалар аның. Сауган чиләкләр шакшыда ауный. Үз сөтең — үз сөтең инде ул! Колхоз — уртак мал. Уртак малны эт җыймас дигәннәр татарлар.

Наилә күкерт булып кабынды.

— Сез ни сөйлисез? Колхозларга яла ягасызмы? Әйтсәм әйтим, сезнең барыгызда да, урамыгыз белән, кулак психологиясе бетмәгән!

Хуҗа хатын чәчрәп арага керде.

— Атасы, надан башың белән сүз көрәштереп утырма әле.

Бары тик өч класс белемле, финанс органнарына партия кушуы буенча кереп урнашкан Наилә үзен «укымышлы, галим, белдекле» дип атауларыннан эреп китә иде, шундук борыны күтәрелде. Әхмәтша, һава үзгәрүен чамалап, ишек бусагасына таба китте, чүнкәеп утырды, кесәсеннән каралып беткән янчык чыгарды, гәҗит кәгазе ертып, беләк юанлыгы тәмәке төрде. Кабызырга өлгермәде, әллә кунаклар алдында өй сасытып утырыр идеңме дип, хуҗа хатын ирен өереп чыгарды. Ишегалдыннан усал этнең сөенеп чинаганы ишетелде.

Ашап-эчеп алгач, хуҗа хатынның куркынган чыраена төс кайткач, Наилә портфелыннан учет бланклары чыгарып Әлфиягә тоттырды.

— Мин әйтеп торам, син яз,— диде.

Әлфия маңгаена сибелеп тир чыкса да, бланкның беренче битен җиңел генә язып бетерде. Анда гомуми мәгълүматлар — хуҗаның исем-фамилиясе, туган елы, эш урыны, яшәгән йортының страховой бәясе, биләгән җир күләме сорала иде. Икенче биттә керем чыганакларын исәпкә алу графалары китте. Боларына җиткәч Әлфия төртелеп калды. Беренче сорауда эре мөгезле терлек саны күрсәтелергә тиеш. Ул курка-курка гына:

— Ничә сыерыгыз бар? — дип сорады.

— Бер, җаным, бер! Артыгын тотарга рөхсәт итмиләр! — диде хуҗа хатын.

Наилә ул биргән җавапка ышанып бетмәде.

— Әгәр сарайга чыгып карасак?

— Карасаң-карамасаң, артыгы юк.

Икенче сорауны Наилә үзе бирде.

— Бәрәңгене өй янына гына утыртасызмы?

Бу сорауга җавап биргәндә, хуҗа хатынborгаланырга, сыргаланырга тотынды.

— Кырга бәрәңге утыртканыбыз да юк, утыртмабыз да. Без ирлехатынлы икәү генә, булышыр кешебез юк, өй янындагысын да көч-хәл белән карап өлгерәбез.

— Юлда килгәндә бер кырыйда зур гына бәрәңге кишәрлеге күрдем. Ул кемнеке?

— Минем бәрәңге җире күргәнем юк якында,— диде хатын, кызарынып.

Наилә бу сорауны сынар өчен генә әйткән иде.

— Яшелчә утыртасызмы? Кыяр, кишер, кәбестә.

— Юк, сеңлем. Без авылныкылар, яшелчә үстерә белмибез.

Хуҗа хатынга тәмам ышанган кыяфәт белән утырган Наиләнең кинәт төсе бозылды, сөйләгәннәренә бөтенләй ышанмавын белдерде, ишегалдына чыгып, барысын да инәдән-җептән үткәреп, җавапның дөреслеген тикшерергә теләде. Телдән биргән җавапларга ышанмаска сәбәбе дә бар иде Наиләнең. Узган ел ревизия вакытында, исәпкә алынмаган керем чыганаклары табып, җанын алдылар аның. Ел буе

телдән тешмәде, киңәшмә саен райфо мөдире аның ялгышын мисалга китерде. Әллә ни гонаһы да юк иде болай, исәп вакытында өч хуҗалыкның яшелчә җирен төшереп калдырган, аерып күрсәтмәгән иде. Эш шунда, яшелчәнең керем күләме бәрәңгенекенә караганда бермә-бер артык исәпләнә. Шуннан бирле кан түкерде Наилә, хуҗаларның бер сүзенә дә ышанмады, кат-кат күздән кичереп, иснәнеп йөреп тикшергәч кенә акт яза торган булды.

Хуҗа хатынның каушавын Наилә генә түгел, тәҗрибәсез Әлфия дә абайлады, алар, өчәүләшеп, ишегалдына чыктылар. Сарай ишегенә сөялеп лыш-лыш тәмәке пышкытып торган Әхмәтша төпчегән җиргә бәрде дә җиллпуч хәтле киң итек табаны белән ышкырга тотынды. Гүя ул тәмәке төпчегән түгел, вакытсыз йөргән налог инспекторларын сыта, изә иде.

Наилә борынын җыерып исни-исни иң элек лапаска керде. Анда ике дәү дуңгыз мыркылдап аунап яталар иде.

— Абау, сез дуңгыз да асрыйсыз икән!

— Безнеке түгел, безнеке түгел! — диде җылар дәрәҗәгә җитеп хуҗа хатын.— Вакытлыча дип авылдан килгән таныш урыс калдырып киткән иде.

— Бер генә түгел, икәү!

— Алып китә ул аны!

— Шулкадәр әйттем,— дип сүгенде хуҗа,— хәрәм малны йортка кертмик дидем.

— Закон буенча ике дуңгыз асрарга рөхсәт ителми.

— Сеңлем, җаныем, зинһар, дим, яза күрмә, бер атнадан килеп карарсың, эзләре дә булмас.

— Суеп сатасызмы?

— Алып китә аларны, урысы алып китә!

— Менә шул, налогны икеләтә түлисез!

— Сеңлем, бәгырем,— дип ялварды хуҗа хатын,— син безгә налог кәгазе китереп торма, акчасын үзең генә ал да шуның белән бетер.

Наилә сискәнеп китте, Әлфиягә күтәрелеп карады, бит алмалары аклы-кызыллы булды, ул чиктән тыш ачулы тавыш белән:

— Ә-ә, син безне сатып алмакчы буласыңмы? Димәк, әле синең яшергән малларың тагын бар! — дип чәрелдәде.

Өйгә кире кереп, Наилә үз кулы белән яңа бланк тутырды һәм, Әлфия язганнарын ертып, яңасын сумкасына салып куйды. Аның хуҗаларны сүзе белән дә, гамәле белән дә кимсетеп-рәнҗетеп, сүгеп-талап кыланулары Әлфиянең косасын китерде. Хуҗаларның ашын аша да башларына т... кит инде! Хуҗа хатын шулкадәр курыкты, кулы калтырап, Наилә яңадан тутырган карточкага көчкә-көчкә имзасын салды.

— Бигрәк инде... үзебез дә... оятның ни икәнен белмибез,— диде урамга чыккач Әлфия.

— Кемнән оялырга тиеш инде без?

— Сыйландык, рәхмәт тә әйтмәдек.

— Рәхмәт ди аларга, кулак калдыкларына! Шулар басты инде шәһәр тирәсен. Сардылар, юлын-җаен таптылар. Шәһәргә качып киләләр дә баерга тотыналар. Ә колхозларда эшче көчләр җитми. Коммунизмны кем төзер? Болармы? Кулымнан килсә, авылдан качып йорт салып кергәннәрнең нигезләренә кадәр яндырыр идем мин!

— Байлыкларын әйтер идем, ташка үлчим.

— Кулакка ирек кенә бир, башыңа менеп атланачак! Байлык җыю каннарына сеңгән, нәселдән килә. Кулакның тамырын корыттык дигән булалар. Корытырсың аларны! Бер җирдә утап ташлыйсың, икенче җирдә хәзер үк калкып чыгалар. Минем әткәй авылда актив иде. Утыз җиденче елны байтак дошманнарны сөрде. Аның эшен мин дәвам итәм.

Әлфия үзенә остаз итеп билгеләнгән кешенең кем икәнен аңлап, бүтәнчә сүз көрәштереп маташмады, йорттан йортка кергән саен күңе-

ле боега барды. Аларның эшләре шактый озакка сузылды, кич җитте. Көн азагына таба Әлфия бик нык арыды, ә Наилә, киресенчә, этләшкән саен, хуҗаларны эт итеп сүккән саен, аның адымнары җиңеләйде, күзенә кабынган усал ут сүнмәде, ул зәһәрен теләсә кемгә теләгән кадәр чәчте.

Өйләренә кайтып егылганда, тәмам әлсерәгән иде кыз. Бүтән көннәрне җизнәләренә очып кайта иде, бигрәк тә апасы Зәйтүнә малай алып кайтканнан соң ул өйләрен яратты... Бүген күзенә ак-кара күренмәде. Равилнең бишеге янына әйләнеп тә карамады, тиз-тиз өстен чишенде дә караватка менеп ятты.

— Син, бүген эштән соң Мансур янына барам дигән идең түгелме? — дип сорады Зәйтүнә.

— Арыдым. Телем әйләндереп сәлам бирерлек тә хәл калмады.

Ул арада Равил тавыш бирде, Зәйтүнә аны бишектән алып ими каптырды.

— Ни булды ул кадәр? Таш кисмәгәнсеңдер бит?

— Таш кисүдән дә яманрак.

Әлфия апасына бүген башыннан кичкәннәрне сөйләде.

— Эшнең берәгәйлесен тапкан сиңа зирәк Мансурың! Безнең авылда Миңлеәхмәт бар иде. Халыкны талап, толларны елатып йөрде-йөрде дә, хәзер, әнә, көнкәйде. Адәм каргышы төшә ул! Башка эш эзлә.

Арага Мансур исеме килеп кергәч, Әлфиянең мәсьәләне чак кына йомшартасы килде.

— Мин читтән карап кына йөрдем, катнашмадым,- диде.

— Иртәме, соңмы, барыбер катнашырга туры киләчәк. Мин дә, араларына кермәм, дип озак маташтым, барыбер пычранасың икән.

— Алда күз күрер. Мин гадел булырга тырышырмын. Кем дә булса налог инспекторы булып эшләргә тиештер бит?

Әлфия, апасының сүзен кире кагып маташса да, икенче көнне Мансур белән очрашкач, зарын озаклап сөйләде. Мансур ул көткәнчә кызып китмәде, күтәрелеп бәрелмәде, Әлфияне сабыр гына тыңлады да тирән итеп бер көрсенде.

— Дөнья шундый чуар, катлаулы инде ул. Күп аның гаделсезлекләре, күп әле аның гаделсез кешеләре. Әгәр гаделләр җаваплы эшләрне ташлап качып бетсәләр, Наилә кебек усалларга да юл киңрәк калачак. Бу, бәлки, ялгыш фикердер, әмма китәргә ашыкма, гадел эшлә, хәзерге заманда эш табу җиңел түгел. Алда күз күрер, бәлки, бер-бер җае чыгар.

## XIII

Зәйтүнәнең декрет ялы бетеп бара, малай әкияттәге кебек күзгә күренеп үсә. Тугыз айдан тәпи йөри башлады, хәзер бөтен өйне актара, һич җитмәгән җире юк. Әтисе улының шуклыгын бик ошата, әз генә вакыты булдымы, улы белән мәшәләнә. Өй иркен, өйалды белән чолан булгач, байтак вак-төякләр шунда күчте. Ата белән ул икәүләшеп идәндә ауныйлар. Хәлим улын муенына атландыра, дүрт аяклап ат булып йөри. Аннары Равилне җилкәсеннән төшерә алмыйча алҗып бетә.

Зәйтүнәгә эшкә чыгарга кирәк. Бер үк вакытта укуын да өзәргә ярамый. Эш, бала, уку — ничек чыдармын дип пошына яшь хатын. Әле ярый Әлфия аларда тора, бала белән кая барыр идең? Ясле турында уйларга ярамый, балаларны яследә тоталар, дигәнне ул кешедән ишетеп кенә белә. Үз күзе белән барып күргәне дә юк. Булса да, анда Зәйтүнәнең малаен алалармы соң? Баласы исәйгәнче өйдә генә утырыр иде, бер кешенең хезмәт хакына ничек тормыш алып барасың...

Зәйтүнә бала багарга кеше эзли башлады. Ары сугылды, бире

сугылды, ахырда авылдашы Гөлсем апасы янына барып егылырга мәҗбүр булды.

Зәйтүнә аның катына улы Равилне күтәреп барды. Гөлсем һәрвакыттагыча аны ачык йөз белән каршы алды. Килүләренә бик шатланды. Чырае ачык булса да, Зәйтүнә апасының йөгәнеп калганын, борчылганын аңлады. Ул да кемгә барып сугылырга, кайгысын кем белән уртаклашырга белмичә аптырап йөри икән. Беренче сүз итеп үпкәсен белдерде.

— Хәл белергә дә килмисез. Мине аңласагыз — сез аңлый аласыз. Бүтәннәргә сөйләсәң, авыз гына ералар.

— Гөлсем апа, җаныем, бәгырькәем, юк-барга кайгырып үз-үзеңне бетермә. Ил белән. Ялгыз башка килмәсен.

Үз кайгысына чумган Гөлсем авылдашының телендә төчелек, базарда отып алган ясалмалык яңгыравын абайламады.

— Яраткан эшемнән аералар лабаса. Кемгә комачаулыйм икән? Шәһәрдә хайван асрауны тыйдылар. Милициядән шәһәр советының карарын калдырып киттеләр.

Гөлсем сыерын бүген генә үз кулы белән ит комбинатына илтеп тапшырган иде. Базарга чыгарып сатарга да рөхсәт итмәделәр. Кичкә кагылырмын, кәгазең кулыңда булсын, дип кисәтте милиционер. Сыерны алыштырган сары кәгазьне кытыршы кулы белән ышкый-ышкый ул бик озак елады. Алладан өзелеп-өзелеп тизрәк мәрхүм ире Фәтхулла белән кавыштыруны сорады. Аның очен бу дөньяда бер төрле дә юаныч калмаган иде. Нихәл итәсең, тере килеш ләхеткә кереп ятып булмый, кызулык белән әҗәлне чакырасың, үлем якаңа килеп ябышкач бүтән фикер тууы да ихтимал.

Сыеры сыер гына идеме, хәзинә иде, үз урамнарындагы ничәмәничә гаилә рәхәтләнде аның сөте белән. Миңкамалларның гарип туган Борһаннары шуның сөтен эчеп кенә сихәтләнде. Хода шаһит, ике ел дәвамында иртә саен җылы сөт килеп ала тордылар, Миңкамалдан бер тиен дә акча түләтмәде Гөлсем. Шул ятимнәр догасы да ходага барып ирешмәде микәнни? Ит комбинатына барып кергәч, сыерын кочаклап озак кына елады. Итчеләргә нәрсә, көләләр генә. Әле ул гынамы тагын, алма бакчасыз да калдырдылар аны. Күтәрә алмаслык налог салдылар. Бакчасында егерме яшьлек егерме төп алмагачы бир иде. Шуларга базар бәһасе белән керем исәпләп чыгардылар да налог кәгазе тоттырдылар. Андый зур сумманы аның төшендә дә күргәне юк. Ул налог кәгазен кире илтеп бирде, бакчасыннан баш тартты.

Нихәл итмәк кирәк, исән чагында бакчадан котылып өлгерәсе иде. Бакчаны калдырсаң, тынычлап үләргә дә ирек бирмәсләр.

Әүвәл башта бакчаның коймасын сүтеп аласы иде, чекерәеп күзгә бәрелеп тормасын. Тик койма сүтү ялгыз карчыкның кулыннан килә торган эш түгел. Гөлсем Зәйтүнәне күргәч тә шуны уйлады. Хәлиме бар ич әле аның, хәле китеп аны онытып тора икән.

Бакча турында сөйләп:

— Хәлим балакаем шул койманы гына сүтеп ташламасмы? — дигәч, Зәйтүнә чәчрәп каршы торды.

— Юк, юк. Гөлсем апа, андый ямьсез эшкә иремне тыкма! Хәлим синең күзеңә албасты булып күренә башлар. Ә безгә синең шәфкатьле күзең кирәк. Синнән бүтән барыр кешебез дә юк ич! — диде.

— Җитмәсә балалар... ярама тоз салалар! Кысыр кайгы белән баш катырма. Йортны бетерергә күптән вакыт. Сыеры да, бакчасы да кирәк түгел, җыен да безгә күчеп кил, дип телеграмма сукканнар.

— Сыерсыз калдым, бакчам бетте дип, үләргәме?

— Дөресен әйткәндә, үләргә дә риза. Үлем хак...

— Чү, Гөлсем апа, кофер сөйлисең түгелме? — Зәйтүнә аны чын күңеленнән кызганды.— Үләргә күп кирәкми, яшәргә кирәк, яшәргә.

— Сез яшьләр, сез яшәгез. Безгә яшәгән кадәресе җитеп торыр, алла иманнан аермасын. Югыйсә кылган яманлыклар өчен күңелгә каралык иңүе ихтимал.

— Апай ук өметсезләнү кирәкми, Гөлсем апа.

— Яшәүнең кызыгы калмады,— Ул бераз тынып торды да.— Мин тиле кеше төсле үземнекен такылдыйм, сиңа авыз ачарга да ирек бирмим, сез ни хәлләрдә?

— Эшкә чыгарга вакыт җитте. Баланы нишләтәсе булыр инде, аптыраган. Әхмәдигә ахирәттә урын юк, диләр.

Зәйтүнә биләүдәге баласын кервә-керешкә караватбашына илтеп салган иде, кайгыга чумып утырган Гөлсем аңа игътибар да итмәде бугай. Гүя үзе турында сүз барганны сизде, диярсең, күпме вакыт тын гына яткан Равил тавыш бирде. Гөлсем аны кулына алды.

— Егет кеше егет инде, үсәм, дип атлыгып тора ахрысы, үсеп беткән. Йә, елмай әле бер, балакаем. Йөрәгемнең бозларын эрет әле. Әниеңне эшкә җибәрмәскә маташасыңмы?

Малай Гөлсемнең җылы мөнәсәбәтен, аны баскан кайгы-хәсрәтнең авырлыгын аңлаган кебек, иреннәрен чапылдатып елмайды. Гөлсем, тәкатьсез калып, тагын елап җибәрде.

— Күрче моны, ничек матур елмая! Әллә үзем! Әллә үзем генә багыйм микән бу егетне?

Ни өчен килеп керүе Гөлсемгә күптән аңлашылса да, Зәйтүнә үзе башлап бала багу турында сүз кушарга кыймый утыра иде.

— Гөлсем апа, чыннан әйтәсеңме?

— Шушы җылы тоенчекне ялгыз калдырып эшкә йөрер идеңме әллә? Кеше тапмасаң, миңа китермичә хәлең булмас.

— И Гөлсем апа, җаным, бу изгелекләреңнең әҗерен ничек кайтарырмын инде?

— Кулдан килгәнне кешедән кызганып торган юк инде анысы. Берберең ә булышмасаң, авыр чакта ярдәм кулы сузмасаң, ни була ул аннары. Ходай безнең җаннарны игелекле итеп яраткан, дөнья боза адәм балаларын, рәхим-шәфкать бетеп бара. Барыбыз да бер алла бәндәсе югыйсә.

— Гөлсем апа, халыкның төрлесе бар! — диде Зәйтүнә, үзләренә атна саен кереп йөргән исерекбаш Мәхмүтне, мут һәм пычрак Юнысны, ана бүре Гөлчирәне хәтерләп.— Кешеләр төрле-төрле шул!

— Ярар, кеше тапканчы карап торырмын.— Гөлсем уйланып торды да.— Сиңа баланы китереп йөрү кыен булыр инде...— диде.

Ул, ара-тирә үзем дә баргалап алгаларлмын, дип әйтергә җыенган иде, Зәйтүнә бүлдерде, сүзен әйтеп бетерергә ирек бирмәде.

— Анысына гына түзәрмен. Баланың яхшы кеше кулында икәнен белгәч, анага килеп йөрү чүп кенә ул.

Зәйтүнәнең өстеннән тау төшкән кебек булды, Гөлсем апасы яныннан җиңеләеп чыгып китте, урамда кая басканын да белмәде. Бер чыккач-чыккач, дип, кайтышлый базарга да керде. Директор исәнлек-саулык та сорашып маташмады, беренчә сүзе итеп:

— Бала белән эшләү кыен булыр,— диде тәртмә генә.— Үзең беләсең, бездә эш нормаланмаган, сезонында вакыт белән исәпләшеп тору юк, бер караңгыдан икенчесенә кадәр чабарга туры килә. План үтәлмәсә, барыбызның да җанын алалар.— Ул Зәйтүнәнең йөзенә күзе төшкәч, ялгышын аңлап, бүтәнчәрәк сайрарга тотынды.— Дөрес, закон буенча мин сине эштән чыгара алмыйм, без Совет илендә яшибез. Безнең илдә хатын-кызларга зур хокуклар һәм чиксез мөмкинлекләр бирелгән. Ләкин намусы бар кеше үзе дә аңларга тиеш.

Зәйтүнә директорына аңлатып торуны кирәк санамады, баласын күкрәгенә кысып кочаклаган килеш, аптырап басып торды да, катыкаты басарга тырышып чыгып китте. Үксеп елыйсы килде. Кайнар күз яше белән кайгысын юса, хәле җиңеләер кебек тоелды. Урам буйлап

бераз атлагач, күңеле тынычланып, үз-үзен әрләргә тотынды. Тукта, нигә шулай өзгәләнә әле ул? Торыр урыны бар, ире, сеңлесе янында. Бер базар гына мыни дөньяда? Бүтән эштә бәхетне сынап карарга кирәк! Шулай уйлап, Зәйтүнә кискен карарга килде, китәргә, китәргә, башын алып качарга! Әлегә ул кая китү турында уйлап җиткермәде, имчәк баласы белән аны кем эшкә алыр икән? Баксаң, шуның өчен өзгәләнә икән күңеле!

Ул кайтып кергәндә, Хәлим белән Әлфия бик тырышып дәрес әзерләп утыралар иде.

— Кайда йөрдең шул гомердән бирле? — диде Хәлим, дәфтәреннән башын калкытмыйча гына.

Зәйтүнә Равилне алдына китереп утырткач, ризасызлыгы шунда ук онытылды, улының елмайган йөзен күргәч, сары майдай эреде.

— Һи, улым кайткан икән! Нихәл? Әтиеңә дәрес әзерләргә булышырга кайттыңмы?

Әлфия үзләренә комачаулаганны өнәми иде, борынын җыерды.

— Апа, бер дә аңламыйсың инде. Җизнинең имтиханга әзерләнгәнен күргәнсеңдер бит инде? — диде.

Зәйтүнә сеңлесенә күзенең агы белән генә карады.

— Мин эштән китәм! — диде ул тантаналы рәвештә.

— Кая китмәкче буласың? — диде Әлфия, бераз тарттерып.

— Син кая киттең соң? Миңа да үз юлымны сайларга вакыттыр? Ниемә дип укып йөргән булам алайса? Сәүдә эшенә күчәм, берәр кибеткә алырлар әле. Студентка-заочницаны читкә тибәрмәсләр.

Аның бу сүзләре Хәлимгә хуш килде, шулай да шиген әйтмичә кала алмады.

— Китүен китәрсең, бала белән эшкә алырлармы икән?

— Кем аларга бала барын әйтеп тора?

— Апа, шашма. Равил бераз исәйсен. Өлгерерсең. Тырышыбрак укырга кирәк сиңа. Шәлей-вәлей йөрисең. Әнә анда, математикадан контроль эшеңә «икеле» чәпегәннәр. Ә җизни «бишле» алган!

Зәйтүнә сискәнеп китте, Хәлимнең тез башында утырган улын җилтерәтеп кулына алды да улы исеменнән Әлфияне тиргәргә керешә.

— Син апа, чукынчык марҗа, рөхсәтсез-нисез минем әнинең дәфтәрләрен актарма, актарсаң, серләрен теләсә кемгә сөйләп йөрмә. Алай бик усаллана башласаң, без сиңа кирәгеңне бирербез!

Әлфия:

— Үзең өчен әйтәм,— дип котылса да, Зәйтүнәнең әр сүзләре аның йөрәгенә барып кадалды.

Артык тамак булмаса да, эшләп ашаса да, ул җизнәсе белән апасыннан читенсенә башлаган иде. Алар Мансурның һаман килеп йөреп тә эшне тизләтмәвенә, аларның өйләнешмәвенә сөерсенәләр иде бугай. Әлфия Мансур абыйсына: «Нигә миңа өйләнмисең соң син?» — дип әйтә алмый бит инде.

Уйлары белән тартып китердемени, өйгә нәкъ шул чакта Мансур килеп керде. Әлфиянең каләме идәнгә тәгәрәде. Егет көлемсерәп:

— Рөхсәттер бит? — дип сорады.

Өйдәгеләр көлеп җибәрделәр.

— Түргә узгач, рөхсәт сорый икән берәүләр!

Хәлим Мансурны күтәреп кенә алмады. Ул аларга дәреслекләр, ярдәмлек-кулланмалар алып килгән иде. Әлфия белән Хәлим китаплар өстенә иелделәр.

— Әлфия! — диде Зәйтүнә сеңлесен әрләп.— Кунакка урын тәкъдим итәр идең. Бу кадәр дә егетләргә ваемсыз булырсың икән.

Әлфия апасына беренче күргәндәй карап торды да Мансурга эндәште:

— Мансур абый, апага урын табарга булыш әле. Базардан китмәкче була!

— Күптән вакыт.
— Зәйтүнә кая керергә телидер бит.
— Кооператив техникумында укып йөргәч, мине совнаркомга эшкә алмаслар инде. Сәүдәгә күчәргә исәп.
— Дөрес эшлисең. Кул куям. Егет кенә...— Мансур Равилгә төртеп күрсәтте.
— Баланы Әлфия карар.
— Җизни белән алмаш-тилмәш карыйбыз аны!
— Болай булгач, эш Мансурда калды. Тапсын бер урын.
— Сөйләшеп карыйсы булыр.
Зәйтүнә тиз генә чәй куеп җибәрде, Хәлим помидор турап салат әзерләргә тотынды. Мансур Равилне кулына алды, туп кебек итеп өскә чөя башлады.
— Һай, сак кылан! Төшереп җибәрә күрмә,— диде Әлфия хафаланып.
— Исең киткән икән. Малай урынына малай табып бирербез.
Әлфия кып-кызыл булды. Мансурның бер дә мондый сүз ычкындырганы юк иде моңарчы.
— Балалар ярата мине,— дип шатланды Мансур.
Чәй кайнады. Зәйтүнә һәммәсен дә табынга чакырды. Хәлим Мансурны үз янына утыртты. Атна буе тоташ күмер бушатып, аның куллары кап-кара иде. Ул уңайсызланып Мансурдан гафу үтенде.
— Минем куллардан җирәнә күрмә тагын. Соңгы вакытта эштән соң юынырга кайнар су бирмиләр. Суык су күмер тузанын җебетеп кенә калдыра.
— Аңлыйм,— диде Мансур, салатка үрелеп,— баштан үткән хәл.
— Мин сине ак он камырыннан әвәләгән дип йөрим тагын. Болай булгач, үз кеше икәнсең әттә генәсе!
Хәлим өстәл өстенә бер ярты чыгарып куйды.
— Җизни,— диде Әлфия кисәтүле тавыш белән,— кирәкми. Хәзер үк алып куй шешәңне!
— Тик кенә утыр,— диде Хәлим беренче тапкыр балдызына җикереп,— һәр нәрсәгә кысылырга иртәрәк түгелме сиңа?
Мансур тиз-тиз Әлфияне куәтләде.
— Чыннан да, Хәлим дус. Болай гына утырыйк. Минем андый нәрсә белән татулык юк.
— Мин дә ялгыз чакта авызыма да алмыйм. Дус-иш белән әз-мәз капкаларга туры килә. Ансыз-дөнья сансыз.— Хәлим курка-курка гына хатыны ягына карап алды.— Бу арада бригада егетләре көн дә салгалый башладылар әле. Эш авыр, тузан шакшы. Шуны эчкәч хәл арулanып китә.
— Әйтәм җирле кайтып керүгә авызын юарга тотына! Бригадникларыңа син ияреәсеңме, әллә аларны ияртәсеңме?
Хәлим хатынының соравына игътибар итмәде, шешәне ачып, ике стаканга мул итеп аракы койды.
— Сез эш урынын сайлыйсыз. Миңа да яхшы чакта аннан китеп котылырга кирәк икәнен берегез дә әйтми!
— Ничек барыбыз берьюлы китик соң, Хәлим? — диде әрнеп Зәйтүнә.— Мин баланы Гөлсем апага илтеп йөри башлыйм. Аны да буш итәргә ярамас.
Хәлим хатынының сүзен, балдызының әрләвен күңеленнән генә хуплап утырды утыруын, мәгәр үз хәлен ачыктан-ачык сөйләп тә бирмәде. Хәлимнәр бригадасы эшли торган станциягә соңгы айларда тимер юл белән зур-зур цистерналарда спирт килә башлады. Ул Казандагы дәү-дәү хәрби заводларның берсенә адресланган була. Заводныкылар үз вакытында вагоннарны бушатырга өлгермиләр. Спирт тутырган вагоннар атналар буе тора. Бригадага ике ай элек кенә бер егет килеп урнашты, өч тапкыр төрмә шулпасын чөмергән егет. Тапкан бит шул эт

хөйләсен, пломбага кагылмыйча да теләгән кадәрле спирт бушатып ала! Чиләге белән алып килә, эчү генә түгел, коен, сат, рәхәтлән! Төшкә кадәр күмер бушаталар да, төштән соң тотыналар эчәргә! Хәлим дә арага катнаша башлады. Эчеп кайтканын хатынына сиздермәскә тырышса да аның төнлә торып чүмеч белән салкын су шопырдатканын тыңлап яткан Зөйтүнә шиккә төшә башлаган иде. Бәйләнер иде, Хәлимнең өйдә эчкәне юк, комагай милиционер Мәхмүтне сыйлаганда да тотмый, туп-туры карап, миңа ярамый, укыйсы бар, дип котыла.

Бүген менә кунак алдында, улы гый-гый килеп нидер сөйләргә маташканда, хатыны-балдызы күз алдында бер-бер артлы ике стаканны йомдырып куйды.

— Хәлим дус, ташла бу эшеңне! — диде Мансур бик җитди итеп.

Күзләре калайланган Хәлим аның иңенә авыр кулын салды.

— Бәхет булмады, Мансур дус. Менә укып йөргән булам. Диплом алып, эш сорап баргач, миңа елмаерлар дип уйлыйсыңмы? Пленда булгансың, кайсы илгә сатылдың, нинди заданиеләр алып кайттың, дип якага ябышмаслар, дисеңме?

— Да-а,— дип сузды бераздан Мансур борчылып.— Спирт тирәсеннән котылырга кирәк сиңа!

Бара торгач, бер нигездә яшәүчеләрнең хәле гаять мөшкелгә әйләнде. Әлфиягә налог инспекциясеннән, Зөйтүнәгә базардан, Хәлимгә спирт елгасы ярында калган станциядән тизлек белән китәргә кирәк икән. Һәм Мансур, арада ных утыра торган, хәвеф-хәтәрсез киләчәге булган кеше, бу өчлекнең язмышын уңай якка борып җибәрергә тиеш. Ә хуҗалар белсә... Мансурның үз язмышы да әлегә кыл өстендә, ул бүген нәкъ шул турыда сөйләшергә дип Әлфия янына килгән иде, хәзер, өчәүләшеп хафага калганда, ул үз кайгысын ачып сала аламы? Кыз кеше аның хәбәрен ничек кабул итәр? Ни уйлар, куркынып: «Безнең тирәдә йөрмә инде син, Мансур абый!» — дисә? Тапканын югалту Мансур өчен үлем белән бер дәрәҗәдә икәнен Әлфия аңлармы?

Мансур, шактый баш ватып, төрле мөмкинлекләрне исәпләп карагannнан соң, Хәлимгә болай диде:

— Син, Хәлим дус, укуыңны дәвам итәргә, тәмамларга телисеңме?

— Сорыйсың тагын, минем иң зур хыялымның шул икәнен беләсең лабаса!

— Алайса сиңа институтка якынаерга кирәк. Ә моның бердән бер юлы бар. Минем сүзне авырга алма: син тот та безгә дворник булып эшкә кер!

Зөйтүнә, Хәлим, Әлфия өчесе бер авыздан:

— Дворник?! — дип әйтеп салдылар.

— Нигә исегез китте? Бездә дворниклар ике урында эшләгән булып санала. Ике урыннан шактый һәйбәт хезмәт хакы килә. Төшкә кадәр эшлисең дә төштән соңгы вакыт үзеңнеке.

— Баланы карыйсың,— дип ялгап алып китте Зөйтүнә.

— Китапханәдә утырасың! — дип, Әлфия Зөйтүнәгә өрле карашын ташлады.

— Кая барасың. Мин ризалашырмын, ахрысы,— диде Хәлим.

Бар да дәррәү хупладылар, шук сүзләр әйттеләр. Алар, шау-гөр килеп утырып, вакытның узганын сизмичә калдылар. Иң элек Мансур кузгалды. Ул сүзсез генә Әлфиягә текәлеп карап тора башлады.

— Бик мөлдерәп карый күзләрең, болай булгач озата бармый да булмас,— диде Әлфия.

— Әллә бармас та идеңме?— диде Зөйтүнә сеңлесен шелтәләп.

— Бергәләр олы башларын кече итеп аның янына киләләр. Ул утыра кылтаеп! Тор, хәзер үк киен! Хәерле юл сезгә.

Зөйтүнә Әлфиягә, озак йөрмә дип әйтергә уйлаган иде, Мансурга карагач, ул уеннан кире кайтты.

— Сизәсеңме, боларның эш куера бит. Мансур яшькә бераз олырак олырагын.

— Сөйләшеп тә карыйсың инде. Үзең соң, үзең! Карт башың белән нинди яшь кызны әләктердең!

Алар гел шул хакта сүз куерттылар, Мансур белән Әлфия, өйләнешкәч, кайда яшәрләр, институт тулай торагының сандык хәтле генә бәләкәй бүлмәсенә Әлфия дә барып керсә, ничек сыярлар, дип хафаландылар...

Бу минутларда Мансур белән Әлфия беренче аңлашкан аулак куаклык тирәсенә барып җиткәннәр иде инде. Мансурның сүзсезлеге, чыраеның гадәттәгедән сытык булуы Әлфиянең эченә пошаман салса да, кыз ашыгып сорашырга базмады. Кешенең күңеле китек икән — йөрәге яралы, диган сүз. Җайсыз сорау бирерсең дә ярага кагылырсың. Мансур яшерә белми, кирәк икән, үзе сөйләсен. Ике арадагы киеренкелек шактый дәвам итте.Мансур кызның иңбашларын кочып алды.

— Сезнекеләр... Хәлим белән апаңны әйтәм...Килә, утыра, йөри, җитди сүз башлаганы юк, дип мине әрләмиләрме?— дип сорады.

— Юк алай... Ул хакта сүз булганы юк.

— Ә үзең, Әлфия?

— Нәрсә — үзем?

— Бу Мансур кайчанга кадәр шулай йөрер икән, дип баш ватмыйсыңмы? Әйтмә, әйтмә — үзем дә беләм. Безгә кушылырга вакыт икәнен дә, миңа башлы-күзле булырга вакыт икәнен дә беләм.Аңлыйм! Бергә-бергә булсак, яшәү күңелле буласын да чамалыйм. Яратуымны беләсең. Бу да сер түгел — Мансур күзләрен тутырып кызга карап торды да, тулышкан иреннәрен суырып үпте.— Аңла, эш миндә генә түгел. Мин сине бәхетсез итәрмен, дип куркам.

— Нигә алай ямьсез уйлыйсың, Мансур абый?

— Әти-әни хакында, үзем күргәннәр хакында мин сиңа сөйләгән идем, Әлфия...

— Әй, әллә кайда еракта калды ич ул хатирәләр!

— Алай түгел икән шул! Калды, онытылды, дип йөрсәм, бер ай элек кенә мине институтның спецчастена дәшеп алдылар. Сорашмадылар, янамадылар, автобиографиямне яздырдылар, личный листок тутырттылар. Ике атна үттеме икән, парткомга чакырттылар. Алар да документларымны өр-яңадан теркәп куйдылар. Ни өчен? Үзем генә чакта тәкермәс тә идем, хәзер янымда син бар. Гомерлек юлдашым итеп сайлаган Әлфиям бар...Казыналар икән — юкка түгел. Каяндыр сигнал кергән булырга тиеш. Юкса, онытылып беткән заманнарны казынмаслар иде...

— Мансур абый! — Кыз Мансурның кочагына сеңде.— Мин бернидән дә курыкмыйм. Синең язмыш — минем язмыш булыр. Сиңа ни килсә дә юлдан тайпыласым юк. Теләсәң, мин бүгеннән синеке.

— Гомер юлымда мин бик күп бәхетсез хатын-кызларны күрдем, Әлфиям. Шуңа күрә сине сайлыйсым килә. Кем белгән, иртәгә үк минем моннан югалуым ихтимал. Көтик бераз, ярыймы, кадерлем. Миңа янаган куркынычның каян килгәнен белеп булмасмы... Аннары гомерлеккә кавышырбыз!

## XIV

Зәйтүнә иртәгесен йокыдан тору белән баласын күтәреп базарга китте. Барып җитәрәк, кирәк бит, юлда Гөлчирә белән очраштылар. Байтактан күрешкәннәре юк иде. Гөлчирә шул кадәр шатланды, Зәйтүнәне кочаклап кат-кат үпте. Тотынды сайрарга!

— Менә дус дип йөр син аны! Килеп тә карамыйсың. Өенә чакырмый да чакырмый инде, ирен ашар дип курка! Бәбәй туе үткәргәндә кеше аркылы булса да миңа хәбәр итәр әле, дип йөрдем, алган бүләкләрем бер кочак, бәби ашлары пешерермен, дип ниятләндем.

— Бәби ашына чакырганны көтмиләр, тоталар да киләләр.
— Тиктомалга барып кереп буламыни? Ишегеңнең кая ачылганын күргән дә юк.— Ул Равилнең битен ачып карады.— Бигрәк матур икән бәбәегез. Кайсыгызга охшаган бу? Сиңа, дип әйтимме? Күз карашлары тач әтисенеке икән!
— Әле аның кемгә охшаганын белә торган вакытмы? Үсеп җиткәнче кырыкка үзгәрер әле.— Зәйтүнә тиз-тиз баланың битен япты.— Күзең каты түгелме? Болай да көйсезләнеп тора, күз тия күрмәсен тагын.
Баланың битен ябу Гөлчирәгә ошап бетмәде.
— Мине белмисеңме әллә? Кешегә гел изгелек эшләргә генә тырышам.— Ул тагын да якынрак килеп, борыны белән чак кына Зәйтүнәгә бәрелмәде.— Болай бала күтәреп иртә таңнан ни кыдырып йөрисең? — Зәйтүнәнең эштән китәргә җыенуын белгәч:— Чумаралы эш таптыңмы, чукынчык? — диде.
— Әле төгәл белгән эшем юк, сәүдәгә күчсәмме әллә, дигән идем.
— Дөрес эшлисең! Монда, базарда, җыен жулик арасында яшь гомереңне бушка уздырып йөрмә!
Зәйтүнә кооператив техникумында укуы белән мактанып алды.
Каядыр бик ашыккан Гөлчирә кинәт юлын үзгәртте, әзми-куймый Зәйтүнәне үзләренә керергә кыстады. Ул баш тартты:
— Директорны күрәсе бар, гариза калдырырга кирәк,— диде.
— Ашыкма, ул анда юк. Мин контордан кайтып киләм. Николай Семеновичны каядыр киңәшмәгә чакырганнар. Төштән соң гына булачак.
Зәйтүнә аптырап калды, Гөлчирә үтереп кыстагач, аңа каршы бар дип әйтергә дә булдыра алмады.
Бүтән вакытта өйгә капкадан үтеп керәләр иде, бу юлы Гөлчирә аны арт ишеккә алып китте. Арт ишектән керүнең серен Зәйтүнә бераз соңрак төшенде.
Запас юл туп-туры кухняга алып керде. Анда, өстәл артында майкачан гына утырган Юнысны күргәч, Зәйтүнә артка чигенде. Кире чыгарга өлгермәде, Гөлчирә шартлатып ишекне ябып куйды. Кунак Юныска ошамады, әлбәттә. Ул аңа кырын-кырын карап торды да майлы кулын чигүле тастымалга сөртә-сөртә икенче бүлмәгә кереп китте, бер сүз дә эндәшмәде.
— Бу адәм күзен тозландырып иртә-таңнан нишләп сездә утыра?— диде, кыек-мыек сөйләшә белмәгән Зәйтүнә.
Юныска карата эчендә сакланган нәфрәтен тыярга көче җитмәде. Гөлчирә аның әче сүзләрен ишетмәмешкә салышты. Бөтен кыяфәтеннән Зәйтүнә чиксез нәфрәт белән караган бу кешенең монда булуына сөенгәнлеге, чамасыз шатлануы сизелеп торды. Зәйтүнәне шул кешене күрсәтү максаты белән генә алып кергәне дә ачылды. Гөлчирәнең авызы колакта,кая басканын да белми, аннан-моннан ризыклар алып, өстәлгә тезә башлагач кына телгә килде ул.
— Син ишетмәгәнсеңдер шул, без Юныс белән кушылдык бит. Ул шундый әйбәт кеше, тфү, тфү, күз тия генә күрмәсен! Минем дә бу кадергә ирешер көнем бар икән. Бөтен эшемне эшли, суына кадәр китереп куя. Кем әйтмешли, көнлеге дә бар, төнлеге дә хәйран! Бәхет дигән нәрсә, бер килә башласа, килә икән ул, аны тыеп та булмый икән. Кеше арасына чыксак та, өйдә утырсак та бер-беребездән күз ала алмыйбыз!
— Леша кайда?
— Аерылдык! Котылдым, илаһым. Кирәк бит, шул шимбәгә алданып гомер юлыма кара тап төшереп йөргәнмен!
— Күптән күренгәне юк, мескеннең, шәһәрдән үк киттеме әллә?
— Итәрсең аны мескен! Бар! Йортны бүлде, ишегалды ягы аңа калды, мин менә арт яктан юл ачтым.

Зәйтүнә үзе дә сизмәстән онытылып, Гөлчирәнең сүзләрен нык кызыксынып тыңлап утырды. Әйе, ул бәбәй табып йөргән арада дөньяда зур үзгәрешләр булып узган.

— Кара җәяүгә калдырып була иде явыз шимбәне, алла бәндәсе бит, кызгандым!

— Кара җәяүгә, дисеңме? Абау!

— Йорт минем исемдә, бөтенләй куып чыгарсам да, хакым бар иде. Атналар буе аягыма егылып елады.

Күпне күргән, утны-суны кичкән хәйләкәр яһүд Мандрус үз гомерендә беренче мәртәбә ялгышты. Ул Гөлчирәне ахмак бер хатынга санап эш башлаган иде. Беренче көннәрдән үк Гөлчирәне яратмады, тора башлауларына ярты ел дигәндә, бөтенләй күрә алмас булды. Ләкин ялгыш адым атланган, Леша Гөлчирәгә аягы-кулы белән бәйләнгән иде. Йорт Гөлчирә исеменә сатып алынды. Өстәвенә, никахлар да законлаштырылмаган. Законлаштырырга да мөмкин түгел, чөнки Мандрус беренче хатыныннан аерылмаган, аерылырга исәбе дә юк. Мандрус тегендә чакта нәни генә промкомбинатта директор булып эшли иде. Кирпеч сугалар, йон тетәләр, итек басалар, кыскасы, халыкка ни кирәк, вактөяк эшнең һәммәсен башкаралар иде. Аның эзләренә басып килүләрен милициядә эшләүче милләттәше хәбәр итте. «Эзеңне суыт!» — диде. Мандрус тиз-тиз җилкәннәрен күтәрде һәм ерак Казанга килеп урнашты. Салган баштан, Гөлчирәнең утлы кочагында исен җуеп, йортны аның исеменә яздырып ташлады. Койрыгы бозга катты шул Мандрусның, югыйсә ул зиначы хатынны күптән ташлап китәргә вакыт иде.

Гөлчирә шактый нык шомарган иде инде, ул сукбай Мандрусны нинди язмыш йөрткәнен тиз аңышты. Яратты да шул каһәр суккан яһүдне! Никахлашырбыз, дип уйлады, алдында ал да гөл булды, Лешаның бөтен теләкләрен үтәде, туганнарына, якыннарына караңгы чырай күрсәтмәде, балалары килгәндә дә чәче белән җир себерердәй булып бөтерелеп йөрде.

Тора-бора күңеле суынды, туймас тәне бер ир белән генә яшәргә риза түгел иде аның. Янып-көеп йөргәндә, Юныс очрады. Юныс Гөлчирә җәтмәсенә эләктеме, әллә киресенчә булдымы, алар дөньяларын онытып бер-берсенең кочакларына ташландылар. Азагын уйлап та карамыйча, Юныс кочагына кергән хатын берзаман мәхәббәт колына әйләнде. Тормышның күп якларын татырга өлгергән Гөлчирәне сөю сукырайтты. Ул Юнысны да үзе кебек сөю утларында яна-көя дип уйлады. Юнысның исә эш бүтәнчәрәк иде. Алар хатыны белән этле-мәчеле яшәделәр. Хыянәт иткән хатынына Юныс берчакта да рәхим-шәфкать күрсәтмәде. Тормышның азагы аерылу белән бетәчәген хатын тиз аңлады, ике баласы өчен каерып алимент ала башлады. Алименттан калган хезмәт хакы, ашау белән тәмәкегә көчкә-көчкә җитә иде. Сөяркәләрне еш алмаштырган, өч-дүрт хатын белән төрлечә шукланырга гадәтләнгән Юныс үзе омтылган байлыкны, үзе ясканган иркәлекне Гөлчирәдә тапты. Гөлчирә аны ашатты, эчертте, киендерде. Юныс өйгә килгәндә табында иң затлы эчемлекләр, иң татлы ризыклар була иде. Барыннан да бигрәк, аның моңарчы Гөлчирә хәтле ярата белгән, шашып-шашып сөйгән хатын-кызны очратканы юк иде.

Кайнар мәхәббәтләре уртак иткән яшерен фатирга гына сыймый башлады. Леша өйдә юк чакларда ул Гөлчирәләрдә кунып калуны гадәткә кертте. Ул кичне дә шулай булды...

Мандрус атына директорны утыртып якын районнарның берсенә киткән иде. Алар анда колхозлар белән договорлар төзергә, аралашу юлларын киңәйтергә тиешләр иде. Һәр елны җәй башында колхозлар базарга яшелчә китереп сатарга йөкләмә ала, димәк, колхоз яшелчәсен ташый, ә базар аңа уңайлы ларегын бирә, бүтән шартларны тудыра. Мондый командировкадан көнен генә кайтып булмый, кайвакытта сәфәр атналарга сузыла. Форсаттан файдаланып, Гөлчирә белән Юныс

үзләре теләгәнчә иркенләп, кәеф-сафа корырга тотындылар. Башта коньяк эчтеләр, аннары шампан шешәсен ачтылар. Юныс комарланып акны да татып карады. Төрле эчемлек бергә буталып, Юнысны камыр кебек изде. Гөлчирәнең моңа әллә ни исе китмәде, күбенгәнче эчкәндә дә, Юныс ирлеген югалтмый торган иде. Ул аны иркәләп чишендерде, юындырды, анадан тума калдырып караватка илтеп салды. Үзе дә чишенеп аның янына менеп ятты, төрле ысуллар белән Юнысны уятырга, дәртен кузгатырга тырышты. Яраткан кешең хакынаниләр кыланмыйсың да, ниләр эшләмисең?!

Ләззәтнең иң югары ноктасы җитеп, Юныс мышнап, Гөлчирә татлы рәхәт татыганда, урам яктан капканы дөбердәтергә тотындылар. Гөлчирә башта берни ишетмәде, ишеткәч тә исе китмәде, ләкин дөбердәү кимемәде, арта гына төште.

Ул сукрана-сукрана тәрәзә янына килде һәм пәрдәнең ябылып бетмәгән бер читеннән урамны күзәтте. Анда капка төбендә җигүле ат тора иде. Димәк, Леша кайткан. Монысын көтмәгән иде Гөлчирә, бер мәлгә югалып калды. Нишләргә? Юнысны каяаткарырга? Аягына басарлык хәле булса, ул аны арт ишектән чыгарып кына җибәрер иде, хәзер аяксыз-кулсыз эреп ята. Чыгарып җибәрү турында уйларга да ярамый. Беткән баш беткән, ни булса булыр. Гөлчирә тавыш-тын чыгармыйча тик кенә утырырга карар бирде. Леша дөбердәтте, дөбердәтте дә, койма аша сикереп, капка келәсен үзе ачты. Җиде катлап сүгенә-сүгенә атны ишегалдына кертте, ишеккә килде.

— Галя, яхшылык белән ач! — дип акырды ул.

Атны тугарып, эшен бетергәч, балта тыгып өй ишеген каерырга тотынды. Ишек имәннән, нык, алай гына бирешә торган түгел иде. Барып чыкмагач, ул тәрәзәгә кагылган тимер рәшәткәгә ябышты. Рәшәткә дә балтага гына бирешмәде. Леша сүгенде, карганды, хәле бетеп бераз тынып торды. Куркытып эш чыкмаслыгын аңлагач, юмаларга, төмле телләнергә керешә.

— Галя, күгәрченем. Беләм, син өйдә ялгыз түгел. Яныңда яткан кешене дә күзгедәге кебек күреп торам. Ач, бәгырем, ачсаң, гафу итәм.

Аның күңеленә шик төште булса кирәк, әллә чыннан да өйдә юк инде, дип үз-үзенә сөйләнеп куйды. Шиге озакка бармады, ишегалдын яңгыратып акырып җибәрде.

— Юк, син өйдә! Ишек ачмыйча котылырмын, дисеңме? Хәзер милиция алып киләм дә ватып керәбез!

Тавышлар тынды, Леша юкка чыкты. Гөлчирә аның янавына ышанмады, милициядән өркеп яшәгән Мандрус үз йортына милиционер алып киләме соң? Каш ясыйм дип күз чыгара торган зат түгел!

Юныс ватык трактор кебек өзек-өзек гырлап йоклый.

Татлы җүләрлекләр белән башланган төн, таңга кадәр газапка әйләнде. Тәрәзәгә таң яктысы төшүгә, ул Юнысны уятырга тотынды. Колагын уды, тешләде, кабыргасын төрткәләп изде, ниһаять, Юныс күзен ачты. Торып утырды, бур мәче төсле ялт-йолт каранды, тирә-ягын күзәтте. Аның бөтен тәне ут кебек яна, теле аңкавына ябышкан, башы тубал кебек авыр иде. Гөлчирә аңа стакан тутырып аракы салып бирде. Шуны эчкәч кенә Юныс әз-мәз аңына килде.

— Леша кайтты бит!

— Кит аннан! Кайда ул?

Юныс ыштанына ут капкандай сикереп торды. Гөлчирәгә аның кыяфәте бик мәзәк тоелды.

— Мин сине шушы кадәр куркак, дип уйламый идем,— диде ул гарьләнеп.

Чалбар төймәләрен каптыра алмыйча интеккән Юныска киенергә булышты. Юныс җәнҗал чыгудан бик курка иде. Лешаның куллары көрәк кебек, тукмый башласа, кая керер тишегеңне тапмассың. Тукмап кына калса бер хәл, эш урыныңа хәбәр итсә — нишләрсең?

Ишектән башта Гөлчирә чыкты, ары-бире урамны карап керде. Кеше-мазар күренмәде. Юнысны озаткач та Гөлчирә иркен сулап куйды. Күңелле җыр мырлый-мырлый киенде, эшкә барырга әзерләнде. Инде тынычланып ишегалды якка чыкса, күзе шар булды. Анда эт баш, сыер аяк иде. Леша ярсып-ярсып нидер эзләгән, ахрысы, көндез кавказлылар кертеп өйгән әрҗәләрне пыран-заран китергән, җиләк-җимештән бушаган тартмаларны таратып аткан. Атны лапаска кертеп башын күтәреп бәйләп куйган. Үзе арбадагы печәнгә ятып йоклаган. Гөлчирә атны чишеп иркенгә җибәрде, кызганды бичараны. Лешаны аягыннан өстерәп җиргә төшерде, чәрелдәргә тотынды.

— Син нәрсә? Коммунизмга чыктыңмы? Капкаң ачык. Ишегалдында ничәмә-ничә мең сумлык товар өелгән. Югалса, бетең белән түләрсеңме?

Леша тезләнде, торып басты, йодрыгын Гөлчирәнең күз төбендә уйнатты.

— Фәхишә син, уйнашчы! Тәмам аздың, мине үз өемә кертмисең!

— Ах, син миңа кизәнәсеңмени?! — Гөлчирә уңлап-суллап Лешаның яңагына чалтыратты да акырырга кереште.— Караул, үтерәләр! Коткарыгыз!

Үзе акырды Гөлчирә, үзе һаман Лешаны яңаклады, яңаклары кабартма булып пешеп чыкканчы тукмады, тамагы карлыкканчы кычкырды.

— Мин өйдә юк идем, ахирәт дусларыма барган идем, шунда куныпкалдым. Кайтып керсәм, капка ачык.— Ул сумкасыннан ачкыч алып йозакка үрелде.— Әнекәчем! Әллә каера ук башлаган инде! Ни хакың бар ишеккә тотынырга? Төрмәдә чертәм мин сине!

— Мин сине өйдә бикләнеп утыра дип уйладым бит...

— Ах, оятсыз! Ах, җирбит!

Песием булып өйгә кергән Леша чөйдәге кепканы күрүгә канатланып китте.

— Әһә! Кем кепкасы бу? Әйт!

Гөлчирә күзен дә йоммады.

— Кичә райбашкармадан синең койрыкларыңны — Кавказ халыкларын тикшерергә килгәннәр иде, шуларныкы онытылып калгандыр.

— Бу кепканы мин мең чакрымнан таныйм! — дип дулады Леша.

— Таныйсыңмы? Бик шәп! Әйе, ул минем сөяркәмнең кепкасы! Җиттеме? Җитсә шул, бүген үк күземнән югал! Чыгып кит!

Леша эшнең зурга киткәнен чамалады, сабыр гына ялына башлады:

— Галя, иплап кенә сөйләшикче. Мин сине акыллы хатынга саныйм. Ниткән эш инде ул ике ир белән тору?

— Син ике хатын белән торасыңмы? Торасың!

Кызды Гөлчирә, тузынды Гөлчирә, ахыр чиктә алар йортны икегә бүлергә, ишегалды ягын атлы Лешага калдырырга килешенделәр. Бик бирмәс иде Гөлчирә ишегалды ягын. Леша аның бик күп этлекләрен белә шул! Чынлыкта Гөлчирә базарда күз буяр өчен генә эшләп йөри. База-кибетләрдәге күп санлы танышлары Гөлчирә аша менә ничә еллар инде кара эшләрен тормышка ашыралар. Кибетләргә сирәк кайта торган кыйммәтле товарларны аның йортына күпләп китерәләр дә ул аларның бәяләрен өч-дүрт тапкыр арттырып, ваклап озата. Элемтә җебенең очы кайларга гына тармакланмаган да, кемнәргә генә барып тоташмаган. Ишле әшнәләренә таянып, Гөлчирә моңарчы тыныч диярлек яшәде. Әгәр Леша белән араны бозып ямьсезләнсә, бер ул гына түгел, бик күпләр шытырдап яначак. Леша арбасында төннәрен бу йортка кайткан товарларны бирәр заман белсәләр... Ишегалдында яшелчә-җимеш күз буяу гына алар! Гөлчирә шәһәрнең вак балыгы түгел, чуртаны, ул бик күпләрне тозсыз-борычсыз кабып йота ала. Гөлчирә дә исән, Леша да тук калырга тиеш.

Шуларны истә тотып, тelләренә төер чыкканчы бер ызгыштылар да,

тынычландылар, өйне нотариальный контора раслаган, договорга теркәлгән пландагыча бүлеп, һәркайсы үзенчә тормыш итә башлады.

Лешадан котылып, аралар тәмам өзелгәч, Гөлчирә Юнысны тулаем үзенеке итәргә карар кылды. Гөлчирә төшеп калган хатынмы әллә? Күрсен Леша, күрше-тирә гайбәтчеләре, базар көнчеләре күрсен — нинди генә ирләрне дә карата ала Гөлчирә!

Ишек икенче яктан ачыла башлагач, Юныс Гөлчирә янына ешрак килеп йөрде. Бераздан бөтенләй күчте. Хатын-кыз куянга дип оста корган ауга кайчагында шактый шомарган төлкеләр дә каба икән!

Шәһәр аһ итте: кушылганнар диме? Юныс белән Гөлчирәме?.. Юныс эткә дә камыт кигерткәннәр икән...

Гөлчирә Юнысның үз янына күчеп килүе белән генә канәгатьләнмәде, ул бик күптәннән законлы, никахлы ир белән яшәргә тели иде. Алдагы көнне дә уйларга кирәк, ул кемнән ким? Һәр иртәдә йокысыннан сикереп тора да көзгә каршысына барып баса, өйләнә-тулгана, корсак асларын сыпырып карый, ботын аерып куя, боргалана, артын сикертеп җибәрә... Юк, берәүдән дә ким түгел! Бөтен җире килгән, һәммәсе сокланырлык. Гәүдәсе тутырган тавык кебек, урамнан ул үткәндә борылып карамаган ир юк, кайберәүләр ваемсызрак үтеп китә башласа, күңеле котырган Гөлчирә бер-ике тапкыр артын уйнатып ала, алары да аңа ияреп байтак җир баралар. Юнысны гына бөкләп сала алмаслык хатынмы ул? Гөлчирә кулында коралның иң шәбе — затлы хатын-кыз тәне.

Гөлчирә атна буе Юнысны куенынннан чыгармады, юлына ак җәймә булып ятты, илдә юкны пешереп сыйлады, алдыннан шешәне өзмәде. Ун көннән никахлашу турында сүз кузгатты. Башта әз-мәзләп кенә сүзен тамызды, очраклы гына телгә керткәндәй кыланды, тора-бара сүзне куертты, һөҗүмгә үк күчте. «Аерылышу» дигән сүз арага кергәч, Юныс кара янды. Әйе, хатынын яратмый иде ул, аларның бик күптәннән янәшә ятканнары юк, әмма үзенә хыянәт иткән хатынны аерып җибәрү — аны бәхетле итү дип санады Юныс. Аермау хатынына мәңгелек җәза иде. Шул җәзадан тәм таба иде Юныс. Ләкин хатын-кызның иблисе булган Гөлчирә Юныска да ачкыч яратты. Юныс үзен үтә эшлекле, төпле финансист дип исәпли иде. Гөлчирә аның шушы йомшак ягын үз файдасына борды. Кая гына бармасын, кемне генә очратмасын Юнысны туктаусыз мактады. «Безнең Юныс Гыйльметдиновичмы? Райсоветта иң абруйлы кеше. Алдагы сайлауларда аны депутат итмәкчеләр. Көзгә орден да алачак. Депутат та булыр, орденын да алыр, аның кебек уңган, аның кебек таләпчән финансчы шәһәрдә юк.

Мөдир авылгамы, анда-монда барса, урынына гел Юныс Гыйльметдиновичны калдыра. Кайтса шакката — эш тагын да алгарак киткән! Дөресен генә әйткәндә, Юныс Гыйльметдинович — районыбызның хуҗасы ул!»

Тәки шул ягы белән алдырды Гөлчирә, аның авызыннан чыккан сүзләр уравыч юллар үтеп, кибетчеләрнең, кассирларның, йорт хуҗаларының колакларына кереп, телләрендә чүкелеп, шомарып барыбер Юныска килеп җитәләр иде. Гомере буе депутат булырга хыялланган, орден алуны төшләрендә күреп җенләнгән Юныс Гөлчирә мактауларыннан соң эреде, никахны законлаштырырга ризалыгын бирде. Ләкин бу тиз генә була торган эш түгел иде, чөнки Юныс беренче хатыны белән аерылышмаган...

Юнысның кем икәнен, эче-тышы шакшы булуын Зөйтүнә бик яхшы белсә дә, Гөлчирәне бүлдермәде, әйдә, сөйләсен, дигән кебек, авызын ачып ике-өч тапкыр иснәп тә алды. Гөлчирә шкафның иң ерак бүлемтегеннән балага бүләкләр тартып чыгаргач, йөзе ачылгандай булды. Бүләкләре затлы иде. Барыбер түзмәде, үзен бик кызыксындырган мәсьәләне ачыкларга теләп, күңелен кытыклаган сорауны бирде.

— Гөлчирә апа, сез язылышып торасызмы соң?

Көтмәгәндә бирелгән бу сораудан Гөлчирә сикереп куйды, авызы ерылды.

— Син мине кем дип беләсең? Законсыз ир белән тораммы соң мин, Зәйтүнәкәем? Язылышмыйча мин аны якын да китермәдем. Ә тегендә, базарда дим, анда һәммәсе дә уен гына иде, шаярышып маташтык без. Язылдык! Язылмаган кая ул? Тагын сиңа гына әйтәм, матри, бусын чәчеп йөрисе булма, никахны да укыттык.

Мин коммунист, дип карышып тормады, риза булды. Синдәй затлы хатын хакына, бөтенесен эшлим, диде Юныс.

Сәгать буе мактау йөк бушатучы белән яшәп яткан Зәйтүнәнең кытыгын китердеме, ул, сиздермәстән Гөлчирәгә карап, кадап алды.

— Леша белән дә язылышкан идегез алайса? — диде.

— Язылышмасак та, без аның белән никахсыз түгел идек. Никахны карт хәзрәт үзе укыды. Мөселман булмаса да, чын күңеленнән ризалык бирсә никахыгызны дөрес була, диде. Никахсыз килеш ирләргә кулымны тоттыраммы соң мин?

Равил көйсезләнеп елый башлады. Зәйтүнә, никадәр тырышса да, улының елавын туктата алмады, күңеленнән, күзе тидеме әллә бу ялганчының, дип уйлады, китәргә җыенды.

— Абау, кая ашыгасың, туйганчы бер сөйләшеп тә булмады ич! Аш салдым, рәхәтләнеп тамак ялгарбыз. Сыйланырбыз.

— Бүтән вакытта иркенләп килермен.

— Ут капкан кебек булды инде бу. Йә, нигә шулкадәр ашыгасыңдыр?

— Директор кайткандыр, тагын чыгып китүе бар. Тизрәк күреп калыйм инде.

— Директор качмас иде әле.

— Ашыкмыйча да ярамый. Эш табарга да кирәк әле миңа.

Зәйтүнә үз хәлен, ниятләрен сөйләп биргәч, Гөлчирә борынын җыерып уйланып торды.

— Болай итәбез,— диде ул, нидер исенә төшкән кебек булгач,— промторгның кадрлар бүлегендә минем бер яхшы танышым бар.

— Гөлчирә апа, җаным! Яхшылыгыңны мәңге онытмас идем!

Эш эзләүдән жаны-тәне курыккан Зәйтүнәнең күзенә Гөлчирә бу мәлдә коткаручы фәрештә булып күренде.

— Үзең беләсең, майламасаң, таба купмый. Бик яхшыларын гына сайлап ике тавык табып керт. Кичләтеп кенә мин танышымның өенә барып кайтырмын. Моңарчы да сүземне кире какмый торган иде, инде бөтен шәһәрне үз кулында тотучы Юныс хатыны да булгач, нужели тыңламас икән?

Зәйтүнә Гөлчирәгә ышанып бетмәде бетүен, аның шапырыну гадәтен белә иде, нишлисең, ике тавык каян килеп кая китмәгән, сынап карарга булды. Җилгә очса очар, баш бәһасы түгел.

## XV

Районда хезмәт куймыйча гына баеп ятучы, керем алучы бәндәләрне ачыклау буенча комиссия эшли башлады. Комиссия район советы депутатларыннан төзелеп, аның составына, депутат булмаса да, Юнысны да керттеләр. Бу аның райфода налоглар буенча өлкән инспектор булуын исәпкә алып эшләнде. Исемлек газетада басылды. Йа, Гөлчирәнең көне килде: исемлек басылган газетаның йөзләбен алып таныш-белешләренә таратты. Лешаның борын төбендә сәгать буе җилфердәтеп торды: бел, бәялә — тутаң кем белән яшәп ята!

Гадәттә, районның налог һәм җыемнар инспекциясендә кемнең нинди керем исәбенә яшәве турында азмы-күпме мәгълүмат тупланган була. Аның хезмәткәрләре аерым кешеләрнең керемнәрен исәпләп

баралар, елныкын елга теркиләр. Бүгенгесе иртәгә ярамый, дигәннәр, бу күрсәткечләр еш кына үзгәрә тора, берәүләрнең кереме кими, икенчеләре баюның астыртын юлларын эзләп табалар, финанс оешмаларыннан яшереп, әллә ниләр кыйраталар. Дөнья ялганнан бирле, исәп-хисап, акча тирәсендә оста куллар ут уйнатканнар, моның меңнәрчә ысулларын уйлап чыгарганнар. Шикле хәбәрләр ишәйгәндә, астыртын эшкуарлар барлыкка килгәндә райфо әнә шул мөһим чараны эшкә ашыра башлый, җаваплы комиссия төзелә.

Райком тәкъдиме белән комиссия рәисе итеп депутат Волков сайланды. Полковник Волковның төп эше акча тирәсеннән шактый читтә булганга (ул районның хәрби комиссары), булдыра алмам, фәлән-төгән, дип каршы килеп тә маташты. Ләкин партия куша икән — алынасың, эшлисең, тының да чыкмый.

— Сезнең урынбасарыгыз Юныс Гыйльметдинович, эш белән яхшы таныш кеше, сезгә гомуми җитәкчелек вазифасы йөкләнә,— диделәр аңа.

Юныс үзен рәис итеп куярлар дип өметләнеп йөргән иде. Волков сайлангач, кәефе кырылып, шактый вакыт койрыкны сыртка салып йөрде. Волков аңа ышанды, ә Юныс эшкә күрәләтә аяк чалды. Ярты ел чамасы үткәч шул мәсьәләгә багышлап шәһәр күләмендә киңәшмә үткәрделәр, киңәшмәдә райбашкарма рәисенә нык кына эләкте. Астан, өстән каен себерке белән пешекләделәр аны. Рәис, киңәшмәдән кайтып керүгә, Юнысны чакыртып алды һәм киңәшмәдә алган «эсседән» аңа да өлеш чыгарды. Сөйләшү бик кискен барды, рәиснең шулай кызганын Юныс беренче тапкыр күрде.

Соңгы сүз усал хөкем булып яңгырады.

— Атна эчендә эшеңне рәтләп куймасаң, үзеңә үпкәлә!

Бу сүзләр Юнысны куркытырга тиеш булса да, ул рәиснең кисәтүен үзенчә кабул итте. Райбашкарма рәисе — районның алласы ул, димәк, Юнысның абруе Волковныкына караганда зуррак булып чыга, сәяси яктан үтә җаваплы эшне аңа тапшыралар! Райбашкарма рәисе Волковны бар дип тә белми, Юнысны пыр туздыра, аңа куша, аңардан нәтиҗә көтә. Мондый очракта ничек куанмыйсың да, ничек шатланмыйсың? Кош булып очып йөри башлады Юныс Гыйльметдинович, бөтен көчен куеп кушылган эшне үтәргә әзерләнде. Райбашкарма рәисе бу хәлдән соң аны тагын да югарырак күтәрәчәк!

Ике көн эчендә ул урам комитеты рәисләрен үз кабинетына җыеп алды, иң ерак, иң аулак урамнардан рәисләрне таптырды. Кемнең ничек сулаганын, тәтеннәре кай якка авышканын алардан да яхшы белүче бармыни? Ярты төнгә кадәр утырып, алар эшнең тәртибен билгеләделәр. Юныс Гыйльметдинович алар алдында «дәүләт күләмендәге зур бурычларны» куйды. Иртәгәдән башлап, ул урам комитеты рәисләренең эшен күзәтү астына алачак, дәүләтне алдап, баеп ятарга маташкан ачкүзләрне дөньяга чыгарачак!..

«Кемнән, кайсы төбәктән эш башларга?» — дип озак уйланды ул. Туп-туры атарга кирәк иде аңа, атарга да тидерергә! Бөтен район киңәшмәләрендә аны кыюлык, тапкырлык мисалы итеп сөйләсеннәр!

Уйлый торгач, тапты тагын — «Нахальный поселок»ка барасы итте. Күп еллар элек бу бәләкәй генә, онытылып калган бер урам булган. Утызынчы еллар башында колхозлардан качып өлгергән тәвәккәл кешеләр шәһәрләргә агылган, күпчелек читтә-читтарак утырган урамнарга килеп сыенган. Эш җае да чыккан аларга, яңа төзелә торган электр станциясенә эшче куллар кирәк булган. Күчеп килүчеләр яңа төзелешкә төрле эшкә ялланганнар. Үзләре янына авылда калган хатыннарын, бала-чагаларын, агай-энеләрен алдырганнар. Рөхсәтсез салына торган йортлар һаман ишәйгәннәр, урамга урам кушылган, урам шәһәр эчендә калган. Шәһәргә кушылса да, аның «Нахальный поселок» дигән кушаматы ябышып калган.

Анда инде менә ата караклар, мал җыярга яратучы, акча эшләүнең мең ысулын үзләштергән кулак калдыклары!

Төбәкнең урам комитеты рәисе булып аның бик якыны Лагутченко Григорий Лукич дигән кеше эшли иде. Ул да читтән килеп утырган кеше. Сугышка бармаган Лагутченко, милициядә эштә калган. Пенсиягә чыгу белән шушы поселокка тап булган, таза тормышлы берәүгә фатирчы булып кергән, акча түләп торган. Төннәрнең берсендә йорт хуҗасын «халык дошманы» дип төрмәгә илтеп япканнар, ирсез калгач «дошман»ның хатыны Украинага кайтып киткән. Алты почмаклы, калай түбәле йорт Лагутченкога күчкән, хәзер шул йортның законлы хуҗасы булып санала. Урам комитеты рәисе поселокта чикләнмәгән властька ия. Аның рөхсәтеннән башка бу тирәдә чебен дә очмый. Кем дә булса тел тибрәтергә йөрәксенеп бер генә сүз ычкындырсын, Лагутченко аны авыр сүзләре белән күмеп ташлый.

— Комитет булып эшләгәнем өчен мин хезмәт хакы аламмы?! Юк! Коммунист буларак, мин ил файдасы өчен тырышам. Җәмәгатьчелек тәртибендә тир түгәм мин!

Дөрес, ул хезмәт хакы алмый, мәгәр аның килерен санап бетерә торган түгел. Поселокта өч йөздән артык хуҗалык исәпләнә. Аларның һәркайсы хайван асрый, бәрәңге, яшелчә үстерә. Күбесенең алма бакчасы да бар. Шул күпчелек үзләреннән артканын базарга чыгара. Базарга барыр өчен белешмә кирәк. Тәртип шулай куелган. Белешмәне Лагутченко гына бирә ала. Тегенди-мондый белешмә сорамый базар, аңа штамп куелганы, мөһер сугылганы кирәк. Сатарга алып барыла торган товарның күләменә карап, Лагутченкога акча түләнелә. Буш кул белән килсә, рәис сөйләшеп тә тормый. Паспорт аласыңмы, алыштырасыңмы, прапискага керәсеңме — баш орып урам комитеты рәисенә барасың. Әгәр бусаганы майламасаң, атналар буе тинтерәп йөрисең. Кергән йомышлылар белән дә сөйләшә белә ул. Коры акча белән генә эшең барып чыкса, син — бәхетле. Әле Лагутченконың тамагын чылатырга, акчаны «юешләргә» дә кирәк.

Аның халыкны кычкыртып талавын бөтен поселок белә, ләкин законсыз эшләренә бөтен кеше шулкадәр күнеккән ки, оятсызлыгын гадәти эш итеп саныйлар. Кемнәрдер, ачулары чамадан ашып, райбашкармага шикаятьләр язып карадылар, тикшерүчеләр дә килгәләде, үзен абындырырга теләүчеләрне рәис белеп алды һәм аларга көн күрсәтмәде, үч алды. Аерым кыю бәндәләр Лагутченко патшалыгын ташлап читкә киттеләр.

Юнисның да аны тикшерергә килгәне булды, бер-ике генә түгел, күп килде. Лагутченконың тыелган «налоготворчество» белән шөгыльләнүен килгән саен ача торды, рәисне җинаять җавапчылыгына тартасы урында, шикаятьчеләрнең исемнәрен ачып бирде, рәис белән берлектә аларга үчләште.

Очрашсалар, авызлары — авызда, өстәлгә кукраеп шешә менеп утыра да алар җан дусларга әйләнәләр. Сыйлау, дигәннән, аның рәтен Лагутченко кадәр белгән кеше бармы икән бу дөньяда? Кирәкле кешесен күбенгәнче эчертә белә ул. Кунак киткәч, халыкны да туный, һәркемнең җиде тиресен салдыра. Тикшерүчеләр, комиссияләр аның янына туктаусыз йөреп торалар. Теләсә-теләмәсә дә эчәргә туры килә. Эчемлеккә, кызмача йөрүгә шул кадәр күнеккән, аекмы ул, исерекме — аны шайтан үзе дә аера алмый. Дөнья сасытып авызыннан сарымсак исе аңкый, ятрак кеше алдында авыз ачуга зарлана башлый.

— Картлыктан яман нәрсә юк, и туганым! Бөтен әгъзалар какшады, чыгырыннан чыкты, уртның рәте китте, зинһар, гаеп итмәгез инде, сарымсак ашаган идем,— дип зарланырга тотына.

Райбашкарма рәисе нык кына пешекләп чыгарганнан соң, Юныс әнә шул кеше янына барырга карар кылды. Заманында атаклы чик

сакчысы Карацупаның «Индусы» гына түгел Лагутченко этнең эте, җиде күзе, дүрт колагы бардыр, дип белерсең аны.

Юныс килгәндә Лагутченко барабан корсагын уып капка төбендә басып тора һәм, кемгә бәйләним икән дә, бүген кемне сыгыйм икән, дип баш вата иде. Юнысны күргәч, күңеленә, йөри бу туймас тамак, дигән уй йөгерсә дә, башмак иреннәр ерылды, йөнтәс керфекләр арасына кереп чумган ун тиенлек акча хәтле генә күзләр җемелдәде.

Лагутченко үз йортының кече ягын урам комитеты өчен тота, үзенә-үзе аренда хакы түли, «дәүләт хезмәтен башкарыр өчен», кече якка махсус ишек тә тиштергән иде.

Конторага керделәр. Григорий Лукич сыңар тәрәзәнең пәрдәсен төшерде, пәрдәнең почмакларын тартып куйды. Хәзер тынычлап утырсаң да була, пәрдә томаланган икән, ут чыкса да, бүлмә ишегенә кагылучы булмаячак. Көтелмәгән хәл булганда, дивар артындагы хатыны уклау белән стенага бәрә дә мич артына чыга торган яшерен тишектән иренә хәбәрне җиткерә. Элемтә җайланган, саклык чаралары күрелгән. Әллә ничә хуҗага хезмәт итеп, почмаклары яньчелеп беткән тимер сейф ачкычы Григорий Лукичның тәресе белән муенында йөри. Ә сейфта... хәер, нигә ашыгырга? Ачылгач, эчтәге хикмәтләрне күрербез. Юныс хәл-әхвәл сораштырганда да күзен сейфның ачкыч тишегеннән алмады, тамак төбе кымырҗыды, борыны туктаусыз кычытты.

Ул, сүз башлаганда, җөмләсен әйтеп тәмамларга ашыкмый иде, бер-ике сүз әйтә дә тына, көттерә, тыңлаучының теңкәсенә тиеп бетә.

— Миңа нинди олы эш тапшырганнарын... син... Григорий Лукич, ишеткәнсеңдер инде... Беләм... Разведкаң шәп эшли. Инде шул, хөкүмәт заданиесен үтәргә, дип синең катыңа килгәнмен икән... Беренче итеп сиңа килдем! Бәялә моны!.. Партия-хөкүмәтнең сиңа булган никлы ышанычы турында сөйли бу, Григорий Лукич!..

Лагутченконың берни ишеткәне булмаса да, ул Юныс авызыннан чыккан һәр сүзне куәтләп, ияген кагып, партия һәм хөкүмәт кушкан һәр эшне үтәргә әзер икәнлеген белдереп, иелә төшеп, бик бирелеп тыңлады. Авыз ачарга базмады, өлерәк кенә бер тустаган спирт түнтәйтеп чыккан иде, әңгәмәгә керешер алдыннан Юнысның да авызын майларга кирәк, шул чагында гына рәис иптәш иркенләп тыңлар да, кирәк урында гына үз сүзен дә әйтер. Юнысның кереш сүзе шактыйга сузылды, ул сөйли торды, Григорий Лукичның кулы изүенә кереп китте, мавыгып, онытылып башта көмеш тәресен тартып чыгарды, аны ашыгыч кына яшерде, сейф ачкычын муеныннан салдыргач, аны тантаналы факел кебек югарыга күтәреп күрсәтте. Юныс сүзен бүлмәде, сейф ачкычына ияреп тишеккә керде, эчке бүлемнәрдә тезелеп утырган шешәләрне, ысланган дуңгыз маен, камыт бөятедәй бөгәрләнеп яткан колбасаларны, банкада тозланган гөмбәләрне күргәч, бер минутка телен тыйды да, ашыгып-кабаланып сүзен йомгаклады, соңгы сүзләре авызына йөгергән төкереккә батып калды. Лагутченко аның чирек сәгатьлек сүзеннән шуны аңлады: «Дәүләтне имеп ятучы бурны табарга кирәк!» Бары шул гына. Аның өчен чирек сәгать сөйләп тору кирәк идеме соң? Бур, дигәндә, Лагутченкога бер сүз җитә: «Өс-с!» — дисәләр, хәзер табып китерә ул аны.

— Каракның зурысы булсын, яшереп шалкан сатучы белән генә мине «сыйлап» җибәрергә уйласаң, батмый бусы, кадерле Григорий Лукич. Син миңа район җыелышларында, киңәшмәләрдә чыгып фаш итәрлек җинаятьчене тап! Эре балыкны! Намуслы яшәп яткан безләрнең алга барышына аяк чалучы кешеләр кирәк!

Лагутченко әле һаман сүз чыгармады, ул авыз эчендә ботка пешереп нидер мөгерәде, ике катлы ияген селкетеп Юнысны хуплагандай итте, ә кулы гел тик тормады, үткен киң пычак белән дуңгыз маен телемнәргә турады, колбаса кисеп таратты, гөмбә банкасын ачып, аңа бизәкле агач кашык батырды. Кырлы стаканнарга мул итеп спирт

койды. Заводтан урлап чыга торган спиртлары оу юлы әшәке исле иде, хуҗа йөзен чытып башын читкә борды. Ә менә азык-төлек кибетеннән бүген шәп колбаса китергәннәр, майлары агып тора, тышы елтырый, хуш исе спирт сасысын күмеп тә китте.

— Тотыйк,— диде ул, ниһаять, стаканны Юныска биреп.— аннары сөйләшербез.

Юнысның су кушмыйча чиста спирт җибәрергә яратканын белә иде Григорий Лукич, кунакның чыт та итмичә спиртны тамагына коюын күргәч, ыңгырашып алды, үзе дә Юныска ияреп төбенә хәтле чөмерде. Ризык капкаладылар, гөмбә, тозлы кыяр ише әйберләрне ярата Юныс, шул җәһәттән Гөлчирә белән талашып та алалар. Гөлчирә, урыс ашы, йә агуланып үләрмен, дип гөмбә ашамый, өйгә дә керттерми. Юныс, сүлен тамыза-тамыза, гөмбә урырга тотынды. Сүзгә керештеләр, тагын берәр тустаган эчеп куйганнан соң, сүз җыр булып агылды.

— Бар андый явыз! — диде Лагутченко.— Бар! Күптән койрыгын кысарга иде ул явызның!

— Кем ул?

— Керосин кибетендә эшләүче Мифтахов! Үткән ел гына бик зурдан кубып йорт эшләтте. Тәрәзә наличникларын күрсәң син! Капкасында ай белән кояш. Верандасы пыяладан! Чарлагы да бар. Коймаларны өр-яңадан корды. Ишегалдына чит кеше түгел, кош та очып керерлек түгел. Кемнән окопаться итә ул явыз? Өч ел элек кенә олы улын башка чыгарды. Анда йорт салдылар. Каян акча керә?

Лагутченко Мифтаховка күптән теш кайрап йөри иде. Буып үтерер иде ул аны, моңарчы җае гына чыкмады. Күпме еллар монда яшәп урам комитетын, аның рәисен санга сукканы юк. Малаена җир алды, берни бирмәде. Йорт салып керде — ник бер ярты куйсын саран! Очраганда сәлам бирәсе килсә — бирә, күп вакыт күрмәмешкә салынып үтеп китә. Имеш, эшенә соңга кала, ашыга. Кәтәләр, имеш. Кәтсәләр, урам кешеләре кадерлеме аңа, рәисме? Ныклап аңлатырга кирәк әле! Хөкүмәт белән партия законны бик вакытлы, бик белеп чыгарганнар.

Четерекле бер нәрсә бар-барын, Мифтаховларга милиция начальнигы килеп йөри. Лагутченко аның һәр килүен махсус дәфтәргә теркәп бара баруын. Күпме вакыт капка бикләп утырганнарына кадәр теркәлгән. Ул алар артыннан үзе күзәтеп вакланмый, шымчылар җитәрлек, сәгате-минуты белән бөтенесен китереп җиткерәләр. Аерата мөһим хәбәрләрне Лагутченко тиешле урыннарга үзе дә җиткереп куя.

Григорий Лукич Юнысны кисәтергә кирәк дип санады, соңыннан сүзе булмасын.

— Син, Юныс Гыйльметдинович, бер нәрсәне исеңнән чыгарма. Мифтахов белән милиция начальнигы — әшнәләр.

— Әгәр Мифтаховны каптырабыз икән, милиция начальнигының кулы кыска. Безнең комиссия турыдан-туры председательгә буйсына.— диде Юныс шапырынып.— Монда барысын да мин хәл итәм!

Юныс белән Лагутченко көне буе тирләп-пешеп комиссиягә материал әзерләделәр, Мифтахов турында әллә нинди уйдырмалар табып теркәделәр. Лагутченконың шикләнүе урынлы да иде. Мифтаховның да кулы туры түгел иде турысын, аның керосин саткандагы кыңгыр эшләрен поселокта белмәгән кеше юк, әмма аның урлашканын исбатлау гаять кыен. Мифтахов ялгыз түгел, аның артында, кыңгыр эшләренә ярдәм итеп нефтебазада эшләүчеләр тора иде. Алар байтак еллардан бирле бергә урлыйлар, ник төйнәлгәннәр, ике арадагы катлаулы эшне районның милиция начальнигы җитәкли иде. Райбашкармага, прокурорга килгән шикаятьләрне Уваров йомдырып кына ала. Лагутченконың әллә кайчаннан шушы шайкага кереп, үзенә дә өлеш алып ятасы килә. Райбашкарма рәисе исеменнән эш йөртеп, Гыйльметдинов үзе килгән икән, хәзер ул караклар төркеме Лагутченкодан тиз генә котылачак

түгел: йә төрмәгә утырта ул аларны, йә аны тиздән тиңдәш санап әлеш бирә башлаячаклар!

Гаепләү кәгазе язылып беткәч, эчкән саен айный барган Лагутченко башын чайкады:

— Ай-яй, ышандырып булырмы? — диде.— Сүз боткасы күбрәк китте.

— Ә син шаһитлар тап! — дип боерды Юныс.

Григорий Лукич уйга калды, катыргы тышлы амбар кенәгәсен тартып чыгарып, озак кына шуны актарды.

— Тәк, тәк... Афанасьевлар кар базы казырга рөхсәт сорыйлар. Мифтаховларга күрше генә яшиләр!

— Мифтаховларга төнлә бүрәнә китерделәр, дип язсыннар.

Юныс белән Лагутченко уйлап тапкан бурлык фактларын расларлык кулай кешеләрнең исемлеге дә төзелде. Аерата юаш, кыюсыз, ятим ялпылар шул исемлеккә керде. Кайсысына ни кирәк, Григорий Лукич шул нәрсәләрне табырга булышыр. Кемне пропискага кертергә кирәк, кемгә белешмә бирәсе булыр.

— Әгәр аларны чакыртып алырга уйласагыз, миңа хәбәр итәрсең. Мин аларга тиешле инструктаж ясармын! Лагутченко сүзеннән кире кайткан адәмнәр юк иде моңарчы! Шулай булыр да.

Шаһитлыкка лаеклы кешеләрнең исемлеге урам комитеты исеменнән язылып, Мифтаховны якты көнгә чыгара торган шикаять хатына теркәлде.

Соңгы атналарда Юнысның болай онытылып эчкәне юк иде, Гөлчирә дә сүгә, эчеп кайтса, бавырымы, уң касыгымы — нидер котырына. Иртәләрен котырып башы авырта. Лагутченко Юнысның нык исергәнен башта көлемсерәп күзәтеп торды, югарыдан килгәннәрне түбән хәлдән тайганчы сыйларга ярата иде ул, азакка таба күңеленә шик керде, өенә ничек кайтып җитәр бу бүкән, дип уйлады.

Урам комитеты рәисе Лагутченко бер нәрсәне белми иде: хәйләкәр карак Мифтахов та йоклап калганнардан түгел, ул да Лагутченконың һәр адымын күзәтеп тора, кем килгәнен, кем киткән — барысын да чуар коленкор тышлы дәфтәренә терки. Кече якка ишегә ябылганнан соң, пәрдә төшүен дә, стаканнар чыңлавын да, киткән чакта затлы кунакларның култык асларында нинди бүктәрләр булуын да эре-эре хәрефләр белән беркетә.

Поселок белән шәһәр арасында йөри торган иске автобуска Юныс артыннан ук ике таза ир менеп утырдылар, болар Мифтаховның улы белән аның кияве иде. Алар юлда барганда, юк-бар сәбәп табып Юнысны котыртырга, адәм көлкесенә калдырырга һәм, шау-шу чыкса, өлкән инспекторны җылы кулдан милициягә илтеп тапшырырга тиеш иделәр. Мифтахов белән Уваров хәбәрләшеп, уйларын берләштереп алганнар иде инде.

Мифтахов җибәргән кешеләргә тырышасы да булмады, автобус кузгалып китүгә үк Юныс тавыш күтәрде, ник миңа урын бирмисең дип бер хатынга бәйләнде. «Урын таптырырга әллә син алланың кашка тәкәсеме? Исерек урам эте!» — диде хатын янына шундук килеп баскан иргә. Юныс үзенең кем икәнлеген әйтеп шапырынырга, мактанырга, җыелганнарны «җир кортлары» дип мыскылларга кереште.

Мифтахов малае белән кияве, милиция тукталышына җиткәч, Юнысны ике яктан элэктереп җиргә төшергәндә, пассажирлар аларны хуплап, Юнысны сүгеп, җир белән тигезләп озаттылар.

Ул өенә дә үз аягы белән кайтмады, аны милиция машинасы белән китереп куйганнар. Әле ярый милиция начальнигы янында аның урынбасары подполковник Арнаутов туры килгән, югыйсә, налоглар буенча өлкән инспекторны хулиганлык кылганы, шәһәр транспортында тәртип бозганы өчен, ябып ук куячаклар икән...

Кичәге хәлләрне ул бик томанлы хәтерләп уянды йокысыннан,

Гөлчирәнең чәр-чәр килгәне истә калган дә автобустагы хатынның: «Синең кем икәнеңне белдек, райкомга хәбәр итәрбез!» — дип янаганы исенә төште. Уянды. Гөлчирә өйдә юк, табын әзерләнмәгән, чәй кайнамаган, киемнәре кайсы кайда аунап ята. Бер оекбашын таба алмыйча, Юнысның җаны чыкты. Аннан-моннан капкалап эшенә китте, кабинетына курка-курка гына кереп утырды. Почта аша килгән калын бер пакетны, хатларны ачып тормады, ачарга курыкты, хатларның берәрсендә аның кичәге маҗаралары бәян ителгәндер дип шикләнде.

Көн хәвеф-хәтәрсез генә үтсә дә, Юнысның җаны тыныч булмады, ул телефон шалтыраган саен дерт итеп куйды, ишек каксалар, коты ботына төште. Телефон төребкәсен куйган саен стакан тотырып салкын су эчте, сусавы басылмады. Әшәке спирт бөтен күзәнәкләрне сусыз калдырып интектерә иде. Төшке ашка буфетка керде, анда да берни ашамады, чәй артыннан чәй эчте.

Әбәдтән соң бүлмәсенә кереп бикләнде дә секретарь кызга кисәтеп куйды.

— Мине сорасалар, юк диярсез. Ашыгыч эшләрем бар. Юк-бар сүзләре белән баш әйләндереп, эшләргә дә ирек бирмиләр!

Мөдирнең эш белән китүеннән файдаланып, ул аның кабинетына кереп утырган иде. Үзе белән өченче көнне үк килгән пакетны алды, аны иренеп кенә ачты да укый башлады. Пакет хезмәттән тыш доход алучы гражданнарның эшен тикшерү комиссиясенә адресланган иде. Анда Гөлсем Шакирова хуҗалыгы турында шактый бай материал тупланган. Бу кешенең исеме дә, фамилиясе дә Юныска таныш кебек тоелды. Никадәр тырышып хәтер капчыгын актарса да, бу хатын белән кайда, нинди шартларда очрашуын күз алдына китерә алмады. Аның уенча, материал бик белеп, төпле итеп тупланган иде. Язылганнарның дөреслеген раслап, берничә шаһит кул да куйган... Ул шулай бөтен дөньясын онытып Гөлсем Шакирова өстеннән төзелгән мөһим материал белән танышып утырганда, телефон шалтырады. «Нәрсә соң бу кызый актыгы мине санга сукмый? Ул аңларлык итеп урысча әйттем ләбаса!» Юнис шартларга җитеп урыныннан торды. «Бервакытта да онытылмаслык итеп арт сабагын укытырга кирәк бу җубалгының! Белсен Юнысның кем икәнен!» Ул ярсып ишеккә атылды һәм үз янына кереп килүче секретарь кыз белән чак кына бәрелешмәде.

— Юныс Гыйльметдинович, телефонда полковник Волков. Сезне эзләп табарга боера.

Әтәчләнгән Юныс, секретарь кызның сүзен ишетеп, кайтып төште. Юешләнгән учыннан төребкә шуып чыкты да рычагка төште, телефон өзелде, ул Волковка үзе шалтыратты.

— Иптәш полковник,— диде ул,— сез мине эзлисез икән.

— Мин сезне асып куям!

Юныс кычкырып көлгән булды.

— Ассагыз асарсыз, тик башлаган олы эшне тәмамларга вакыт бирегез, иптәш полковник.

— Мине райкомга чакырып әрләделәр!

Ни өчен икәнен белмәсә дә, Юныс аңлады, әлеге дә баягы комиссия эше белән кызыксыналар булыр!

— Мин ялга чыгарга тиеш идем,— дип гөрләде Волков,— хәзер китмәскә кушалар. Ә минем путевкам алынган, билет кесәдә. Хатын мырлый!

— Иптәш полковник! — дип шатланып кычкырды Юныс.— Китегез рәхәтләнеп! Сездән башка да сынатмабыз!

— Анда, безнең райбашкармада, комиссия өстеннән килгән материал бар икән.

— Ә?! Миңа берни әйткәннәре юк.

— Иртәгегә билгеләнгән утырышны үземә үткәрергә боердылар,— диде Волков.

— Мин риза, риза,— дип мыгырдады Юныс.

Беренче утырышта үзенең рәислек итәсе, иптәшләре арасында рәис сыйфатында күренәсе килгән иде. Ул нәүмизләнеп телефон төребкәсен атып бәрде, әче итеп, ныгытып, урысчалатып сүгенде. Һәрвакыт шулай инде! Җил гел аңа каршы исә! Зур дәрт белән бер эшкә тотынам, дигәндә генә дилбегәне аның кулыннан тартып алалар. Үзенең егетлеген, эшне оста оештыра алуын район хуҗалары алдында күрсәтәм дигәндә генә, Волков аның кулыннан форсатны йолкып маташа. Андый хәл бер булса, түзәр дә идең, юк шул, гел кабатланып тора шундый афәтләр...

Аңа тәкъдим иткәндә, техникумга җиңел эләгеп була иде, хәзер читен, диләр. Былтыр әнә Саблуковны имтиханнарда бәреп ектылар, ут егет иде югыйсә, ут! Имтиханнар рәисенә акча төртергә оныткан, дип сөйләделәр. Авыр булса булыр, ул быел финанс техникумына читтән торып укырга керергә уйлый. Керер өчен җиде еллык белем бик җиткән. Фактта Юнысның җиде еллык белеме бар. Ул авылның тулы булмаган урта мәктәбен бетерде. Алар укыганда мәктәп колхоз яшьләре мәктәбе дип атала иде. Урысча аны ШКМ, ә татарча латин хәрефләре белән КИМ дип язып йөртәләр иде. Хәзерендә Юныс кулында КИМ тәмамлаганга бер документ та юк. Мәктәптән бирелгән таныклыгы сугыш вакытында югалды. Армиядән кайткач та, инде погоннар бар чакта, хәстәренә керешсә «урта белемле» дигән кәгазьне дә кулга төшерергә була иде. Погоннар балкып торганда сөйләшергә була, күрәсең ич, әнә Волков полковник! Сүзе боердән генә чыга. Аңа барлык җиңеллекләр бирелгән.

Юныс үз гомерендә бик күп анкеталар тутырды, ботенесендә дә белеме турында сораган графага «җиде класс белемле» дип язды. Әмма бу турыда документ таләп итмәделәр. Сорасалар, әз-мәз кыймылдар иде, ул укыган мәктәп тә исән иде. Хәзер мәктәбе юк, авылы да беткән, таралган. Җиде классны тәмамлады дигән кәгазьне ничек табарга? Әр-яңадан имтиханнар бирү турында уйларга да ярамый. Ничек булса да ул техникумга керү хакында уйларга тиеш. Быелдан калмаска! Соң, әйләнеп як-ягыңа кара, авылдан килгән эте-бете аттестат тотып килә. Базарда эт типкәсендә йөргән Зәйтүнә техникумга керде. Ул хакта көнләшеп аңа Гөлчирә сөйләгән иде. Ә тегеә... үлчәү табасы белән аның чыраена бәргән Әлфиясе институтта укып йөри икән! Хурлыгыңнан үләрсең! Ярый әле алдан чарасын күрде Юныс. Наилә белән сөйләшеп, килешенеп куйды. Бер-бер гаебе чыга калса, дөбердәтеп эштән куачак ул аны! Төрмәгә үк утыртасы иде! Бер-ике ел кара ипи белән судан бүтәнне күрмәсен иде. Эх, Лагутченко яшьрәк түгел. Менә аны налог инспекторы итеп алсаң, йомыш-юлыңа рәхәтләнеп чабар иде! Соң инде, ниндидер Гөлсем Шакировалар илне имеп, халыкны талап череп баеганда, Юныс кебек эшлекле, уңган кешеләр, партиянең, хөкүмәтнең тоткалары коне-төне тир түгәргә мәҗбүрләр. Әйдә, комиссиянең алдагы утырышын кәпәренгән Волков алып барсын. Киңәшмә үтмичә, ул аңа бер генә актны да, документны да күрсәтәчәк түгел. Сөйләшсеннәр! Ә кәгазьләр Юныс Гыйльметдинов кулында. Гөлсем Шакирова өстеннән килгән шикаятьләрне дә чыгарып салмас. Алга, югарыга үрләргә күперне ул үзе салмаса, кем салыр?

Тагын телефон шалтырады. Алыргамы, алмаскамы? Ишектә секретарь кызның башы күренде.

— Юныс Гыйльметдинович, сезне милициядән подполковник Арнаутов дәшә.

Ә, Арнаутов! Әшнә, дус кеше. Арнаутовның баҗасы теш мастеры, алтын-көмеш белән эш итә. Адәм баласының кулы алтын-көмешкә тия икән, аның төрле чагы була. Арнаутовның баҗасын шактый бәла-казалардан йолып калганы бар Юнысның, эзли икән,— тиккә түгелдер.

Арнаутовның бераз шөбһәләнгән тавышын ишеткәч, Юнысның күтәренке күңеле сүрелә төште.

— Бер минут торма, хәзер үк минем янга килеп җит! — диде Арнаутов.

Чакыра икән, барырга кирәк. Тавышында хәвеф бар икән — кемгәдер бәла яный, дигән сүз. Ачкүз баҗасы берәр бәлагә тарыгандыр, мөгаен. Туймады шул яһүд! Барып барын бушатып кайтасы инде әллә? Менә кем таба затлы коньякларны! Лагутченко сыман сасы спирт белән маташмый. Инде барырга чыккач, өченче каттан икенчегә төшкәч, Юныс үз кабинетына әйләнеп керде. Арнаутовның тавышы да, чакыру рәвеше дә ошамады аңа. Нииндидер ямьсезлек булганга ошый. Ул шкафын ачты. Шкафта калын-калын папкалар артында үткән атнада гына үткен, елдам Наилә алып кайтып биргән ике шешә коньягы тора иде аның. «Әгәр шушы коньяклар ярдәмендә яңа инспекторым Әлфияне кулга ияләштермәсәм!» — дип адарынып та куйган иде Юныс, хәзер шуларны сумкага тыкты. Сумкасының төбенә караса... йә ходай, Лагутченко белән тутырган документларның берсе дә юк!

Уе кинәт йөгерекләнде Юнысның, югалган документлар белән Арнаутов чакыруы арасында уртаклык бар сыман тоелды. Налог инспекторы Наиләнең җеп очы чыкканмы әллә? Ул да туймас тамак булды! Эчертеп-исертеп, хатынын аертып берәүгә кияүгә чыкты, ирен алкашка әйләндерде, хәзер зарлана, эчә, имеш. Эчсә, бу дөньяда эчмаган кеше бармы?

Арнаутов бүлмәсендә ялгызы иде. Болай да балта эләрлек бүлмәнең форточкасын ачкан да иңе белән кашагага терәлеп «Казбек» суыра. Юнысның сәламен баш кагып кына кабул итте дә:

— Утыр,— диде. Өстәл тартмасыннан бер төргәк кәгазь чыгарып Юныс алдына ташлады.— Таныш.

Ба-а, Лагутченко белән бергәләп әзерләгән кәгазьләр ич болар! Ничек Арнаутов кулына килеп кергәннәр? Ул, телсез калып, Арнаутовның сытык чыраена карады. Подполковник, өстәл тартмасыннан икенче бер төргәкне алып, анысын да Юныска сузды.

— Бусын да укы. Бу кәгазьләр миңа полковник Уваров аша килеп керде. Икесен чагыштыр да — уйла. Бик нык уйла! Монда бер кешенең генә башы җитә торган түгел! Син нык каптырдым дип уйлагансың, алар сине тагын да ныграк эләктергән...

Юныс, Лагутченко белән парлап әзерләгән кәгазьләрен читкә эшереп, Уваров кулы аша үткән кәгазьләргә йотылды. Нилэр генә язылмаган иде монда! Аның эчеп-исереп автобуска утыра алмыйча азаплануы да, балалы хатынга бәйләнеп (баласы юк иде, валлаһи!), аның ире белән сугыша башлавы да, автобустагы намуслы совет гражданнарын «кулак калдыклары», «буржуй элементлар», «эшлексезләр» һәм башка шуның кебек пычрак, кабахәт сүзләр белән хурлавы да, һәммәсе дә бәйнә-бәйнә язылган, имзалар белән ныгытылган иде. Кара син аны, теге тимер кысалы күзлек кигән табак битле бәндә фән кандидаты икән. Милициягә сөйрәгәндә аның: «Бу эшне болай гына калдырмам, төбенә тоз салырмын!» — дип кычкырганы хәзер генә исенә төште Юнысның. Төсе-кыяфәте дә истә явызның! Фән кандидатының обком тирәсендә дә танышлары булса... Эх, каты ялгышылган, нык хаталанган ул көнне Юныс!

Иң түбәндә язылган бер сорау аны аерата нык куркытты: «Юныс Гыйльметдинов Лагутченко янына еш килә, килгән саен күбенгәнче эчә, киткән чакта урам комитеты рәисе ришвәт итеп аңа аракы, коньяк һәм азык-төлек төяп җибәрә. Ни өчен Лагутченко эчертә аны, бусына тикшерү органнары җавап бирергә тиеш?»

Арнаутов дәшмәде, ул аңа күзен күтәреп карарга курыкты. Шактый вакыт үтте, ишек шакыдылар. Арнаутов кырыс кына:

— Көтегез бераз! — дип кычкырды.

— Нишләтәләр мине? — диде Юныс юаш кына.
— Партиядән куалар, эшеңнән чыгаралар. Җитәрме?
Юнысның күзеннән сытылып яшь чыкты.
— Василий Иванович!
— Василий Иванович булсам да, мин Чапай түгел, сине коткарып калырлык власть юк миндә.
— Үтермә, зинһар! Тап җаен.
— Кычытмаган җирне кашып йөргәнсең. Мифтаховның Уваров белән дус икәнен сиңа әйтмәделәрмени?
— Әйттеләр дә...
— Лагутченконың да ике кат тиресен тунарга кирәк!
Йә, ни әйтсен Юныс? Ни әйтә алсын? Ул күшеккән тавык кебек утырды-утырды да чынлап ук елап җибәрде. Арнаутов аның елаганын кәефләнеп күзәтте, власть иясе иярләре ирләрнең елаганын яраталар. Ирләр елаганда эшләнгән яхшылык онытылмый, бәрәкәтле була. Юнысның кулы моңарчы да юмарт иде, моннан соң ул Арнаутовның колына әйләнәчәк. Власть иясенә колдан да яхшы кеше бармыни?
— Җитәр. Уваров синең өстән язылганнарны юк итәргә каршы түгел. Ул моны минем хакка эшли! Ишетәсеңме, минем хакка! — Арнаутов Юнысның кулын этәреп җибәрде.— Үз чиратыбызда без дә Мифтахов өстеннән язылганнарны дөньядан югалтырга тиеш. Лагутченкога әйт, Мифтаховка кагылмасын! Күрмәсен ул аны! Бүтән бәйләнер кеше беткәнме аңа поселокта? Янына бар, сөйләш, ләкин исеңдә тот, кабасы булма! Хәзер синең язмыш кыл өстендә.
Юныс ашыга-ашыга сумкасын ачты, ул чыгарган шешәләрне, Арнаутов, бер дә исе китмичә генә, караңгы почмактагы шкаф киштәсенә куйды, шкафны бикләде.
— Йә, бар... Моннан болай мине кыен хәлгә куйма.
Юныс, әгәр Арнаутов «чукын!» дисә, чукыначак та иде, кат-кат баш иеп, арты белән ишеккә барып җитте. Чыгам дигәндә генә Арнаутовның йомшак, дустанә тавышын ишетте:
— Юныс Гыйльметдинович, хатынга бик яхшы көзге пальто кирәк иде. Караштыр әле. Размерын беләсең!
— Булыр! — диде Юныс һәм күз алдыннан югалды.

## XVI

Мифтахов белән янды Юныс Гыйльметдинов, җитмәсә, Лагутченконы яндырды. Бу әле алар икәүләшеп бирелде диген сүз түгел, көрәш башлана гына. Күп еллык тәҗрибәсеннән чыгып, Юныс бер нәрсәне белә — күзгә-күз көрәш чын алыш түгел әле ул, чын алыш — астыртын көрәш! Монда инде кеше күзенә күренми торган кораллар эшкә китә. Бүген Мифтахов — аның кан дошманы. Уваров та начальник булып мәңге утырмас, бәлки, аны Мәскәүгә күчерерләр дә начальник булып Арнаутов калыр. Әлегә Юныс начальство күзенә ташланырлык хезмәт күрсәтергә тиеш. Хәзер ул үтә сак, сабыр һәм дөртле булырга тиеш. Әгәр тагын бер мәртәбә оттырса, бетте баш! Ике көннән аңа горфо мөдире шалтыратты. Исәнме-саумы юк, туп-туры яра:
— Хургин сезнең районда мы?
— Бездә. Нишләгән тагын?
— Нишләгәнен сездән сорарга кирәк.
— Иван Ефимович, безнең аны күздән ычкындырганыбыз юк. Шушы арада гына өенә барып тикшереп кайттылар.
— Күпме налог исәпләдегез?
Юныс кычкырып көлгән булды.
— Сез нәрсә, Иван Ефимович, ничек итеп налог исәплик ди без аңа?

Өендә беркемне кабул итми, узган елдан бирле ике урында эшли, район поликлиникасында һәм заводта.

— Кара аны, Гыйльметдинов, үкенерлек булмасын. Сезне узып ни өчен горфога чыгулары да шикләндерә, сезгә районда ышаныч кимедеме әллә?

Горфо мөдиренең шулай янавы, болай да куркып-калтырап торган Юнысның акылын иләс-миләс итте. Бер үк вакытта ул аңа рәхмәт тә укыды. «Рәхмәт, Иван Ефимович,— диде күңеленнән генә.— Бик вакытлы хәбәр иттең. Хәзер үк ашыгыч чарасына керешербез!»

Горфо мөдире шалтыраткан икән, бу инде җитди сигнал. Юктан барны, бардан юкны табарга кирәк! Ул ашыгычлык белән Хургин эшли торган поликлиникага шалтыратты. Бүген эштә юк икән. Заводына барырга иртә. Ул, гадәттә, смена азагына барып йөри. Кайда булуы мөмкин? Мөдир нинди шартларга ишарә ясады? Әгәр Хургин бүген, налог инспекциясе тикшереп китте инде, дип тынычланып, үз өендә авырулар кабул итеп ятса? Бик мөмкин андый хәл. Хургин ачкүз булмаса, барлы-юклы акчага кызыгып заводка барып йөрмәс иде. Әгәр горфодан килеп әләктереп алсалар, Хургинга гына түгел, район финанс бүлегенә дә хурлык булачак! Элегрәк тә, Хургин өендә алтын теш куя, дигән хәбәр кергән иде. Хургин ничек котылды соң ул чагында? Югары даирәләрдән берәү аяп калды бугай аны. Юнысның ул вакытта ул докторга ачуы чыгып калган иде. Әгәр Юныс горфо хезмәткәрләреннән алда Хургинны кисәтеп куйса? Алтын-көмеш белән эш итүчене нигә егарга? Бик нык баш ватарга кирәк — кайсысы Юныс өчен файдалырак булыр? Аның кыңгыр эшен фаш итеп көнгә чыгарумы? Хәзер сине тикшерергә киләчәкләр, итәкләреңне җыештыр, дип кисәтүме?..

Кабинетта озак утырырга һич ярамый иде, ул тиз генә Хургинның өенә барырга җыенды. Баргач, күз күрер тагын, әгәр юмартланып китеп, чаманы чамага туры китереп төртсә, Хургинны әлегә аярга да булыр. Юк икән — чыкмаслык итеп батырырга? Тыелган һөнәр белән шөгыльләнә, алтын теш куя.

Хургинның йорты шәһәр читендә, Ремесленный дип аталган тар тыкрыкның азагында иде. Белмәгән кеше көндез чыра кабызып эзләсә дә таба алачак түгел. Юныс сүгенә-сүгенә килеп җиткәндә, һәрвакыттагыча капка бикле иде. Тәрәзәдә бер хатын күренде. Юныс күрү белән таныды, Хургин хатыны. Ул да Юнысны таныды. Ат кадәр олы гәүдәле хатын тәрәзәдән юк булды да озак кына күренмичә торды. Юныс кыңгырауга кат-кат басты. Шуннан соң гына хатын алпан-тилпән чыгып җитте.

— Гафу итегез, этне тыяр хәл юк, көттердем.

Юнысның ачулы тавышын ишеткәч кенә эчтә бикләнгән овчарка котырып өрә башлады. Керделәр. Хатын эт тавышы килгән чолан ишеген куна тактасы белән каплап Юнысны өске катка меңгереп җибәрергә чамалады булса кирәк.

— Сара Исаевна, анда менеп йөрергә минем вакыт юк. Бер минутка гына Иосиф Данилович кирәк иде.

— Хәзер чакырам. Менә торыгыз.

Юныс аны тыңлап та тормады, уң яктагы ишектән аскы катка үтеп тә китте. Аны күреп, Хургинның чырае кара коелды. Юныстан бигрәк үз хатынына ачуы килде, аскы катка чит адәмнәрне кертмә, дип мең мәртәбә кисәткәне бар югыйсә. Тыңламаса да тыңламас икән!

Хургин чибәр генә бер хатынга теш куеп маташа иде. Күзлек астыннан усал күзләрен алартып, нидер әйтмәкче иде, Юныс аны туктатты.

— Башлаган эшегезне бетерегез, Иосиф Данилович.

Юныс канәгатьлек белән кулларын уа-уа бер читтәге буш урындыкка утырды. Горфодан тикшерү килеп җитмәгән — бу бер, икенчедән, ул хәйләкәр Хургинны тыелган эш өстендә тотты. Хәзер аның белән

сөйләшергә була! Арнаутов хатынына пальтолык өлеш чыгармый икән — яна Хургин! Эш прокурорга бирeләчәк. Ни ашыкса да Юныс сабыр гына аның эш бетергәнен көтеп утырды, хатын чыгып китүгә Хургинның якасына ябышты.

— Нишләп син законлы эшеңә чыкмадың? Кырык җирдә койрыгың каткан, шуңа карамастан, сине эзләп өеңә килергә туры килә!

Хәйләкәр Хургин, эшнең кәкәй икәнлеген күздә тотып, турыдан-туры ялагайланырга тотынды.

— Юныс Гыйльметдинович, кичерегез, һич көтмәгәндә килеп чыкты. Бу хатын ашыгыч командировкага бара икән. Ялынып өйгә килгән, еламый гына! Сүзен тыңламыйча булдыра алмадым.— Аннары, иелә төшеп, төче елмаеп, авыз читен учы белән каплап дәвам итте.— Бик кирәкле кеше үзе. Файдалы урында эшли. Таныштырырмын кирәксә.

Юныс һавалы кыяфәттә аягына басты.

— Менә нәрсә, Хургин, син төзне турылап маташма. Минем вакытым юк. Иртәгә иртүк минем янга кер.

Хургин аны капкага кадәр озата чыкты, җиң эченнән кызыл утызлык чыгарып, аны Юнысның кесәсенә шудырды. Юныс утызлыкны тартып алып, җирәнгән кыяфәт белән хуҗасына кире кайтарды. Юк, алай ансат кына котыла алмас бу юлы Хургин! Утыз сум белән котылмакчы! Олы башын кече итеп утыз сумга монда килеп йөриме Юныс?

— Азсынасызмы? — Хургин як-ягына каранды.— Үзем белән башка акчам юк. Соңыннан бәхилләрмен.

Юныс вәгъдәгә ышанамы? Җүләрме әллә ул?

— Хәзер дә, соңыннан да кирәкми!

Ул капканы шалт итеп япты, чоланда абалап эт өрергә тотынды. Юныс тыкрык уртасына җиткәндә, юан тал көүсәсе астына поскан хатынны күрде! Хургинның клиенты! Ашыгыч командировкага китәргә тиешле хатын! Кай арада Хургин аңа пышылдап өлгергән диген. Эшләре бетмәгән аларның, мөгаен, шулай. Юныс, юан тал турысыннан сызгыра-сызгыра үтеп, ачык капкага кереп йомылды. Теге хатын аны күрмичә дә калды. Юныс башын капкадан тыгып караганда, ул иләп кенә Хургиннарның ачык капкасыннан кереп бара иде. Хәзер Юныс эш сәгате беткәнче райбашкармага кайтып элгәшергә тиеш. Бәхетә, шәһәрдән дәү ЗИЛ машинасы — такси килеп чыкты да тар тыкрыкка кермәде, кире борылды. Менә бәхет! Такси Юнысны җәһәт кайтарып җиткерде. Сәгатенә карады, эш бетеп килә икән килүен! Наилә белән Әлфия баскычтан төшеп киләләр иде. Ул аларны кире борды.

— Мин горфо заданиесе белән йөрим. Мөдир ашыгыч эш тапшырды. Хургин өендә кеше кабул итә башлаган. Белмим, сез ни карап йөрисездер. Урамда такси, акча түләнгән. Хәзер үк Хургинның өенә бастырып барыгыз. Нинди юл белән булса да өенә элəгергә тырышыгыз!

Әлфия нишләргә дә белмәде, ул бүген эштән соң Мансур белән очрашырга тиеш.

— Юныс Гыйльметдинович, иртәгә барсак ярамасмы?

Юныс аңа котырып карады, Әлфия иңеп китте.

— Монда базар түгел, базарда гына сатулашалар! Өендә клиент утырганда, сез барып басарга тиеш! Моннан да җайлы очрак булмас! Ашыгыгыз!

Юныс шулай өздереп әйтте, карышырга, бәхәсләшергә урын калмады, инспекторлар Юныс карап торганда чабып, ул күрми башлагач салынкы атлап, таксига кереп утырдылар.

— Юкка эт куабыз,— диде Наилә.— Әгәр өендә клиент булса, безне бусагасына якын да китерми ул. Эттән талатыр.

— Авыз йомып тормыйлар аны, үзенә әйтәләр,— диде Әлфия.

— Каршы килеп кара! Шуңа ул начальство!

Алар бераз тын бардылар, шофер да дәшмәде. Тыкрыкка җитәрәк, Наилә машинаны туктатты.

— Моннан ары җәяү генә барыйк,— дип пышылдады ул Әлфиягә.

Юныс машинага акча түләмәгән икән, инспекторлар түләмәскә маташсалар да, шофер аларны тиз җиңде, утыртам да милициягә алып барам, дип янады. Озак юанырга ярамый иде, клиентның әз суытуы бар. Наилә зарлана-зарлана тиешле акчаны түләде дә машинадан чыктылар. Әлфиянең мондый ялтыравыклы кара, затлы машинага утырганы юк иде, күпме түләргә икәнен белгәч, сызгырып куйды.

— Әнекәем лә, акчаны каера икән болар!

— Түләве уртак булыр.

Әлфия күңеленнән генә түләнгән акчаны урталай бүлеп бара башлады, зиһене буталган иде, һич очына чыга алмады. Наилә дәшмәде.

— Шуны уйлап барам,— диде ул бераздан,— ничек итеп безгә Хургинның өенә эләгергә?

Әлфия аптырап, иңбашын уйнатып алды. Аның үз кайгысы-кайгы: озакламыйча аларга Мансур килеп җитәргә тиеш. Ярый ла берәрсе өйдә булса.

Наилә мондый эшләрдә тәҗрибә туплап өлгергән иде инде, ул юри-юри генә, Әлфия алдында дәрәҗәсен күтәрер өчен генә каушаган, курыккан булып барды. Каушаган булып кылана да, соңыннан, менә нинди явызны да җиңдек, дип мактаначак. Алар Хургин йортына җитәрәк бер капка төбендә туктадылар. Наилә капка төбендәге эскәмиягә утырды.

— Утыр, ял итик.— Әлфия басып торуында булды, ул, ничек тә эшне тизрәк бетереп, Мансур янына кайтып җитәргә ашыга иде.— Утыр, утыр. Безгә озак юанырга туры килмәгәе. Әнә теге ике катлы йортның капкасыннан күзеңне алма! Безнең бәхеткә, начальство әйткән клиент килеп чыкмасмы? Анысы китеп өлгерсә, бүтәне кермәсме?

Халык эштән кайта башлады. Бала күтәргән, иңнәренә сумка, беләкләренә букча аскан хатын-кызлар өйләренә ашыгалар. Кайберәүләрнең күзе аларга төшә, аларның эшсез утыруларына гаҗәпләнәләр дә каш астыннан карап китәләр, сүз кушарга кыймыйлар. Менә алар йотылган капка тирәсендә эт өргәне ишетелде. Күп тә үтмәде, капкадан бер хатын чыкты. Бу үзе, Юныс күргән, алтын теш куйдырырга килгән хатын иде.

— Тор, киттек,— диде Наилә, Әлфиянең беләгеннән тартып.

Чатны борылганда алар хатынны куып җиттеләр.

— Апакай-алмакай, сезне бер генә минутка туктатырга мөмкинме?

Көтмәгәндә артыннан куып җитеп янына килеп баскан ике хатын-кызны күреп тегенең коты очты. Яңа куелган алтын тешләре тыкрыкны яктыртып ялтырап алды. Хатын-кызларның, бигрәк тә яшьрәгенең гади кешеләр икәнен күргәч кенә җиңеләеп калды.

Наилә чыраена серле кыяфәт чыгарып сайрады.

— Гафу итегез, без дә Иосиф Данилович янына бара идек. Сезнең алардан чыкканыгызны күрдек тә сорашырга уйладык. Киңәшле эш уң була, диләр! Әйтегезче, зинһар, аңа ышанырга, теш куйдырырга буламы?

Хатын: «Нишләп мин алардан чыгыйм, бернинди Даниловичны белмим, ишеткәнем дә юк!» — дип кырт кисәргә уйлаган иде, икесенең тиң ялварып карап торганнарын күреп тынычланды, бик теләп сүзгә керешә. Алтын теш артында сүз торамы соң?!

— Ярты ел чамасы элегрәк Иосиф Данилович иптәш хатыныма теш куйган иде, мактап бетерә алмый. Белмим, минеке ничек булыр. Әллә нигә ашыккан кебек булды.

— Озак йөрттеме?

— Юк. Озак йөртергә ярыймы соң, тотылудан курка.

— Бәһасе ничек? Бик тозлы түгелме?

— Яхшы эшләсә, бәясеннән тормыйсың инде аның!

Хатын теш куйдырган өчен күпме акча түккәнен тиененә кадәр

әйтеп бирде, сөйләгән саен сүзе артты — алтын теш куйдырган хатынның сүзе бетәме соң?!

— Нишлибез, акыллым? — дип сорады Наилә Әлфиядән, үзе аның җавабын көтеп тормады, кесәсеннән кызыл катыргы тышлы кенәгә алып хатынга сузды.— Безгә сезне беразга тоткарларга туры килер.

— Моны ничек аңларга? — диде хатын авызын тиз ябып.

— Сайлагыз, райбашкармага барабызмы әллә монда гына эшне бетерәбезме? Курыкмагыз, сез — корбан гына!

Хатын таш кебек катып калды. Катыргы кенәгә аңа аяз көнне яшен суккандай тәэсир итте. Таныклык иясенең кем булуын сорарга да онытты. Әгәр кенәгәне кулына алып, сабыр гына укып чыкса, ул кадәрле җебеп тә төшмәс иде. Таныклык аның хуҗасына урамда очраган кешене тоткарларга бернинди хокук бирми, ул Наилә Сабир кызы Сабированың район финанс бүлегендә налог инспекторы булуын раславучы гап-гади документ иде. Гамәлдәге закон буенча аңа бары, кешеләрнең үзләреннән сорап, налог салыр өчен доходларын исәпләү хокукы гына бирелгән. Кызыл төснең магик тәэсире хатынны бөтенләй чыгырыннан чыгарды. Ул үзеннән бигрәк, җаваплы урында утырган ирен уйлап хафаланды. «Аңа барып җитсә!...» Хатын карышмады, берсүзсез Наиләгә буйсынды. Наиләнең кызыл кенәгә белән әллә ниләр кыйратканы бар иде. Сыналган ысул! Алар бер читкәрәк тайпылдылар.

Наилә бер чиста кәгазь алып, хатынның исемен, атасының исемен, фамилиясен язып куйды. Адресын, эш урынын сораша башлагач, хатынның тагын авызы йомылды. Озак кына әйтмичә торды. Сүз теш куйдырган өчен түләүгә күчкәч, хатын сүзне гел кирегә борды.

— Иосиф Данилович безнең ерак туганыбыз, бушка куйды, бер тиен дә түләмәдем,— диде.

Моңарчы Әлфия аны кызганып, жәлләп тора иде, хатын күзгә карап алдаша, койрык болгый башлагач, аның да алтын тешкә ачуы кабарды. Наилә кызып ук китте.

— Гражданка, сездәй чибәр ханымга алдашу килешми. Күпме түләвегезне әйткәнгә биш минут та узмады. Сезгә кем кызганычрак, үзегезме, череп баеган Иосиф Даниловичмы?

— Куркытмагыз, минем кеше әйберен урлаганым юк.

— Кайчагында яшереп калдыру урлаганнан да яманрак була.

Хатын нишләргә дә белмәде, куркуыннан калтырый ук башлады. Әлфия аны чын күңеленнән кызганса да, киреләнеп маташуын ошатмады.

— Әгәр хәзер әйтмәсәгез, иртәгә сезне прокурорга чакырып алырлар. Анда инде башкачарак сөйләшерләр.

«Прокурор» дигәнне ишеткәч хатын тәмам коелып төште. Наилә кулындагы актны тартып алып:

— Китер, кай төшенә имза салырга? — дип сорады.

Кулын куйды да шайтаннан качкан фәрештә кебек күздән югалды.

— Менә хәзер Хургин белән сөйләшергә була! — диде Наилә, балалар кебек шатланып. Алар калай түбәле, ике катлы өйнең капка төбенә барып басканда, күз бәйләнә башлаган иде инде.

Наилә аяк өсте торып, капка тактасына куеп повестка язды да аны почта әрҗәсенә төшереп җибәрде. Ул иртәнге сәгать тугызга Хургинны райфога чакырган иде.

## XVII

Гөлчирә сүзендә торды — Зәйтүнәне промтоварлар кибетенә эшкә урнаштырды.

Кибет Кәҗә бистәсендә, асты таш, өсте бүрәнәдән эшләнгән йортның ярымподвалында урнашкан иде. Әле ачылмаган, Гөлчирә аптырап тормады, юлын әйбәт белә икән, Зәйтүнәне ишегалды аша, арттан алып

керде. Монда, арт ишекне үтеп кергәч, склад иде. Ул төрле зурлыктагы әрҗәләр белән туп-тулы. Бер кырыйга аркылы-торкылы кием-салым өелгән. Кәч-хәл белән шуларны аралап нәни генә бер бүлмәгә уздылар. Бүлмә шулкадәр кечкенә иде, басып торыр урын да юк. Гөлчирә белән Зәйтүнә көчкә сыйдылар.

— Исәнмесез,— диде Гөлчирә, ишекне ачу белән бүлмә хуҗасына сәлам биреп.

Анда, өстәл артында чут төймәсе тарткалап, табак битле, сипкелле бер ир кеше утыра иде.

— Сезнең хәер-догада, бик шөкер әле, шөкер!

Ул күтәрелеп карамыйча гына әле һаман төймәләрен әрле-бирле йөртте.

— Миннән хәер-дога алган кеше бер чакта да ким-хур булмый. Әни мәрхүмә бирәр эшкә тотынса, кызым, теләктә тор, синең теләгең гел кабул була, дия торган иде.

Гөлчирә куеныннан кәгазьгә төргән нидер алып кибет хуҗасының кулына тоттырды.

— Санаргамы?

— Соңыннан!

Әгәр Зәйтүнә каушап калмаса, ярым караңгы бүлмәдә күзе әлҗе-мәлҗе килмәсә, Гөлчирәнең сипкелле битле кешегә шактый саллы акча төргәге тапшыруын абайлаган булыр иде, хәзер исә аңа эченнән рәхмәт кенә укыды. Алып килде, хуҗа белән тигез торып сөйләшә. Берүзе чыкса, бу кибетне гомерендә дә эзләп табачак түгел икән Зәйтүнә. Аның изгелекләрен ничек кайтарасы булыр инде, үзенең бер тиенлек файда китергәне юк Гөлчирәгә. Ә ул аны, тере ят кешене, акча бирә-бирә эшкә урнаштыра.

Зәйтүнә шулай югалып, баш иеп торганда, Гөлчирә аңардан торг приказын сорап алды.

— Әхәт абый, бу хакта сезгә хәбәр иткәннәрдер инде?

Шул чакта гына Әхәт Зәйтүнәгә күтәрелеп карады. Чәче юкка мыек үстереп, агарган мыегын карага буяп йөрүче бу күсе инде алтынчы дистәне ваклаган иде. Шулай да хатын-кызга, бигрәк тә яшьләргә тыныч күз белән карый алмый. Ул ала күзе белән Зәйтүнәне аркылыга-буйга күзәтеп торды да:

— Авыртмас башка тимер таяк булмасмы? — дип сорады.

Гөлчирә көлеп җибәрде.

— Ялгышканым да, абынганым да юк. Кешеләрне таныйм, Әхәт абый, рәхмәт әйтерсең!

Зәйтүнә, һаман үз уйларына бирелеп, аларның үзара сөйләшүләренә игътибар бирмәде, Гөлчирәнең куллары, күз-колаклары белән Әхәткә ясаган ишарәләрен, ымнарын бөтенләй күрмәде, әңгәмәнең үзе турында баруын аңлап бетермәде. Ул бу минутларда Гөлчирә апасына тәмам ышанган, дөнья йөзендә аңардан да мәрхәмәтле, шәфкатьле, ярдәмчел кеше юк та иде.

— Сеңлем,— диде, ниһаять, Әхәт аңа эндәшеп,— моңарчы сезнең сәүдәдә эшләгәнегез бармы?

Зәйтүнә өчен ашыгып-ашыгып Гөлчирә җавап бирде:

— Урамнан адашып кергән кеше дип уйлама тагын, Әхәт абый. Эшләде. Эшләмәгән булса, торг аны синең катка җибәрер идеме?

Кибет зур түгел икән, зур булмаса да, ни белән генә сату итмиләр монда! Теккән киемнәр, трикотаж, хәтта спорт кирәк-яраклары да бар. Ул елларда махсус көйләнгән кибетләр юк дәрәҗәсендә иде. Дөрес, кайчандыр монда төп кибет иде. Шәһәр базарларында аларның күп санлы лареклары бар иде. Гөлчирәнең Әхәт белән танышлыгы да шул чакта башланды һәм бер башлангач өзелмәде. Яңа салынган биш катлы йортның аскы катында зур кибет ачылгач, бусы филиал булып кына калды. Уңай шартлар булмагач, филиалны ябарга да җыендылар. Әхәт

теше-тырнагы белән каршы торды — яптырмады, төп кибеткә күчерергә теләделәр, күпме сатучы эшләсен белгәч — бармады. Якын-тирәдә промтоварлар белән сәүдә итүче бүтән кибет юклыгын сылтау итеп, торг белән шактый бәхәскә керде, шушы тирәдә яшәүче халык аны яклады. Шәһәр хуҗалары халык белән исәпләшмичә булдыра алмады. Шул көннән бирле Әхәт үзенең җиңүе белән мактана килә.

Әлеге филиалның эше ал да гөл, гөрләп бара, бер айда да товар әйләнеше планын үтәмичә калганы юк. Төп кибет исә һаман аксый, һаман көйләнеп бетә алмый. Моның серен шәһәрдә өч кенә кеше — Әхәт үзе, торг директоры һәм план бүлеге начальнигы гына белә.

Филиалның эше хутта — штатта нибарысы ике кеше, мөдир дә бер сатучы. Менә айдан артык инде мөдир Әхәт үзенә бер сатучы эзли. Моңа кадәр Чистай ягыннан килгән бер сатучы эшли иде, холкы яман булып чыкты, килешә алмадылар. Ике бүре башы бер казанга сыймады. Хатын китәргә мәҗбүр булды.

Әхәт белән Гөлчирә күптәнге танышлар, әшнәләр дисәң дә дөрес, сатучы урыны бушау белән Әхәт Гөлчирәгә яраклы кеше табарга кушты. Эшчән дә булсын аңа, телсез-тешсез дә булсын, яшь тә булсын, чибәрлеге дә булсын. Гөлчирәгә генә ышанып Әхәт үзе дә тик ятмады, әлбәттә. Ләкин күңеленә ошаган, бөтен ягы да килгән кешене бүгенгәчә очрата алмады. Озакламыйча аңа пенсиягә китәргә туры киләчәк. Шушы соңгы талпынышта эшләп, тәмамлап бетерәсе планнары байтак иде әле аның. Аңа кулай кеше кирәк, ярдәмче, ышаныч тоткасы.

Гөлчирә күп күзәтеп, үлчәп йөри торгач, Зәйтүнәгә тукталды. Бераз чыгымчылыгы бар-барын, мәгәр ул Әхәт белән ярашып эшли алыр, дип уйлады Гөлчирә. Ярлы хатын, ире дә мал таба торганнардан түгел, баласы бар. Сеңлесе аның тәрбиясендә. Ничә карама акча җиткерә алмый. Нужа бабай кешенең холкын тиз үзгәртә ул. Зәйтүнә дә кырын кергән акчаның эч тишмәгәнлеген аңлар. Вак-төяк җыем акчасын үз кесәсендә калдырып сабак алган иде, хәзер акыллырак булыр, суык суны да өреп кабар. Зәйтүнә акчага мохтаҗ, акчага хирыс булып үсәчәк.

Барыннан да бигрәк Гөлчирәгә Зәйтүнәнең йорты, йорт тирәсе кулай тоелды. Шәһәр читендә, аулакта, тирән ерганак эченә салынган йорт. Кеше күзеннән читтә урнашкан мондый «җылы почмак»ны елап эзләсәң дә таба торган түгел. Ул бу хакта Әхәт белән сөйләшеп, бөтен ягын алдан кайгыртып куйган иде. Алар кичләрнең берсендә, эңгер-меңгердә, шыпан-шыпан гына Зәйтүнәләрнең йортын карап та кайтканнар иде инде.

Леша белән килешенеп яшәгәндә, Әхәт озаткан дефицит товарларны ул һич курыкмыйча үз йортына алып кайта ала иде. Моңарчы ул, Леша дәшмәс, үзенең дә койрыгы бозга каткан, дип яшәде. Юнысны ир итеп сайлап алып кайткач та әллә ни тузынмады, хәзер исә Гөлчирәнең күңеленә курку иңде, кон туса Леша белән очрашудан курка. Койрыгым бозга каткан, дип тормас, тәки этлек эшләп ташлар! Әйдә, эт күңеле бер сөяк, дип Юнысы юк чакта кайнар кочагына да алды Лешаны Гөлчирә, элеккеге ире янында кан калтырап ятты, башкайларына гына җитмәсә ярар иде бу сукбай яһүд! Лешадан тыш эт-кош беткәнме тирә-күршедә? Күзәтәләрдер әле аларның ихатасын, милициясе дә иснәнеп йөридер. Димәк, яшерен сәүдә Гөлчирә өендә тукталырга тиеш түгел. Сәүдәне ашыгыч рәвештә Зәйтүнә йортына күчереп торырга кирәк. Аның ире Хәлим дә шешәне иптәшлеккә ияртте, анысы белән ара көйләнер, кирәк икән — Юныс белән танышырлар. Әйдә, парлашып шешә төбенә кереп утырсыннар...

Әхәт чучканың Зәйтүнәне алу-алмау мәсьәләсендә икеләнеп торуы Гөлчирәгә бер дә ошамады, ул эшне кызулатырга теләде. Кибетне ачарга да ярты сәгать кенә калып бара.

— Әхәт абый, назландырма, чыгар тегене. Кеше-кара кузгалганчы, Зәйтүнәнең аягын юабыз. Курыкма, акчасын үзем түлим.— Ул өстәлгә

акча ыргытты.— Зәйтүнә үзе алырга тиеш тиешен. Тик аның кыен вакыты, миннән булсын яхшылык!

Зәйтүнәнең колагына быдыр-быдыр сөйләшкән тавышлар ишетелә башлаган иде, ул сагаеп шуны тыңлап торганга, Гөлчирәнең соңгы сүзен юньләп ишетеп тә бетермәде. Каяндыр тоташ гөжләү ишетелә иде.

— Гөлчирәкәй, мин эчемлек белән сату итмим,— диде Әхәт, әллә чынлап, әллә уйнап.

— Ах, әле син шулаймы? — Гөлчирә шаярган булып Әхәтне читкә этәрде һәм аның уң кул ягындагы тимер сейфның ишеген тартты. Ишек бикле түгел икән, шартлап ачылды. Аның аскы тартмасында тигез тезелгән коньяк шешәләре янында, кургаш бүрекләрен ялтыратып шампан шешәләре ята иде. Гөлчирә бер шампанны алып Әхәткә тоттырды.

— Ач тизрәк, ишетәсең ич, анда халык гөжли. Миңа китәргә кирәк.

Урам яктан ишекне дөбердәтә башлагач кына Зәйтүнә тавышның каян килгәнен аңлады. Әхәт җитез кыланып шампан шешәсен ачты, хуш ис таратып, сыеклыкны өч стаканга агызды.

— Тот, синең өчен эчәбез.

Зәйтүнә теләсә-теләмәсә дә стаканны кулына алырга мәҗбүр булды, ләкин эчмәде, нәфрәтләнеп, Әхәт белән Гөлчирәнең вак-төяк кабып, иртә таңнан шампанский чөмергәннәрен карап торды.

— Син нәрсә? Сабый кебек кыланасың? — дип җикерде Әхәт.

— Әхәт абый, көчләмә, үз хәлен белә торгандыр,— диде Гөлчирә.— Тормыш өйрәтә ул. Вакыты җиткәч, кулыңнан тартып алып эчә башлар әле! — Ул ясалма шаркылдады.— Шулай бит, Зәйтүнә сеңлем? — Ул Зәйтүнә кулындагы стаканны алып, эчемлекне Әхәт белән икесенә бүлде.— Исең китмәсен, безгә күбрәк эләгә... Әхәт абый, матурым, бәхетебез шулай мөлдерәмә тулып торсын!

Тышкы якта шау-шу көчәйде, ишекне тагын да ныграк дөбердәтә башладылар.

— Мин сыздым,— диде Гөлчирә, иреннәренә ябышкан шоколадны кулы белән сөртеп.— Ач тизрәк, югыйсә ишегеңне ваталар.

Кибеткә хатын-кыз кофталары килгән иде. Чит илнеке, затлы йон кофталар. Мондый товарның кибеттә күптәннән булганы юк иде. Ни сәбәптәндер, бүгенгә кадәр товарны сатарга рөхсәт булмады. Ә халык арасында чыбыксыз телефон бик шәп эшли, кофталарның кайчан сатуга чыгарыласы сәгате-минуты белән бөтен шәһәргә таралды. Атна буе халык кофталарны саклады, тугыз тулар алдыннан кибет алды ярминкәгә әйләнде, иртә таңнан килеп басучылар кәтәләр-кәтәләр дә буш кул белән кайтып китәләр. Бүген: «Тәгаен чыгачак, сатылачак!» — дигән хәбәрне ишетеп, шушы өтек кибеткә шәһәр уртасыннан да кешеләр җыелган иде. Кара болыт! Башта чәңгелдәвек тавышлы бер хатын халыкны чиратка тезеп маташты, шәмәхә каләм белән уч төпләренә номерлар сукты. Бераздан икенче бер хатынның шундый ук каләм белән, шундый ук чәңгелдәвек тавыш белән кычкыра-кычкыра икенче чират оештыруы мәгълүм булды. Култык таякларын селкә-селкә инвалидлар аерым чират ясап куйдылар. Кая ул, көчленеке замана, үгез кебек тап-таза ирләр, хатын-кызны һәм карт-корыны таптап узып, алга үттеләр. Кайсы елый, кайсы көлә, кемдер аты-юлы белән җиде катлап сүгенә. Тапталган, кысылган кешеләр ярдәм сорап ялваралар. Ишекне ачып җибәргәч, Әхәт прилавка аша сикереп кереп кенә калды, җыелган халык ташкыны кибет эчен шыплап тутырды. Басым шулкадәр көчле булды ки, прилавка буйлап сузылган юан тимер торба сыгылып кәкрәйде. Зәйтүнә мөдир артына чыгып басты, күзләре шардай ачылды, йөрәге ярылырдай булып типте.

— Әгәр тынычланып чиратка басмасагыз, сатуны башламыйм,— дип акырды Әхәт.

Эчтәгеләр нидер аңлатырга тырышты, тышта калган бичаралар

зинһарлап: «Чират монда! Алар чиратсыз керде!» дип инәлделәр. Әхәтнең мондый тамашаны күп күргәне бар, этешү-төртешүгә аның мыегы да селкенми, аның өчен чиратсыз алаларны, түгелме — барыбер, чиратсыз керүчеләр файдалырак та — ул тизрәк акчасын ыргыта да чыгып таю ягын карый, акча кайтаруны сорап вакланмый.

Кофтаның үлчәвен, сыйфатын тикшереп тору юк, андый эш белән маташу мөмкин дә түгел. Һәркемнең күзе тонган, сирәк кайта торган кофтаны эләктерсә, бүтәне чукынып китсен. Күбесе бер белән генә канәгать түгел, икене, өчне эләктерергә тырыша. Әхәт очлы күз, сатып алучыны тиз таный, кемгә ничә кофта бирәсен белә. Ул Зәйтүнәне үз янына бастырды, аңа киндердән тегелгән зур янчык белән вак акча тоттырды, сатып алучыларга сдача бирү вазифасын йөкләде.

Бер төргәкне сатып бетерделәр, икенчесен чиштеләр. Күрә Әхәт, берәү дә кибеттән чыгып китми, әле генә алган бөхетлеләр, тагын чиратка кереп кысылалар, этеш, төртеш, сүгенү. Колаклар берни ишетмәс булды, арттагылар этә, кибеттән чыгып китү мөмкинлеге дә калмады. Әхәт, сатуны туктатып, мең бәла белән ишекне ябып куярга мәҗбүр булды. Кибет эчендә калганнарга товар җибәреп, берәмтекләп арт ишектән чыгара башлады. Урамда гауга көчәйде, җыелганнар дөррәү ишеккә ябырылып бикне ваттылар һәм эчкә ыргылдылар. Ишектән кысылып кергәндә, бер авыл хатынының юбкасы сыдырылып төшеп калган, ул, кызулык белән үз хәлен бөтенләй сизмичә, җан-фәрман алга ыргыла иде, янындагы ир артына төрткәч, ирнең яңагына алагаемга берне китереп чәпеде. Ир:

— Хайван! Күтең ачылган ич! — дип тегеңә җавап кайтарды.

Кем көлә, кем елый, тышкы яктан юбканы эчкә ыргыттылар, бер егет аны хатынның башына каплады. Көмит!..

Кофталар җыелган халыкның яртысына да җитмәде. Аңа карап берәү дә кибеттән чыгарга ашыкмады, берәү дә товарның сатылып бетүенә ышанмады. Ике хатын Әхәт янына эчкә үк үтеп керделәр, мөдирнең ике ягына басып:

— Чыгар кофталарны! Юкса, тентибез! Тапсак, җаныңны алабыз! — дип чәрелдәделәр.

— Рәхим итегез, тентегез! Прилавка асты буп-буш.

— Оста! Син безгә складыңны күрсәт.

— Склад ачкычы миндә түгел, торгта.

Хатыннар тәмамысы шашканнар иде.

— Нәрсә аның әкият сөйләгәнен тыңлап торырга?! — дип кычкырды арадан берәү.— Ватабыз да керәбез!

Бунт көчәйде, хатыннар җыйнаулашып эчкә ябырылдылар. Ишек шактый нык, иң белән генә төрткәнгә ачыла торган түгел. Калай белән тышланган, яңагы да имән агачыннан, биге эчке яктан эленгән ишек алай тиз генә бирешмәде. Бер ир кеше, каян тапкандыр, күгәреп беткән рельс кисәге күтәреп керде. Хатыннар, һау-һаулап, ур-ра кычкырып, шул тимер белән ишекне төя ашладылар. Хәл җитди төс алды. Нишләргә? Кибет телефоны ватык, поселокта яшәүчеләр телефонның ни икәнен дә белмиләр. Әхәт тиз генә Зәйтүнәне милиция чакырырга җибәрде.

— Оч! Аптека тирәсендә участковый булырга тиеш. Әхәт абый чакыра, диген. Әгәр участковыйны очратмасаң, милиция бүлегенә бар. Кибетне талыйлар, диген.

Зәйтүнәнең аягы җиңел, чабып чыгып та китте. Бер минутка: «Әллә чыккан-чыккан бу гаугалы кибеттән бөтенләй ычкыныргамы? Рәт чыкмас монда, барыбер эшләп булмас!» — дип уйлады. Бу уе тиз үтте: «Тагын Гөлчирәгә барып егылырга туры килер. Ул ни дияр? Рәхмәт әйтмәс! Көн дә-көн дә йөн кофталар кайтып тормас әле! Ни булса булыр, без күрәсен кеше күрмәс!» — дип үз-үзен юатты.

Аптека янында йөренеп торган милиция кече лейтенантына: «Талыйлар... Әхәт абый!» — дип әйтү җитте. Мондагы тамашаны күреп

бирмәлгә кече лейтенант та югалып калды. Эшнең нәрсәдә икәнен төшенгәч, билендәге каешка фасон өчен генә тагылган буш кобурасына тотынды һәм яшелле-кызыллы тавыш белән акырырга тотынды. Ишек ватып маташкан хатыннар, милиция күренүгә рельс кисәген идәнгә төшерделәр, берәүсенең аяк башына тиеп чәчрәп кан чыкты, кан күренгәч, арттагылар: «Кеше үтерәләр!» — дип чинадылар. Кеше үтергән җирдә хатын-кыз торамы, эчтәгеләр урамга чаптылар һәм халык арасына кереп юкка чыктылар. Төркем әкренләп читкә тая башлады, ишек тирәсе бушады, тамак ярып акырып торган кече лейтенант, аңына килеп, әлерәк кенә ишек катына килеп баскан арык кына, ач чырайлы бер кызчыкны беләгеннән эләктереп алды.

— Качмый тор! Качармын мин сиңа!

Беләкләре ямалган, иске кофтасына акшар тамчылары чәчрәп ябышкан кыз ычкынырга теләп тартылды, ычкына алмагач, елап җибәрде. Аягындагы зур резин итекләре чыжтырдады. Милиционер аны бая мөдир утырган табут хәтле генә бүлмәгә алып керде.

— Минем гаебем юк,— диде кыз еламсырап.

— Әһә! Ишекнең өстәге тупсасы сынган. Әгәр милиция килеп җитмәсә эш харап иде. Ватык ишек өчен кем җавап бирә?! Кибет талау гаеп түгел икән синеңчә?

— Кем талый? Мин әле генә килеп кердем.

— Күзгә карап алдашасыңмы?

— Ышанмасаң, әнә мастердан барып сора. Мин биш минут элек кенә эштән сорап чыктым. Без балалар бакчасына ремонт ясыйбыз. Ремонт беткәч, мин шунда тәрбияче булып эшкә калам. Рәхмәт мастерга, син кыз кеше, ди, бар, ди, бирәр җүнле кием эләктерә алмассыңмы, ди. Бик әйбәт кеше ул безнең Бикә апа.

Урамда яктыда йөгереп йөреп күзе тышта калган идеме, әллә кибеттәге куркыныч вакыйгалар, чак-чок бәрелгән тимер тавышлары Зәйтүнәнең аңын аударган идеме, ул бичара кызга юньләп карамады. Соңра, үз хәлен аңлата башлагач, кызның тавышы таныш кебек тоелды. Алар авылында, түбән очта кем шулай тәмле итеп, бераз сузыбрак, бераз җырлабрак сөйләшә иде соң? Бәрәч, Фәһимә ич бу, ятим кыз, әткәсе сугышта үлеп калды. Әнкәсе бер башы җиде бала тәрбияли! Фәһимә шул, Фәһимә! Әлфия белән алай дуслашып йөрмәсәләр дә, бер класста укыдылар, авылдашлар.

Ул көчен җыеп мөдир Әхәт абыйсының җиңеннән тартты, милиционер белән кызны эчтә калдырып, кибеткә чыктылар.

— Әхәт абый!

— Нәрсә бар тагын?

— Бу кызның гаебе юк. Беләм мин аны. Авылдаш ул минем.

— Беләсең?

— Җибәрегез, дим.

— Ә ватык ишек хакын кемнән түләтәбез? Әле күпмелек товар урланганын белмибез. Ревизия үткәрмичә дә булмас. Әгәр кызны ычкындырсак, гаепле булып кем кала? Синме? Син шуны телисеңме?

— Алай димим.

— Димәсәң, май кап.

— Авылдаш кыз бит. Ятим. Ярлы.

— Һи-и, авылдаш, имеш! Ярты Казан минем авылдаш. Берсенең дә китереп биргәне юк. Берсенең дә! Син, кара аны, кибеттә ныгып калсаң, авылдаш дигәнне оныт. Танысаң-танымасаң, эндәшмә! Ни пычагыма кирәк алар. Кирәк кеше белән мин сине үзем таныштырырмын.

Зәйтүнәнең тагын бер тапкыр шушы ярым караңгы кибетне, карага буялган мыеклы Әхәтне, бүгенге ыгы-зыгыларны ташлап качасы килде. Тагын икеләнде, уе ары-бире талкынды, кая барыр, каян эшен табар. Ә болай... бер уйлаганда, төшемле дә, уңайлы да урын булырга ошый. Нүжәли Әхәт абыйсы бер кофтаны аңа бирмәс? Әлфиянең туена менә

дигән бүләк булыр иде. Әллә икене үк сораргамы? Ни гомер шәһәрдә яшәп, әнкәсенә бер бүләк җибәрә алганы юк. Булмас, икене үк сорарга ярамый, каян акчасын аласың, дигәндәй...

Алар бүлмәгә борылып кергәндә, милиционер кызыйны почмакка бастырып, өстәлгә җәйгән ак кәгазенә эре хәрефләр белән яза-яза сорау ала иде.

— Кем сине склад ишеген ватарга өйрәтте? Рельсны каян табып алып кердең? Алдан ук әзерләп куйган идегезме? Иптәшләреңнең исемен ата!

Кызның мескен кыяфәтеннән, теш арасыннан калтырап чыккан һәр сүзеннән аның һич гаебе юклыгы аңлашылса да, милиционерның үз кырыгы кырык иде. Ул, бар булган сәләтен җыеп, кызга нахак бәла тагарга тырышты.

— Паспортыңны бир. Исем-фамилияңне дөрес әйттеңме икән әле.

— Фәһимә инде мин, Фатихова Фәһимә. Паспортымны үзем белән йөртмим. Безнең эш пычрак бит.

— Алдама!

— Мә, ышанмасаң кара.— Кыз иске кофтасының салынып төшкән бердәнбер кесәсен әйләндереп күрсәтте.

— Хатын-кызның документны кайда йөрткәнен беләбез без. Нука, изүеңне чиш әле.— Кыз аңа шундый нәфрәт белән карады, ни әйтергә дә белмәде, сүзен тапмады.— Әле син карышып маташасыңмы. Власть вәкиленә каршылык күрсәткән өчен мин сине!

Милиционер тимердәй каты кулы белән кызның йомры күкрәген капшап, күлмәк изүен аерып җибәрде. Кызның туып-үсеп шушы көнгә кадәр нәфис күкрәген берәүгә дә тоттырганы юк иде әле, гарьләнепме, авыртуданмы, ачы тавыш белән кычкырып җибәрде. Зөйтүнә кызны күрмәс, үзе күренмәс өчен аяк очларына басып кына кибеткә чыккан иде, авылдашының ачыргаланып кычкырганын ишетеп, конторага керде.

— Иптәш милиционер, сез бу кызны юкка азаплыйсыз! Склад ишеген ватучылар сезнең шәүләгез күренү белән чыгып сыздылар инде. Кыз — гаепсез!

Бичара Фәһимәнең урысчасы такы-токы, каушаудан сүзләрен онытып, күбрәк ым, ишарәләр белән аңлатырга тырыша, үзен юньләп тыңламауларына гаҗиз калып, илереп елый иде. Ул да Зөйтүнәне таныды, әмма аны-моны белдермәде, әнкәсе өйрәткәнне буенча, бәлага тарыганда, бүтәннәргә сылтарга да, сыенырга да ярамаганын белә иде кыз.

Әхәт Зөйтүнәгә сүзен әйтеп бетерергә ирек бирмәде, тагын төрткәләп кибет ягына алып чыкты.

— Син! Бүген эшкә урнаштың. Бүген авылдашың кибет басарга кергән. Милиционер шуны белсә, сезне күмәк гаептә санап, хәзер үк кулга алачак. Авылдашым, дип бер тының чыктымы, беттем, дигән сүз.

Бу фикер Әхәтнең башына әле генә килде һәм ул үзен шактый акыллы, законны яхшы белүче санап, Зөйтүнәнең колагын тартты.

Кече лейтенант якасын чишеп җибәрде, фуражкасын алып өстәлгә куйды, аның нык лап торып эшкә тотынганы күренеп тора иде. Әхәт Зөйтүнәгә кибет идәнен себереп чыгарырга, каерылган ишектән коелган чүпләрне җыярга, кибетне тәртипкә китерергә боерды.

— Иртәгә ачмыйбыз, әйберләрне барларга кирәк булыр! — диде.

Кече лейтенантның атна-ун көн инде күз төшәрлек беркетмә төзегәне, юньле бер җинаять тә ачканы юк иде. Милиционерның эше, нигездә, беркетмәләр саны белән бәяләнә. Яхшы исәптә йөрисең килсә, аларны күбрәк язасың. Сизенә, соңгы айда начальство аңа кырын күз белән карый башлады. Бүген аңа берничә беркетмә төзергә мөмкинлек бар иде. Авыз ачып, җебеп калды, ишек ватып ятучыларны өерләп ябып куярга иде! Юк инде, ул бу кызны ычкындырачак түгел. «Кибет складын-

ның ишеген вату... Товарларны урлау. Бунт!» Ничек шәп яңгырый. Кече лейтенант әлерәк кенә авылдан килгән татар кызларын яхшы белә, ышанучан алар, куркак, куяндай йомшак. Алардан әллә нинди балавыз сыннары ясап була! Бу кызны да бөгәчәк кече лейтенант, бер-ике көн карак кызлар, фахишәләр янында КПЗда тотса, ни язса — шуңа кул куячак.

Фәһимә ничек кенә тырышып укымасын, протоколда нәрсә язылганын аңлый алмады. Аның тизрәк моннан чыгып ычкынасы гына килде. Бер чыгып киткәч, тот син аны! Берничә көннән милиция кече лейтенанты язган беркетмә нигезендә, эшләгән җиренә, хезмәт хакыннан штраф тотып калырга боерган кәгазь килер дип башына да китермәде кыз.

Ул чыгып киткәч Әхәт җиңел сулап куйды.

— Син булмасаң, эш харап иде,— диде ул тегенең салпы ягына салам кыстырып.— Рәхмәт, син туры килгәнсең. Ватан онытмас!

Ул Зәйтүнәне, урам ягыннан ишеккә йозак эләргә кушып, чыгарып җибәрде. Ул чыгып китүгә:

— Аяк ялы,— дип, милиционерның кесәсенә утызлык акча тыкты.— Гаеп итмә, күп түгел. Җае чыккач, тагын бәхилләтермен.

Сейф тагын ачылды, бу юлы аннан тәгәрәп коньяк чыкты. Ике стаканга мөлдерәп эчемлек акты.

— Эш вакыты бит, килешеп бетәр микән?

— Тот, тот, саф һавада йөргән кешегә бара ул,— дип Әхәт калган коньякны шешәсе белән кире сейфка тыкты.— Калганы да синеке, бүгенгә артыгын бирмим. Кичкә әйләнеп кер, иркенләп утырырбыз.

Әхәтнең милиционердан тизрәк котыласы килә, ә ул китәргә җыенмый иде әле.

— Миңа ике кофта кирәк,— диде ул кинәт.— Берсе үземә, берсе хуҗага. Менә болай кирәк! — дип кулы белән бугазын кистереп, аркылы сызып күрсәтте.

«Алдашма, малай!» — диде Әхәт эченнән генә. Начальнигың алданрак киенде. Аның хакына кибеткә иртәрәк килергә мәҗбүр булдым. Тик менә акчаны китереп түләр микән? Бушлай алырга бик ярата... Шулай эче пошса да, участковыйга сөйләп тормады, нигә артыгын чәпчергә, алла сакласын, авызында сүз тормый, дигән хәбәр таралса? Усал эткә сәлам, милиционерга ришвәт бирәсең.

Яшереп калдырган байтак кофталар бар да складта. Анда участковыйны кертергә ярыймы соң? Күрми торсын әле. Уйлый торгач, Әхәт юлын тапты.

— Коля, кадерлем, үзең күреп торасың, безнең монда бөтен нәрсәнең асты-өскә килгән. Кайдадыр кысылып калган берничә кофта булырга тиеш. Нәрсә-караны рәткә салганчы, шактый вакыт узачак. Бая әйткәнемчә, кичкә таба әйләнсәң, яхшы булыр иде.

Коляны өйрәтәсе юк, беренче тапкыр гына авызы пешүе түгел, калган эшкә кар ява!

— Кабат-кабат килеп йөрергә минем вакытым юк.

— Алайса иртәгә иртәнчәк кагыл, кибет ачылыр алдыннан сугыл. Иркенләп, менә дигәннәрен сайлап куярмын.— Коляның йөз чытыклыгын күреп, Әхәт өстәп куюны кирәк тапты.— Икәү кирәк диденме әле син? Икәү дә булыр...

Милиционер чыгып китүгә, мөдир Зәйтүнәне тыкырдата башлады.

— Гөлчирә апаңнарга бар. Әйт, хәзер үк килеп җитсен. Милиционерга ышаныч юк, иртәгә киләм дип чыгып китәр дә кичкә таба күзен челәйтеп килеп тә җитәр.

Зәйтүнә аптырашта калды, Әхәт нигә аны төшке аш вакытын әрәм иттереп әллә кая йөгертә? Гөлчирә белән иртәнчәк күрештеләр, тагын ниемә кирәк булды икән? Зәйтүнәнең икеләнеп торуын мөдир үзенчә аңлады.

— Гөлчирәнең өен беләсеңдер бит? — дип сорады.
— Белә́м белүен...
— Белсәң, иренмә, зинһар, тиз генә барып кайта күр. Күрәм, күрәм, арыгансың! Көне дә артык шау-шулы булды, һаман алай булмас әле. Гөлчирә апаңны алып килсәң — бүгенгә кирәгең дә калмый. Өеңә кайтып рәхәтләнеп ял итәрсең.
Зәйтүнә чыгып китүгә, Әхәт ишекне бикләп алды. Дөньяда төрле хәлнең булуы мөмкин, товар күп сатылган көнне ялгыз калуыңны белсәләр, сәер итеп ташларга күп сорамаслар. Бу арада шомлы хәбәрләр йөри, усаллар арта бара, саклык берчакта да комачауламый.
Ул чама белән кофталар сатудан күпме акча кергәнен белә иде, шулай да санамыйча ярамый. Акча санаганны, Әхәт акчаны санарга ярата. Тәк, тәк... Баштагы берничә сатып алучыны исәпләмәгәндә, берәүгә дә вак-төяк сдача кайтарылмады. Хәзер тиенен тиенгә санап үз өлешен аерып куярга кирәк...
Акча чүмәлә булып өелде, аны тиз генә санап бетерә торган түгел иде. Әхәтне акча санарга өйрәтәсе юк. Бу эшкә маһирлыгы җитәрлек. Әүвәлге эше — ул акча өемен купюраларга аерды, прилавка өсте йөзлек, иллелек, утызлыклар белән тулды. Салават күпере булып балкый хәзер прилавка. Ярата Әхәт шул эре акчаларны! Йөзлекләрне санаганда аеруча тәм таба.
Никадәр ашыкса да Әхәт Гөлчирә белән Зәйтүнә килеп җиткәндә эшен йомгаклый алмады. Ул аларны алай тиз килеп җитәрләр дип уйламаган иде. Дөбердәү кат-кат кабатлангач кына, яраткан эшен бүлеп, люктан карарга мәҗбүр булды. Ишекне ачып аларны эчкә кертте дә:
— Син товарыңны ал да тиз үк ычкын,— диде Гөлчирәгә.— Монда тоту куркыныч.
— Ничәне калдырдың?
— Җитәрлек. Сөйләшкәнчә.
— Үзем генә күтәреп китә алырмынмы соң?
— Әнә, Зәйтүнә булышыр.
— Зәйтүнә каршы килмәсә, мин риза. Каршы килмәссең ич, Зәйтүнә?
— Кая алып барабыз соң боларны?
— Гөлчирә апаң сезгә куеп торсакмы әллә дигән иде. Карт нинди кеше? Бик кызыл авыз түгелме?
— Алай минем сүздән чыкмый торган иде дә...
— Ә-ә, әйтми торам икән! Һәрбер эштән үзеңә өлеш чыгар. Гөлчирә апаң сиңа кофталарның берсен бирер. Үзеңә иң ошаганын сайлап ал. Бушка!
— Кытыклана башласа, ирене аңлат, без сезне буш итмәбез. Өлешегезне тиярәнчә алырсыз. Яңа тормыш төзегәндә акчаның артыгы булмый.
Гөлчирә дә сүзгә катышты:
— Сеңлең белмәсә, яхшырак булыр. Ә теге йортыгызга килеп йөри торган егет, Мансурмы әле, ул берни дә белмәсен!
Зәйтүнә шунда гына үзенең нинди эшкә алынуын аңлады. Ул хәзер кофталарны күтәреп кайтачак. Аны Гөлчирә итәк астыннан кыйбат бәягә сатачак. Берсе бүләк рәвешендә аныкы булачак. Бер генә нәрсәне — ни өчен кофталарны Гөлчирәнең аларга куеп торырга теләвен генә аңламады. Уйлап-уйлап та очына чыга алмагач, бу эшне уңган, елгыр, юмарт Гөлчирә апасының чираттагы яхшылыгы дип кабул итте.
Әхәт арттагы ишектән чыгып тирә-юньне карап керде дә ике кулларына да дыңгычлап тутырылган зур-зур сумкалар тоттырып, Гөлчирә белән Зәйтүнәне озатты. Ишекне чыкканда: «Ә бу кызыең җитез генә күренә. Молодец!» — дип пышылдады.

Хатыны почта әрҗәсеннән повестканы алып кереп тоттыргач, Хургин соң дәрәҗәдә гаҗәпләнде. Имеш, аны иртәгә, сәгать тугызга райфога чакыралар! Ничек була әле алай? Повесткага: «По особо важному вопросу».— диелгән, бармас идең, бастырып тагын килеп җитәрләр, барырга туры килә.

Хургин нәкъ тугыз тулганда райфога барып керде. Налог һәм җыемнар инспекциясе начальнигының ишеген тартып карады, ишек бикле иде. Юныс булмагач, ул башка хезмәткәрләр янына кереп тә тормады. Юныстан башкаларны белми дә, белергә дә теләми. Кат-кат йөрмәскә, килгән-килгән Юнысны күреп, эшен бетереп китәргә уйлады. Шул исәп белән коридорның аргы башындагы буш урындыкларның берсенә барып утырды да Юнысның килгәнен каравылларга булды.

Коридор кешедән бушап тормый, хезмәткәрләр бүлмәдән-бүлмәгә тыз-быз йөри, райфо мөдире бүлмәсеннән чыккан бер хатын:

— Гражданин, сез байтак утырасыз, кемне дә булса көтәсез ахрысы? — дип сорады.

— Миңа Юныс Гыйльметдинович кирәк иде.

— Ул мөдир кабинетында.

— Тиз чыгар микән?

Хатын әче генә көлемсерәде, мөдир өч көнгә больничныйга чыккан иде, Юнысның хәзер һәр форсаттан файдаланырга тырышуын, кабинет бушауга, шунда кереп кәпәренеп утыруын Хургинга аңлатып тормады, кыска гына:

— Керегез, ул анда ялгызы,— диде.

Хургин ашыгып мөдир кабинетына юнәлде, бик тырышып машинкада тукылдаган секретарь кыздан, Юныс янына керергә рөхсәт сорамакчы иде, тегенең кергән-чыккан кешегә борылып карамавын чамалап, рөхсәтсез генә кабинет ишеген ачты.

— Сезне югары күтәргәннәр икән, Юныс Гыйльметдинович! Килешә, яңа урын сезгә бик килешә! Яңа урынны болай калдырырга ярамый, юарга кирәк аны, бүгеннән калмый юарга!

Юныс иренеп кенә кулын Хургинга сузды.

— Ничек килергә булдыгыз, Иосиф Данилович?

— Үзең чакырып киттең ләбаса. Җитмәсә, менә бу повестка...

Хургин повестканы күрсәтте, Юныс берни белмәгәнгә сабышты.

— Повестка калдырган иптәш белән сөйләштегезме?

— Юк. Туп-туры сезгә кердем.

— Минем кичәдән бирле аны күргәнем юк. Ул сезнең янга горфо кушуы буенча бармадымы икән?

— Мин аларны сез җибәргән дип уйладым!

— Мине бөтенләй ахмакка чыгарасыз, Иосиф Данилович. Кырык эшне кырык якка ташлап, әүвәл үзем барам, аннары кеше җибәрәм ди! Булмаганны!

— Гафу итегез, аптыраганнан әйтәм. Повестка калдырып киткән ханым кайда утыра?

— Ашыкмагыз! Җәһәннәмдә көтеп тә торырлар. Инде кергәнсез икән, әйтәм, яхшы иткәнсез! Мин алдан аларны күреп, эшнең нәрсәдә икәнен ачыклап чыгыйм әле.

Наилә иртән, эшкә килә-килешкә Юныс янына кереп, үзләре башкарган җаваплы эш турында әнәсеннән җебенә хәтле сөйләп биргән иде инде. Юныс аны күккә чөеп мактады. Әченнән генә Наиләне анда җибәрүенә үкенеп тә куйды. Болай гына, Хургин шыр җибәрсенгә озаткан иде ул Наиләне, ә теге барган да хәйләкәр конспиратор Хургинның эзенә төшеп кайткан! Клиентның да бигрәк ачык авызлысы туры килгән шул. «Моннан ары Наиләдән саграк булырга кирәк»! — дип күңеленә беркетте иртүк Юныс.

Хургин алтын теш куйган хатын хакындагы актны сорап кергәч, Наилә. һич көтмәгәндә, төпченә башлады. Аның колагына Хургин белән Юнисның яшерен эшнәлеге хакында кайбер хәбәрләр чалынган иде инде. Юнисның кашы җыерылды.

— Соңыннан, соңыннан,— диде ул. Хургинның мөдир кабинетында кан калтырап утырганын әйтмәде.

Гомумән, Наиләнең белмичә, күрмичә калуы яхшырак. Наилә яныннан чыккач та ул турыдан-туры кабинетка кайтмады, вакыт үтсен өчен, райбашкарманың гомуми бүлегенә юнәлде, андагы кыз-кыркынның күкрәген тоткалап, артларына чәпештереп йөри торгач, шактый вакыт узды. Хургин барысына кул селтәп кайтып китәргә җыенган иде, ишектә Юнис белән кара-каршы очраштылар.

— Иосиф Данилович, нык эләккәнсез, шулай саксыз кыланаларамы соң?! — Юнис чиктән тыш борчылган кеше сыман шомлы тавышлар чыгарып сүз башлады.— Налог түләп кенә котыла торган булмаган, эш тикшерү оешмаларына, судка барып җитәчәк.

— Арттырасыз!

— Арттыру, киметү хәзер прокурор кулында. Хәзер без — финанс кортлары бу акт алдында көчсез.

— Аңламыйм,— диде Хургин, борын очына асылынган тамчыны сөртеп.

— Мә, таныш. Алтын теш куйдырган хатын бөтенесен сөйләп, актка кул куйган. Безнең тарафтан ике иптәшнең имзасы ярылып ята!

Эшнең җитдилеген Юнисның шомлы тавышы гына җиткерә алмады, Хургин иренеп кенә куен кесәсеннән күзлеген алды, озаклап аның пыяласын сөртте, актны укып чыкты да үзен тыныч күрсәтергә тырышып:

— Сезнең ул хезмәткәрләрегезгә совет гражданы артыннан шымчылык итү хокукы бирелгәнме? — диде.— Беренче чиратта прокурор моментның шул ягы белән кызыксыначак! Мин шикаять итәм!

— Чәпчемә, чәпчемә! — диде усалланып Юнис.— Дулап кемнең киртә җимергәне бар? Закон безне — финанс эшчеләрен яклый! СССР Финанс министрлыгының инструкциясе райфо инспекторларына, гражданнарның яшертен керемен ачыклау буенча, шаһитлардан сорау алырга рөхсәт итә.

— Сорау алу белән сорау алуның аермасы бар!

— Анысы инде инспектор эше! Нинди әмәлләр кулланып сорау алса да, әгәр доход расланса, аңа беркем бәйләнә алмый. Беркем дә! Синең кебек законсыз эш алып барган адәмнәргә исә авыз да ачтырмыйлар. Шапылдатып биш елны ясыйлар да куялар!

— Бу башбаштаклык! Закон бозу!

— Теләсә ни дип ата. Доход турындагы Указга кырык икенче елны Калинин бабаң кул куйган.

— Сугыш чорында чыккан закон бүген дә гамәлдәме? Абсурд! Сафсата! Мин прокурорга барам!

Хургин әтәчләнеп кулларын болгаса да, тавышы торган саен йомшады, тосе үзгәрде, ул ишеккә җиткәндә, нидер исенә төшеп, кире борылды.

— Юнис Гыйльметдинович, сезнең ул инспекторыгыз мин теш куйган хатынны каян эзләп тапкан? Ничек итеп?

— Бер каян эзләп йөрмәгәннәр.— Юнис туйганчы көлеп алды.— Теш куйдырып сездән чыгып барганда тотып алганнар да «киңәшкәннәр».

— Ник аны минем янга алып кермәгәннәр?

— Иосиф Данилович,— диде яңадан кыза башлап Юнис,— сез боларны башка береүгә сөйләгез, яме.

— Ул хатын минем кардәшем, бергә керсәләр, һәммәсе урында ачыкланыр иде.

— Кардәш дип тормаган әле, башыннан азагынача сүткән.
— Хәзер нишләмәкче буласыз?
Юныс тантаналы минутның кадерен белеп, күзләре белән Хургинны тишә-тишә озак кына аның йончыган кыяфәтенә карап торды.
— Эш прокурорга китәчәк.
Юнисның байтак шуклыгын күреп белгән, четерекле генә хәлләрдән утыз-кырык сум белән котыла торган Хургин Юныска бүген дә шул алымын сайлады, шаярта, өркетә, аннары чишелеп китәр, дип уйлаган иде, аяк астында килеп чыккан бу упкынның хәтәрлеген ул хәзер генә аңлады. Юныс кына түгел инде монда, хатын-кызлар да катнашкан, ә аларның алла каргаган кавем икәнен Иосиф Данилович бик яхшы белә. Минут эчендә аның кешелек горурлыгы юкка чыкты, хәзер ул түбәнәергә дә, чыгымнар тотарга да әзер — эш прокурор кулына барып кермәсен дә аны бу бәладән йолып алсыннар!
— Юныс Гыйльметдинович,— диде ул еламсыраган тавыш белән.— Үтермәгез мине, зинһар, коткарыгыз.
— Ничек итеп?
— Сез монда прокурор да, судья да...
— Алла ук түгелме?
— Алла да! Актны сезнең кул астындагы инспекторлар төзегән. Сез абруйлы, таләпчән җитәкче...
— Хәзер мин алар янына керәм дә, Хургин күптәнге әшнәм, зинһар аны батырмагыз,— дип әйтәм. Шулаймы?
— Ул инспекторларны ничек ризалатырга?
Юныс Хургинның холкын-фигылен әз-мәз белә иде, аның белән уртак уйга, бугазына пычак салгач кына килергә мөмкин. Ул шуңарчы карышып маташачак, минут эчендә кырык төрлегә борылып төсен үзгәртәчәк. Теш куярга дигән алтынны дәүләт кибетләреннән алмый ул, анысын да аңа урлап, ерак Себер рудникларыннан китерәләр. Мондый караңгы якларга кереп тормый Юныс, сорашып та маташмый, шәһәрдә Хургин кебекләр булу аңа чат файда гына. Яшәсен, бүтәннәргә рәхәт яшәргә ирек бирсен — эләкмәсен генә! Ә монда көпә-көндез тигез җирдә абына язган. Шуның өчен җәзалый ул бүген Хургинны, шуңа күрә авызлыклый, рөхсәт булса рәхәтләнеп тотып ярыр иде: «Ачык авыз булма! Ачык авыз булма! Теләсә кем белән мөнәсәбәтләргә кермә!»
— Нишлибез? — диде Хургин.
— Ни уйларга да белмим. Биш минуттан мин председатель янына керәм.
— Сез анда озак булырсызмы?
— Нинди эш белән чакыра торгандыр бит. Һәрхәлдә, тиз генә котылып булмас.
Юныс урыныннан кузгалды. Аны беркемнең дә чакырганы юк, ул Хургинны ашыктырыр өчен генә бу хәйләне уйлап тапкан иде.
— Мин сезне кайчан күрә алам соң?
— Бер җае чыгар әле.
— Туктагыз, ашыкмагыз... Мин бераз аванс калдырыйм әле.
Ул эчке кесәсеннән йөзлек акчалар тартып чыгарды. «Шулай»,— дип уйлады Юныс, дәдәңне миңгерәүгә санап... Утызлык биреп котылырга тели! Арнаутов хатынына пальто кирәк... Көн саен Гөлчирәдән теләнү дә яхшы түгел. Бу юлы, доктор иптәш, чын бәһасен биреп кенә котыласың... Тагын бер йөзлекне өстә, икене, саранланма, чыгар, чыгар! Җаның кадерле икән, юмартлан! Арнаутов хатыны әйбәт пальто кисен... Миңа калырлык та булсын!»
Ул Хургин кулында калтырап торган мең сумны читкә этәрде:
— Сез минем башны таш капчыкка тыгарга чамалыйсыз! Тыгып куй акчаңны!
— Йөгез инде, Юныс Гыйльметдинович, беренче мәртәбә түгел бит.
Юнисны корт чактымы, юлда тәгәрәп яткан еланга бастымы, сикереп куйды.

— Аһ, син узганнарны искә төшереп маташасың икән! Шулардан файдаланмакчы буласың! Миңа ышан сиңа.

— Юныс Гыйльметдинович, зинһар! Дәшмәм! Кабер, валлаһи!

Ул мең янына тагын ике йөзлекне кушты, өчне, сумманы мең ярым иткәч кенә Юныс акча төргәген алды һәм оста гына куен кесәсенә шудырды.

Ике арада дәвам иткән дуэль аның җиңүе белән тәмамланды, екты яһүдне Юныс, хәзер җиңеле — Наиләне бәхилләтү генә калды. Юлын табар, теге ханым, чыннан да, туганы булган икән, фәлән-фәсхет, дияр. Ә Әлфия, җүләр, үз кадерен үзе белми торган чабата...

Аларның сүзләрен генә түгел, уйларын да бүлеп телефон шалтырады. Юныс трубкага бер генә сүз әйтте: «Ярар!»

— Анда мине көтәләр, Иосиф Данилович, хәзергә...

Ул, аны озата чыккач, як-ягына каранды: Хургинның килеп китүен Наилә яки Әлфия күрмәделәрме? Бәхеткә каршы, коридор буш иде. Ул кабинетка кире керде, кулларын иягенә терәп уйга чумды. Бу юлы аны иртәгә булачак комиссия утырышына чакыралар иде, райбашкарманың гомуми бүлегеннән шалтыраттылар. Утырышта хезмәт куймыйча доход алучы гражданнарның эше каралачак. Нигә ул хакта комиссия рәисе Волков дәшми тора? Ул уйланып кына Волковның телефонын җыйды. Полковникны горкомга чакырып алдылар, диде мөлаем тавыш.

Димәк, тагын бер генә юл кала, райбашкарманың гомуми бүлегендә эшләүче ханым янына сугылырга да мөмкин булса, серне аңардан алырга! Кемнәрне карарга җыенабыз да, нигә бу эшләр Юныстан яшереп эшләнә? Әллә куркыныч аның үзенә дә яныймы?..

Гомуми бүлек мөдире булып эшләүче бу хатынга Юныс биһуш. Әллә кайчаннан күзе кызып йөри. Очрашсалар, аның яныннан тиз генә аерылып китә алмый. Шулкадәр гашыйк ул аңа, ханым янында үзеннән яшьрәк, үзеннән күркәмрәк ир күрсә дә үлеп көнләшә. Хатын үзе дә төшеп калганнардан түгел, райбашкармада иң затлы киенүче, иң оста бизәнүче — ул. Өс-башы, килеш-килбәте бүтән хатыннарга һич тә охшамаган. Юнысны бер генә нәрсә тотты моңарчы: дәрәҗәсе. Белеме юк, осталыгы чикле, ичмасам мөдир булса икән. Ул чагында эш башка! Үз кабинетында — үзең баш, үзең — түш. Кыяфәт үзгәрә, тавыш көр чыга башлый, ул да мөдир, син дә мөдир. Уртак тел табарга була!

Песием булып кына Мәдинә ханым янына сугылды һәм иртәгәге утырышта ике кешенең эше тикшереләчәген белде. «Берсе ир, икенчесе хатын-кыз»,— диде Мәдинә ханым. Ныклап сорашырга, фамилияләрен белешергә һич җай чыкмады, Мәдинә ханымны чакырып алды.

## XIX

Юныс килгәндә, утырыш башланырга шактый вакыт бар иде әле. Аның бала чактан сеңгән бер гадәте бар, чакырылган урынга алданрак барырга ярата. Бу юлы да гадәтенә хыянәт итмәде, килде, керде, ашыкмыйча гына өстәлдәге кәгазьләрне тәртипкә салды. Наилә төзегән актка карап уйланып утырды. Юк, бу актны кеше күзендә, өстәлдә калдырырга ярамый. Сейфка тыкты. Тыныч күңел белән диярлек кабинеттан чыгып, икенче катка, утырышлар залына менде. Зал ачылмаган иде, ишек катында берничә кеше утыра, чакырылган кешеләр шулар булса кирәк. Юныс залның ишеген тартып карады да, бикле икәнен белгәч, тукталып карап тормады, райбашкарманың гомуми бүлегенә китте. Мәдинә ханым бер ялгызы ниндидер мөһим язулар укып утыра, йөзе җитди, хәтта ап-ак маңгаена тирән бер сыр яткан.

— Залны ачарга вакыт түгелме? — диде Юныс, үзендә җиңел генә каушау сизеп.

— Ах, Юныс абый, эш белән мавыгып мин ачарга кушарга онытып җибәргәнмен.— Ул өстәл тартмасыннан алып Юныска ачкыч сузды.— Минем дә вакытым юк, зинһар, үзегез ачып керегез инде.

Юныс аның ачкыч сузган кулын кысып тотып алды. Мәдинә ханым җитдиләнде, карашы салмакланды.

— Ой, Юныс абый... Авырттырасыз.

— Кулыгызны миңа биреп җибәрәсез, дип шатланган булам тагын...

— Анысы ук булмас! Кулымның хуҗасы бар!

— Чү, алай димәгез. Алдагысын алла белә, төрле хәл булуы бар.

Бу юлы да Юныска Мәдинә ханым янында озаклап юанырга җай чыкмады, өзлексез телефон шалтырады, мөдир ниндидер кәгазьләр эзләде, тапты һәм кемгәдер нилəрдер аңлата башлады. Юнысның күз алмаларын тәгәрәтеп күзәтүен бөтенләй онытты.

Юныс ишек катында утыручыларга бу юлы дә күз салмады, эре кыланып ишекне ачты, эчкә узды. Монда кергәч кенә сизде, ачкычтан борынны ярып хушбуй исе аңкыды. Кулына да хушбуй исе йоккан. Ешкына авызыннан аракы, коньяк исе аңкый торган Гөлчирәсе исенә төшкәч, Юныс җирәнеп, калтырап алды. «Әрәм үтте гомер. Мәдинә кебек затлы хатынга тиенә алмадым»,— дип уйлады ул.

Сәгать унике тулып килүгә карамастан, комиссия әгъзаларыннан беркем дә юк иде әле. Юнысның ялгызы, каңгырып утырасы килмәде, коридорга чыкты.

— Сез чакыру буенча килгән кешеләрме?

Читтәрәк утыручы хатын, дәшми-тынмый гына, аңа повесткасын тоттырды. Аның өстендә үзе бәйләгән йон кофта, башында читләре чигелгән батист яулык. Яулыгын татарча, тамак астыннан бәйләгән. Юныс бер хатынга, бер повесткага язылган фамилиягә карады.

— Гөлсем Шакировамы?

— Без идек.

Ир кеше дә аңа повесткасын сузды. Юныс күзен ала алмыйча, сихерләнгән сыман, тораташ катып калды.

— Танышыгызмы әллә?

Ир кеше — урам комитеты рәисе Логутченко белән көне буе янып, пешеп, үзен чакырмыйча гына комиссиягә материал әзерләнгән керосин сатучы Мифтахов иде...

— Әз-мәз таныш,— диде Юныс, каушавын сиздермәскә теләп.

Аның эрелеге шунда ук юкка чыкты, башы түбән иелде, чигәсе сызлап сулкылдарга тотынды. Ни бу? Провокациям? Әллә Юныска корылган тозакмы? Мифтаховның эшен ул үз кулы белән Арнаутовта калдырды ич? Кем аша Волков кулына килеп ирешкән бу эш? Менә ни өчен Юнысны эш башыннан алып чөйгәннәр икән! Хәзер комиссия утырышында керосинчы Мифтаховка түгел, Гыйльметдиновка җавап тотарга туры килмәс микән?! Озак уйлап торырга вакыт калмаган иде инде, бер-бер артлы комиссия әгъзалары килә башлады. Әүвәл башлап ике хатын килде. Таный аларны Юныс, әнә теге озын буйлысы — мәктәп директоры, олы яшьтәге, куллары химикатлар белән ярганалып беткәне аяк киемнәре фабрикасында эшли. Активлар, үзара гел очрашып торалар. Директор кул биреп күреште, аяк киемнәре тегүче баш кагып кына исәнләште. Әллә боларны кисәтеп куйганнармы, бик кырыс күренәләр, чырайлары сытык. Алар артыннан ук бер ир кеше килеп керде, бусы төзү трестының кадрлар бүлеге начальнигы, ул исәнләшеп тә тормады, керүгә үк китү турында кайгырта башлады.

— Озак булырбызмы икән? Тапканнар вакытын! Бүген тагын өч комиссия утырышына өлгерәсе бар.

Аңа җавап бирүче булмады, ике-өч кеше ияртеп Волков килеп керде. Ул гадәтенчә хәрби киемнән иде. Баш кагып исәнләште дә түрдәге өстәл артына кереп утырды. Комиссия әгъзаларын күздән үткәргәч, сүз башлады.

— Мин әле генә гомуми бүлектә булдым, депутат Моисеев килә алмый. Утырышны аңардан башка гына үткәрергә туры килә.

— Ничек инде килә алмый? Менә без киләбез бит! — диде кадрлар бүлеге начальнигы.

— Ашыгыч командировкага җибәргәннәр.

— Мәсьәлә бик җитди, кеше язмышын хәл итәргә туры киләчәк. Тулы составта булмагач, утырыш үткәрүнең мәгънәсе булырмы? — диде мәктәп директоры.

— Вера Михайловна, сез алай дисез дә, безгә комиссия үткәрмичә калырга һич ярамый. Безнең сүлпәнлек аркасында рәиснең күзен ачырмыйлар. Бусы бер. Икенчедән, мине дә райкомга чакырып нык кына кисәттеләр. Моисеев командировкадан кайткач очрашып сөйләшермен. Ул яхшы иптәш. Мин аңа ышанам, күмәк хәл ителгән мәсьәләгә каршы килә торган гадәте юк. Безгә, иптәшләр, бик җитди эш тапшырылган. Без үз районыбызда социалистик закончалыкны тормышка ашырырга тиешбез.

— Юныс Гыйльметдинович, белешегез әле, безгә кирәкле кешеләр килде микән? — диде Волков. Юныс аның алдына райбашкармадан җибәрелгән ике повестка китереп куйды.— Әһә, килгәннәр икән. Бик яхшы. Кемнән башлыйбыз? Ир кешедән башласак, кулайрак булыр. Кайсыгыз анда Мифтахов? Бирегә керегез!

Мифтахов керде, ишекне япмады, бусаганы атлагач та туктады, кулындагы каешланып беткән кепкасын уңыннан сулга күчерде.

— Узыгыз, уз. Курыкмагыз.

— Нигә куркыйм ди мин!

— Үһу, батыр! — дип мыскыллап кычкырды кадрлар бүлеге начальнигы.

— Ни очен чакырганны беләсезме?

Юныс эсселе-суыклы булып китте. Мифтахов бу сорауга җавап бирмәде. Волков алдына ачып салган кәгазьләрне селкеп күрсәтте.

— Безнең кулда тупланган мәгълүматларга караганда, керосин сатып керткән доходтан күз явын алырлык итеп мәһабәт сарай салып куйгансыз.

Кадрлар бүлеге начальнигы сикереп торды.

— Ә ярты Казан, намуслы эшчеләр подвалларда, ярым подвалларда, җимерек йортларда яшәп яталар! Сугыш инвалидларына торыр урын юк. Ә бу үгез... сарай салган! Йортын тартып алырга и все! — дип кычкырды ул.

Волков ишарә белән аңа утырып торырга кушты, Мифтахов аңа көлемсерәп карап торды.

— Кая барасын белмәгән килеш, ник атны камчылыйсыз? — диде ул.— Аңлатып сөйләгез, дәлилләп.

«Лагутченко эше бу! — дип уйлады Юныс.— Мифтаховны элегрәк тә саткан булган. Шикаяте райбашкармада яткан! Мәгаен, шуның этлеге»

— Каралты-кура җиткергәнсез. Келәт салгансыз, кар базы. Ихатагызны такта белән әйләндереп алгансыз. Болар һәммәсе соңгы өч-дүрт ел эчендә! Урлашмаган, читтән акча кертмәгән кеше берчакта да боларны башкарып чыга алмый.

Мифтахов белегән сызганып күрсәтте.

— Кулларыма рәхмәт. Һәммәсен үз кулларым белән эшләдем.

— Ә материал? Монда сезнең шушы еллар эчендә күпме хезмәт хакы алуыгыз теркәлгән, хәзерге бәяләрдән чыгып исәпләгәндә ул акчага эт оясы гына корырлык. Шулкадәр төзелеш материалын ходай тәгалә күктән төшерде, дип әйтергә җыенмыйсыздыр ич?

Волковның тавышы көчәя барды, Мифтахов бер мәлгә каушап калды, кадрлар бүлеге начальнигы тагын сикереп торды.

— Мал-мөлкәтен конфисковать итәргә! И все!

Мифтаховның каушап төшмәве, гомере буе эшләвен, бер сәгатькә дә тынмавын сөйләп, нидер расларга тырышуы комиссиянең бүтән әгъзаларын да кытыклады, алар да Мифтаховка карата иң югары җәза — йорт-җирен конфискацияләүне судка тапшырырга кирәк, дигән фикерне куәтләделәр. Бер Юныс кына әлегә дәшмәде.

— Укымаган кешегә рәт бармыни? Гомер буе нужа чигәм. Башыннан азагына кадәр сугышта йөрдем. Аннан кайткач, керосин кибетенә эшкә кердем. Бик озак грузчик булып эшләдем. Хәзер менә сатучы...

— Хезмәт хакына йорт-җир төзегән. Әле киенергә кирәк, ашарга, эчәргә! Урлаша, әлбәттә.

Уртак фикер сабыр Вера Михайловнаны да уятты, ул бармакларын бөкли-бөкли күршесендәге аяк киемнәре фабрикасы эшчесенә нидер исбатларга тырышты. Тегесе аның белән килешмәде, ахрысы.

— Кара эшчегә сан юк инде. Керосин кибетен әйтер идем. Исе-косы, пычраклыгы, көне буе караңгыда утыра шунда череп. Рәхәт эш белән баемаган инде!

— Күкрәк көчен кызганмасаң, акча табыла. Тота белеп тотсаң — акча җыела. Ит, май үзебезнеке. Бәрәңге, яшелчә үз бакчабызда үсә. Ашаудан артканын сатабыз. Быел бер тана, ике сарык симертеп саттым. Акча шулай җыела.

— Биредә урам комитеты рәисе иптәш Лагутченконың кызыклы бер белешмәсе бар. Поселокта нәкъ сезнең кебек бакча тотып, яшелчә үстереп, мал асрап яшәүче гаиләләр байтак икән. Эшче көчләре артыклары да бар. Йорт яңарта алмыйча, унар ел интегәләр икән алар. Дәүләттән кредит алалар, процент түлиләр. Өй сала алмыйлар. Ә сез? Дворец! Келәт! Кар базы! Койма! Капка! Әйтегез әле, йортыгыз күпмегә төште?

Волковның болай усалланганын, шушы кадәр кызганын Юныс күргәне юк иде. Мифтахов та җебеде, каушады. Ул каушаган саен комиссия әгъзалары усаллана баралар, хәзер бер минут үтәр дә, яман карар кабул ителер кебек иде.

— Аның күпмегә төшүен әйтүе кыен, материалы еллар дәвамында ваклап җыелды. Үз хезмәтем...

— Әкият сөйләүдән туктыйсызмы-юкмы?

Шулвакыт зал ишеге ачылды, анда милиция начальнигы Уваров күренде. Ул бармагын изәп Волковка нидер әйтергә маташты. Волков Мифтаховны ботарлаудан туктап, аның янына чыкты, анда шактый озак тоткарланды. Кадрлар бүлегеннән килгән иптәш төкерекләрен чәчеп аларны каргарга тотынды.

— Бу ни хәл? Ике полковник бер-берсен күрмичә тора алмыйлар, ахрысы! Бер карак өчен күпме вакыт әрәм китте! Тотарга да атарга мондый соры кортларны! Судка озатырга кирәк!

Юныс башын тиз-тиз эшләтте, Уваровның Волковка нинди йомышы төшәргә мөмкин, дип уйлады. Комиссиянең эшен бүлдереп, дәшеп ала икән, монда Уваров юк-бар артыннан йөрми булыр. Шунда гына аның зиһене ачылып китте. Уваровка Мифтаховны тикшерү хакында яңарак кына хәбәр иткәннәр дә, ул аны йолып алырга килгән!

Волков Уваров яныннан әйләнеп кергәндә, танымаслык дәрәҗәдә үзгәргән иде. Чыраен сытып, өстәлдәге кәгазьләрне бер читкәрәк этәрде дә озынча, сөякчел бармаклары белән барабан кагып алды.

— Иптәш Мифтахов! Без һаман бер-беребезне аңлап бетерә алмыйбыз.

— Мин бер нәрсәне белмим: бурны кайчан исә бер тоталар. Мине тоткан кеше юк.

— Димәк, сез йортны үзегезнең кул көче белән тапкан акчага салдык, бүтән бер тарафтан да килерем булмады, дип раслыйсыз инде?

— Булды. Ник булмасын? Авылда хатынның әти-әнисе бар иде, таза тормышлы кешеләр иде. Алар вафатыннан соң мирас калды.

— Башка балалары юк иде мени?
— Юк иде, минем хатын бердәнбер кызлары иде.
— Ул йортны монда, шәһәргә алып килдегезме.
— Саттык.
— Минем башка соравым юк,— диде Волков һич көтмәгәндә.— Сорауларыгыз булса, бирегез.

Волковтагы кискен үзгәреш комиссия әгъзаларын аңгырайтты, алар беравык исәңгерәп сүзсез утырдылар. Кадрлар бүлеге начальнигы сүз сорады.

— Минемчә, мәсьәлә ачык. Урам комитетыннан килгән хатта бик нигезле итеп, йортның нинди акчага салыну мөмкинлеге әйтелгән. Безнең коммунист иптәш Лагутченко биргән мәгълүматларга ышанмаска һич хакыбыз юк! Комитет рәисләре үз урамнарындагы халыкның ничек сулавын бик яхшы белеп торалар. Мин гражданин Мифтаховның йортын, хезмәт куймыйча алынган доходка салынган, дип исәпләргә, дигән тәкъдим кертәм.

— Тагын нинди тәкъдимнәр булыр? Безнең арада шушы фронтның зур белгече, күп еллар дәвамында дәүләт кесәсенә керүчеләрне батырларча фаш итеп килүче хөрмәтле Юныс Гыйльметдинович Гыйльметдинов бар. Ул да үз фикерен белдерсен иде.

Бөтен башлар Юныска борылды.

Юнысның уе уйга чапты, ялгана алмады, күз алдыннан байтак адәмнәрнең шәүләсе тезелеп узды. Гыйльметдинов сөйләсен дип, Уваров котыртып керттеме Волковны? Лагутченко этнең эте икән, райбашкармага язган шикаяте хакында ник бер сүз әйтсен!.. Ник яшерде икән эт җан? Нишләргә? Ни сөйләргә? Волковның йөз процент Мифтахов ягына авышуы күзгә бәрелеп тора. Димәк, шул сукмактан! Бүтәнчә юл юк!

Шушы көннәрдә генә Мифтаховны кандала урынына сытарга җыенган, шуның гәүдәсе аша үтеп чыгып данга үрләргә өметләнгән Юныс Гыйльметдинов, уңга-сулга бөгелә-сыгыла, иреннәрен ялап-ялманып, күз алмаларын як-якка тәгәрәтеп, керосинчы каракны якларга тотынды.

— Хөрмәтле иптәшләр! Безнең кулда Мифтаховның керосин урлап сатуы турында бер генә конкрет документ та, факт та юк. Ревизияләр үз вакытында үткәрелгән, тиешле кешеләр керосин кибетен күздән ычкындырмаганнар...

— Юныс Гыйльметдинович,— диде Вера Михайловна,— сезгә тагын нинди документ кирәк? Поселок халкы исеменнән урам комитеты рәисенең, Мифтахов керосин урлады, шуңа күрә баеды, дип раславы җитмимени?

— Имеш-мимешкә ышансаң, кеше үтерде дип әйтүләре бар,— диде аяк киемнәре тегүче хатын.

— Сез чыгып торыгыз әле,— диде Волков Мифтаховка,— бераздан чакырып кертербез.— Ул Мифтахов артыннан ишек ябылганны сабыр гына көтеп торды, аннан соң гына сүзен дәвам итте.

— Мин, иптәшләр, делодагы документларны кат-кат күзем аша үткәрдем. Турысын әйткәндә, анда Мифтаховны гаепләрлек бер генә факт та юк! Бары да коры сүз. Мин урам комитеты исеменнән кергән гаризаны нәтиҗәсез калдырырга тәкъдим ясыйм. Без бу өлкәдәге зур белгеч Юныс Гыйльметдиновның фикерен дә исәпкә алыйк.

— Бәхәсләшеп вакыт үткәрмик, тавышка куегыз,— диде кадрлар бүлегеннән килгән вәкил.

Тавышка куйгач, Волков тәкъдиме кабул ителде. Волков үзе коридорга чыгып, Мифтаховны чакырып кертте дә комиссия әгъзаларының карарын белдерде. Мифтахов кат-кат рәхмәт укыды, Юныс ягына борылып башын түбән иде. Райбашкарма ишеге төбендә аны полковник Уваров көтеп тора иде.

Гөлсем Шакированы чакырып кертер алдыннан, Волков кыска гына аның кем булуы турында информация ясады.

— Иптәшләр, без гамьсезләндек, сыйнфый дошман дигән сүзне онытып та барабыз. Ләкин бар алар, нәкъ шулар безнең илнең ныклыгын киметәләр, революциянең үсешенә аяк чалалар. Без бүген шундый бәндәләрнең берсе белән очрашачакбыз. Бу хатын белән башкачарак сүз алып барырга кирәк булыр! Бу хатын тарих безгә калдырган каты тамырлы чүпләрнең берсе. Моннан йолкыйсың, теге баштан килеп чыга андый чүп үләннәр. Ул — кулак кызы. Утызынчы елда эти-әнисен авылдан сөргәннәр. Бу хатын — ул вакытта яшь кыз, качып калган. Ишетәсезме, иптәшләр, качып калган! Кем белә бит, аны явыз максат белән калдырган булулары да бик ихтимал. Ул ансат кына үзенең зарарлы тамырын ерак яшереп өлгерә. Кулак калдыклары йокламый, иптәшләр! Алар гражданнар сугышында катнашып, геройлык күрсәткән ярлы крестьян егетен шул кулак кызына өйләнергә мәҗбүр итәләр. Ут белән суны бергә кушалар, иптәшләр! Кулак нәселенең эзенә төшә башлагач, алар авылны ташлап, шәһәргә күчәләр. Ләкин, иптәшләр, бүреккә салсаң да, бүре башы урманга карый. Нәселдән килгән комсызлык, байлык җыю инстинкты җай чыкканын гына көтеп тора. Үзе телэгән юл кулак кызына ире фронтка киткәч ачыла. Ире барында ул әле бик үк җәелеп китә алмый. Ни әйтсәң дә, ире безнең кеше, ярлы крестьян малае, хатынына азынырга, байлык җыярга ирек бирми, авызлыклап тота. Ире сугышка киткәч, кулак кызына юл ачыла. Иркенләп спекуляция белән шөгыльләнергә тотына. Сугыш вакытында азык-төлекнең ни бәһадә булганын барыбыз да беләбез. Бу хатын ит, май, бөрәңге, яшелчә белән сату итәргә керешә. Спекулянтның остасына әйләнә. Андыйларга халыкның тере килеш тиресен тунау берни тормый. Бу хатын — шундыйларның иң комсызы. Аның бер кешегә яхшылык эшләгәне юк. Кыскасы, аңа карата бернинди ташлама булырга тиеш түгел.

Волковның информациясе комиссия әгъзаларына ул теләгән, ул көткән тәэсирне ясамады. Халык, әгәр берәр кешене аяктан егарга туры килсә, социаль чыгыштан сүз башлануына күнегеп беткән инде. Гөлсемне коридордан мәктәп директоры Вера Михайловна алып керде.

— Сез тәҗрибәле кеше, ни өчен бирегә чакырылуыгызны белә торгансыздыр,— диде Волков һавалы гына.

Гөлсем Волков эндәшүгә үк коелып төште, тез буыннары калтырап, йөзеннән кан качты.

— Юк, белмим,— диде ул ишетелер-ишетелмәс зәгыйфь тавыш белән.

— Сез кайчаннан шәһәрдә яшисез? Кайчан күчеп килдегез?

— Качып килгән ич ул! — диде кадрлар бүлеге вәкиле.

— Күптән килдек инде, мин кияүгә чыккан елны.

— Авылда ни ошамады сезгә?

— Яшәргә мөмкинлек калмады,— диде гомерендә дә алдамаган Гөлсем, көрсенеп.— Миңа өйләнгән өчен иремне партиядән чыгардылар.

Волков, Гөлсем ялганлар, койрык болгарга тотыныр, дип уйлаган иде, дөресен ишеткәч, бер мәлгә югалып калды, тавышы йомшады.

— Ирегез кайда хәзер? Армиядә юкка чыктымы?

Гөлсем кулындагы ак кулъяулыгына төрелгән кәгазьләр арасыннан иренең фашист юлбасарлары белән барган сугышта, батырларча һәлак булуы турында фронттан җибәрелгән хатны алып күрсәтә башлаган иде, Волков аны туктатты.

— Монысы безгә мәгълүм, анысы кирәкми,— диде дорфа гына.— Комиссия әгъзаларына һични яшермичә, алдамыйча сөйләп бирегез әле, хәзер яши торган йортыгызны нинди акчага салдыгыз?

— Нинди акчага, дип... Бүрәнәләрен, такта-токтасын, идән-сайгагын ирем әзерләп калдырган иде. Үзе барында эшләтә генә алмады. Сезгә мәгълүмдерме, юктырмы, ул ат белән эшли иде. Бүрәнәләрен берәмтекләп ташыды. Юньле йортка тиенәбез, дигәндә генә каһәр суккан сугыш башланды. Егет чагында аклар тылында партизан булып йөргән егет бит ул! Бер минут тормады, үзе теләп сугышка китте. Нишлисең, кайтырга насыйп булмады үзенә. Чит-ят җирдә ятып калды...

— Елап безне ышандырмакчы буласызмы? — дип акырды кинәт Волков.— Йортны нинди акчага салдыгыз? Шуны сөйләгез безгә?!

Гөлсем бик озаклап күз яшен сөртте.

— Әүвәлге йортыбыз тактадан гына иде. Кышын-җәен стенасы аша җил өреп торды. Картым сугышка чыгып киткән елны ук бер почмагы ишелеп төште. Торырга урын булмагач, ямаштырып, сылаштырып бик күп иза чиктем. Юеш, дымлы, исле...

— Акча күктән яудымы? — дип сүз кыстырды Юныс.

— Актык сыерымны суеп саттым. Кырга шактый бәрәңге утырткан идем, минем бәхеткә, ул елны бәрәңге котырып уңды. Бер төптән чиләк-чиләк чыкты, үзе эре — беләк-беләк, үзе төмле...

— Сез ул елларда күпләп бәрәңге утырткансыз. Кемнәрне яллап эшләтә идегез? — Гөлсем сорауны аңлап бетермәгәч, Волков тагын сүзен кабатлады.— Шул кадерле җирне бер башыгыз эшкәртә алмагансыздыр инде. Булышырга ничә кеше яллый идегез?

— Нинди яллау? Нинди кеше? Улым белән икәү чиләндек. Кара көзгәчә бәрәңге алдык...

Төне буе дәфтәр тикшереп утырган Вера Михайловнаның башы түбәнгә төшеп-төшеп китә, кадрлар бүлегеннән килгән Егор Иванович кул сәгатенә карый да авыз эченнән генә сүгенә, аяк киемнәре фабрикасыннан килгән апа, олтаннарымны өстәлдә калдырган идем, урлап бетермәсәләр ярар иде, дип дөньясын оныткан Волковны кем тыңлады, кем тыңламады, тыңласаң-тыңламасаң да рәис сүзе сүз булачак, әйдә, сөйләсен. Волков комиссия әгъзаларына мөрәҗәгать итте.

— Кемдә нинди сорау бар? Юкмы? Минемчә дә шулай, сүз куертып, вакыт үткәреп торуның берәүгә дә кирәге калмады, мәсьәлә көн кебек ачык. Гражданка Шакирова, сугыш китереп чыгарган авырлыклардан ифрат оста файдаланып, азык-төлек белән спекуляция эшен нык җәелдереп җибәргән. Мин, ул яшәгән йортны, спекуляция юлы белән хәрәм акчага салынган, дип исәпләргә тәкъдим итәм. Башка тәкъдим бармы? Юк. Тавышка куям. Рәхмәт. Минем тәкъдим бер тавыштан кабул ителде.

Гөлсем сүзнең ни хакында барганын, комиссия әгъзаларының ни өчен кул күтәрүләрен аңлап та бетермәде, шулай да күңеле гаделсезлекне сизде.

— Ничек булды бу? Сез мине йортымнан куып чыгарасызмы?

— Сезнең ул йортта яшәргә хакыгыз юк,— диде Юныс, Волковка карап.— Без материалны халык судына җибәрәбез. Сезне йортыгызда калдыру-калдырмау мәсьәләсен суд хәл итә.

— Комиссиянең эше шуның белән тәмам,— диде Волков.

Зал ишегеннән чыкканда, Гөлсемнең башы әйләнеп, күзалды караңгыланды, чак кына йөзтүбән барып төшмәде. Аякларын көчкә өстерәп, почмактагы буш урындыкка барып утырды. Дөньяда күпме яшәп, аның үзен беркайчан да хәзерге минуттагы кебек япа-ялгыз итеп сизгәне юк иде. Озак утырды ул анда хәлсезләнеп, үткәннәрен бер-бер артлы күз алдыннан үткәрде. Күпме уйласа да, башыннан кичкәннәрне, бүгенге газапны сөйләп кайгысын бушатырлык ышанычлы кешесен таба алмады. Ата-анасы алар белән олыларча аралашырга да өлгерә алмады. Ата-ана Гөлсемне баласытып килделәр, берчакта да ачылып китеп күңелләрен бушатмадылар. Ире белән дә күпме генә яшәде. Иңне-иңгә терәп бала-казаларны артта калдырабыз, дигәндә, ул һәлак булды.

Ялгызлыкны авыр кичерде Гөлсем, өе кырык тирәүле, җылыга сара-
булса да, Ленинградтан эвакуацияләнгән гаиләне сыендырды. Фатир
хакы өчен бер тиен сорамады, бушлай ашатты, яшелчәсен, бәрәңгесен
җәлләмәде, өс-баш киемнәрен бүлеште. Өч елга якын бер язмыш
белән, бер гаилә булып яшәделәр. Киткән чакта Яков Вульфсон Гөл-
семне кочаклап елады:

— Дүрт балам синең аркада гына исән калды, чир-чорны, ачлыкны
белмәделәр,— диде.

Алардан да күптән хәбәр-хәтер юк...

Улы, улы... Күз карасы... Иренең төсе, мәңгелек авыр хатирәсе
сөенече. Чакыра ул, котыл Казаннан,— ди. Бик чыгып китәр иде Гөл-
сем, бер көн тормас иде, килене марҗа. Марҗа килен белән кай-
наналар болай да тыныша алмыйлар, аның мисалын Гөлсем белгән-
күргәннәр авызыннан мең ишеткән. Авылда үскән татар марҗа килен
түренә барып керә алмый шул, ходай сакласын, стрәпкә булып та
барасы килмәде. Серен бирәүгә дә ача алмады Гөлсем, ире еш-еш
кына: «Без телне тыеп яшәргә яратылган халык»,— дип искәртеп кил-
де, үзенең илдән сөрелгән кулак кызы булуы турында хәтта бердәнбер
улына да чишмәде.

Тукта, нигә әле ул бүгенге вакыйганы шул тиклем авыр кичерә? Тегe
чакта, җитеп килгән кыз чагында, ата-анасыннан аерылып калганда
болай ук авыр булмаган иде. Әллә онытылган гынамы? Яшьлек белән
кайгысы да үзәккә үтә алмаганмы? Кинәт, дөнья малы була да ул, бетә
дә ул, дигән җыр исенә төште. Чәнчелеп китсен йорты! Ихатасын
җимерделәр — түзде. Баш исән булсын! Башы исән булса — урамда
калдырмаслар. Ипи-тозлык акчасы бар. Күпме авылдашлары шушы
гомер эчендә аннан игелек күрде? Һи-и, бихисап! Кайсысына акчалата,
кайсысына киңәш-табыш белән ярдәм итте Гөлсем. Миһербанлы авыл-
дашларыннан берәрсе сыендырмасмы аны? Бала карап булса да то-
рыр, аш-су пешерер. Иптәшкә бәләкәй Равиле бар ич әле аның! Ул
балага шундый нык ияләште, хәзер аңардан башка яшәүне күз алдына
да китерми.

Җитәр! Монда кагаеп утырудан файда юк! Ул җайга гына атлап
баскычтан аскы катка төште, баш әйләнгәнен тыя алмыйча, күзләрен
чытырдатып йомып, бер минут чамасы ишек катында басып торды. Шул
чагында аны кемдер килеп кочаклады. Күзен ачып җибәрсә, аны
кочаклап Әлфия елап тора.

— И Гөлсем апа, и Гөлсем апа, нишләттеләр алар сине? Сезнең
яннан чыккач Юныс Гыйльметдинович, карчыкны йортсыз калдырдык,
комиссия аша үткән материалны судның расламый калганы юк әле, дип
мактанып сөйләде. Йортсыз-җирсез калдыралар бит үзеңне! Алданрак
белгән булсак, бер-бер чарасын күрер идек тә...

Янында җаны йомшак, яшь коеп торган кеше барында, Гөлсем
җебеп тора алмый инде, ул тиз-тиз күз яшьләрен киптерде, елмая
төшеп Әлфияне кочаклады.

— Баш исән булсын, кызым. Намусың саф булсын. Исән кеше,
гөнаһларга батмаган булса, чыгар юлын ничек тә таба. Ходай сәламәт-
легемне алып егып ташламасын. Җан биргәнгә юнен бирер әле. Елама,
кызым!

## XX

Ниһаять, Мансур кандидатлык диссертациясен яклады, аның хез-
мәтен бер тавыштан яхшы дип таптылар. Гыйльми совет әгъзалары
Мондый эш ВАКта да тоткарланмас, бик тиз расланып кайтыр, дип
өметләндерделәр. Институт ашханәсенең галимнәр генә йөри торган
нәни бүлмәсендә бәләкәй генә мәҗлес булып узды.

Диссертация яклау Мансур өчен зур бер киртә иде. Гыйльми утырышның икенче көнендә үк үзенең киләчәге турында ачыграк уйлый башлады, алдагы адымнарын ышанычлырак итеп күрде. Үз исеме тирәсендә кара көчләрнең казынуын күреп шиккә төшкән егет, шул ук көчләр аның фән юлына да аркылы ятырлар, дип уйлаган иде. Яклауның читләр тыгылмыйча гына, тавышсыз-тынсыз үтүе аны бөтенчәрәк уйларга да мәҗбүр итте. Әйе, аның яшьтәшләре күптән башлы-күзле булып бетте, икешәр-өчәр бала үстерәләр. Буйдак булып тагын күпме йөрергә мөмкин? Фатир юк, киләчәккә ныклы ышаныч юк, дип, сынықка сылтау табып, күпме йөрергә мөмкин? Әлфия мең кат риза, өйләнергә дигәч өйләнергә, әлегә ничек тә тулай торактагы кысан бүлмәгә дә сыярлар. Диссертациясе расланып кайтса, кафедрага эшкә урнашса, фатиры да тиздән булыр.

Соңгы көннәрдә алар Әлфия белән көн саен очрашалар. Мансур аны эшеннән каршылый, ермак эчендәге тату йортка озатып куя. Озату кайчагында ярты төнгәчә сузыла. Башта ул Әлфияне өенә кайтара, аннары Мансурны Әлфия трамвайга хәтле озата. Караңгы ермак эчендә ялгызына куркыныч дип егет тагын аңа ияреп китә. Бер-берсен күңелле озатышып йөри торгач, төн уртасы җитә.

Ниләр турында гына сөйләшмәделәр алар шул минутларда, мәгәр Мансурның өйләнешү турында кистереп сүз әйтергә һаман йөрәге җитмәде. Сазаган егетләр үтә җитди булалар, алар кыз язмышын үзенеке итәргә күп очракта кыймыйлар. Абый белән сеңел шикелле йөриләр дә йөриләр, Әлфия иске гадәт буенча Мансурга һаман «абый» дип дәшә, үз чиратында егет тә кызга «сеңлем» ди.

Кичләрнең берсендә, ай нурлары дөньяны бизәп-яктыртып торганда, ул кызны кочагына алып суырып үпте дә:

— Син минекеме? Минеке буласың киләме? — дип сорады.

— Килә,— диде кыз.

Бернинди икеләнүсез әйтелгән шушы сүз аның күңелен күтәреп җибәрде.

— Язылышыйк та, тормыш корып җибәрик, Әлфия.

— Син бик тиз...

— Тагын күпме йөрергә була? — дип көлеп җибәрде Мансур.

— Иң элек мин әнидән рөхсәт алырга тиеш.

— Ул рөхсәт бирмәсә?

— Әнинең хәер-фатихасын алмыйча, мин кияүгә чыкмыйм, Мансур абый.

Әлфиянең назланып, үзенә тулы ышаныч белән сөйләшүе Мансурның күңелен тагын да ныграк җилкетте.

— Әйдә, икебезнең исемнән хат язабыз!

— Алай гына булмый, икәүләшеп авылга, әни янына кайтабыз.

Авыл ерак та түгел-түгелен, юллар өзек чак, октябрь азагы. Өзлексез диярлек яңгыр сибәли. Җәяү ничек кайтып керәсең? Тездән лай ерып, пычракка батып, өйләнәм, дип кайтып керсәң, кыз әнкәсенең түгел, авыл мәзмайларының котын алырсың. Бер танышы бар барын, Рәдиф исемле егет. Ну ялындырырга ярата да инде. Ике көн ялварды Мансур, ахыр чиктә Рәдифне күндерде, алар шимбә көнне, эштән соң, кич кырын юлга чыктылар. Мансур белән Әлфия артта утырдылар. «Победа» күндәм генә кузгалып китте.

Бу юлдан гомер-гомергә атлылар үтеп йөргән, арба тәгәрмәчләре тәгәрәгән, җәяүлеләр юлны таптаган. Әле ярый, урыны-урыны белән юлга таш җәелгән. Ташны, колхозлашу башлангач, һәр хуҗалыкка җан башыннан бүлеп бирәп мәҗбүри җәйдерткәннәр. Кайбер хуҗалар җирәнә җиткереп җәйгәннәр, тырышканнар, андый кишәрлекләрдә машина гөрләп кенә бара.

Шәһәрдән чыгып, шактый баргач, урман кырыйлап бер яклап тезе леп утырган кечкенә генә авылга барып керделәр. Алар монда, егер менче еллар азагында, Гөреч юлы ягыннан күчеп утырганнар. Һә поселокны «Чыңгыз» дип атаганнар. Татар авылына шундый дәһшәтл исемне кем биргән, диген.

Авылны чыгуга Казансу буйлап дистәләрчә чакрымнарга сузылга урман башлана. Иленнән, җиреннән рәхимсез рәвештә куылган Каза ханлыгы чоры шушы карурманга ышыкланып, аңа сыенып илбасарла белән көрәш алып барган. Көчләр тигез булмаган, әлбәттә. Татарла елганың аръягына, Казансуның башына таба чигенгәннәр. Шулай д татар авылы исемнәре хәзергәчә сакланып калган: Дәрвишләр, Киндер ле, Колсәет, Чыпчык...

Татарның нәселен тәмам корыту мөмкин булмаган, алар, җиңел сәләр дә, өмет өзмәгәннәр, Казансуның уң як ярларына күченгәннәр, урман алларында яңа тормыш башлап җибәргәннәр. Хәзер бу тирәлә дә урманнар калмаган, иген басуларына тарыккан татарлар урманна ны кисеп, яндырып бетергәннәр.

Ниһаять, күп азаплана торгач, төн уртасында гына авылга кайты җиттеләр. Урамнар буп-буш, тып-тын, бер якта да ут-мазар, җан иясе күренми. Машина мәчет каршындагы салам түбәле тәбәнәк йорт кар шысына килеп туктады. Әлфиянең әтисе түбәне такта белән ябу турын да хыялланып йөргән иде йөрүен, җитешә алмады. Мансур салам түбәле йорттан кәләш алуына борчылмасмы икән? Мәчетнең дә исеме генә мәчет. Манарасын сугыш алдыннан кисеп төшергәннәр иде, шун нан бирле түбәсеннән язгы сулар агып, череп утыра. Алай да әлегә ул авылда иң күркәм бина. Хәзер анда башлангыч мәктәп. Халык аны барыбер искечә «мәчет» дип атап йөртә. Әлфия дүрт классны мәчетк йөреп тәмамлады. Мәчет-мәктәп аның күңелендә изге бер урын булы уелып калган. Ул машинадан төшкәч шул якка да карап өлгерде.

Яңгыр суы эчеп авырайган капка интектереп кенә ачылды. Белә Әлфия, коймалары, капкалары искергән аларның. Капка баганаларына терәү куелган. Мотор тавышынамы, ут яктысы чамалапмы өйдә ут элделәр. Тонык яктылыкта ишегалдын күзәткән кеше башлары күрен де.

— Әни, әни, ач ишекне, без кайттык.

Кызы янындагы озын ят кешене күреп, Хәбирә телсез-авызсыз калды, Мансур янына Рәдиф тә килеп баскач, тәмам һушсыз булды.

Өйгә сүзсез генә керделәр, пычранган аяк киемнәрен дә ишек катында сөйләшмичә генә салдылар. Буй җиткән сеңлесе Сәҗидә, ят ир-атны күреп, мич арасына кереп китте, каушап сулы комганны аудар ды, ул яктан су саркып килеп чыкты. Әле һаман берни аңлый алмаган ике малай, корама юрган белән авызларын каплап, сәке түреннән ялт-йолт карандылар. Ниһаять, Хәбирә телгә килде.

— Бу ни тамаша, балалар? Мондый көндә яхшы хуҗа этен дә куып чыгармый. Бер-бер күңелсезлек булмагандыр бит? Нишләп йөрүегез?

— Әни, бәгырем, ачулана күрмә. Бик мөһим эш белән кайттык. Бераз сулу алыйк та һәммәсен сөйләп бирербез.

Әлфия югалып калмады. Мансур белән Рәдифнең өске киемнәрен салдырып, өйалдына кибәргә элде. Рәдиф ул арада машинаның хәлен белергә чыгып китте, Мансур да аңа иярде.

— Кызым, балам, нинди ирләр ияртеп кайттың син? — диде Хәби рә, Әлфияне кабаландырып. Аулакта кызның серен белергә ашыга иде ана. Аның шомырт кара күзләре мөлдерәмә булып, менә тамам, менә тамам, дип торалар иде. Әнисе өстендәге терсәкләре ямалган иске күлмәкне күреп, Әлфиянең йөрәге әрнеде. Ул тиз генә үзе белән өйгә ук кергән төенчекне чишеп, аннан яшел бизәкле штапель күлмәк чыгарды һәм әнисенә тоттырды. Хәбирә күлмәкне ике кулы белән күкрәгенә кысып торататш булып катып калды. Әлфия төенчектән әйбер-кара чыгаруын дәвам иттерде.

— Сажидәгә яулык,— диде ул, ефәк яулыкны сеңлесенә биреп.

Шәһәр бүләгеннән коры калмыйк тагын, дип, энекәшләре дә сәкедән төштеләр. Әлфия аларның икесенә дә чиратлатып брезент туфлялар кигертте. Малайларның авызлары колакка җитте. Күптән, бик күптән бу йортка мондый шатлык иңгәне юк иде.

Әллә юлда туңудан, әллә дулкынланудан Әлфиянең бөтен гәүдәсе ут булып яна иде. Ул әнисенең беленнән кочып алды да, тыела алмыйча елап җибәрде:

— Әнием, кадерлем, ризалык бирерсең микән, мин кияүгә чыгам.

— Күңелем сизгән иде аны... Нинди кеше?

— Син безгә бәхет телә. Фатихаңны бир.

— Ата-анасы бармы?

— Ятим, беркеме дә юк.

— Кызым, ялгышмыйсыңмы? Ятим-ялпы белән гомер итүе авыр бит. Ата-анасыз үскән бала юньле булырмы?

— Моңарчы бик күп ярдәме тиде аның миңа. Бик акыллы егет.

Өйгә Мансур килеп керде. Ул, ана белән кыз арасында сүзнең ни турында барганлыгын аңлап, аларга якынрак килде дә Әлфиянең култыгыннан алды. Әле Рәдифне кияү егете дип уйлаган Хәбирә имәнеп китте. Мансур аңа озак уйларга ирек бирмәде.

— Безгә фатиха бирегез, Хәбирә апа,— диде, түбәнчелек белән. Без бер-беребезне яратабыз. Ни күрсәк тә — икәү бергә күрик. Һәрхәлдә ким-хур булмабыз.

Хәбирә Мансурга түгел, Әлфиягә карап эндәште.

— Апаңнар ни хәлдә? Җизнәң чирләмиме? Икесенең берсе кайткан булса да, сөйләшү җиңелрәк булыр иде. Ни әйтим соң? Кызым урамнан табып алып кайтмагандыр инде. Балаларым тәрбияле. Ярлы булсак та. Күңелегез дөрес икән, миннән хәер-фатиха! Бәхетле булыгыз!

Ул арада самавыр гөжләп кайнап чыкты, тыштан Рәдиф керде. Арага чит кеше кушылу белән әңгәмә читкәрәк тартылды, авыл хәлләрен, туган-тумачаларны сораштыра-сораштыра майлап, баллап чәй эчтеләр. Май савыты бик бәләкәй, бал савыты бик тәбәнәк иде.

— Ярар, балалар,— диде Хәбирә,— уйламыйча гына, ашыгып эшләнә торган эш түгел. Һәр кешенең үз акылы бар, иртәгә актыккы сүземне әйтермен.

Хәбирә төне буе йокламады. Ни хәл итсен соң, балалар үсәләр дә китеп югалалар. Менә икенчесен озатачак. Болай барса, авылда җан иясе калмаячак. Тегәрҗеп урам бетте, йорт тәрәзәләренә аркылыторкылы такта кадакланган. Чүлмәк атавында утыз йорттан нибарысы сигезендә кеше яши. Калганнары бикле. Алар, очы белән, яңа төзелгән Калининград өлкәсенә күчеп киттеләр. Дөрес булса, бөтенесен сыерлы иткәннәр, ди.

Аңа да туган-үскән җирен ташлап китәргә туры килер микәнни? Бар өмете Әлфиядә иде Хәбирәнең. Укырга керә алмавына да сөенгән иде. Арьякның Озын Мәрьям белән сөйләшеп тә йөриләр иде. Аның бердәнбер улы бар. Егет солдат хезмәтен тутырып кайткач, ничек тә Әлфия белән икесен кавыштырырга чамалаганнар иде. Галәү менә дигән егет, күз алдында үскән, эчми, тартмый, телле-тешле түгел. Озын Мәрьямнең әйтүенә караганда, егет Әлфиягә хат та язган булырга тиеш иде. Зәйтүнәләрнең адресын да кереп алган иде алуын. Хат язмадымы, әллә язып та Әлфиясе санга сукмадымы? Артык нык чаяланганга охшый Әлфиясе, телгә дә остарган. Һай, бу шәһәр дигәннәрен! Аждаһа инде, аждаһа! Бер дә ким түгел, авыл яшьләрен сихерләп бүксәсенә суырып кына тора.

Иртән, Әлфия су җылытып, кием-салымнарны юыштырып йөргән арада, Хәбирә Мансурга берничә сорау бирде.

— Синең, улым, яшең бар сыман күренәсең. Өйләнгән кешеме син? Элеккеге хатыныңда бала-чагаң юкмы?

Гаебе булмаса да, Мансур бурлаттай кызарды.

— Яшем бар анысы, Хәбирә апа. Мәгәр хатын-кыз белән шаярганым булмады. Әлфия минем беренче мәхәббәтем.

— Ефәк кебек кызның башын ашарга гына йөрмисеңме диюем.

— Йөрәгемне ярып күрсәтим, дисәм... Ышаныгыз, Хәбирә апа.

— Кала егетенә авыл кызы тиң булырмы, дим.

— Мин дә авыл егете ләбаса! Якташлар да әле без!

Мансурга кыскача гына тормышы, көнкүреше, ятимлектә үсүе турында сөйләп бирергә туры килде. Бер нәрсәне яшерде — утызынчы елда илдән сөрелүләрен әйтмәде. Курыкты. Авыл хатыны булса да Хәбирәнең колагына да төрле шомлы хәбәрләр кермичә калмагандыр, кызымны кулак баласына бирмим, дип кырт кисәр дә куяр. Хәбирә дә ул җәһәттән кызыксынып маташмады. Мансурның коммунист икәнен белгәч, чырае ачылып киткәндәй булды.

Ана бит, бер башлагач, ярты юлда туктап калмады Хәбирә:

— Өйләнүен өйләнәсең, кәләш алып кайтырлык торыр җирең бармы соң синең? — дип сорады.

— Кечкенәрәк бер бүлмәм бар. Хәзергә сыярбыз.

— Шатлыкта сыярсыз, кайгы-хәсрәт килсә, ничек түзәрсез? Дөньяда бар да була бит.

Өй арасында тыз-быз эшләп йөргән Әлфиянең колагы әнисе белән Мансур янында иде, бераздан ул да сүзгә кушылды.

— Сез килешеп тә киттегез ахрысы,— диде, ул егеткә күз кысып.— Сүзегез һич бетми.

Алар Хәбирәне икесе ике яктан кочаклап алдылар. Ул кайсы якка карарга белмичә аптырады.

— Һай-ай, кызым шул тиклем үзгәрер дип башыма да китергәнем юк иде. И бу шәһәр дигәннәрең! Харап итә безнең авыл халкын. Хәер, дөньясы шулай үзгәрә торгандыр, мөгаен. Язмыштан узмыш юк. Миннән дога сезгә, балалар.

Шушы ике-өч сүзне ишетер өчен кайткан яшь кияү белән яшь кәләш сөенечләреннән нишләргә белмәделәр.

Хәбирә кичтән камыр куйган икән, кунакларын иртәнге чәйдә кабартма белән сыйлады. Зур мичтә, утлы күмер катында пешкән кабартманы, күңелләре күтәрелгән яшьләр урдылар гына. Әлфиянең энеләре мичтән чыккан кабартманы ташый-ташый тиргә баттылар. Ниһаять, кече энекәше түзмәде.

— Әни кабартма башка юк, дияргә кушты,— дип ычкындырды.

Кунаклар егыла-егыла көлделәр.

Чәйдән соң ук Рәдиф кайту ягын кайгыртты.

— Миңа иртәгә таңнан эшкә,— диде ул кистереп.

Җавап көтеп тормады, ишегалдына чыгып машинасын юлга әзерли башлады.

— Бик ашыгыч була ич бу! Ут капкандай кая ашыгасыз? Без бит әле иң кирәген сөйләшмәдек. Туй турында берни әйтмәдегез?

— Туй?! — дип, Мансур белән Әлфия бер-берсенә караштылар.

— Күрәсез, минем туй итәрлек хәлем юк. Иң яраткан кызымны туйсыз бирәсем дә килми. Нишләрбез икән?

— Туйны үзебез хәл итәрбез, әни. Син борчыла күрмә.

— Дүрт авыз белән колхозга карап торабыз, бүтән килеребез юк. Әле ярый, шөкер, быел менә сугыш беткәннән соң беренче мәртәбә хезмәт көненә икешәр йөз граммнан бодай өләштеләр.— Хәбирә кабартмадан бушаган тәлинкәләргә карап көрсенеп куйды.— Елның-елына кысыр таякка эшләдек шул.

— Без икебез дә эшлибез,— диде Мансур.— Туй итәрлек кенә мая табарбыз. Шулай бит, Әлфия?

— Ата-анадан калган йола бар, никахын булса да укытыгыз.

— Никах? — Мансур белән Әлфия тагын бер-берсенә карашып шаркылдадылар.

Хөбирәнең чак кына күңеле кителде. Ай-һай, укытып йөрерләр микән хәзерге яшьләр? Укытсалар, кайчан укыталар әле. Нигә моннан ук никахлы итеп җибәрмәскә? Ашыгыч була булуын, мәгәр йолача була, дин кушканча була. Кунаклар машинага утыргалаганчы, калган камырыннан кабартма пешереп, чәен яңартып, Фәйзерахман картны дәшеп тә алды. Күршедә генә ич. Фәйзерахман теркелдәп кереп тә җитте.

Утыз җиденче елда авылның указлы мулласын себергә сөрделәр, авылда дини йолаларны үтәргә кеше калмады. Мулла өстеннән кәгазь язучылар арасында Фәйзерахман да бар икән, дигән сүзләр йөрде. Дин кануннарының бөтен нечкәлекләрен белеп бетермәсә дә, муллалыкны иплэп-өкренләп әнә шул Фәйзерахман үз өстенә алды. Әзерлеге югын белсәләр дә, киртәсенә керсә ярар, дип, балага исем кушарга, мәет күмәргә, никах укырга аны чакырдылар. Тора-бара ул бу эшкә жаныгәне белән бирелде, йорт эшләреннән читләште, теле шомарды.

Беркемнән дә садаканы сорап алмый, бирсәләр, баш та тартмый, күпме бирсәләр, шуңа риза. Колактан-колакка гына Фәйзерахманның иман аты да таралып килә иде. Имеш, ул үзенең кайда нинди йола үтәвен, шул уңай белән халык арасында нинди сүзләр йөрүен бер дәфтәргә теркәп бара икән дә, ул язганнар белән районда да, Казанда да гел кызыксынып торалар икән.

Буласы булды, налог түләгәннән калган соңгы өч тәңкәсен биреп Хәбирә Әлфия белән Мансурга никах укытты.

Никах укытканда кыз белән егет шул мәҗлестә булып ризалыкларын бирергә тиешләр. Балаларның ата-аналарының да ризалыгы кирәк. Фәйзерахман бу нечкәлекләрне искә төшереп тормады, колагына учын куя-куя Мансурның исемен, атасының исемен кат-кат тәкрарлатты...

Әлфия Мансурның бәләкәй бүлмәсенә күчеп килде. Хәбирә биреп җибәргән мендәр-ястыклардан бүлмә тагын да тараеп, кашагалардан, түрләмәләрдән тагын да матураеп калды. Үзләренчә нәни генә, җылы гына туй да үткәрделәр, туйларына Гөлсемне, Хәлим белән Зәйтүнәне, Мансур иптәшләреннән өч кеше чакырдылар. Яңа гаилә зур өметләр белән тату-дус яши башлады.

Туйлар үтеп ай уздымы икән, Мансурны институт парткомына чакырдылар. Чакыруны ишеткәч тә йөрәге жу итеп куйды, аягы бер дә тартмады. Партком секретаре беренче сүздән үк аның гаилә хәле белән кызыксынды. Кайчан, кемгә өйләнүен сорады.

— Авылга да кайтып килгәнсез икән,— диде ул серле итеп.— Мансур аңа: «Минем авылда булуымда кемнең ни эше бар?» — дип әйтмәкче иде, тыелып калды.— Сер булмаса, әйтегез әле, ник кайттыгыз авылга?

Мансур бу юлы чыдамлыгын югалтты.

— Сез мине сорау алырга чакырдыгызмы, бүтәнгәме? Моны ничек аңларга?

— Теләсә ничек аңлагыз. Без сезнең авылга ник кайтуыгызны белергә телибез.

— Кем инде — без?

— Институт парткомы.

Мансур саклык кирәклеген онытып:

— Җыегыз алайса партком членнарын! Шунда әйтермен ник кайтуымны! — дип кычкырып җибәрде.

— Әһә, песи тырнакларын күрсәтә башлады,— диде секретарь. Икәүдән-икәү генә сөйләшеп, гаебегезне үз генә булса да йомшартырга теләгән идем.

Нинди гаеп? Ни сөйли бу секретарь?!

— Нинди гаеп чокып чыгардыгыз инде сез, ягъни мәсәлән?

Партком секретаре өч йозаклы тимер сейфын ачып, иң өске катта яткан хат букчасын тартып чыгарды, зур саклык белән ачты һәм

шакмаклы дәфтәр битенә эре хәрефләр белән язылган хатны Мансурга сузды. Хат шактый озын иде. Олы кеше әйтеп торып бала кулы белән язылганга охшый. Мансурның моннан чирек гасыр элек авылдан куылган эре кулак баласы булуына аерата басым ясалган иде хатта. Әтиәнисенең эзсез югалуын язганнар. Мансурның соргеннән ничек качып кайтуы белән кат-кат кызыксынганнар.

— Йә, ничек? — диде партком секретаре, тонык күзләре белән Мансурга текәлеп.

— Сез шушы ялганнарга ышанасызмы?

— Ышанмаска хакым юк. Хатка кем кул куйганын күрәсезме?

Мансур шул чакта гына игътибар итте — хатка колхозның партоешма секретаре Нуриев кул куйган иде.

— Дин кануннарын өстен чыгарып, авыл халкына агитация ясап никах укытуыгызны ничек аңлатасыз?

Мансур бу юлы түзмәде, көлеп җибәрде.

— Әгәр никах укытырга теләсәм, мин монда, шәһәрдә законлы мулладан укыта ала идем. Авылда мулла калмаган, себергә соргәннәр.

— Әһә, әле сез дин әһелләрен сөрүне дә хуплап бетермисез икән. Хәер, үзе дә сорелгән кулак баласыннан ни көтеп була?!

Мансур тыелырга тырышты, дәшмәде.

— Партиягә кергәндә социаль чыгышыңны яшерүегезне ничек аңлатасыз?

— Ятим үстем. Ата-анамның кем булуы турында шикләнмәдем. Мин белгәндә, әтинең аягыннан ыштыр-чабата төшмәде. Җәен-кышын ат урынына эшләде.

— Ни өчен раскулачивать иттеләр соң аны?

— Хата булган. Илдә аннан да зуррак хаталар барлыгы хакында хәзер ачыла башлады ич.

Партком секретаре астына ут капкандай сикереп торды.

— Нәҗес! Череп таралган кулак калдыгы! Әллә нәрсәләр уйлап чыгарып, бөек юлбашчыбыз тормышка үткәргән чараларга кара ягасызмы? Әз-мәз йомшаклык биргәннәр икән, кулак-мулла балалары хәзер баш калкыталар!

— Сез тирәнгә кердегез,— диде Мансур,— мин ул хакта сезнең белән сүз көрәштерергә җыенмыйм.

— Партиягә кереп оялаган бит әле!

— Партиягә фронтта, дошман чолганышын өзәргә, дигән һөҗүмгә күтәрелгәндә кердем. Әгәр шуны «оялау» дип атыйсыз икән, мин сезнең белән сөйләшеп тә тормыйм.

— Сөйләшерсез! Авызыгызны ачарбыз да, ябарбыз да!

Чәче чаларган, илле яшьләр тирәсендәге бу сабыр кешене Мансур моңарчы хөрмәт итеп йөри иде. Сөйләүләренә караганда, ул авыр торм··ш юлы үткән. Яшьлегендә Донбасс шахталарында күмер чапкан. Сәләтле егетне укырга җибәргәннәр. Утызны узганда гына институт тәмамлаган. Миначев тырышып укыган. Сәләтле дә булган. Ярлы баласы булуын искә алып, аны институтта эшкә калдырганнар. Социаль чыгыш мәсьәләсендә ул бернинди килешүне белми торган аяусыз иде. Кеше таза тормышлы гаиләдән чыккан икән — бетте, ул гомер-гомергә Миначевның дошманына әйләнә. Секретарь Мансур белән байтактан кызыксына башлаган иде инде.

Институт җитәкчеләреннән ректорның, профессорларның Миначев каршысында аяк очларына гына басып йөргәнен күреп-белеп торган Мансур, бу аның югары абруеннан килә, дип исәпли иде. Секретарьның «авыр тормыш юлының» байтак сәхифәләрен белеп бетерми иде әле егет. Утыз җиденче елда, халык дошманнарын һәр җирдә фаш итү компаниясендә, ул үзен иң ышанычлы кеше итеп танытты. Миначев язып кул куйган характеристикаларга таянып, байтак профессорларның гомере өзелде. Дөнья үзгәрсә дә, Миначев үзгәрмәде. Әле янарак

кына партиянең егерменче съезды булып узды. Ләкин Миначев кебекләр өчен партия — бер, аның тоткан юлы изге, Сталин дөнья халыкларының бөек юлбашчысы иде.

Тимерне кызуында сугарга ашыкты Миначев, белмәссең, көтелмәгән хәлләр килеп чыгуы бар, бирешмәскә кирәк, бирешмәскә. Дөнья Миначевлар барын онытырга тиеш түгел. Икенче көнне ашыгыч бюро җыеп, Мансурны партиядән чыгардылар. Гомуми җыелыш бер тавыштан диярлек бюро карарын раслады. Җыелышта бер-ике кеше каршы килеп, сүз әйтергә маташканнар иде, Миначевтан шүрләп, алар да бюро карарын хуплап кул күтәрделәр.

Мансур төн йокысын югалтты. Атна эчендә, элеп киптергән кебек ябыгып, күзләре эчкә батты. Бәла ялгыз килми, берсе өстенә икенчесе өстәлә. Аны эштән чыгарып, тулай торактагы бүлмәдән дә кудылар. Алар вакытлыча Хәлим белән Зәйтүнә янына күчеп килделәр. Нәкъ шул көннәрдә халык суды, Гөлсем Шакированы яшәгән йортыннан сөрергә, дигән хөкем чыгарды. «Барыр җире юк, Гөлсем апаны да үзебезгә алып кайтырга туры килер»,— диде Әлфия. Хәлим бу фикерне хуплады. Мансур яклады. Зәйтүнә генә дәшмәде. Аның хәзер, бу йорт кешеләреннән аермалы буларак, үз тормышы, үз юлы, үз максатлары бар иде. Мансур белән Әлфия бер комачау булсалар, Гөлсем очлы күз дә көченеп килсә, үзенчә яши алырмы соң Зәйтүнә?

Хәлимнең мең мәшәкать белән оешкан такта йортында байтак язмышлар бергә төйнәлде. Исәеп килгән Равилне дә кертеп санасак, гаилә ишәйде, чуарланды.

## XXI

Зәйтүнә — кибет мөдире Әхәт көткән кеше булып чыкты. Кыяркыймас йөргән, сүзе дә юньләп ишетелмәгән хатын баш-аягы белән сөүдә итү эшенә чумды. Суырып кына алды сөүдә Зәйтүнәне, әүвәл башлап укуын ташлатты. Әлфия белән Мансур кисәтеп караганнар иде, колагына да элмәде, алай гынамы сиңа, пәрмә-пәр ызгыша башлады.

— Минә син, Мансур, ничә ел баш катырып укып йөрдең? Диссертация яздың! Хәзер ничек яшисең? Гафу ит, тишек ыштаныңнан чыпчыгың очып китәргә тора!

Зәйтүнәнең алласы — Әхәт. Ул, акча үз аягы белән килеп кергәндә чумырып алырга кирәк аны, һаман алай булмас, дип кабатлый. Әхәт сүзен ойдә дә сөйли. Әлфия белән Мансур, Зәйтүнәнең бар этлеген белмәсәләр дә, чамалыйлар, үгетне көн дә бирәләр — шеш тупа, тула да тишелә. Ахырын уйла.

Равил Әлфия белән Мансур карамагында калды. Күр син ташбашны, «әни» дип теле ачылды һәм... «әни» дип Әлфиягә әйтте. Зәйтүнә ирен дә, улын да бик сирәк күрә хәзер. Аның бөтен вакыты кибет белән ой арасында йөреп үтә. Әхәткә мач килде, Зәйтүнә күтәрә алган хәтле төйи дә китә. Ара шактый ерак, транспорт көндезләрен сирәк йөри.

Көндезгә сәяхәтләр белән генә эш бетми, кичкә караңгыда куркакурка товарны Гөлчирәгә илтеп тапшырырга кирәк. Тегесе күрмәсен, бусы сизмәсен, дип йөри-йөри, Зәйтүнә кичкә кадәр эт булып бетә. Ике-өч баруның берсендә Гөлчирә хезмәтенең әҗерен түли, кулга акча керү белән Зәйтүнә бөтен газапларын оныта. Кырын кергән акча адәм баласын сукырайта да, акылдан да шаштыра. Мансур белән Әлфия кем йортында яшәүләрен яхшы аңлыйлар, читләтеп кенә аңа үгет бирәләр, Хәлим соңгы вакытларда еш тузына, әзрәк салып кайтса, гауга чыгара. Ул сүгенә, Равил акырып елый, мәхшәр.

— Кара аны! — дип кисәтә Хәлим.— Тукта койрыгыңа басканчы!

Зәйтүнә иренең акыллы киңәшләрен тыңларлык хәлдән узган шул, кулын гына селти.

— Синең урам себереп алган тиеннәреңә риза булып яшәсәң, тәпі сузарсың!

— Ач тамагым, тыныч колагым, дигән сүзне онытма. Бу көннәрне сагынырсың әле.

Зәйтүнә тиз арада күзгә күренеп үзгәрде, киемнәрен яңартты, кыйммәтле тунын киеп, кәҗә мамыгыннан бәйләнгән затлы шәлен бәйләп җибәрсә, аны, алачык хәтле генә кысан кибетнең гади сатучысы, димәссең. Хәлимнән шифоньер алдырды, аны ефәк күлмәкләр, йон кофталар белән тутырды. Хәлимгә дә өлеш чыкты, аңа да яңа костюм, бобрик пальто эләкте. Өй эченә дә байлар төсе керде, стенага күз явын алырлык бизәк төшерелгән зур келәм эленде.

Күчеп килеп атна үтүгә, Мансур үзләренең бу йортта бөтенләй артык кеше булуларын аңлады. Якын туган булса да, Зәйтүнә үзенең кыек эшләрен, мөмкин кадәр, алардан яшерергә тырыша, бу аны адым саен ялганларга, хәйләләргә мәҗбүр итә. Мондый икейөзлелек, тарсыну сизгер һәм саф Мансурны хатыны Әлфия алдында уңайсыз хәлгә куя иде. Тагын шунысы, Зәйтүнәнең күрәләтә эшләнгән җинаятьләрен алар нинди күз белән карап торсыннар? Әлфия дөньялыкта җинаятьчеләр белән көрәшә, инспектор вазифасын башкара, ә үз йортында — урлап ташыган әйберләр склады. Үзенә читен, иреннән оят. Хәлимгә эндәшү читен, Зәйтүнәне күрәсе дә килми. Усал язмыш аларны өйдәшләр иткән, беркая бара алмыйсың. Мансурның кара көннәрен Әлфия бизәсә, Әлфиянең җан сыкрауларын Мансур җиңеләйтергә тырыша.

Ир белән хатын никадәр тату булмасыннар, фатирсызлык үзеннән үзе канәгатьсезлек китереп чыгара. Арага салкын кырау төшкәнгә кадәр, бу ыгы-зыгылы йорттан чыгып китеп, фатир табарга кирәк иде. Йөри торгач, анысын да табып кайтты Мансур. Эсперанто урамында үз йортлы кеше подвалына кертте. Подвалның өстенлеге шунда — коньякка карый торган ике тәрәзәчегә бар. Яртылаш җирдән калкып торган тәрәзәләр аша подвалга да яктылык төшә, кояшлы көннәрдән гел ару була. Идәннәрен кырып юып, өстәл, карават куйгач, подвалга ямь кереп, кеше яшәрлек хәлгә килде.

— Үз почмагыбыз! — диде Әлфия шатланып.— Хәзер безгә берәү дә комачаулый алмый! Үзебезчә көн күрербез!

Фатирның бәясе тозлы булу өстенә, кысмыр хуҗа ярты еллык бәяне алдан сорады. Мансурның «караңгы көнгә» дип җыйган маясы җитте дә, бетте дә. Тормыш тагын бугазны китереп кысты, җайлырак, төшемлерәк эшкә урнашырга кирәк иде. Эш табуның берчакта да җиңел түгеллеген Мансур чамалый иде. Егетнең махсус белеме, әзерлеге, тәҗрибәсе бар. Мәскәүгә язган үтенеч хатларына җавап килгәнче, берәр финанс оешмасына кереп эшләп торса, ничек булыр? Ул туптуры горфога юнәлде. Мөдир кабинетында ниндидер киңәшмә бара иде. Киңәшмә беткәч тә тиз генә эләгә алмады, бертуктаусыз мөдир янына хезмәткәрләр кереп-чыгып, Мансурны кабул итәргә ирек бирмәделәр. Аның мөдир белән ялгыз, икәүдән-икәү генә очрашасы килде. Алар, якын таныш булмасалар да, бер-берсен беләләр, очрашканда исәнләшеп, баш кагып йөриләр иде.

Шуңа күрә дә ул горфо мөдиренең ишеген кагарга булды, ул булышмаса, аңа тагын кем ярдәм кулы сузар. Беренче һәм соңгы ишек иде бу. Күтәреп ала икән — ала, юк икән — Мансурга бүтән һөнәрләр арасыннан эш эзләргә туры киләчәк. Мансурның Николай Григорьевич катына баруын Әлфия дә хуплады, алар арасында да «горфо мөдире — яхшы кеше» дигән хәбәр таралган икән. «Яхшы кеше» Мансурны шактый салкын кабул итте.

— Нинди җилләр сезне безнең якларга ташлады? — дип сорады.

Мансур боргалап-сыргалап тормады, хәйләгә бармады, туры ярды:

— Вакытлыча бер-бер эш бирегез.

— Бездә нинди кулай эш булыр икән? Сез — махсус әзерлекле, диссертация яклаган белгеч.

— Мин теләсә нинди эшкә алынырга да риза.

Мөдирнең сул як ирен чите, зур өтер булып, аска чалшаеп алды.

— Кыен чакта без бөтен түбәнлекләргә риза. Шуннан карыйсың, әле аягы эшкә кереп җитмәгән, ул бүтән эш даулый! Дәрәҗәсенә тәңгәл эш кирәк аңа! Горфода фән кандидатына нинди лаеклы урын булсын? Мөдир, дисәгез, әлегә мин монда утырам.

— Сез мине эшкә алырга куркасыз, күрәм. Мин сезнең урынны дәгъваларга җыенмыйм. Уйламыйм да. Миңа гаиләмне туйдырырлык, җан тынычлыгы бирерлек бик гади эш тә ярый. Риза.

Мөдирнең карашы тагы салкынайды.

— Мәсьәлә куркуда түгел. Безнең эшнең җитдилеген сез бар кешедән дә яхшырак аңлыйсыз. Без халык арасында партиянең финанс сәясәтен үткәрәбез! Безнең финанс органнарында сыналган, тәҗрибәле, белемле һәм чиста намуслы кешеләр эшли. Без җәмгыятебезнең генә түгел, үз арабызның да саф, керсез булуы өчен көрәшәбез. Шуннан уйлап карагыз, мин сезне — сәяси яктан ышанычын югалткан кешене эшкә алыйммы? Әгәр мин сезне коммунистлар партиясеннән куылган кешене эшкә урнаштырсам... Югары оешмалар мине аңламаслар!

Мөдир һәр сүзенә, һәр җөмләсенә генә түгел, яшькелт күзләренең тоныклыгына да мәгънә салып Мансурны таптап изгәндә, ул өзмәс аңа карап утырды. Хәзерге халәтеннән чиксез риза булуы да, шушы югары дәрәҗәдәге урыны өчен теләсә кемнең бугазын чәйнәп ыргытырга әзер булуы да күренеп тора иде аның карашында. Ул соңгы сүзләрен әйткәндә, урыныннан торды, каршыдагы кием шкафы янына килде, көзгегә карап саргылт чәчләрен бер якка кайтарып тарады, җайлап кына киенергә тотынды. Кыйммәтле кондыз бүрек, каракүл якалы драп пальто килешә икән үзенә. Киенгән саен буе биегәйде, гәүдәсе турыланды. Аптырап идән уртасына чыгып баскан Мансур да, аның чуаланган язмышы да, эшсезлеге дә юк иде Николай Григорьевич өчен. Ни өчен «яхшы кеше» дип атаганнар бу бәндәне? Министр үз канаты астына алгангамы? Бәлки, чыннан да бүтәннәргә, якыннарына бик күп яхшылык эшли торгандыр? Гаиләсе, хатын-балалары өчен җан атадыр? Ә Мансур нәрсә? Мансур бүгенгә кисеп ташланган кыерчык, булмыш кандидат, йортсыз-җирсез узгынчы. Дөрес, «яхшы кеше» Николай Григорьевич та Мансур өчен моннан болай дөнья йөзендә юк иде. Ләкин бу югалтулардан кемнең уңганын, кемнең туңганын аңлау бер дә кыен түгел иде. Мансур гәүдәсен туры тотарга тырышып, бары алга гына карап, коридорга чыгып китте.

... Казанның баш түбәсе булган калкулыктан ул шактый вакыт ерак офыкларга, Идел киңлекләренә сокланып карап торды. Чиксез иркенлек, шәһәргә булган мәхәббәте, үзен шушы җир кешесе, татар итеп тою, Әлфиясе хакындагы җылы уйлар аны аңына китерде. Нигә соң әле ул финанс оешмаларының бусагасын таптап, үз-үзен кимсетеп, ялынып йөри? Әллә бүтән җирләрдә эш беткәнме? Киң ич дөнья, зур ул Казан! Кече яшьтән кул көче белән эшләп үскән, ныгыган кеше. Һич югында кара эшкә кереп эшләр. Хәлим урам себерә, рәхәтләнеп эшли, рәхәтләнеп ашый. Башы бераз ял итәр, диссертация язганда күпме чиләнде? Күпме төннәрен йокламыйча өстәлгә кадалып үткәрде! Какшаган нервылары ныгыр, белегенә көч кайтыр, алда күз күрер тагын. Тормыш гел болай гына бармас әле. Егерменче съездда калкынган фикерләр хәзер әкренләп халык арасына тараламы? Тарала! Кара эшкә! Димәк, гади, кул көче белән азык таба торган эшчәннәр арасына! Бу фикер аны канатландырып җибәрде. Ул юлында беренче очраган кибеткә барып керде.

Кибет директоры хатын-кыз икән, иңе-буе тигез булса да, күзгә-

башка чибәр генә икән. Ул Мансурны башыннан аягына кадәр күзеннә
үткәрде дә:

— Кыяфәтең бер дә кибеттә эшләрдәйгә охшамаган. Турысын гына
әйт, син иртә таңнан салырга тотынасыңмы, әллә эштән соң чөмерерг
яратасыңмы? — дип сорады.— Шешә белән дуслыгың ничек?

— Ничек дип әйтергә?

Бөтенләй эчмим, дисә, бу апа аны бөтенләй кешегә санамас. Эч
кәлим, дисә, кире борып чыгарыр. Ни дияргә?

— Булгалый. Сызыктан чыкканым юк. Ул яктан тулы тәртип.

— Кара, син бик шома сөйләшәсең. Моңа кадәр кайда эшләдең?

— Төрле эштә.

— Кая, хезмәт кенәгәңне бир әле.

Мансур әлегә кенәгәсен күрсәтми торырга булды.

— Ә-ә... кенәгә элек эшләгән җирдә. Әгәр эшкә алсагыз, иртәгә ук
китерермен.

— Хезмәт кенәгәңне алып кил, сөйләшербез.

Мансур чыгып китә башлаган иде, директор аны туктатты.

— Кабат-кабат йөрерлек булмасын, мә, моны да тутырып кил.

Ул аңа, өстәл тартмасыннан алып, «Личный листок» бланкы тоттыр-
ды. Мансур бик җентекләп карап, нинди сорауларга нинди җаваплар
бирсәм, уңармын, дип, карап тора башлады. Директор аның бу хәрәкә-
тенә дә игътибар биргән икән.

— Боза күрмә,— диде,— бланкның актыккысы. Үзеңнең кулыңнан
килмәсә, торган җирегездә берәр грамотный бардыр, сорасаң, тутырыр-
га булышырлар. Аның әллә нәрсәсе юк, сорауларга җавап төрткәләрг
генә кирәк.

Бу юлы Мансур тыела алмады, кычкырып көлеп җибәрде.

— Нәрсәсе көлке? Монда көләргә түгел, еларга кирәк! Шундый
чибәр егет... Неграмотный... Нишләп укымадың?

— Үземә күрә... әз-мәз ермачлыйм мин.

— Хәзер әз-мәз белән яшәп булмый, күп кирәк.

— Миңа бар булганы җитеп торыр.

— Шулай сөйләп аңгыра ябалак булып калгансың да... Эх, егет!

Өстәлдәге телефон шалтырады, директорны каядыр чакырдылар
бугай, ул кабалана башлады, урыныннан купты, чыгып китәргә җыен-
ды.

— Моны иртәгә китерсәм дә ярыйдыр? — диде Мансур, кулындагы
кәгазьне селкеп.

Иртәгесен «Личный листок»ны китереп тоттыргач, Мансурның чик-
тән тыш гаҗәпләнүенә каршы, Зоя Петровна аңа күз төшереп тә тор-
мады, алды да сейфка тыгып та куйды.

— Ярар, булган. Сынау срогы белән бер айга эшкә алып торырбыз.
Бер айга! — диде коры гына.— Алда тагын күз күрер. Кибетче кызлар
белән азынмаска! Бар, эшкә кереш. Йокче булырсың.

## XXII

Адәм балалары дөнья яралганнан бирле бер-берсен күрә алмый-
лар, бер-берсеннән көнләшәләр, бер-берсенә үчләшәләр. Һәрзаман
көнчеләр, үчлеләр кулына үзе сайлаган коралны бирә. Тыныч заманда
иң көчле корал — әләк. Ишегеңнең биген эләсең, тәрәз пәрдәләреңне
төшерәсең дә, тотынасың уңга-сулга, түбәнгә-югарыга язарга! Имзаңны
да куеп тормыйсың, кем икәнеңне белдермисең, язган әләгең үз юлын
үзе таба, барып җитә, анонимика дип аталса да, аңа ышаналар. Власть
кешеләренең иң яратканы — әләк, анонимика. Кеше үзе юк икән,
аның мәшәкате дә кимрәк була. Үзе юк, ә әләге бар!..

Финанс министрлыгына чираттагы әләк хаты килде. Шундый ук хат,

шул ук көнне горфога да килеп төште. Хатлар икесе дә бер үк кул белән язылып, бер үк ноктага төбәп атылганнар иде. Хат язучы «теш врачы Хургинның үз өендә нык тыелган эш — алтын теш кую белән даими шөгыльләнгәнен» хәбәр иткән. Хат Хургинның күршеләре исеменнән язылган һәм янау белән тәмамланган: «Әгәр ашыгыч һәм каты чара күрелмәсә, турыдан-туры Мәскәү аша эш йөртәчәкбез».— диелгән.

Министрлыкта да, горфода да мондый әләкләргә, янауларга әллә кайчан күнегеп беткәннәр. Хатларны алалар, тишек тишеп калайлы катыргыларга беркетәләр, бүлектән бүлеккә бара-бара әләк-чәләкләр зур кешеләргә, абруйлы хезмәткәрләргә барып ирешә. Бу юлы әләк горфо мөдире Николай Григорьевич өстәленә кадәр менде. Хат зур, тиңдәшсез дәрәҗәгә иреште. Хургинны белә идеме, әллә якын аралар-да Мәскәүдән килгән бер циркуляр аны сагайттымы, ул Хургин өстеннән килгән материалны читкә алып куйды. Бүтән хатларның почмакларына төрле-төрле резолюцияләр тамгалап озаткач, тагын теге хатка кайтып төште. Мәскәүдән килгән циркулярда күрше өлкәләрнең берсендә нәкъ шуңа охшашлы хәлне фаш итү хакында язылган иде. Алтын приискаларында эшләүче берничә кеше төйнәләләр, Идел буе калаларының берсендә яшәүче теш докторы белән мөнәсәбәткә керәләр һәм берничә ел дәвамында хөкүмәтне кычкыртып талыйлар. Алар китергән зыян миллионнар белән исәпләнә. Хургин — таныш исем.

Аның кыек, кыңгыр эшләре турында ул бүлек начальнигы булып эшләгәндә дә сүзләр йөргән иде. Сүзләр йөрде, ә Хургин судан коры чыккан әнә, котылган. Бу юлы аны болай игътибарсыз калдырырга ярамас, тикшерү җибәрергә һәм тикшерү эшен таләпчән, намуслы берәр иптәшкә тапшырырга кирәк.

Финанс министры Әюп Җамалиевич шикаять-әләкне, налог һәм җыемнар бүлеге аша, ревизор Мөбарәк Сафинга тапшырды. Аны үз катына да чакырып алды.

— Шушы җитди сигналны тикшерү белән бергә, районың эшчәнлегенә дә ревизия ясап кайтырсың. Соңгы вакытларда ошамыйлар алар миңа! Өсләреннән бик нык яза башладылар.

Мөбарәк министр янына шигәебрәк кергән иде, Әюп Җамалиевич яныннан канатланып чыкты. Димәк, ул ярты ай чамасы өйдә хатыны һәм яшь баласы янында булачак.

Эш шунда иде ки, Мөбарәкнең өйләнгәненә җиде ел үтеп китсә дә, озак еллар бәбәйләре булмады. Казан врачларының күпчелеген йөреп чыктылар алар, хатынын Мәскәү, Ленинград докторлары дәвалады. Якыннарының киңәшләре белән имчеләргә күренделәр, түләүле поликлиникадагы кыйбатлы консультацияләрдә булдылар. Ниһаять, көткән көннәре килеп җитте, уллары туды. Хатыны Галия авырлы чакта да командировкаларга теләр-теләмәсрәк йөргән Мөбарәк, бәбәй кайткач, шәһәрдән китмәс булды. Дөнья синең хәлеңне беләмени? Акча, түләү, керем-чыгым, налог тирәсендә гомер-гомергә гауга бетеп тормаган, хәзер дә шулай, бигрәк тә авыллардан күп язалар, әләк килә, сорау килә, зар килә. Синең үз тормышың бармы, кырык чоең кырылып ятмыймы, ревизор икәнсең, берәү дә анысын тикшереп тормый. Командировка ал, чык, тикшер, йөр, отчет яса. Инде яңа елга кадәр чыгармасалар, берәр яры җибәрмәсәләр дип теләктә йөргәндә, аңа районы тикшерүне йөкләделәр. Иптәшләре аңа йөкләнгән эшне белгәч, Мөбарәкнең кәефен бераз кырдылар-кыруын: «Тикшерүләрнең иң авыры, иң чуалганы — районда казыну. Башыңа бәла алгансың!» — диделәр. Әйтсеннәр! Ул хәзер унбиш көн, тегәл ярты ай Казанда булачак.

Янып килми ич. Хургин дә әллә кая китмәс, бер-ике көн эшкә бармаса да, дөнья чите кителмәс. Хатынына йортта булышыр, бәбәй чүпрәкләре юар, идән тузанын сортеп чыгарыр.

Эш хутта Мөбарәкнең, бер көн бармады, ике көн кузгалмады, ошап китте ял итү, өченче көнне дә хатыны, баласы янында иркәләнеп йөрде.

Дүртенче көнне генә райфога китте. Беренче эше итеп Юныс Гыйльметдиновны эзләп тапты һәм аңа үзе белән алып килгән берничә таблица тоттырды.

— Дүрт көн эчендә шушы таблицалар тутырылган булсын,— диде Юныска сораулы караш ташлады да: — Карагыз аны, бутамагыз, алдамагыз, дөрес тутырыгыз, соңыннан һәр санны тикшерәчәкмен,— дип өстәде.

Таблицалар райфоның кадрлар составы, белемнәре, өзерлекләре, финанс туплау планының үтәлеше, недоимка эзләп алу буенча эшнең торышы, шул юнәлештә билгеләнгән чаралар, кустарьлар белән эшләү һәм башка мөһим, бик кирәкле мәгълүматлар күзгедәге кебек ачыкландырылган иде. Шундагы җавапларга нигезләнеп, тәҗрибәле ревизор башкаларның бер атна вакытын ала торган эшен ярты көндә төмамлый. Мөбарәк әнә шундый тәҗрибәле, күп тапкырлар сыналган, республикада күк күкрәтә торган ревизорларның берсе иде. Моңарчы шундый кеше иде Мөбарәк Сафин, баласы туганчы шундый-шундый титуллы хезмәткәр иде. Баласы туды — үзгәрде дә куйды кеше, валлаһи! Әгәр элекке чак булса Хургин турындагы хатны алганнан соң, аны өендә тотып булыр идеме? Өстергән эт тә аның сыман җитез чапмас иде! Барып җитеп Хургин-Мургиннарның җиде буынына төшәр иде.

Тагын бер карап алды Мөбарәк Юныска, имән бармагын тырпайтып янады.

— Синнән яшерен-батырын эш юк,— диде ул, элеккеге өз-мөз танышлыкларын күздә тотып.— Каныңа тоз салып, күзеңә кергән кылчык булып, мин райфода утырырга җыенмыйм, хатын янына өйгә кайтам. Минем малай булганны ишеткәнсеңдер инде?

— Ишеттем, ишетмәгән кая,— диде Юныс, ишеткәне булмаса да.

— Әгәр югарыдан берәвесе кызыксынса, участокта, кустарьлар тикшереп йөри диген. Кстати, минем аларны йөреп чыгасым да бар. Үзең һәр көн, иртәнге якта эш урынында булырга тырыш. Телефоннан белешкәләп торырмын...

Юныс, министрлыктан ревизия киләсен белгәч, шыр җибәргән иде. Мөбарәктән, дәһшәтле ревизордан шундый ягымлы сүзләр ишетеп, авызын ерды, сүз әйтеп бетерергә дә ирек бирмәде.

— Тукта әле, тукта! Синең безгә килеп эш башлавың беренче мәртәбә. Бу булды — раз! Икенчедән — малай туды! Бусы булды — два! Хәзер туры ресторанга кереп утырабыз, танышлар бар, аерым бүлмә әзерләп куярлар, шунда барын да иркенләп сөйләшербез.

Мөбарәк бу тәкъдимнән катгый рәвештә баш тартты. Тәҗрибәле ревизор буларак, күңеленә шик тә төште: нигә әле бу Гыйльметдинов, һич тайчынмыйча, туп-турыдан суктырып мине эчәргә чакыра? Моның ике сәбәбе булуы ихтимал. Беренчедән, ул Мөбарәкне кулга тиз ияләшә торган аумак кеше дип саный, икенчедән... Икенчедән, аның кылган гөнаһлары шулкадәр күп ки, хәзер ул куркудан узган, йә пан, йә пропал, дип текә ярдан упкынга ташланырга да әзер.

— Бигайбә,— диде ул, кулын күкрәгенә куеп,— чакырганыгыз өчен рәхмәт, бара алмыйм. Ә малайның тәпиен юуга килгәндә, аның сөекле әнкәсе бар, көненә өч тапкыр коендырып чыгара егетне!

Юнысның кәефе кырылуы чыраена чыкты. «Юк инде, булмаганны... Башта килгән бере шулай баш тарткан була да соңра мичкәсенә төшеп утыра!» Аның җыерылган маңгаена карап, Мөбарәк елмаеп куйды. Гыйльметдиновның башында нинди уйлар кайнаганын аңлады.

— Тыныч бул! — диде ул.— Вакчылланып, юк-бар чатаклыкны актка терки торган гадәтем юк, төзәтә алырлыгын ревизия дәвамында рәткә салырга тырышам. Әгәр инде усал ният белән закон бозулар табылса, саклан, шәфкать көтмә.

«Калай әтәч! — дип уйлады Юныс.— Өеңдә качып ятып әллә ни кыра алмассың! Куркытмакчы була, синең кебекләрнең йөзен ашап коскан, тәре чырай!»

— Көчләмим, мәйлең, үзбәкләр әйтмешли. Ләкин болай кыланырга да ярамый. Бәлки, бу мине сатып алырга тели, дип уйлыйсыңдыр. Юк, кардәш, курка торган эшем юк. Минем ничә ел финанста әйләнгәнне беләсеңдер, шәт? Закон бозуларга үзебез дә юл куймыйбыз, кулдан килгән кадәр тырышабыз. Бер тугарылып, үзебезнең агайне белән гәпләшеп утырырга гына теләгән идем.

Юныс ачуы чыккан мизгелләрдә саклык чараларын онытып җибәргәли, бүген шундый чагы булдымы, әллә Сафинның, һич яшермичә, өйдә качып ятарга нияте барлыгын ачып салуы аның саклыгын киметтеме, Мәскәүдән килгән ревизорларны берзаман аяктан екканчы сыйлавын сөйләп, шапырынырга тотынган иде. Мөбарәк аны туктатты.

— Синең чакыруыңны кабул итеп барсам, шытырдап янасы икәнмен,— диде.

— Нигә?

— Мәскәү ревизорына мине исертеп екканыңны сөйләп күңелләрен күтәрәсе икәнсең!

Юныс аның усал, нык карашыннан куырылып китте.

— Юк ла, үз агайнемне нигә шулай сатыйм? Без бит бергә, бер шәһәрдә гомергә яшисе.

— Гафу ит,— диде йомшарып Мөбарәк.— Үзем эшен тикшергән кешеләр белән бергә утырып аракы түгел, чәй дә эчкәнем юк.

— Эчү — заман чире, ул безне әллә кая кадәр алып барып җиткерер. Сагай син аннан!

Улы янында кинәнеп утырырга да, бәбәйдән соң һаман хәлгә килеп бетмәгән Галиясенә булышырга да туры килмәде. Юнысны ошатмады ул, кыекка кереп киткән әңгәмә аның эчен пошырды, икенче көнне эш сәгате башлануга райфога килеп җитте, Юныска кагылып тормады, туп-туры налог һәм җыемнар инспекциясенә барып керде. Наилә гадәтенчә исерек ире белән мәшәләнеп соңга калган, бүлмәдә Әлфия бер ялгызы кәгазьләр актарып утыра иде. Ул тырышып-тырышып кустарьларның квартал эчендә алган доходларын исәпләп утыра икән. Күрештеләр, таныштылар.

— Сезгә кәгазь тирәсен калдырып торырга туры килер,— диде Мөбарәк аңа ягымлы тавыш белән.— Хәзер без икәүләшеп участокка чыгып керербез.

— Наилә апа килгәнне көтмибезме? — дип сорады Әлфия.

— Хуҗа чыгып киткәләгәнче барып җитәргә иде.

Әлфия теләр-теләмәсрәк кенә урыныннан кузгалды, Мөбарәк шуңа да игътибар итте, ул бик боек иде.

— Әллә авырыйсыз инде?

Әлфия аңлатып җавап биреп тормады, аскы иренен генә тешләде. Чыннан да, аның бик борчулы чагы иде. Өченче көн генә аны горфоның кадрлар бүлегенә чакырып алып, нык кына кисәттеләр: «Беләбез сине, намуслы, тырыш хезмәткәр икәнлегеңне дә беләбез. Читтән торып укуыңны дәвам итүең дә мәгълүм. Әмма эш бездән тормый, сезгә мондый хәлдә финанс органнарында эшләргә ярамый. Өстән күрсәтмә бар. Яхшы чакта үзегез гариза язып китерегез».

Ул ни өчен икәнен сорап төпченеп тормады, сәбәбен ярты сүздән аңлады. Кадрлар бүлегендә утырган абый хаклы: өстендә күк күкрәп, аяк астында җир тетри башлаганчы, аяк киенеп куярга кирәк. Югыйсә, соң булачак. Үзе гариза язып китермәсә, кулына башка эшкә керә алмаслык документ тоттырып чыгарып җибәрәчәкләрен көт тә тор. Йөрерсең аннары...

Тик бу хакта сынык күңелле Мансурга ничек кайтып әйтергә?

Әле ул җиргә тотынып түгел, Әлфиясенә тотынып яши иде, аның тормышы әйбәт булачагына ышана иде. Торыр җирләре юк, Әлфияне квартир чиратына куюларын да белә иде.

Егерменче съездан соң байтак вакыт узуга карамастан, барлык

тармакларда эш нәкъ искечә дәвам итә иде әле. Җаваплырак эшкә түгел, вак-төяк урыннарга керергә теләгәндә дә беренче чиратта кешенең социаль чыгышы тикшерелә. Үзе, ата-анасы гына түгел, чыбык очы туган-тумачаларыннан берәү-икәү сәяси яктан гаепләнмәгәнме? Чит илләр белән мөнәсәбәтләргә, андагы кардәш-ыруларга аерата басым ясала. Үзең яки туганнарыңнан берәү чит илгә чыгып йөргән икән, мәрхәмәт көтмә, ышаныч бетә. Шундук «карандашка» алачаклар.

Чит илгә командировкаларга йөргән кешеләргә дә ташлама ясалмый, аларның һәр адымын инә күзеннән үткәреп тикшерәләр.

Мансурның партиядән чыгарылуы, эшеннән куылуы да көне-сәгате белән Әлфиянең эшендә — райфода мәгълүм булды. Җитәкчеләр генә түгел, үзе белән бергә эшләүчеләр дә аңа кырын карый башладылар. Әлфия аерата Наилә апасының кискен үзгәрешләрен авыр кичерде. Наилә хәзер адым саен диярлек аңа авыр сүзләр әйтә, минут саен Әлфиянең түбәнлегенә басым ясый, вак-төяк йомышлар белән йөгертә — анда бар, моны алып кил, тегене эшлә! Нәни генә карышып кара, шунда ук әшәке, ямьсез сүзләр белән күңеле китек Әлфияне коендыра. Элек Әлфия Мансуры белән горурлана иде, көн саен диярлек иренең яңа, матур сыйфатларын таба, табигый буларак, бер бүлмәдә эшләгән Наилә апасына сөенечләрен әйтеп уртаклаша иде. Ә Наилә үз ирен сүгүдән бүтәнне белми, телендә гел әшәке, кара сүзләр була торган иде. Хәзер ул җәһәттән дә өстенлекне алды. «Минем ирем, ичмасам, эчсә дә, җимертеп эшли. Аның илгә хыянәт иткәне дә, итәсе дә юк. Вөҗданы да, намусы да саф аның! Илләә мәгәр кайбер кешеләрнең ирләре бар, эчләренә кара елан кереп урнашкан икән, билләһи!»

Моңарчы Әлфиянең күңел түрендә бер якты өмет саклана иде әле. Аның Мансуры берчакта илгә дә, халыкка да хыянәт итмәгән! Юк! Ул андый кеше түгел. Теге чакта аның атасын юкка җәберләгәннәр. Әнә ич, Гөлсем апаның әти-әнисен дә алып китеп юкка чыгарганнар, туганнарын эзсез таратканнар. Хаксыз заманалар булганмы? Булган! Мансуры акланачак әле аның... Хәзер, әнә кит, китеп кал, юкса, гөрзи белән башыңа орачаклар, диләр. Ә Әлфиянең ил каршысында ни гаебе бар? Үзе теләп эштән китсә, гаебен таныган булып чыга түгелме?

Юк, ревизорның карашы җылы, тавышы ягымлы булса да, чишелеп китәргә ярамас. Мансуры һәркөн аның колагын тукый: «Сак бул. Абай эшлә. Кырын эшләрнең якынына килә күрмә! Адымыңны үлчәп атла. Бигрәк тә Юныстан саклан. Аның синең юлыңа кара таяк ыргытасын көттә тор!»

— Болай сау-сәламәт сизәм үземне,— диде.— Начар йокладыммы, шуңа кәефсез күренәмдер.

Берара сүзсез генә атладылар.

— Сер булмаса, әйтегез әле, без кая барабыз? — дип сорады Әлфия.

— Бер сигнал тикшереп кайтабыз.

Мөбарәк шуннан артыгын әйтмәде, Әлфия дә өстәмә сорау биреп, төпченеп тормады.

Алар Ремесленная урамына борылдылар. Таныш урамнар!

— Аңлашылды,— диде Әлфия серле генә.

— Әллә булганыгыз бармы?

— Булмыйча! Тик алар өйләренә беркемне дә кертмиләр.

Мөбарәк туктап калды.

— Соңгы мәртәбә кайчан килдегез?

Әлфия уйланып торды да килүләренең төгәл көнен атады.

— Кертмәделәрме?

— Мөбарәк абый, анда барып чокчынып йөрисе юк. Чарасын күрергә генә кирәк. Ул бит алтын теш куя. Без бит Хургиннарга барабыздыр?

— Шуларга. Аның алтын теш куйганын каян беләсез?

— Бәй, белмичә! Алтын теш куйдырган бер хатыннан Наилә апа белән бергә сораштык.

Мөбарәк читтән тыш житдиләнде.
— Акт төзедегезме?
— Акт та төзедек, хатын фактны раслап имзасын да куйды.
Мөбарәкнең үзгәргәнен, житдиләнгәнен күреп, Әлфия ашыгып сөйләвенә үкенә башлады, ашыгыбрак ычкындырдым, дип уйлады.
— Ул акт кайда?
Бу юлы Әлфия ашыкмады. Әйтергәме, юкмы, дип, баш ватып уйланып торды.
— Акт Юныс абыйда булырга тиеш. Наилә апа актларны һәрвакыт аңа тапшыра.
— Шуннан тагын берәр мәртәбә тикшерергә килмәдегезме?
— Миннән башка килсәләр инде.
Хәзер Хургин янына барып йөрүнең кирәге дә калмаган иде. Беренче нәүбәттә Наиләне эзләп табып, актның кайдалыгын ачыкларга һәм аның ни өчен хәрәкәтсез яткырылуын белергә кирәк иде. Мөбарәк Юнысның төче елмаеп бөтерелүен күз алдына китерде дә йодрыкларын йомарлады. «Ну... оятсыз!»
Әлфия элегрәк үз эше, эштә күргән-белгәннәре хакында Мансурга сөйләштерә, аның белән киңәшә һәм киңәшләрен тотарга да тырыша иде. Эштән китәргә тәкъдим иткәннән бирле ул сүзгә саранланды, берике сүз әйтә дә үз эченә йомылып кала. Бүген, Мөбарәк Сафин белән үткәргән көннән соң, кайту белән Мансурны чакырып алды, башым әйләнеп тора, әйдә, бераз саф һавада йөреп керик әле, диде. Ермакның аулак читендә, күнегелгән кадерле урынга җиткәч, эч серләрен сөйләп бирде. Горфога чакырып алуларын, эштән китәргә туры киләчәген дә яшермәде.
— Бүген министрлыктан ревизор килде, туп-туры минем янга кагылды, мөгаен, мине күзәтергә җибәргәннәр аны. Әллә китәргә гариза илтеп кайтыйммы? — диде.
Мансур да курка калды, әгәр Әлфияне күңелсез кәгазь тоттырып эштән алсалар, ничек яшәрләр алар? Икесенә бер өмет бар иде, Әлфиянең укып бетерүенә, яхшы эшкә урнашуына ышаналар иде, хәзер ул яктагы яр да җимерелде.
— Бар да гаризаңны биреп кайт, тамаклары тыгылсын. Илдә чыпчык үлми, без дә яшәрбез әле,— диде Мансур хатынын кысып кочаклап. Әлфия аны үзенә таба тартты, гәүдәләр гәүдәгә сеңде һәм Әлфия оялып кына Мансурның колагына пышылдады:
— Мин бәби алып кайтырга җыенам бугай...
Ул икенче көнне, иртән үк гаризасын күтәреп горфога китте һәм кадрлар бүлеге мөдиренең эшкә килгәнен көтеп торды. Беркөнне нык итеп: «Кит!» — дип җавап биргән мөдир, бүген икеләнеп калган иде. Ашыкма әле, сеңел, сездә министрлык ревизоры эшли башлады, ул сине җибәрми торырга кушты, диде. Бусы тагын да сәеррәк иде.

## XXIII

Атна эчендә гаҗәп хәлләр булып алды.
Җир тамырын юллап көнгә чыккан чишмәне туктатам, димә. Агар су үзенә туры юл таба! Таудан тәгәри башлаган бер йомарлам кар, төшәтөшә лавинага әйләнә, юлындагы каршылыкларны ватып-җимереп бетерә. Юныс Мөбарәк Сафинның кай сукмакка чыгып киткәнен белүгә Наиләне чакыртып алды. «Бернинди тикшерүнең, актның булганы юк, бу гыйбәтне бары тик Әлфия генә тарата. Ә аның кем икәнен беләсең. Ире халык дошманы, кулак баласы, социал чыгышын яшереп партиягә үрмәләгән сатлык җан. Хәзер, эшеннән куылгач, кибеттә йөк бушатучы булып эшли. Унике кило он урлавы беленгәч, директорга кереп акчасын түләгән. Шул котыртып ята Әлфияне. Чын күңелдән совет закон-

нарын саклаучы намуслы хезмәткәрләргә, гаделлек сагында торучы сиңа, миңа үч итеп яман атыбызны сата»,— дип, куркынган хатынны ныгытты һәм Наиләнең өстәл тартмасына ике утызлыкны тыкты. «Ни бу?» — диде Наилә куркынып. «Миннән сигезенче март бүләге»,— диде елмаерга тырышып Юныс. «Сигезенче мартка ерак ич әле!» «Сигезенче март җиткәч, тагын булыр, ала тор!» Алса да алды Наилә, алмаса да алды.

Мөбарәк эшне кызу тотты, инспекция хезмәткәрләренә тын алырга да ирек бирмәде. Наилә белән Әлфияне очраштырды, иплән, җайлап сораша торгач, җепнең очын үз кулына алды. Башта киреләнеп маташкан Наилә Әлфиянең ныклыгын, үз сүзендә торуын күреп, җебеп төште. Хәтере шәп иде Әлфиянең, ул алтын теш куйдырган хатынның исем-фамилиясен генә түгел, адресын да исендә калдырган икән.

Ревизия беткәнне дә көтмәделәр, Юнысны эшеннән алдылар. Шул көннәрдә Үзәк Комитетта Мансурның апелляциясе каралып, аны каты шелтә белән партия сафларында калдырдылар. Миначев урынына сайланган партбюроның яңа секретаре: «Якын араларда эшеңә кире кайтару мәсьәләсен карыйбыз»,— дип сөендереп чыгарган. Мансур диссертациясен яңадан карауны сорап ВАКка озын хат язып салды.

Мандрус та йоклап йөрмәгән икән, ул Гөлчирәне баш-аягы белән ОБХССка илтеп тапшырган. Гөлчирә белән спекулянтларның төп курьеры Зәйтүнә дә эләкте. Аны эшеннән куып, шартлы рәвештә өч елга хөкем иттеләр. Яшь баласы барлыгын искә алып, әлегә төрмәгә утыртмадылар. Мансур адвокат яллаган иде, нәзек кенә хатын-кыз Зәйтүнә файдасына байтак сүзләр сөйләде. Хәлимнең ярты гомерен алган, мең газап белән әрҗә такталарыннан кормаштырган йорты конфискацияләнде.

Гөлчирә нык утырды. Үзе артыннан шактый кешене өстерәде. Кибет мөдире Әхәтне, база директорларыннан ике кешене кулга алдылар. Бәладан — башаяк, дип, шул гаугалы көннәрдә Мандрус шәһәрдән үк чыгып качты. Казанга якын гына район үзәкләренең берсендә ул күптән куыш һәм кәләш тапкан иде. Мал-мөлкәтнең байтагын шыпырт кына яңа нигезенә ташып та куйган иде.

Гөлчирәгә судка кадәр яшәү насыйп булмады, сукыр эчәгесенә операция ясаганда, һич көтмәгәндә үлеп китте. Халык телендә, Гөлчирәгә операция бөтенләй кирәк булмаган, милициядә эшләүче югары начальникларның урындыкларын тетрәтә башлагач, үтергәннәр аны, дигән имеш-мимешләр йөрде. Хәбәр бөтенләй нигезсез дә түгел иде. Кырыкка да җитмәгән, янып торган тап-таза хатын юк-бар операциядән җан тәслим кылсын әле. Шикле, бик шикле иде бу яңалык. Гөлчирәнең бөтен мөлкәте дәүләт файдасына конфискацияләнде. Аның йортыннан чыккан малны санап бетерерлек түгел иде. ФРГ, Италия, Франция, Япония һәм социалистик илләрдән килгән товарлар, кием-салым, кофталар, аяк киемнәре, йөге-йөге белән Гөлчирәнең чоланнарына, сараена күчкәннәр. Бәллүр савыт-саба, җиһаз, зур-зур Иран келәмнәре, алтын сәгатьләр, беләзекләр, алтын акчалар йортның бөтен аулак почмакларына яшерелгән иде.

Юныс белән Гөлчирәнең никахы загста теркәлмәгәнлектән, закон буенча аңа өлеш чыкмый иде. Шуңа күрә тагын хәйлә юлына басарга туры килде. Аракы белән коендыра торгач, ике кеше шаһит булып судка бардылар һәм: «Пианино, бәллүр вазалар, стенка һәм зур келәмне Юныс сугыштан трофей итеп Германиядән алып кайтты»,— дип расладылар. Юныс Гыйльметдинов малларын төяп беренче хатыны янына кайтты. Каны каткан хатын, шулкадәр байлыкны күргәч, ирен кире бора алмады, кабул итте, балалар хакына кичерде.

Гөлчирәнең дәүләт файдасына конфискацияләнгән әйбер-каралары суд карары нигезендә, район финанс бүлеге аша сатуга чыгарылды. Кибеткә барасы нәрсә-каралар Әлфия кулы аша үтәргә тиеш булды. Бу

аваплы, кетелмәгән, күрелмәгән эш белән аңа озак чиләнергә туры илде.

Шәһәр промторгының комиссион кибете, кибет димәсәң хәтере калыр, тактадан кадакланган, барак сыман бинага урнашкан иде. Директоры тумыштан гарип, аяклары чак-чак йөри торган Габдрахманов фамилияле урта яшьләрдәге бер ир иде. Гомере буе сәүдәдә азу ярган, элгә беткән бу кешене ул чакта шәһәрдә белмәүче булмагандыр. Өтердә калырлык чибәр йөзе, җор теле аны күркәм ир итә, кузгалып иткәч аның гарип икәнен күрәсең.

Конфискацияләнгән әйберләрне Әлфия күзәтчелеге астында Гөлирә йортыннан кибеткә ташыдылар. Ул аларны көннекен көнгә бәя уеп, күздән үткәрерлек итеп кенә ташытты. Мондый очракны саклап ына торган козгыннар беренче көнне үк кибет тирәсен сырып алдылар. Эш әле башланырга да өлгермәгән иде, кибеткә тек-тек басып милиция подполковнигы килеп керде.

— Хәсбиуллин, ОБХСС начальнигы урынбасары,— дип таныштырды ул үзен. Нинди мал килүе белән кызыксынды.— Товар бөтен кибетләргә китмиме? — дип сорады, бер кырыйда бәя куярга дип өеп куелган шәлләргә ишарәләде.— Болар ничә данә?

— Биш.

— Ун булырга тиеш! Кайда калганнары?

— Әле килеп җитмәгән.

— Паутинкаларны безнең рөхсәттән башка сатуга чыгармагыз,— дип боерды ул. Әлфия сәбәбен сорап бәхәскә кереп тормады, гомумән, үзенә ышанып тапшырган эшне башкарганда, милициянең арага кысылырга маташуын өнәмәде.— Мин көне буе үземдә булам, бер-бер аңлашылмаучылык очраса, шундук шалтыратыгыз.

Әлфиянең эш буенча эчке эшләр хезмәткәре белән беренче тапкыр очрашуы иде. Хәсбиуллинның кыяфәте дә, сүзе дә аңа ошамады — нигә чокчынып йөри әле монда? Ни өчен Әлфия аңа киңәшкә барып йөрергә тиеш? Аңардан башка да сатарлар әле! Милиция кешесе чыгып киткәч, Әлфия түзмәде, Габдрахмановтан:

— Бу адәм нигә монда буталып йөри? — дип сорады.

— Тәртипләре шундый аларның, үзләренә ошаган әйберне алып бетермичә, товарны сатуга чыгартмыйлар. Әле бәя куйганда да тыкшынып җанны алалар.

Әлфия өстәлгә финанс министрлыгының ике йөз туксанынчы номерлы инструкциясен чыгарып салды.

— Без ул теләгәнчә түгел, закон кушканча эшләрбез. Закон мондый эштә чит кешенең катнашуын рөхсәт итми.

— Ай, кызым, алар белән бәхәскә керү ярап бетәр микән?!

— Ярамаса, яратырбыз!

— Бу эшеңә мин катнашмыйм, үзең кара,— диде сак Габдрахманов.

Товарга бәһа куя башлагач та тоткарлык килеп чыкты, кирәкле прейскурантлар җитеп бетми икән. Чит ил товарларына прейскурантлар юк дәрәҗәсендә.

— Хәзерге кадәр безнең кибеткә чит ил товарлары бик сирәк килеп керә иде,— дип аңлатты Габдрахманов.

Торгтан прейскурантлар табып китергәнче, нидер эшләргә кирәк иде, кул кушырып тик утырырга яратмаган Әлфия бәһа куюны мамык шәлләрдән башлады. Фабричный булмаганга аларга бәяне болай гына да куеп була, шәлләр кул белән бәйләнгән. Мондый йоп-йомшак, җепҗиңел, зур, учка сыеп бетәрлек затлы шәлләрне Әлфиянең базарда сирәк-мирәк күргәләгәне бар иде.

— Заказ биреп бәйләнгән шәлләр булса кирәк, сирәк очрый торган затлы мал, чит булмас — ал берсен үзеңә! — диде Габдрахманов, шәлләрне тоткалап карагач.

Әлфия көлемсерәде:

— Гомеремдә шәл күрмәсәм дә, алачагым юк. Бу шәлләр берәүне үлемгә китерделәр инде, җитәр!

Габдрахмановның Әлфиядә түгел эше, үзенең бер шәлне эләктерәсе килә, ал, дип, кызның җебен тартыр өчен генә әйткән иде.

Әлфия һәр шәлнең зурлыгын, иңен-буен метрлап үлчәгәч, бәяләрен кибеттә сатыла торган шәлләргә тәңгәл итеп куйды.

— Бик арзан була түгелме? — диде Габдрахманов иреннәрен ялап.

— Базарда шәлләр кыйммәтрәк йөри, әлбәттә. Ләкин без халыкның сыртын тунар өчен куелмаган.

— Белеп эш итегез, болай да спекулянт кулына барып эләгүләре ихтимал.

— Хәзер спекулянт кулына эләкми торган юлы бар ич аның!

Әлфия шәлләргә бәһасен күрсәткән биркалар такты да сатуга чыгарды.

— Нишлисез сез? Харап булабыз ич! — диде куркынып Габдрахманов.

Әлфия прилавка янына басып, шәлләр сатылып беткәнче каравыллап торды. Аларны минут эчендә алып бетерделәр. Шәлләр сатылып бетеп ярты сәгать тә үтмәгәндер, кибет алдына милиция машинасы килеп туктады. Атылып-бәрелеп, мышкылдап кибеткә Хәсбиуллин килеп керде.

— Шәлләр кайда?

— Нигә болай кычкырасыз? — диде көлемсерәп Әлфия.— Тыныч кына сорарга да буладыр ич?

— Кем рөхсәте белән аларны сатуга чыгардыгыз?

— Бар андый рөхсәт, без шуңа таяндык,— дип, Әлфия аңа инструкцияне күрсәтте.

— Алай! — диде Хәсбиуллин, тагын да ярсып.— Сез мине, милиция подполковнигын, саннамаска маташасыз икән!

— Сез подполковник кына, ә мин үз эшемдә бүгеннән генерал!

Аһ, кызын күрсә иде шушы мизгелләрдә Хәбирә апа! Аның Әлфиясеме бу? Кайчан гына бер чиләк күкәй күтәреп калага юнәлгән юаш баламы? Милиция белән пәрмә-пәр сөйләшә, сүз өчен кесәгә кереп тормый. Дөресен әйткәндә, Әлфиянең милиция хезмәткәрләренә нәфрәте байтактан, калага килгән көннәрдән үк башланды. Кайчандыр авылдашлары булган әрсез Мәхмүтнең, айлар буена, йорт салынып беткәнче, керә-чыга йөрүе, кергән саен күзе тонганчы аракы чөмерүе, җизнәсе белән апасының шул көчектән кан калтырап торулары аны бүгенге ныклыкка, тел үткерлегенә китергән иде. Хәсбиуллин шартларга җитеште, ул мондый сүзләрне ишетергә күнекмәгән иде. Шулай ныклярсыды, сүз әйтә алмас булды, хәленнән килсә, Әлфияне өзгәләп ташлар иде. Әгәр Габдрахманов, бүтән кибетчеләр карап тормаса, ул бу башбирмәс кызны машинасына төртеп кертеп, үзе белән алып китәр иде. Баргач, сәбәбен уйлап табарлар иде әле.

Әлфия прейскурантларны актарырга керешкән иде, җилкәсе аша ярсып сулап торган Хәсбиуллинга борылып:

— Эшләргә ирек бирегез, комачауламагыз,— диде.— Эш урыныгызда, дәрәҗәдән файдаланырга өйрәнгәнсез, күрәм. Яхшылык белән хәзер үк чыгып китмәсәгез, бөтен эшемне ташлыйм да туп-туры райкомга барам.

Бу ни хәл? Бу нинди явызлык? Хәсбиуллин гына түгел, Габдрахманов та шашып калды, ярый әле аның кибетендә мондый кире беткән сатучылар юк, моның белән яшәү мөмкин түгел... Әлфия хаклыкның үз ягында икәнен бик белеп сөйләшә, ул телгә алган инструкциядә милиция хезмәткәрләренә конфискацияләнгән товарны сатып алу катгый тыела. «Бүтән чакта бәйләнер нәрсә чокып чыгарыр бу бәндә, бүген исә кул кыска!» — дип уйлады Әлфия. «Конфискацияләнгән товарларны

реализацияләү» дигән темага ул күптән түгел курс эше язып «бишле» билгесе алган иде. Бүген бик ярап куйды «бишлесе!»

Хәсбиуллин ОБХССта күптәннән эшли, райфо хезмәткәрләренең күпчелеген яхшы белә иде. Шунысы гаҗәп иде — шактый җәнҗаллы бу кыз өстеннән аның кулына моңарчы бер материал да кермәгән икән! Моңарчы ник кызыксынмаган ул аның белән? Бүген үк, хәзер үк аның кемлеген ачыкларга кирәк! Кояшта да таплар бар, бер-бер чатагы чыкмыйча калмас!

Хәсбиуллин киткәч, инде тынычлап эшлим, дип җиңел сулаганда, аны эзләп кибеткә бер кеше килеп керде. Күрер күзгә яшь кенә булса да, йөзе таушалган, күз карашы боек, моңсу иде бу адәмнең. Әдәп белән генә борчуы өчен гафу үтенде.

— Бар өметем сездә, коткарыгыз. Тормышым бозылды, зинһар ярдәм итегез,— диде.

Әлфия аны кибеттә эшләүче берәр хезмәткәрне эзләп килгән дә, үзенә ялгыш мөрәҗәгать итә дип уйлады.

— Сезгә кем кирәк? — дип сорады ул, бик аптырап.

— Мин әле генә райфода булдым. Анда эшләүчеләр өйрәтеп җибәрде мине. Әлфия Сабитова сез буласыздыр ич?

— Мин булам. Йомышыгызны әйтеп карагыз алайса.

— Минем самолетта югалган чемоданымны аэропорттан сезгә тапшырганнар.

Юлчыларның самолеттамы, тимер юлдамы, пароходтамы онытып калдырган әйберләре, алты ай эчендә хуҗасы табылмаса, реализацияләп, акчасын дәүләт файдасына күчерер өчен, финанс оешмаларына тапшырыла. Әлфия янына гозер белән килгән кеше — фамилиясе Ибраһимов — санаторийдан кайтканда чемоданын югалткан. Дөресрәге, өенә нәкъ үзенеке төсле чит чемодан күтәреп кайтып кергән.

Ибраһимов сөйләвенә караганда, ул Кисловодск кибетләреннән хатынына кыйммәтле бүләкләр алган булган. Кайтып кереп, хатынын чакырып китереп, чемоданын ачса — бүләкләрнең берсе дә юк. Аңа шактый керләнгән хатын-кыз кием-салымнары дыңгычлап тутырылган! Хатын өйдә буран куптара. Китә ызгыш, җәнҗал башлана.

— Аерылышыр дәрәҗәгә җиттек инде. Бер гаепсезгә бит! Ләкин гаебем юклыкны ничек исбатларга да хатынны ничек ышандырырга?

— Ничек исбат итмәкче буласыз?

— Йөри торгач, чемоданның эзенә төштек. Шөкер, мин чемоданын алыштырып киткән хатын юньле кеше булган. Моннан ике ай элек чемодан сезнең кулга килеп кергән. Райфога.

— Без әйбер-караларны озак асрамыйбыз. Сезнең әйберләр әллә кайчан сатылгандыр. Бусы — бер. Тагын шунысы, сез әйткән чорда, хуҗасыз калган әйбер-караны реализацияләү белән бүтән кеше шөгыльләнә иде. Дөрес, ул бездән эштән китте. Бүтән шәһәргә күчте.

— Миңа әйбер дә, сатылган булса, акчасы да кирәкми. Чәнчелеп китсен! Минем намуслы исемем генә кире кайтсын! Чемоданымның тәгаен сезгә килеп керүен раслап язу бирсәгез, миңа шул җитә.

Әлфия уйга калды. Мондый чакта ашыгыч вәгъдә бирергә һич ярамый иде, соңгы чиккә җиткән кеше йөрәгенә яра өстенә яра өстәрсең!

— Сез уйлаганча җиңел генә эш итә алмыйбыз без, иптәш. Иң элек чемоданыгызның безгә килеп керүен ачыкларга кирәк.

— Менә аэропорт биргән белешмә.

Ибраһимов аэропортның саклык камерасыннан кәгазь алып килгән икән. Әлфия аны бик җентеклән укып чыкты.

— Алардан белешмә алып яхшы иткәнсез. Ләкин бу эшне ачыклар өчен, райфодагы документларны күтәрергә кирәк. Сезнең гозерне тыңлап, мин өйлән соң кайтырга тырышырмын. Шунда килерсез, эзләп карарбыз.

Ибраһимов райфога килгәндә, Әлфия анда иде инде. Ул «Конфискацияләнгән һәм хуҗасыз милекне исәпкә алу» кенәгәсеннән үзенә кирәкле эшне эзләп табып, дикъкать белән шуны өйрәнә иде.

— Сезнең чемоданда нинди әйберләр бар иде, иптәш Ибраһимов?

— Трикотаж костюм, ике нейлон күлмәк, бер пар туфли, хатынга алган бүләкләр,— дип саный башлады Ибраһимов.

— Алар нинди хәлдә иде?

— Ничек — нинди хәлдә?

— Искеме, яңамы, диюем.

— Кем инде ялга барганда иске-москы өстерәп йөри? — Ибраһимов бик нык гаҗәпләнде.— Трикотаж костюмны юкка гына йөк итеп йөрткәнмен, кияргә дә туры килмәде. Аның бәһасы бар. Шактый акча тора ул! Хатыныма бүләккә иске киемнәр җыеп кайтаммы мин? Өр-яңа кофта алдым. Анысы мең ярым тора!

Әлфия Ибраһимовка Юныс тарафыннан төзелгән актны тоттырды.

— Сезнең чемоданыгыз, иптәш Ибраһимов, кибеткә барып җитмәгән.

— Кая киткән соң ул? — Ибраһимовның төсе үзгәрде, чемодан тагын эзсез югалган икән, дип хафаланды.

— Актны укыгыз, аңларсыз.

Ниләр генә язылмаган иде актка! Трикотаж костюм булган — аны көя кисеп бетергән. Нейлон күлмәкләр канга буялган... Туфляның табаны купкан. Кием-салымнарны, кофтаны... Эштән чыгарып күрсәтер өчен нинди генә сүз табылмаган да нинди бәяләр бирелмәгән! Актка райфоның өлкән инспекторы белән аэропорттагы саклык камерасының кизү хезмәткәре кул куйган. Соңгысының имзасын аерырлык түгел, таракан йөгереп үткән.

Ибраһимов гасабиланып актны кат-кат укып чыкты.

— Әйберләр минекенә охшаган. Ләкин мондый кәгазьне явыз жуликлар язган булырга тиеш.

— Үзегез күреп торасыз, бу актка таянып, сез райфодан акча таләп итә алмыйсыз.

— Акчасы кадалып китсен! Башта үзем җүләр булдым, исәңгерәп йөреп, чемоданны эзләтмәдем. Тәмам аңгырайдым. Шуннан акыллы кешеләр киңәш бирде, эзлә дә эзлә, диләр, бәлки, очына чыгарсың... Акча! Гаиләне акча ялгыймы? Миңа белешмә бирсәгез, шул җиткән.

Әлфия тагын уйга калды.

— Юк, алай ансат хәл итәргә ярамый. Монда нидер бар!

— Мин нишлим инде хәзер?

— Прокурорга барырга кирәк.— Ибраһимов кул гына селтәде.— Без белешмәне бирербез. Ләкин сезнең әйберләрне үзләштергән жулик фаш ителергә тиеш.

Икенче көнне Әлфия туп-туры аэропортка китте. Саклык камераларының башлыгы хуҗасыз чемоданнарны райфога тапшырганда, эчтәге әйбер-караларның нинди хәлдә булуын тасвирлап, опись төзеп бара икән. Описьның күчермәсе аларда саклanганга, ул бик ансат кына Ибраһимов чемоданына төзелгән кәгазьне эзләп тапты. Озак баш ватарга да туры килмәде. Юныс, описьның төп нөсхәсен юкка чыгарып, саклык камералары вәкиле белән икесе исеменнән, ялган акт төзегән.

— Минем мондый актка кул куйганым юк, фальшивка бу! — диде камералар хуҗасы.

Әлфия тагын бер кат описьның саклык камерасында калган күчермәсен күзеннән үткәрде: Ибраһимов әйткәнчә, чемодандагы барлык әйберләр дә өр-яңа булганнар. Описьта Юнысның имзасы да ярылып ята. Юныс Гыйльметдинович райфода эшләгәндә бик күп авызларны бикләгән иде, авызлар тоташ ачылдылар, җитәрлек күзәтү булмаудан файдаланып, хезмәткәрләрнең күзе күрмәвенә таянып, Юныс бик еш

дәүләт кесәсенә кул сузган икән, моның караңгы тамырлары шактый ук еракка киткән иде...

Әлфиянең абруе берьюлы үсеп китте. Аның белән азау теше ярган финансистлар да исәпләшә башлады, аеруча четерекле эшләрне райфо мөдире аңа тапшырды. Райбашкармада, Әлфия Сабитованы институт тәмамлаганчы ук налог һәм җыемнар инспекциясенең өлкән хезмәткәре итәргә җыеналар, дигән хәбәр таралды.

Әлфия кая басканын белмичә очып кына йөрде. Инде вәгъдәләре чынга ашып, Мансурны да институтка кире алсалар... Бер-бер җай белән квартира ягы да рәтләнсә... Күп шул әле алда торган киртәләр, бик күп шул, берсен үтеп киттем, дип кенә юанасың, тагын каяндыр каршылык килеп чыга. Мансурның көннән-көн ныграк борчылуын, кыйналуын күреп, Әлфия аңа үзе тикшергән бер эшне сөйләп бирде.

— Бар ул дөньяда батыр кешеләр, үз көчләренә ышанган, намуслы яшәүләренә таянган искиткеч кызыклы кешеләрнең берсе...— дип башлап китте ул сүзен.

...Инде эш бетәргә якынлаша иде. Хатын-кызлар аяк киемнәрен алмашалар, сумкаларын тотып буфет тирәсен урап киләләр, гайбәт сөйләшәләр. Әлфия катына Иван Иванович Балабанов дигән кеше килеп керде. Байтактан пенсиядә булса да, нык гәүдәле, ачык карашлы, тоташтан чал чәчле бу кеше нигәдер Әлфиягә ошап китте. «Иртәгә килегез, бүген соң инде»,— дип әйтергә ачылган авызы:

— Сөйләгез, мин сезне тыңлыйм, Иван Иванович,— диде.

Югары белемле бу инженер гомере буе урман хуҗалыгында эшләгән. Һич уйламаганда, Балабанов өстеннән җинаять эше кузгаталар, җиде елга төрмәгә утырталар, партиядән чыгаралар һәм бөтен малмөлкәтен хөкүмәт файдасына тартып алалар. Туктамый Балабанов, сынып төшми, хаксызлыкка буйсынмый, көн яза, төн яза, Мәскәүне дә борчый, Казанга да тынгылык бирми. Ниһаять, надзор буенча прокурор эшне кире кайтара һәм Татарстанның Югары суды аны тулысынча аклый. РСФСР Югары суды бу карарны раслый. Балабанов төрмәдән котылып өенә кайта...

Ул бүген Әлфия янына РСФСР Югары суды карарын алып килгән икән. Карарда Балабановның аклануын һәм конфискацияләнгән милкенең аресттан азат ителүе язылган. Тору урынындагы финанс оешмасына аресттан азат ителгән милекне тулысы белән хуҗасына кайтарып бирергә боерылган. Кызганычка каршы, райфода Балабановның милкен конфискацияләү турында бернинди мәгълүмат юк иде.

— Сезне кайда хөкем иткәннәр иде, Иван Иванович? — дип сорады Әлфия.

— Үзебезнең районда.

— Кайда яши идегез?

— Сездән ерак түгел, әнә теге чатта.

Закон буенча милек, хөкем ителгән кешенең яшәү урынындагы район финанс бүлегенә тапшырылырга тиеш.

— Сезнең милекне хөкем карары чыкканчы кая һәм кемгә тапшырдылар?

— Эчке эшләр министрлыгының саклау камераларына.

— Аңлашылды,— диде Әлфия, бөтенләй үк аңлашылып бетмәсә дә.

Аның уен алдан ук сизенгән шикелле, Балабанов Әлфиягә бик таныш кешенең исемен атады.

— Өйдән подполковник Хәсбиуллин алып киткән.

— Аны күреп сөйләштегезме?

— Янына барып карадым, сөйләшергә дә теләми.

— Гаебен сизәме әллә?

— Белмим, йорим, йорим, ничек очына чыгарга да белмим. Ләкин барыбер очына чыгачакмын!

— Бу эшне, Иван Иванович, прокурордан башка хәл итеп тә булмас.

— Булдым. Прокурорны күреп сөйләштем. Сезнең янга мине ул җибәрде.

Шактый озак сөйләшеп утырдылар алар, иртәгесен Әлфия МООП белән элемтәгә керде. Алардан «Балабанов милке Югары оешманың махсус күрсәтмәсе белән Мәскәүгә җибәрелде»,— дигән җавап алынды. Әлфия райфода озаграк эшләгәннәрдән белеште: «Безнең эш практикасында андый хәлнең булганы юк»,— диделәр аңа. Димәк, кемдер астыртын эш йөртә, нинди махсус күрсәтмә булырга мөмкин? Кемгә андый хокук бирелгән? Ни өчен андый чара Балабанов милкенә карата гына күрелгән? Кайбер кешеләр, юк белән чуалма, кечеңне генә әрәм итәрсең, прокурор эшенә тыгылма, соңра тешеңне җыеп ала алмассың,— диделәр. Ә Балабанов аңа ышана, көн саен диярлек кагылып чыга, көтә, өметләнә. Юк, Әлфия андый кешене урамда хәерче хәлендә калдыра алмый, бер тотынган икән, азагына кадәр барачак.

Әлфия Балабановтан суд башкаручысы тарафыннан төзелгән описьның күчермәсен соратып алды. Опись бәләкәй түгел — тәгәл илле биттән тора! Аны үз эшен тирәнтен белә торган тәҗрибәле суд башкаручысы төзегән. Югала торган әйберләр юк та анда! Һәммә нәрсә ваклыкларына кадәр тасвирланган. Беренче номер итеп «Волга» машинасы теркәлгән. Алтын-көмеш, бизәнү әйберләре, җиһазлар, савыт-саба — болар берсе дә югалган яки төшеп калган нәрсәләр түгел. Балабановның әйтүенә карагэнда, язмага алынган милек арасында иң кыйммәтлесе — ау мылтыгы.

— Андый мылтык Союзда икәү генә,— диде ул.— Аларны патша гаиләсенең заказы буенча атаклы немец остасы эшләгән. Мылтыкка оптик җайланма көйләнгән.

Бу байлыкны чын хуҗасына кайтару буенча ашыгыч чара күрүне үтенеп, Әлфия горфога мөрәҗәгать итте.

— Була торган эш түгел,— диделәр анда.

Әлфия бер сүзгә дә карамады, ялгыз башы дәреслекне эзләргә кереште.

— Маташма, муеныңны сындырырсың,— дип куркытырга теләделәр.

— Бер сынганнан әллә ни булмас! — дип, Әлфия аны да уен-көлкегә алды.

Ул бер-бер артлы югары оешмаларга хат, үтенечләр язарга тотынды. Башта республика прокурорына хат язды, җавап килмәде. Җәмәгать тәртибен саклау министрлыгына язып карады, җавап ОБХССтан килде. Хатка Хәсбиуллин кул куйган иде. Ул хатта: «Балабановның милке кибетләр аша реализацияләнгән, акчасы бюджетка күчерелгән»,— диелгән иде. Кайсы бюджетка, суммасы күпме, ул турыда ләм-мим.

Әлфиянең ярты юлда туктарга исәбе юк иде. Мәскәүгә, РСФСР прокурорына хат юллады. Аннан: «Хатыгыз, тиешле чара күрү өчен, Татарстан министрлыгына җибәрелде»,— дигән кыска гына җавап килде. Чара күрүче әлегә табылмады, күп оешмалар кеше язмышына төкереп карадылар, бу гаделсезлек Әлфияне суытмады, киресенчә, кыздырды гына. Уйлап-уйлап йөрде дә конфискацияләнгән һәм хуҗасыз милекнең тәртибен билгеләгән оешмага — СССР Финанс министрлыгының дәүләт доходлары идарәсенә хат юллады.

Хат китеп, бер атна вакыт узгач, райфо мөдире Король Әлфияне үз янына дәшеп кертте. Аның янында кырыс кына милиция полковнигы утыра иде. Полковникның үзен тотышы Әлфиягә бер дә ошамады, әйтерсең лә, кабинетка хуҗа булып алган. Өстен салган, мөдир урынына кереп утырган, йодрыкларын өстәлгә куйган.

— Сез тиешсез эшкә керешкәнсез,— диде ул.

— Минем андый эшкә керешкәнем юк.

— Намуслы хезмәткәрләргә яла ягасыз!

— Аңлатыбрак сөйләвегезне үтенәм!

— Өч тиен тормаган бер эш өчен. Союз күләмендә гауга күтәреп, республикага кара тап төшерәсез! Башыгыз эшлиме сезнең, юкмы?

Әлфиягә урын тәкъдим итүче булмады, авырлы килеш басып торырга теләмәгәнгә, ул җайлап кына бер кырыйдагы урындыкка барып утырды.

— Сезнең грандиоз зур эшләр янында безнең эш, бәлки, өч тиенлектер. Ә безнең өчен ул — намус эше. Көпә-көндез кешене төрмәгә утыртып куялар. Исеменә пычрак ягалар. Җитмәсә, бар мал-мөлкәтен талап алалар. Өч тиенлек кенә мал түгел анда.

Полковник мөдиргә карап алды.

— Сезнең хезмәткәрләрнең телен чарлыйлар икән,— диде.— Балабановны, төптән уйлаганда, гаепсез утыртмаганнар. Андыйларның тамырын корытырга кирәк.

— Мүкләк сыерга ходай мөгез бирми, ди татарлар.

Полковник Корольгә ташланды.

— Мондый җәнҗалчыны эштә ничек тотасыз сез? Сүз әйтер хәл юк! Ә сез битараф килеш утырасыз да утырасыз! Чылбырдан ычкынган...

Мөдир күңеленнән генә Әлфия белән килешеп, аңа сокланып утыра иде. Ул аны шундый кыю, чая дип күз алдына да китерә алмый иде.

— Сез, иптәш полковник, безнең хезмәткәрне «чылбырдан ычкынган эт» дип атаганда мин түзмәм... Сезгә дә саграк, уйлабрак сөйләшергә киңәш итәр идем.

— Гафу итегез, кызыбрак кителгән.

Ул Король үзен яклар дип өмет иткән, күрәсең, яклау тапмагач, чигенергә мәҗбүр булды.

— Сез Балабановның кем икәнен белмисез! Белсәгез, бөтенләй башкача сөйләшер идегез.

Әлфия Балабанов белән якыннан танышып киткән иде инде. Юридик яктан өзеп сүз әйтә алмаса да, Балабанов кеше буларак аңа нык ошады. Эшлекле кеше — югары белемле. Гомерен Мари урманнарында үткәргән. Ничәмә еллар дәвамында урман кистереп, немецлардан азат ителгән районнарга агач материаллары озатып торган. Такта яруны оештырган. Эшелоны-эшелоны белән Көнбатыш районнарга такта җибәреп торган, ике ел рәттән орден белән бүләкләгәннәр. Хезмәт өчен түләү аккордлы булган. Нык эшләгәннәр, мул итеп акчасын да алганнар. Әнә ул кайберәүләргә ошамаган. Эшлекле янында һәрвакыт ялкау була. Бу фикерне аңа Мансур әйткән иде инде.

Балабанов белән сөйләшеп, эш белән танышып чыккач, Әлфия үзе дә шул фикергә килде.

— Череп баеган. Әллә эштән алган акчага баеганмы?

— Алайса Татарстан Югары суды аны нигә аклаган? РСФСР Югары суды бу карарны раслаган.

Полковник кулын гына селтәде.

— Беләбез без ничек аклауларын! Акчага бөтенесен эшләп була.

Җаваплы урында утыручы милиция полковнигы авызыннан мондый сүзне ишетеп, Әлфия үз колакларына үзе ышанмады.

— Сезнеңчә, судларның барысында да сатлык җаннар утыра булып чыга!

Полковникның торган саен ачуы кабара, кызның үҗәтлеге, үз сүзен сүз итәргә маташуы канын котырта, кызып китеп ялгыш фикер ычкындыруын да сизә, әммә ярсуын тыя да алмый иде.

— Ярар, бу хакта сүзне кыскартыйк. Без хәл итә торган эш түгел.— Ул Әлфияне бөгеп булмаслыгын, райфо мөдиренең дә аңа тартылуын күреп, икенче төрле сукалый башлады.— Буласы булган! Балабановны коткарганнар. Яшермим, мондый хәл бездә сирәк була. Минем сезгә булышасым, эшегезне җиңеләйтәсем килә. Хәзер Балабановның милкен кайтару мөмкинлеге калмаган. Язмагыз төрле якка хатлар! Малы

әллә кайчан сатылган, акчасы безнең хисапта. Болай итик, сез безгә нәни генә хат язасыз, ә акчаны без аның үзенә кайтарабыз. Ризалаштыкмы?

Бу юлы мөдир сүз кыстырды.

— Сез безне бер катлы тинтәкләр дип уйлыйсызмы? Соңгы сүз хокукын сезгә тапшырсак, әлерәк кенә төрмәдән чыккан Балабановны куркытып, теләсә нинди якка бөгәрбез, дип уйлыйсызмы?

— Җәлләп әйтәм, авыр, булмастай эшкә тотынгансыз.

— Без эштән курыкмыйбыз,— диде Әлфия.— Закон бар, без шуңа таянабыз.

Полковник Әлфия утырган якка карамый да иде хәзер, ул мөдир урыныннан чыгып, аның янына килеп басты.

— Эшне зурга җибәрмәссез дип уйлыйм. Безнең белән дус яшәргә киңәш итәр идем. Без дус яшәргә тырышабыз, в конце концов! Үзем килмичә, мин монда берәр старшинаны гына җибәрә ала идем.

Король салмак кына, һәр сүзен үлчәүгә салып җавап бирде.

— Безнең югары оешмабыз бар. Алар белән киңәш итеп карарбыз.

Әлфия әңгәмә-бәхәснең шулай килешенә язып тәмамлануы белән һич ризалаша алмады.

— Балабановның төгәл описька алган милке судка кадәр сезгә сакларга тапшырылган булган. Описьтә язылганнар тулысынча хуҗасына кайтарып бирелгәнче, мин тынычланачак түгел. Әгәр мал реализацияләнгән икән, закон нигезендә җавап бирерсез.— Мөдирнең үзенә төбәлгән ягымлы карашын сизеп, Әлфия сүзен дәвам иттерде.— Сез, Николай Константинович, теләсә нәрсә әйтегез, мин бүген үк үз исемемнән МООПның явыз ният белән закон бозуы турында Үзәк Комитетка телеграмма сугам. Без барыбыз да законнарны һәм кеше хокукларын хөрмәт итәргә тиеш.

Әлфия кыек атып туры тидерде: беренче көннән җәмәгать тәртибен саклау министрлыгыннан «хөкем карары чыкканчы, аларга сакларга тапшырылган милекне алырга» чакырып хат килде. Әлфия үзе белән милек хуҗасы Балабановны да ияртеп барды.

Аларны ярым караңгы, озынча бер бүлмәгә алып керделәр.

— Әнә, бар булганы шунда. Опись буенча эзләп алыгыз,— диде тәбәнәк кенә бер капитан, ачкычларын ачу белән селкә-селкә.

Төрле-төрле әйберләр бинаның дүрт почмагына дыңгычлап тутырылган иде. Нәрсә-караларны теләсә ничек кертеп атканнар, шкафларның ишекләре каерылган, креслоларның аягы сынган, кием-салымнарның байтагысы пычранып, таушалып беткән. «Волга» ишегалдында, ачык һавада, чүп әрҗәсе белән янәшә тора иде. Аның тышкы кабыгы гына калган, кыйммәтле частьләрен сүтеп алганнар.

Ау мылтыгы хакында саклау камерасы начальнигы капитан бернәрсә дә белми. Көне буе казынсалар да, Балабановның әйберләре табылмады диярлек. Бүлмәдән бүлмәгә йөреп сораша торгач, мылтыкның язмышы бераз ачыкланды — мылтыкны исемен фаш итәргә ярамый торган Мәскәүдән килгән милиция генералы алып киткән икән. Описька алынган кыйммәтле әйберләрнең яртысыннан артыгы юкка чыккан.

— Алары да аякланып Мәскәү ягына китмәдерләрме соң? — дип сорагач, капитан һаман ачкычлары белән уйнап, погоннарын гына сикертте.

Әлфия бу хакта акт төзеп, югалган әйберләрнең бәһасен эзләп алу турында судта эш кузгатты.

Ничектер сакланып калган бизәкле бер вазаны чүп арасыннан тапкач, Балабанов Әлфиягә бүләк итәргә теләде, Әлфия алмады...

Сугыш вакытында тәмам җимерелгән, бөлгенлеккә төшкән җирле предприятиеләр, нык кына аякка басып, елдан-ел көчәйделәр, халык хуҗалыгы хаҗәтләрен үтәргә тырыштылар. Алардан алына торган түлә-

үләрнең күләме дәүләт бюджетында хәлиткеч факторга әйләнде. Халыктан җыела торган налогларның суммасы күзгә күренеп кимеде. Керемнәрнең, табыштан түләүләрнең исәп-хисаплары шулкадәр катлауланды, аларның дөреслеген һәм төгәллеген махсус экономик белемле хезмәткәрләр генә тикшерә ала иде. Эшнең шул якларын искә алып, райфоларда үзгәрешләр ясалды. Дәүләт керемнәре һәм халыктан алына торган налогларның инспекцияләре берләштерелде. Берләштерелгән инспекция начальнигы бер үк вакытта райфо мөдиренең урынбасары булып та китте. Король һич икеләнеп тормады, урынбасар вазифасын Әлфиягә тәкъдим итте. Әлфия, эштә тәҗрибәсе җитмәвен сәбәп итеп, баш тартып маташкан иде, мөдир:

— Авызыңны да ачма! — диде.— Бу эшкә син — иң лаеклы кеше. Алдагы көнне дә уйлага кирәк, гомер буе инспектор булып налог җыеп йөрмәссең. Хәзер син иң авыр мәктәпне үткән кадр.

Дәүләт доходлары инспекциясенең яңа билгеләнгән хезмәткәрләрен министр кабул итте. Министр олы яшьтәге, түбәннән югарыга күтәрелгән, таләпчән һәм абруйлы кеше иде. Ул җыелганнарның белеме белән кызыксынды. Арада читтән торып институтта укучы Әлфия берүзе булып чыкты. Соңгы сүзендә министр аны үрнәк итеп телгә алды. Әлфия министр яныннан канатланып чыкты...

Район предприятиеләре дәүләт бюджетына квартал саен йөз миллионнан артык акча түлиләр. Шул байлыкның дөрес исәпләнүен һәм билгеләнгән срокта бюджетка керүен Әлфия тәэмин итәргә тиеш. Кызыл утызлыгын учына йомарлап шәһәргә ашкынган Казан арты кызы бүген миллионнар белән эш йөртә. Әлфия кыю бала, ул миллионнар белән эш итәргә тиз күнекте, кайбер вак-төяк эшләрне хәл иткәндә генә тормыш аны киртәгә китереп терәде.

Райфога халык судыннан ашыгыч үтәлергә тиешле ике «Исполнительный лист» килеп керде. Беренчесен үтәмәскә җай юк, гаделхөкем! Икенчесе — гаделсезлекнең кычкырып торганы!

Халык судыннан килгән башкару кәгазе нигезендә ике йортны дәүләт файдасына алып, җирле советларның торак фонды балансына бирергә кирәк. Моның өчен әллә ни баш ватасы юк, биш-ун минутта хәл ителәсе эшләр. Стандарт форма белән райбашкарма утырышының карар проектын язасың да — вәссәләм!

Әлфия кичә үк кергән бу кәгазьләргә тотынырга куркып утырды да тәрәзә каршысына килеп басты. Ике иңендә ике авыр уй аның. Икесе дә аның үткәненә, Казанга аяк баскан көннәргә әйләнеп кайта. Башкару кәгазенең берсе — Әлфиянең яраткан җизнәсе Хәлим Сәлимовның Бакалтай чүплегеннән күтәреп ташып, ватык-потык әрҗә такталарыннан рөхсәтсез, мең газаплар күреп, интегеп салган йортын конфискацияләү турында чыгарылган хөкем карары иде.

«И, апа, апа! — дип ачыргаланды аның күңеле.— Тал чыбыгы белән артыңны бер ярасы иде дә...» Бу аның үз сүзләре түгел, ачуы нык кабарса мәрхүм өткәсе шулай дип ычкындыра торган иде. «Җизни белән Равил кызганыч!..»

Мәсьәләнең икенче бер четерекле ягы бар — рөхсәтсез салынган йортларны җирле советлар үз балансларына алмыйлар. Шуны белгән хәлдә карар проектын язып райбашкарма өстәленә кертеп салырга кирәк. Шул эш эшләнмәсә, «Карар үтәлмәгән!» — дип халык суды тавыш күтәрәчәк.

Башкару кәгазенең икенчесе — Гөлсем Шакированың йортын дәүләт файдасына тартып алу турында иде. Хөкем карарында: «Йортны хуҗасына торыр урын бирмичә конфискацияләргә»,— дип әйтелгән.

Димәк, күпме изге эшләр үтәгән, күпме ятим күңелләргә җылы биргән Гөлсем апаны картаймыш көнендә урамга куып чыгаралар.

Ул бүген дә тиешле кәгазьләрне райбашкармага җибәрмәде. Гөл-

сем апасы өчен көне буе йөрәгә әрнеде. Авылдаш апасы булганы өчен генә түгел, аның йөрәген гаделсезлеккә нәфрәт телгәләде. Сыңар канат, ире ил азатлыгы өчен тормышын биргән, сугыш аны ялгыз калдырган һәм менә сиңа... рәхмәт!

Кич белән райфога, аны алырга Мансур килеп җитте. Күзләре көләч, авызы ерык иде. Ул тыела алмыйча яңалыкларны тезә башлады:

— Әлфия, кадерлем, мине яңадан эшкә алалар! Теге бүлмәне үзебезгә кайтаралар! Көзгә фатир булуы да бик ихтимал! Минем урынга кибеткә йөкче булып ялланырга кем килгәнен беләсеңме? Белсәң, көлеп үләр идең! Юныс Гыйльметдинов! Әгәр Рәхимҗан булмаса, алалар иде. Рәхимҗан аяк терәп каршы килде. Әгәр аласыз икән, мин китәм, ди. Беләм мин бу йолкышны, кая басса да урынын пычрата, ди. Тәки алмадылар!

Әлфиясе ул көткәнчә көлмәде дә, елмаймады да, җавап та бирмәде, ул Гөлсемнең язмышын сөйләп бирде.

— Гөлсем апага берәр ярдәм күрсәтеп булырмы? — дип сорады.

— Уйларга кирәк.

— Уйлап торырга вакыт юк!

Зәйтүнә судына яллаган адвокат белән Мансур соңгы вакытларда танышып, якынаеп киткән иде. Иртәгә үк шуны күреп сөйләшергә булдылар. Шул сәгатьтә үк Гөлсемнәргә киттеләр...

Гөлсемнең өй ишеге төбенә кадәр киерелеп ачылган иде. Әлфия куркып китте: ничә килеп мондый хәлне очратканы юк иде.

— Гөлсем апа!

Җавап булмагач, Әлфия Мансурның җылы кулын ычкындырып эчкә узды. Залда берничә чемодан, төенчекләр күреп, артка чигенде. Әлфия артыннан Мансур да кереп җитте.

— Гөлсем апа, кайда син?

Почмактан үксеп елаган тавыш килде. Гөлсем идәнгә камыш намазлык җәйгән дә гыйбадәт кыла иде. Укып бетергәч, намазлыгын култык астына кыстырып Мансур белән Әлфия янына чыкты.

— Гөлсем апа, бу нинди чемоданнар?

— Теге... Мәхмүт милиционер хатыны белән килеп калдырып китте. Бу йортка без күчәбез, иртәгә үк эзеңне суыт, үзеңә фатир тап, дип кисәттеләр. Һушым китте. Авылдашның баласы бит әле җитмәсә!..

Тикшергән адәмнәрнең явызлыгы, судның гаделсезлеге дә аны шушы кадәр кимсетмәгән иде, йортыннан куып чыгарырга килүченең авылдаш кеше булуы аны таң калдырды.

— Беркая бармыйсың, Гөлсем апа. Синең «Исполнительный листың» миндә. Монда миннән башка берәүнең дә керергә хакы юк.

Әлфия карчыкның күңелен күтәрер өчен әз генә арттырып та җибәрде, мәгәр ул бу минутларда аның өчен һәммәсенә дә риза иде — барыр, күрер, юлын таба, мәгәр Гөлсем апасын нигезендә калдырыр!

Ул залдагы чемоданнарны берәм-берәм оялдына ташырга тотынды. Мансур белән икәү тиз арада өйне чит әйберләрдән бушаттылар.

— Әлфия кызым, кагылма, зинһар, мине харап итәсең! — дип инәлде Гөлсем.

Әлфия белән Мансур өйне тышкы яктан бикләделәр дә Гөлсемне кунарга үзләре белән алып киттеләр.

Иртәгесен Әлфия халык суды рәисе белән элемтәгә керде, милиционер Мәхмүт Гафуровның башбаштаклыгы турында хәбәр итте. Суд рәисе Гөлсем Шакированың кассациясе Югары судта каралганчы, аңа үз йортында яшәп торырга рөхсәт бирде.

...Йортны хуҗасына кире кайтардылар...

*1988—1991*

# ШИГЪРИЯТ

## Мөхәррәм Каюмов

### Дүртенче

Жирнең ничәнче каты бу?..
Ташлар — карт үгез кебек,
Катламнарны тотып тора,
Мөгез очына элеп.
Кузгалмый да, кымшанмый да,
Сыгылмый — шундый чыдам.
Икс тәртә арасында
Басып йоклаган сыман.

Бар нәрсә дә сәер монда:
Һавасы, ташлар моңы.
Шушы буладыр ул, бәлки,
Жир асты патшалыгы?
Урамы бар, йортлары юк,
Йолдызы бар, күге юк.
Түбәнгә киткән күпме юл,
Әллә Жирнең төбе юк?..

Кар эрегән чак диярсең,—
Исертә яз исеннән.
Тамчылар кояш сәламен
Ташыйлар жир өстеннән.
Әйтерсең лә, жылы яңгыр
Яңа гына тукталган,
Салават күпере төсе
Ташларга сеңеп калган...

* * *

Иңгә-иңне куеп өчәү атлый,
Ә каршыга халык — корт күче...
Төркемдә ят кош баласы кебек
Бераз артка калган дүртенче.

Өчәү — алда...
Таш штольня гүя
Мозаикалы зур йорт эче.
Сәнгать дөньясына кергәнмени,—
Хәйран калып бара дүртенче.

Өчәү — алда...
Һәрбер адым саен
Арта кебек йөрәк, дәрт көче.
Көч-куәте сынап каралмаган,—
Яңа кеше әле дүртенче.

Үз күләгәң кебек арттан калмый
Жир астында шөбһә — карт көнче.
Ышаныч һәм шөбһә уртасында
Салмак кына атлый дүртенче.

---

Мөхәррәм КАЮМОВ (1941) — *шагыйрь. Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы. Казанда яши.*

* * *

Күмер, күмер!
Һәрбер бөртегендә —
Кояш нуры, йолдыз яктысы.
Күк болытлар назы, язгы күкрәү,
Чәчрәп очкан яшен чаткысы.

Күмер, күмер!
Тирән катламнарда
Яшеренеп яткан Җир көче.
Әсәрләнеп аның тылсымыннан,
Кайнарлана Туган ил миче.

* * *

Тезелешеп язгы бәбкәләрдәй,
Өчәү бара — егет арттарак.
Тыгыз һава:
— Җәһәтрәк! — диеп,
Җиң очыннан куя тарткалап.
Караңгылык кара томан төсле,
Томан аша тора сизелеп:
Егет күзләрендә сүнмәс өмет,
Уйларында аның изгелек.
Онтылган бар сөю газаплары...
Ул җавапсыз тәүге мәхәббәт
Сүнми һаман күңелендә, шуңа
Тормыш матур, яшәү рәхәт.

Кай яклардан егет, кем атлы ул,
Атасы кем, нинди нәселе?
Юк, болары безгә хаҗәт түгел,
Ул бит гади Кеше исемле.

Мин барам ул шулай...
Очам төсле,
Җир астында үзем бер шахтер.
Заман чирли менә...
Җылы җитми,
Һәрбер шахтер бүген — чын доктор.
Терелтергә кирәк заманаы,
Җылы җитми — күмер сулышы.
Кай төштәндер, бик тирәннән килә
Җирнең эчке чакыру тавышы.

* * *

Мин — төяүче. Штректа калдым.
Көтеп торам күмер акканын.

Гел көттем мин...
Көттем гомер буе
Бәхетемнең ишек какканын.

Чамалардан ашар шатлык көттем,
Күнелемнең ачып капкасын.
Ярый, килмәде ул, юкса йөрәк
Ярылыр иде — алла сакласын.
Чит җирләрдә булды хатлар көткән,
Күмәкләп тә көттек, ялгыз да.
Яшьтәшләргә җавап хаты килде,
Тик язмады миңа бер кыз да...
Һаман көтәм. Күнел тыныч түгел,
Бер могҗиза булыр шикелле.
Итәгемә килеп төшәр кебек
Тулган ай төнлә кителеп.
Гел көттем мин...
Көтеп үткән гомер
Кире кайтмас инде яңадан.
...Шартлатабыз! — диеп, иптәшләрем
Сигнал бирер кебек лавадан.

* * *

Күмер ага...
Куе төтен килә
Елан кебек җирдән шуышып.
Трап буйлап төшә. Аждаһалар
Уйныймыни шулай куышып.
Мин күмелә барам шул төтенгә,
Суга күмелгәндәй эсседә.
Һәм йокыдан уянгандай булдым,
Иптәшләрем төшкәч исемә.
Палубага менгән матрос кебек
Күтәрелдем өскә траптан.
Лава тулган ачы төтен белән.
Һавасына, гүя, ут капкан.
Тын кысыла. Бөркү. Ашаганны
Чыгара ул эчтән актарып.
(Шундый камерада корчангыдан
Дәвалыйлар иде атларны.)
Башларына ябып курткаларын,
Котылмакчы икәү афәттән.
Өлкән шахтер әнә, җан биргәндәй,
Өзгәләнә күмер түшәктә.
Берәм-берәм сөйрәп төштем аска,
Противогазларын кидердем.
Сыгылса да сынмаячак хәзер
Өч агачы шул өч гомернең...
Бик якында, димәк, пласт яна,
Төтен ага язгы су сыман.
Миңа исә хәлсез чуртан кебек
Юл ярасы шул «су» астыннан.
Тимер вагончыкка тезеп салдым
Хезмәттәшләремне янәшә.
Этәм — кузгаталмыйм, вагончыкны
Эләктергән кебек келәшчә.
Көч-куәтем сүрелгәнен әллә
Тәгәрмәчләр шунда сизенде.
Кузгалдылар — әйтәлмичә калдым
Ачы итеп сүгенү сүземне.

Әй куера тәтен, әй куера.
Мин ютәллим, чәчим, абынам.
Төтен түгел, ялкын бәрә кебек
Бездән артта калган янгыннан.
Ачып кидем противогазны мин.
Һава килми. Кем соң алдаган?
Төзек түгел әйбер биргән миңа
Җәяү качкан нәрсә Алладан.
Үгез кебек башны тәрәп этәм,
Ике кулым — ике буферда.
Газапланам агу йоткан кебек,
Һәм егылып калдым ахырда...
Зиһен эшли. Күңелемнән елыйм,
Дымсу җиргә башны бәргәләп.
Вагончыгым китте...
Саф агымга
Тәгәрмәчләр илтер тәгәрәп.
Җирдә ятам...
Юк, мин түгел... егет.
Күз алдында уйный төрле ут.
Йә йолдызлар бии тезелешеп,
Йә атыла яшен ялт та йолт.

* * *

Җаваплылык таләп итә бу чор,—
Вакытында баса вахтага;
Космоска ул башлап очмаса да,
Алдан төшә һәркөн шахтага;
Урман кисә Себер тайгасында,
Төньякларда тимер юл сала;
Һәм һәрвакыт үзе булып кала —
Кай төшендә Җирнең булса да —
Татар егетләре...

* * *

Санамадым, ничә адым үткәч
Өзелде яшь егет сукмагы.
Әйтерсең лә, ул егылу белән
Җир астында тормыш туктады.
Җир өстендә яшәү дәвам итә,
Кеше туа, мәет җирләнә.
Чәчәк ата җимеш агачлары,
Басуларда иген тирбәлә.
Ачып куеп тәрәз канатларын,
Шатлыгыннан кемдер җыр суза.
Күршесенә кара кайгы килгән,—
Күтәрелер микән ялгызы?
Рәнҗетелгән гаделлекне кәтә,
Карт-корылар — җиңел үлемне.
Тамагы тук затка кызык кирәк,
Ачыкканга — икмәк телеме.
Күпме чәчәк — шулкадәре язмыш.

Һәрбер гомер — тормыш бизәге.
Кайда булса афәт, шул ноктадан
Үтә бүген Җирнең үзәге.
Ә исемнәр кала истәлеккә
Ташларда йә мәрмәр тактада.
...Юлда төшеп калган әйбер кебек
Һушсыз ята егет шахтада.

* * *

Ята егет...
Соры шинель кигән
Яшьтәшләре шушы вакытта
Башкаланың урамнары буйлап
Асфальт ватып бара танкта.
Таныш күренеш бу...
Көнбатыштан
Килгәннәр бит шулай бервакыт.
Тик әтиләр әрсез кунакларны
Тукмый-тукмый куйган озатып...
Приказ үти бүген яшь солдатлар
(Тыңлаучанлыкка да була чик!)
Тәхетенә илнең елан кебек
Шуышып килә яңа Пиночет...
Ник егылдың, егет, тыныч халык
Яклауларга мохтаҗ вакытта? —
Ата-анасына каршы бара
Үз уллары әнә танкта.

* * *

Ята егет...
Казан элеккечә
Тыныч кебек — баксаң ерактан.
Ә асылда күптән инде монда
Бикфорд шнурына ут капкан.

Белми егет —
Ерак Казанына
Дөнья карар менә бик тиздән.
Дулкын булып кубар ул көн халык,
Әверелер мәйдан диңгезгә...

* * *

Балачакта өч алмагач алып
Утыртты ул көзен.
Берсе — әти,
Берсе — әни, диде,
Кечкенәсе — үзем.
Агачлары үсте,
Чәчәк атты,
Әйбәт бирде җимеш.
Агач утырту һәм чишмә ачу
Изге, савaплы эш.

Үткән төндә таң алдыннан гына
Күрде коточкыч төш.
Алмагачларының чәчәкләрен
Кырау суккан, имеш.
Уянды ул шабыр тиргә батып,
Дер калтырап тора.
Кемдер әйткән: начар төшеңне дә
Син яхшыга юра.
Белмәде ул ничек юрарга да,
Юш килерме юрау?
Калды шул төш — күңелендә җавап
Табалмаган сорау.
Төштә нигә бакчасында учак
Якмады соң, ахмак.
Өч гомернең алмагачын әмма
Калды бүген саклап...

* * *

Забастовкалардан аңлашуга
Барып життек...
Ләкин замана
Түшәгендә яткан хаста кебек,
Берчә өзгәләнә, бер яна.
Савыктырасы бар заманаңы,
Җылы җитми — йөрәк дәвасы.
Кызганмый як мичкә күмерләрне,
Суынган ич Илнең һавасы.
Ягулыкның келәтләре бушый,
Күңел тора шуңа пошынып.
Пласт яна, гүя, Вакыт яна
Акча белән бергә кушылып.
Һәр адымда афәт саклап тора,
Курку били, йөрәк кысыла.
Сынауларны үтүебез бүген —
Үзебезгә кайту асылда...
Алда әле күпме бусага бар?
Беркем белми. Беркем үтмәгән.
...Агуланган балык кебек, егет
Ята менә төтен-ятьмәдә.
Куркынычлар куркытмыйлар аны,
Үтәләсе бурыч үтәлгән.
Күккә багып кичен хозурланмас,
Чәчәк өзмәс инде түтәлдән.
Бусагалар аръягында ни бар?
Юк, язмаган икән күрергә.
Алмагачларыдай өчәү аңа
Әрнү белән карар гомергә...

## Хөрмәтле укучылар!

*Белгәнегезчә, журналыбыз битләрендә кызыклы роман һәм повестьлар даими басыла килә. Алар арасында татар халкының хәзерге заман тормышын чагылдырган әсәрләр төп урынны алып тора. Мисал өчен, соңгы өч елны гына алсак та, журналыбыз битләрендә татар халкының хәзерге тормышын күрсәтүгә багышланган әсәрләрдән түбәндәгеләр басылган: «А. Гыйләҗев «Балта кем кулында?» (7—8 сан, 1990 ел); М. Маликова «Фидая» (10—11 сан, 1990 ел); З. Хөснияр «Каешлану» (6 сан, 1990 ел); Г. Ахунов «Гомер юлы» (1—2 сан, 1991 ел); Ф. Гыйльми «Зәйтүнәкәй — акчарлагым» (9 сан, 1991 ел); Ә. Баянов «Җәй белән җәй арасы» (6 сан, 1991 ел); Ә. Галиев «Авылдашлар» (9—10 саннар, 1992 ел); А. Хәлим «Өч аяклы ат» (6—7 сан, 1992 ел) һ. б.*

*Менә бу санда без сезнең игътибарга бүгенге көн тормышына багышланган тагын бер яңа роман тәкъдим итәбез һәм, шул уңайдан, сезне якын арада журнал битләрендә башланачак сөйләшүгә чакырабыз. Сөйләшүнең темасы: «Безнең тормыш. Безнең әдәбият».*

*Фикер алышуда барлык укучыларның һәм шулай ук язучыларның, тәнкыйтьчеләрнең актив катнашуларын көтеп калабыз.*

**Фоат Садриев**

# ТАҢ ҖИЛЕ

РОМАН

I

Аны фәрештә дип уйларга мөмкин иде. Кардай ак озын күлмәк, кардай ак яулыгы астыннан күренеп торучы кардай ак чәчләр... Ак фәрештәдәй, ул ямь-яшел Ык буена килеп басты, чыкта юешләнгән чүәкләрен бер-берсенә тери язып якын китерде, җиерчыклар белән бизәлгән йөзе илаһи кыяфәткә керде. Кошлардан башка әле бар җиһан татлы йокыда. Пыяладай шома су өстеннән урыны-урыны белән аксыл пар күтәрелә. Ык аръягындагы яшел куаклар да, зәңгәрләнергә өлгер-

---

Фоат САДРИЕВ (1941) — *әдип, драматург, «Их сез, егетләр», «Кондырлы кодачасы» һәм башка пьесалар, «Шаһзаманов эше» кебек повестьлар һәм хикәяләр авторы. Мөслимдә яши.*

Әсәр кыскартылып, журнал вариантында бирелә.

мәгән күк тә әле төн шәүләсен саклыйлар. Нуриасма башын бераз күтәрде дә карашын Ык аръягы өстеннән йөгертеп, еракка — зәңгәрсу өрфия артында күкләргә ашып торучы Чия тавына юнәлтте. Бу тау аңа кечкенәдән үк әнисенең күкрәген хәтерләтә, тик ул ими очы белән аска түгел, күккә карап тора, әнисе чалкан яткан килеш йоклыйдыр гына, күкрәге сөт белән тулгандыр да, хәзер Нуриасманы имезә башлар кебек... Аның оч ягын күкшел күкрәкчә төсле урман каймалаган, астарак чиялек, аннары гәүдә өлеше булып алтын сары басулар җәелә. Күкрәктән сулга таба бил өлеше сыгылып төшкән кебек иңкүләнеп тора. Кояш, кызыл түбәтәен кыңгыр салып, көн саен шуннан чыга, иң элек күкрәкне алсу-саргылт төскә мана. Кояшның алтын бишеге тау итәгенең әнә шул бил турына асылгандыр кебек тоела Нуриасмага. Кояш, алтын бишегеннән күтәрелмәгән килеш уянып, күзен ачуга, җиһанга алсу нур иңә. Таң беленә, таң ата... Таң, таң, таң... Исеме үк чыңлап, моң таратып, җырлап тора. Чаң каккан шикелле. Ул арада алтын бишегенең зәңгәр пәрдәсен куллары белән аралап, кояш киерелә-киерелә күтәрелә, елмаеп җибәрә. Җиһанның төнгелеккә сүрелгән, йокыга чумган тормыш елгасы кабат ташый башлый... Нуриасма гомере буе таңга, кояшка, җиргә табынды, аның өчен иң илаһи нәрсәләр шулар булды.

— Килдеңме? — диде ул кояшның тәүге нурларына битен куеп.— Менә бүген дә түземсезлек белән көттек сине. Син тереклекне бар иткәнсең. Син бәндәләрне бар иткәнсең. Шуңа күрә синең нурларың белән ата-бабаларыбыз рухы иңә. Рәхмәт сиңа! Әйдә, рәхмәтең белән, хәерең белән кил!

Әмма аның теләге кабул булмады. Хәере белән килмәде бу көн...

* * *

Сәгать тугызлар тулып киткәч, Нуриасма, оныгы Маратны ияртеп, агач бакчасына чүп утарга чыкты. Бераздан машинасы белән җир селкетеп Гарифҗан кайтып төште, аңа Мизхәт тә ияргән иде. Бер-бер артлы килеп туктауга, машиналарның «пош-ш-шш!» итеп һава чыгарганнары ишетелде. Марат койма ярыгыннан карады да:

— Миҗхәт абый кайтты! — дип урамга чыгып йөгерде.

Гарифҗан исерек иде. Аның ал күлмәге тирләгән аркасына ябышкан, изүләре ычкындырылган, башындагы ак фуражкасы бер колагында гына эленеп тора. Ул кесәсеннән Мизхәткә нидер алып бирде дә, чайкала-чайкала барып, Бәрияләргә кереп китте. «Комбайннан ашлык ташый торган вакытта нишләп йөриләр болар?» — дип хәвефләнде Нуриасма, бакчадан чыгып, урамның каршы ягына атлый-атлый.

— Гарифҗаннан нәрсә алдың? — диде ул малаеның күзләренә текәлеп.

Мизхәт көлеп җибәрде һәм кесәсеннән җиз төсле бер кечкенә озынча калай алып әнисенә сузды. Калайда латинчага охшаган язу, эт башы төшерелгән иде.

— Джинсыга тегү өчен бу...

— Шуның өчен басудан кайттыңмыни?

— Комбайнның урагы сынды, шуны мастерскойга кайтардым. Хәзер китәбез.

— Ә минем котым очты: аракы алырга акча бирде дип торам.

— Ни сөйлисең, әнкәй... Нишләп мин аракы алып йөрим ди...

Шулчак мотоциклда Рәмзи белән аның хатыны Мәдинә килеп туктады. Рәмзинең кыска җиңле зәңгәр ефәк күлмәге таза тәненә сыланып тора, куе кара чәчләре, гадәттәгечә, кыска итеп калдырылган. Шома түгәрәк йөзе кояшта янып каралган. Ул матаеннан төште дә иң элек Нуриасма белән, аннары Мизхәт белән ике куллап күреште, хәл-әхвәл сорашты. Тузан тимәскә кигән иске плащын мотоцикл бишегенә аткач,

Мәдинә дә исәнләшеп чыкты. Кинәт машина кычкырткан тавышка барысы да сискәнеп киттеләр: кабинада машина руле боргалап утырган Маратның «мине күрмисезмени?» диюе иде бу.

— Нихәл, Маат? — диде Рәмзи абыйсы Маратның үзе кебек юри сакауланып һәм аны күтәреп алды.— Эшлә баамы?

— Баа,— диде Марат.— Бамача атына тибәбеж.— Рәмзи өйрәткән бу сорау-җавапны инде бөтен авыл кабатлый иде.

— Молодец! — диде Рәмзи, үзенең тырышлыгы бушка китмәүгә куанып.

— Әмжи абый, чикет әле! — диде Марат аны муенынннан кочаклап.

— Чикелтелгәме? — диде Рәмзи.— Чикелтәм, ник чикелтмәчкә.

— Бала-чаганың көйләтүе бетмәс, әйдәгез әле керик,— диде Нуриасма аларны кыстап.

— Ю-у-ук, Маатны чикелтмичә булмый, әббәче!

Рәмзи аны ике култык астыннан тотып югарыга чөеп җибәрде дә җиргә төшеп җиттем дигәндә тотып алды, тагын чөйде, тагын тотып алды. Марат шатлыгыннан нишләргә белмәде, машина кабиналары түбәсеннән дә югары күтәрелгән саен чырыйлап кычкырды, аның бит алмалары алланды, күзләреннән очкын чәчелде, авызы әбисе пешергән шишара кереп китәрлек булып ерылды. Мәдинә иренең кыска җиңнәрен ертырдай булып уйнаклаучы мускулларына сокланып та, горурланып та карап тора иде. «Бигрәкләр дә яратып карый, алай ук кирәкмидер»,— дип уйлап куйды Нуриасма аны күзәтеп. Аннары шундук үзен тиргәп ташлагандай итте: «Яратып та карамагач, ник яшәргә ди? Рәмзи үзе дә хатынын өрмәгән урынга да утыртмый ләбаса».

Рәмзи аның иренең туганы иде. Сәгыйдулласы үлгәндә әйтте: «Каргыккаем,— диде,— берүк туганнар белән араны суытма, балалар аралашып үссеннәр»,— диде. Нуриасма аның сүзен тотты. Бәләкәй Күкеледәге Әкрәм белән Мөнәвәрә, аларның балалары, шул исәптән кечесе Рәмзи кунакка килеп-китеп йөрделәр, үзара аралашып, ярдәм итешеп яшәделәр. Нуриасма белән Мизхәткә Рәмзи бигрәк тә якын иде. Чөнки бу өйне үзенең ике иптәше белән ул эшләде, тиешле акчаның да яртысын гына алды, калганын Сәгыйдулла абый рухына багышлыйм, диде. Рәмзи тирәюньдә иң яхшы балта остасы буларак кына түгел, игелеклелеге белән дә халыкка танылган иде... Ул Маратны һавага чөеп туктагач та кочагыннан төшермәде. Нуриасма белән Мизхәт аларны тагын өйгә керергә кыстый башлагач, Рәмзи мотоциклын кабызырга ук әзерләнде.

— Өс-башны гына алыштырам да урманга китәбез,— диде ул.

— Беркөн үк мунчалык агачыңны алып кайттым дигән идең, ләбаса.

— И, Нуриасма түтекәем,— диде Рәмзи аның иңбашыннан сөеп.— Өч көн элек отпуск алдым, эшли дә башлаган идем.

— Соң шулай булгач?

— Һаман бүленелә бит. Әле менә бүген чуаркаем район үзәгенә барып кайтыйк дигәч, ничек тыңламыйсың? — Рәмзи белән хатыны бер-берсенә елмаеп карадылар. Ул аны мәк кебек вак кына сипкелләре өчен яратып шулай атый иде. Ул сүзен дәвам итте:

— Олы юлга чыгып та җитмәдек, председатель очрап, кире борды. Урманга гына барып кайтыйк, ди. Ничек карышасың? Шулай бит, Маат? — диде Рәмзи Маратның муенын бармагы белән кытыклап. Тегесе пырых-пырых көлде. Рәмзи абыйсының юан муены артында үрмәләп, шунда яшеренмәкче булды.

— Үзегез бер килеп чыгыгыз әле, гел күренмисез соңгы вакытта,— диде Мәдинә аларның кыставына чик куярга теләгәндәй.— Мизхәткә матай белән биш минутлык юл югыйсә. Шулаймы, Мизхәт?

— Шулаен шулай,— диде Мизхәт, кызарып.

— Әллә гел кызлар янынннан кайтып кермиме? — диде Рәмзи.— Өйләндерергә кирәк аны.

— Өйләнми бит,— диде Нуриасма.

— Элек хатын-кыз ир-атны яшәрткән, хәзергеләре картайта, диләр. Шуннан куркасыңмы әллә? — Рәмзи шаяртып Мизхәтнең кабыргасына төртеп алды.— Чуарны эзлә — оттырмассың. Әгәр курыксаң, бер дигән итеп агачтан ясап бирәм мин сиңа хатынны. Заказыңны гына бир: усактанмы, чаганнанмы, сәяннәнме? Җайлы инде, малай, теле-теше юк. Ошамаса, мичкә тык та як.

Рәмзи рәхәтләнеп көлде, аңа Мәдинә белән Нуриасма да кушылды, Мизхәт исә, әллә көлүеннән тыелып, әллә көлә алмыйча бурлаттай кызарып басып торды.

Мотоцикл бер тибүдә кабынды, алар кузгалып киттеләр. Кырык-илле адым киттеләрме икән, Рәмзи артына борылып тагын елмайды, кул болгады. Рәмзинең керәсе килгән икән, кыставым җитмәде, кыстасам керәсе булган дип ачынып уйлады Нуриасма...

— Ярый, улым, син дә эшеңә бар,— диде ул кискен генә.

Мизхәт кузгалып киткәндә, Гарифҗан кыяр кимерә-кимерә чыгып килә, Бәрия дә аңа ияргән иде. Аны өенә озаткач, Бәрия Нуриасма янына килде.

— Ни хәлләр бар, җиңгәчәй?

— Ару әле...

Бәриянең яшькелт күзләре гадәттәгечә туктаусыз хәрәкәтләнделәр, Нуриасманың әле йөзенә, әле аягына, әле кулларына йөгерделәр, элэктерер әйбер тапмагач, бер генә мизгел тукталып алдылар да тагын эзләнә башладылар. Нуриасма кешенең күзенә карау белән аның күңелендә ни ятканын чамалый. Ә менә Бәриянең эчендә ни яшерелгәнен ул гомер буе белә алмады. Аның туктаусыз йөгерүче карашы астында Нуриасма үзен тәненә нииндидер ят, салкын нәрсә ышкылып киткәндәй тоя. Шуңа күрә ул аның белән электән үк озаклап сөйләшә алмый, тыны кысылгандай була һәм тизрәк сүзне өзеп, аерылып китү ягын чамалый иде. Бу юлы да шулай эшләде.

— Бәрия, харап итәсең бит кешене,— диде ул аның туктаусыз чәбәләнүче карашын электерергә тырышып.— Аракы эчкәч, ни булмас, ул бит руль артында...

— Ни сөйлисең, җиңгәчәй,— дип сузды Бәрия үтә нык рәнҗүле тавыш белән.— Гөнаһлы булма, нишләп эчерим ди мин аны.

— Мин бит сукыр түгел. Иртән печән алып кайткач та кереп чыкты Гарифҗан.

— Алып кайттылар — эчермәдем,— диде Бәрия, аның күзенә туптуры текәлеп.— Ышанмасаң, кер дә кара.

Җил-җил атлап китеп тә барды. Шулчак ак «Нива»сы белән колхоз рәисе Хөснуллин килеп туктады һәм машинасы каты итеп кычкыртты. Ул рульдә үзе, янында төзүчеләр бригадасы бригадиры Салахов утыра иде. Бәрия тиз генә кереп шылды да күзен капка ярыгына терәде. «Кемдер җиткергән, хәзер эчкән өчен Гарифҗанның эштиенә киләчәк» — дип уйлады Нуриасма. Ул да булмады, капкада җиңнәре сызганулы Хәдичә, аңа ияргән Гарифҗан күренде.

— Иптәш Хөснуллин, бу юньсез тагын эчкән бит инде,— диде Хәдичә елый язып.— Ун көн айныганы юк. Җитмәсә урманга барам, ди. Штраф салыгыз, теләсә ни эшләтәгез, машинасына гына утыртмагыз!

— Эчмәдем мин, кичәге генә ул,— диде Гарифҗан, исереклеген яшерергә тырышып.

— Сөйләп тор, оятсыз!

Хәдичә йодрыгы белән малаеның маңгаена тукылдатып алды, ә тегесе шаркылдап көләргә тотынды. Председатель машинасыннан төште. Ул кыска җиңле ак күлмәктән, кара галстуктан, җитәкчеләр кия торган киндер кепкадан иде. Салмак адымнар белән килеп, Хәдичәгә сәлам бирде, аннары Гарифҗанга сынаулы карашын төбәде.

— Миңа аның эчүе хакында бу арада беркемнең дә әйткәне юк иде әле,— диде ул үз-үзенә сөйләгәндәй. Аннары карашын Гарифҗанның

йөзенә кучерде дә: — Әллә правоңнан колак кагасың килә, егет? — дип өстәде.

Гарифҗан ык-мык итте:

— Иптәш Хөснуллин... янадан кабатламам... яшьлегем белән ялгышлым...

— Сиңа бүген урманга барасыны әйткәннәр идеме?

— Әйе...

— Теләсә нишләтегез, правосын гына ала күрмәгез инде,— дип ялынды Хәдичә.

Гарифҗанга карап, Хөснуллин шактый вакыт сүзсез торды. Мотоциклга атланган ике егет килеп туктады. Егетләр күрше авылдан, председательне эзләп килгәннәр, күрәсең. Хөснуллин аларга көтеп торыгыз дигән мәгънәдә кул селтәп куйды.

— Бер юлга гафу итегез инде,— дип ялынды Гарифҗан.

Ул Хөснуллинның кичерүчән икәнлеген белә, шуңа исәп тота иде. Биш ел рәис булып эшләү дәверендә тәртип бозып яки башка гаеп белән аның каршына басучылар аз булмады. Идарә әгъзалары каты җәза сораганда да Хөснуллин каршы чыга, кешеләрне эш белән төзәтүне алга сөрә иде. Ләкин халык шунысын да аңлады: Хөснуллинның миһербанлык күрсәтүе иң каты җәзадан артып китмәсә, бер дә аннан ким булмый. Гаепле кешенең җиде тиресен тунап эшләтә белә Хөснуллин. Бу минутта Гарифҗан да, правосын алмаса, рәиснең табанын яларга әзер иде.

— Синең хакка гына калдырам, Хәдичә апа,— диде Хөснуллин һәм, Хәдичәнең рәхмәт сүзләрен дә тыңлап тормастан, Гарифҗанга кырыс кына эндәште: — Урманчыларны утыртып идарә каршына кил!

«Нива» артыннан Гарифҗан да кузгалды. Хәдичә аңа йодрык селкеп калды. Бакчага кабат чүп утарга кергәч, Нуриасманың кулы бик озак эшкә бармады, әлеге күренеш күз алдыннан китмәде. Ошатмады ул аларның сөйләшүен. Хәдичә дә, Гарифҗан да, Хөснуллин да аныңча түгел иде. Нуриасма андый юл белән бармады, ул беркайчан да арбаны үз кишәрлегенә бормады.

Аның үлчәү ташлары бөтенләй башка һәм ул аларны үлчәү тәлинкәсенә бик гадел итеп, йөрәге ничек куша, шулай салырга тырышты. Мизхәтне дә шуңа өйрәтте. Өйрәтеп җиткерә алмаган, күрәсең. Мизхәт Гарифҗан тирәсендә бөтерелә. Ярый, бөтерелсен дә, ул аның яшьтәше, дусты. Гарифҗан исерек, ә Мизхәт аңа тыныч кына карап тора. Ә ни өчен кисәтми, тыймый? Әллә Гарифҗанның шулай кәефле, авызын ерып йөрүе ошыймы аңа? Әллә соң Нуриасма гомере буе юкка тырыштымы? Төрле уйлардан башы тәмам каткач, ул бакчадан өйгә кереп китте. Өйдә дә җанына урын табалмады, үтереп эче пошты. Кабат бакчага чыкты, әмма әз генә селкенүгә, кулы салынып төште. Юк, эшләп булмый, эчтә нидер яна иде. Марат иптәшләре белән су керергә киткән иде, ул-бу булмасын тагы дип, Ык буена төште. Бала-чага күп, кайсы суда чыпырдый, кайсы комда кызына. Нуриасма яр буендагы ташка басып, аякларын чайкап маташучы Хәсән кызына дәште:

— Кызым, безнең Марат күренәме?

— Күренә, Нуриасма әби,— диде кыз бармагы белән комлыкка төртеп күрсәтеп.— Әнә шунда алар. Чакырыйммы соң?

— Кирәкми, чакырма, рәхмәт, кызым,— диде дә кабат өенә юнәлде.

Шулай да күнеле урынына утырмады, давыл алдыннан шомлы тынлыкка чумган табигать төсле бер халәт кичерде Нуриасма.

Давылның беренче өермәсе озак көттермәде. Ык буеннан кайтышлый аңа Мосаллия очрады. Июль ае өчен бер стакан көнбагыш мае, өч йөз грамм дөге алып кайтып килеше. Он беткән, булмаячак та ди.

— И, Нуриасмакаем, Хәдичәнең Гарифҗаның ишеттеңме соң әле? — диде Мосаллия барган җиреннән туктап.

Нуриасманың йөрәге кысылды, тез буыннары йомшады. Башыннан «менә, менә ул сиздергән нәрсә» дигән уй яшендәй йөгереп узды.

— Ни булган? — диде ул замандашының борчулы йөзеннән күзен алмыйча.

— Әле ачык кына белүче юк шул,— диде Мосаллия.— Нәрсәдер булган, урманга ашыгыч ярдәм машинасы җибәргәннәр. Мөхәммәтҗан абзыйның оныгы Наил бүген больницага барган булган, шул ишетеп кайткан ди...

Нуриасма гомергә Мосаллияне чәй эчерергә алып кермичә калмый торган иде, бу юлы бер әйтте, ул ашыгам, кереп булмый диде, Нуриасма кабат кыстамады... Менә ул хәзер үзенең эчендә нидер өзелүен аңлады, тик әле моның ни икәнен белеп булмый иде. Әгәр Мизхәтне дә урманга җибәргән булсалар? Комбайнга бүтән машина куеп, аны җибәргән булсалар? Колхозга булгач, алар бер генә машина бармыйлар ла инде. Шулай уйлаган саен ул моның хаклыгына ышанган кебек булды, йөрәгенең киләсе күңелсезлекне алдан ук сиземләве бер бүген түгел, Нуриасма моны төгәл белә... Төшлектә өйгә кагылып чыккалый торган малае бүген күренмәде. Туктале, болай торып булмый, ындыр табагына менеп төшәргә кирәк, анда белми калмаслар, дип урамга чыкты. Аннары кинәт кире уйлады. Ул-бу булса, Хәдичәләргә әйтерләр дип, аларга кереп китте. Хәдичә Гарифҗанның ике яшьлек кызына ботка ашатып утыра иде.

— Ни хәлләрегез бар, малай? — диде Нуриасма борчылуын яшерергә тырышып.

— Менә килен соңарды, карлыган коелыг ята — җыярбыз дигән идек тә... Нишләп чит кеше кебек ишек янында торасың, кил әле утыр, хәзер чәй эчәбез,— диде Хәдичә калагын оныгының кулына тоттырып.— Тамызмыйча гына аша, яме. Юкса, мәэмәй итәрмен.

Хәдичә суыткычтан сөт, май, варенье алып килеп өстәлгә тезә башлады. Нуриасма ничектер ул әйткән сүзләрнең асылына төшенмичә, колак очыннан гына уздырып тыңлады, хәтта аның чәй эчәргә чакыруын да аңламады ахрысы. Ләкин ул биредә үзе ачыкларга теләгән сорауга җавап юклыгына, Хәдичәнең әле урмандагы хәлләрдән хәбәрдар түгеллегенә төшенде. Үзе дә белмәгән нәрсәне әйтеп, аны борчыйсы да килмәде. Бәлкем әле ул-бу юктыр, барысы да әйбәттер. Шулай уйласа да, Нуриасма хәзер чәй эчеп утырырлык хәлдә түгел иде. Тизрәк чыгарга, төпченергә, белергә, төгәл җавап табарга кирәк, шунсыз йөрәк басылмаячак иде. Ул рәхмәт әйтеп чыгып китте, Хәдичә мәзәксенеп аның артыннан иярде:

— Нишләвең бу, Нуриасма, ризыктан олы түгелсеңдер лә, ут капкан төсле чык та кит, имеш...

Ләкин ул үпкә сүзләрен әйтеп бетерә алмады, урам капкасының кечесе шалтырап ачылып китте, аннан үкереп елап Гарифҗанның хатыны Хәлимә килеп керде. Аны күрүгә Нуриасманың йөрәге туктагандай булды...

— И әнкәй, хараплар булдык бит! — диде ул елавыннан тыела алмыйча.

Нәрсә, ни икәнен тәгаен белмәсә дә, Хәдичә дә елап җибәрде:

— И ходаем, тагын ниләр булды инде?!

— Гарифҗанны авыр хәлдә больницага салганнар!..

Моны ишеткәч, Хәдичә йөзен алъяпкыч итәге белән каплап бөгелеп төште.

— Ни булган соң, кызым?! — диде Нуриасма өзгәләнеп.

— Авария ди. Рәмзи абый да больницада ди...

Хәлимә, барысы да бетте инде дигәндәй, кулын селтәде дә ашыга-ашыга өйгә кереп китте. Хәдичә белән Нуриасма аңа иярделәр. Олыларның елавын күргәч, тыныч кына ботка ашап утыручы сабый да, нечкә тавыш белән елап, аларга кушылды. Хәлимә шифоньерны ачып ниндидер чүпрәк-чапраклар йолкып алды, нәрсәләрнедер атып бәрде, урындыкларны аударды.

— Нишләмәкче буласың, килен?! — диде Хәдичә аптырап.

— Нишләмәкче булыйм — Гарифҗанны сакларга китәм,— диде ул тагын нәрсәләрнедер атып бәреп.— Бу йортка килен булып төшеп, мина азап-борчуларсыз бер генә көн дә торырга язмагандыр инде!..
— Гарифҗан исән булсын дип телә, килен, әле синең без күргәннәрнең чиреген дә күргәнең юк,— диде Хәдичә ул аударган әйберләрне горгызып, чәчелгәннәрен җыеп.
— Шушыннан да ары тагын ни күрсәтер идең мина?! — дип кычкырды Хәлимә яшенә буылып.
— Мин түгел, килен, язмыш, язмыш...
— Язмышны да кемнәрдер чәчә — аны гына беләбез,— диде Хәлимә, аяк астында елый-елый буталып йөргән кызын читкә этәреп.
Аларны тынычландыру өчен ни сүзгә катышырга, ни чыгып китәргә базмыйча морҗа янында тораташ катып Нуриасма Хәдичәнең беләгеннән килеп тотты, Хәлимәгә сиздермичә генә терсәге белән аңа кагылып куйды.
— Әйдәле, Хәдичә, кирәк әйберләрен киленгә тизрәк тутырышыйк,— диде ул Хәдичәне кабат сүз әйтүдән тыю өчен.
Ул арада Хәлимә өйалдына чыгып керде дә:
— Машина килгән,— диде.
Кирәкле әйберләрне бер зур сумкага тутырып бетергәч, Хәлимә кызын алып сөйде дә ишек алдына чыктылар. Колхоз рәисе үзенең «Нива»сын җибәргән иде. Машина янына килеп җиткәч, Хәдичә тавышсыз гына үксеп:
— Ә мин?... Кызым... мин? — дип нидер сорамакчы булды.
Хәлимә аны кочаклап алды.
— Әнкәй, ачуланма инде... Йөрәк янганга түзә алмыйча әллә ниләр әйтеп ташладым...
Хәлимә машина белән кузгалып китүгә, Хәдичә оныгын күтәреп алды, Нуриасманы ай-ваена карамыйча өйгә алып кереп китте. Ләкин Нуриасманың чәе тамагыннан үтмәде, уйлары әллә кайда буталды. Ясалган чынаягын да эчеп бетермәде, «Марат кайткандыр»,— дип, үз ихатасына йөгерде. Башы ни уйларга да белмәде. Тавык-чебешләрен карады, бәрәңге пешереп, Маратны ашатты, әмма үзе бер тәгам ризык та җыймады. Берәрсеннән юньле хәбәр ишетмәммме дип, урамга чыкты — беркем дә күренмәде. Капка төбендәге утыргычка утырды, көтте. Көтүе юкка булмаган, машинасы белән тузан туздырып, Мизхәт кайтып туктады, кабаланып кабинасыннан төште.
— Әнкәй! — диде ул әллә нинди сәер тавыш белән.
— Нәрсә?
— Ни... Рәмзи абыйны...
— Ишеттем, ишеттем,— диде Нуриасма сабырсызланып.— Хәле ничек микән?
— Хәле... — Мизхәт нидер уйлагандай туктап калды.
Улының җебеп торуына Нуриасма ачуы чыга башлавын сизде.
— Бармадыңмы? Хәлен белмәдеңме? — диде ул кабаланып.
— Белдем... — Мизхәтнең тавышы ишетелер-ишетелмәс кенә чыкты.
— Соң?
— Рәмзи абый...— малае башын аска иде.
Нуриасма каядыр убылып төшкәндәй бер куркыныч сиземләү якынлашуын чамалады.
— Нәрсә?..
Малае дәшмәде.
— Нәрсә дим?!
— Үлгән...
Мизхәтнең бу сүзне әйткәнлеге юньләп ишетелмәде дә, Нуриасма аны малаеның иреннәре кыймылдавыннан, дөресрәге инде ул әйткәнче үк аңлаган иде... Әмма йөрәк бу коточкыч нәрсәне кабул итәргә теләмәде,

чөнки әле генә шушында шаярып-көлеп торган япь-яшь кешене үлгән итеп күз алдына китерү гайре табигый иде. Нуриасма еламады, кабат бер сорау да бирмәде, беркая да кузгалмады, багана кебек тик катып торды. Мизхәт аны култыклап алды, акрын гына өйгә керделәр, утырдылар, бер сүз дә сөйләшмәделәр. Шулай өнсез булып шактый утыргач, Мизхәт торып басты.

— Мин эшкә барыйм инде, әнкәй...

Нуриасма шунда гына айнып киткәндәй сикереп торды:

— Ә Күкелегә, Рәмзи абыең янына кайчан?

— Әле аны ярырга алып киткәннәр. Мин эштән кайткач барырбыз инде...

Нуриасма малаеның өйдән чыгуын да, машинасын үкертеп кузгалуын да сизмәде... Кая гына караса да, Нуриасманың күз алдына Рәмзинең бая мотоциклда китеп барышлый борылып, шикәрдәй ак тешләрен күрсәтеп елмаюы, Маратка кул болгавы килде дә басты. Үзе эшләгән шушы өйгә кереп соңгы мәртәбә чәй эчәсе килгән иде бугай аның... Нуриасма торып әле өйнең бүрәнәләрен сыйпады, әле ишек-тәрәзә борысларына кагылды, әле тыгыз итеп кысылган түшәм-идәннәрен карады... Аларның һәммәсе дә Рәмзинең кул җылысын, күз нурларын саклый иде... Моңа түзү өчен йөрәк урынына таш булуы кирәк иде. Нуриасма битеннән тәгәрәп-тәгәрәп төшкән күз яшьләрен сөртмәде, урамга чыкты, тау битләреннән әйләнеп кайтты, бераз күңеле утыргач, зиһенен җыйгач, кибеткә барырга булды. Урамда да, кибеттә дә бөтен кешенең телендә шул хәлләр, Рәмзинең үлеме иде.

Фаҗига төш җиткәнче, әле урманга барганда ук булган. Гарифҗан кабинасына Рәмзи белән Ерак Аланның бер тәүчесен утырткан. Котсыз чапкан, аңа акрынрак бар дип әллә ничә мәртәбә әйтеп карадык, тыңламады, Рәмзигә «төшеп кал!» дип җикерде, дип сөйләгән теге кеше. Алдагы көнне генә анда көчле яңгыр явып үткән булган. Коточкыч текә үрдән төшкәндә — сул якта урман, уң якта тирән чокыр икән — машина уйнаклый башлаган. Теге кеше белән Рәмзи сикермәкче булган, Гарифҗан: «Сикермәгез, берни дә юк, төшеп җитәбез»,— дип боларны туктаткан. Шулай да теге кеше сикергән, ул аягына басарга да өлгермәгән, машина бөтенләй чокырга таба салулаган һәм Гарифҗанның: «Сикер!» дигән тавышы ишетелгән. Рәмзи сикергән, тик машина аның гәүдәсе аша түбән тәгәрәгән...

Кич казларны, сарыкларны эчереп япкач, сыерны саугач, Мизхәт кайтты, мотоциклын гараждан алып чыкты. Маратны Хәдичә янында калдырдылар да Бәләкәй Күкелегә юл тоттылар.

— Менә, улым, күпме бәхетсез, күпме ятим,— диде Нуриасма, йөрәгенең януына чыдый алмыйча.— Моңа синең белән мин дә гаепле...

Мизхәт аңа «ялт» итеп карап алды да мотоциклның тизлеген арттырды.

— Рәмзи абыеңның башына без дә җиттек дип уйла, улым. Газраилен күрәләтә машинага утыртып җибәрдек бит.

— И әни! — диде Мизхәт өзгәләнеп.— Айнык баштан да әллә нинди аварияләр килеп чыга. Хәер, мин аңа әйттем, арыгансың, утырма машинаңа, сүндер дә куй, дидем. Тыңламады. Әгәр Хөснуллиның үзенә бүрәнәгә барасы булмаса, ике аягымның берсен дә атламас идем, диде...

Әллә дөрес ишетмәдемме икән дип, Нуриасма кабат сорады:

— Хөснуллиның үзенә дисеңме?

— Әйе, Чирмешән ягында әтиләренә өй салдыра ди бит. Гарифҗаннарны больницага да үзе илтешкән.

Алар Күкелегә барып җиткәнче бүтән бер сүз дә сөйләшмәделәр. Рәмзиләрнең капка төбендәге машиналарны, кайгырышып басып торучыларны күрүгә үк Нуриасманың күңеле тулды. Ишек төбендә, өйалдында да тын, сүзсез торучы кешеләр яныннан үтеп өйгә керделәр. Мөнәвәрә Нуриасманы кочаклап алды.

— Рәмзиебез калдырып китте бит!..— диде ул, үксүен тыя алмыйча.

Нуриасма аның иңбашларыннан сөйде, тынычланырга кушты, язмыштан узмыш юк, диде. Менә түр өйгә үттеләр. Рәмзине күптән түгел генә ярдырып алып кайтканнар, нәкъ уртага агач караватка ак күлмәк, кара костюм кигереп салганнар, башы марля белән чорналган. Бераз агарып киткән йөзендә сыдырылган-бәрелгән урын күренми, әйтерсең, йоклап кына ята. Хәзер уяныр да, гадәттәгечә күзләрен кысып бетереп көләр, җорлана башлар шикелле... Мөнәвәрә әйләнеп керә дә Рәмзинең әле бер, әле икенче кулын иңбашыннан аска таба сыпыра, иркәли, сөя... Куәтле мускуллары, таза беләкләре костюмы аша ук беленеп торган бу көрәктәй кулларның кабат балта тота алмавына һич тә ышанасы килми, бу хәл башка сыймый иде... Хатыны Мәдинә сын кебек аның каршында басып тора, кулларын чытырдатып йодрыклаган, ә күзләре мөлдерәп төшәрдәй булып иренә төбәлгәннәр. Аның йөзенә, күзләренә әле курку, әле елмаю катыш өмет, әле сагаю, әле коточкыч аптыраш чыга, нәрсәнедер аңларга тырышудан маңгаен газаплы җыерчыклар каплый... Ул шулай тора-тора да аһылдап, бәргәләнеп диванга ава. Аңа укол кадыйлар, ул тора да тагын шул урынга килеп баса... Быел сигезенче класста укыйсы кызлары Гүзәлнең кеше кыяфәте калмаган. Ул коты очып әтисенең үле гәүдәсенә карап ала да сыннары катып, елый башлый. Әле алты яше тулмаган Рөстәм генә берни дә белми, шунда килгән бала-чага белән уйный, әмма ул да житдиләнгән иде. Нуриасма Рөстәмне кочаклап сөйде, аңа да, иптәш малайларына да җиләк кагы, вафли, конфет бирде. Бәрия инде күптән монда булса кирәк, ул әле Мөнәвәрәне, әле Мәдинәне, әле балаларын юата, өйдә дә, ишек алдында да нидер кайгыртып бөтерелә, изгелек кылырга тырыша иде...

## 2

Җәйнең тук башаклы иген басулары һәм мул җимешләре белән күкрәп торган иртәсендә бер төркем ир-ат зиратка килеп керде. Иске каберләр өстенә үскән зур-зур тупылларның, каеннарның күләгәләре үлән төбендәге төнге салкынлыкны кояштан саклый. Каберлектә генә була торган тынлык хөкем сөрә, каберлектә генә була торган төче ис аңкый. Биек куе үлән өстеннән тавыш-тынсыз гына йөри-йөри кабер казучылар урын сайладылар. Ике урынга тукталып караганнар иде дә, Рәмзинең абыйсы Мөхтәр ошатмады, аларны һаман капкадан еракка-рак — зиратның авыл эченә үк кереп торган башына алып китте. Моннан Мөхтәрләрнең түр тәрәзәләре күренеп үк тора.

— Тәвәккәллик шушында — диде Мөхтәр саңгырау тавыш белән.— Ичмасам каберенә көн дә күз атармын...

Арадан берәү кабернең кыйблага торышын, зурлыгын билгеләде.

— Шушылай ярармы?

— Ярар,— диде Мөхтәр ишетелер-ишетелмәс кенә.

Көрәкләр яшел чирәмгә шытырдап баттылар, биш минут үттемеюкмы, өске катлам кәс-кәс итеп алып кырга куелды. Шактый вакыт үлән тамырларын, җир кискән, балчык аткан, көрәккә көрәк бәрелгән, мышнаган тавышлар гына ишетелеп торды. Аннары барысы да туктап калдылар. Читтәрәк басып торучы Мөхтәргә дүрт почмаклы бу кара җир йотарга әзерләнгән авызны хәтерләтте. Бая кабернең зурлыгын үлчәгән ир җыерчыклы маңгаеннан, пеләшләнә башлаган баш түбәсеннән тир бөртекләрен сөртеп алды да:

—Нинди кеше иде бит, ә? Күңел һаман да ышанмый...— диде, тагын нидер әйтергә теләде дә тотлыгып калды. Бераздан бөтенләй башка тавыш белән сөйләп китте: — Үләренә өч сәгать кала безгә утын төяшеп китте бит әле ул. Борылмадан мотоцикл белән килеп чыкты. Мәдинәсен утырткан. Районга дип юл тотулары булган икән. Мин ярдырырга

дигән агачларны хатын белән тәяп маташа идем. Безне күрүе булды, унга борыласы урынга сулга каерып капка төбенә килеп тә туктады, без күтәрә башлаган агачны уртасыннан эләктереп машина әрҗәсенә дә очырды. Үзе зәп-зәңгәр ефәк күлмәктән, затлы чалбардан. «Кит, минәйтәм, өстеңне пычратасың»,— дим. «Мин өс-башка тигермичә генә күтәрәм»,— ди. Тәки төяшеп бетерде. Эчмәгәнен белсәм дә, кыен бит: «Әйдә кереп бераз тотыйк»,— дим. «Аллаһы боерса, киләсе елда сабан туенда»,— диде дә көлә-көлә китеп барды...

— Рәмзинең кешегә күрсәткән игелекләрен бизмәнгә салсаң, әллә ни чаклы булыр иде,— дип күтәреп алды аның сүзен озын буйлы икенчесе.

— Ай, кызганыч, егетләр, ай, кызганыч!...

Озын буйлысы тагын өстәп куйды:

— Мин бит Хөснуллинга әйттем, икенче шофер алыйк, дидем. Ә ул кул гына селтәде. Аның теге исерекбашы үзе үлгән булса ичмасам.

— Үлмәсен, Габдулла, ул да үлмәсен, суларга һава барыбызга да җитә бит.

— Эчем янганга әйтүем инде...

Шуның белән сүз бетте, тагын казырга тотындылар...

Бу вакытта Рәмзинең туган йортында да аны ашыга-кабалана мәңгелек юлга озату хәстәре башланды: кәфенлекләр, хәергә бирергә вак акча, яулык-сөлге барланды, мәетне юарга су җылытылды, колаша комганнар алып кайтылды. Уттай урак өсте булса да, ишек алдына, капка төбенә ерып йөри алмаслык дәрәҗәдә яше-карты җыелды. Бу якларда Рәмзинең кул көче кермәгән урын сирәк иде. Шуңа күрә колхозның дүрт авылыннан гына түгел, тагын әллә кайлардан төркем-төркем халык агылды. Мөхтәр зираттан кайтып ләхет ала башлауларын, кабернең ярты сәгатьтән әзер булачагын әйткәч, картлар мәетне юабыз диделәр, чит-ят кешеләр өйдән чыгып китте, хатын-кызлар кече якка күчте. Әнисе Мизхәткә читкә китмәскә кушкан иде. Ул картларның һәр боерыгын үтәде, өйгә нәрсәләрдер алып керде, өйдән нәрсәләрдер чыгарды, тик үзенең ни кылганын белмәде. Күңеле таш булып катты, башы эшләмәде, бөтен гәүдәсе, кул-аяклары агачка әверелгәндәй берни сизмичә хәрәкәтләнделәр, кемнәрнеңдер әмеренә буйсынып йөри бирделәр. Бу ниндидер куркыныч төш кебек иде, ул төш һич тә бетмәс шикелле һәм гел бер төсле иде. Өйгә керсә дә, ишек алдына яисә урамга чыкса да, Мизхәт кайгылы, нурсыз йөзләргә, яшьләнгән күзләргә, елаучы иреннәргә ышкыла язып үтте, шуларны күрмәс өчен карашын аска яшерде. Ләкин карашны яшереп булса да, йөрәкне яшерү мөмкин түгел иде, уфтанулар, елаулар, юатучының үзеннән башка беркемгә дә җинеллек китерми торган юату сүзләре колактан үтеп бәгырьнең нәкъ уртасына кадалдылар... Мизхәт бу кадәр халыкның аерым-аерым кемнәр икәнен дә абайламады, чөнки моның нишләптер берниндиәһәмияте юк, чөнки барысы да бер генә төсле иде. Бу ихатада, бу йортта Рәмзинең һәрвакыттагыча шат тавышының, дөньяларны яңгыратып рәхәтләнеп көлүенен ишетелмәве бөтенләй гайре табигый бер хәл булса, шушы кадәр халыкның гөжләмичә тып-тып торуы, бер генә кешенең йөзендә елмаю-шатлану билгесе булмау шулай ук башка сыймый иде. Гүя бу якты дөньяның яме каядыр куылган, кайгы сөреме аны мәңгегә томалап юк иткән. Шушы кайгы сөремен ерып йөргәндә Мизхәт, үтсә дә, сүтсә дә, йорт башы Әкрәм абзыйга курку белән карады. Ул төнлә аңын җуйган, вакыт-вакыт зиһене яктырып алса да, томыкланып калган күзләре беркемне дә аермый, теле әйләнми иде. Аның янында ак халатлы шәфкать туташы утыра, әледән-әле пульсын тикшерә, укол кадый, су йоттыра. Кемнәрдер пышы-пышы сөйләшә, берьюлы ике мәет җирләргә язмасын, андый кайгы бирә күрмә, дип, аллага ялваралар...

Ярганнан соң Рәмзине күлмәк, костюм-чалбар кигереп алып кайтканнар. Әнисе Мөнәвәрә моңа башта ризасызлык белдермәсә дә, картлар килгәч, малаен кәфенгә төреп күмүне үтенде. Аның сүзләренә алар

да, Мөхтәр дә каршы килмәде, ана кешенең соңгы теләге берсүзсез үтәлергә тиеш иде.

Мәет юу әйберләре караңгы чоланга кертеп куелган иде. Мизхәт бер агай белән иң элек ак калайдан эшләнгән зур колашаны түр өйгә алып кереп картларга бирде. Шул чакта ул колашаның тәннәрне чемердәтерлек салкын булуына хәйран калды. Комган, алъяпкыч, тастар кебек нәрсәләр дә кертелде. Хатын-кызлар «Җиһансылуныкы бугай» дип тастарны җәеп карадылар. Мизхәт ап-ак тастарның бер почмагына яшел җеп белән чигелгән сүзләрне хәйран калып укыды. «Бу тастарны Мөхәммәтҗан кызы Җиһансылу текте» дип чигелгән иде анда. Мөхәммәтҗан бабай — Мизхәтләрнең урам аша күршесе, ә аның кызы Җиһансылуның үлгәненә инде ун еллап бар иде. Шушы мизгелдә ул аның чигәннеке төсле кара-кучкыл йөзен күргәндәй, «Мизхәт үскәнем, кил әле, алма бирәм!» — дип дәшүен ишеткәндәй булды. Мизхәт, иңбашына җинелчә генә кагылуга, сискәнеп, артына борылды.

— Туганкай, әйдә безгә булыш әле,— диде уң кулына берьюлы ике комган тоткан карт. Аңа ияреп, ул өйнең түр ягына үтте. Биредә картлардан икесе алъяпкыч бәйләгән, колаша бер башы авышрак итеп ике урындыкка куелган, читтәрәк ике таз күренә иде. Рәмзинең өстенә капланган япманы алганнар, аның йөзе агарып киткән, күперенке ирен сызыклары ничектер элеккеге рәвешләрен югалтканнар, шинеп авыз эченә бата язганнар.

— Әйдәгез, колашага күчерик,— диде баягы карт һәм Мизхәткә Рәмзинең бил турыннан аска кертелгән сөлгенең ике очын бирде. Кемнәрдер иңбашларыннан, аякларыннан тоткач, әгузебисмилла әйтеп, мәетне күтәрделәр. Шул чак Мизхәтнең күзе аска төште: простыня кыпкызыл кан иде.

— Аркасындагы ярасыннан һаман да кан килә икән, шәһит киткән икән, матурым,— диде кемдер акрын гына.

Мәетне колашага илтеп салгач, Мизхәт чыгып китмәкче булды, ләкин әлеге карт аңа мәрхүмнең бер як култык астыннан тотарга кушты.

— Хәзер утыртабыз,— диде ул.

Мизхәт ни үле, ни тере хәлдә калтыранган куллары белән Рәмзи абыйсының иңбашыннан тотты, тәненең ничектер тыгыз, каты булуыннан сискәнеп куйды. Аның үлгән кеше тәненә үз гомерендә беренче мәртәбә кагылуы иде. Үзенә каршы якка Мөхтәр абыйсы килеп баскач кына Мизхәткә җан кергән кебек булды. Мәрхүмнең билдән өске өлешен киерелеп утырган рәвешкә килгәнче күтәрделәр. Канлы сөлгене кемдер читкә алды. Алъяпкыч бәйләгән картның берсе кайчы тотып килде дә Рәмзинең костюм сәдәфләрен ычкындырды, арка ягына чыгып, костюмны итәгендәге ярыгыннан муенга таба кайчы белән кисәргә кереште. Кискән өлешен ул күтәрә барды, күлмәккә дә, костюмга да калак сөягенә кадәр кан җәелгән иде. Кисеп бетергәч, ике ягын ике кулдан салдырып алдылар. Аннары теге карт мәетнең чалбарыннан күлмәк итәген тартып чыгарды. Күлмәк күкрәк авызыннан аска таба ычкындырыла торган түгел иде. Карт итәк очын әз генә кискәч, ике ягын ике кулы белән тотты да күлмәкне шытырдатып ертып җибәрде. Рәмзинең майкасы юк иде, Мизхәт аның муен төбеннән касыгына кадәр ярып, бүртмәч-бүртмәч җөйләп тегелгән тәнен, йөрәк турыннан түбәнгә таба күгәреп-күгәреп торган урыннарын күрмәс өчен күзләрен чытырдатып йомды... Карт кайчысы белән күлмәк җиңнәрен дә буйга ярып чыкты, аннары аны ансат кына салдырып алдылар. Ул инде хәзер Рәмзи абыйсының шәп-шәрә тәннәрен тотып тора иде. Шәрә гәүдәне акрын гына колашага яткырдылар, колаша һаман да салкын иде. Теге карт җәһәт-җәһәт кенә Рәмзинең оекбашларын салдырып алганнан соң, чалбар сәдәфләрен ычкындыра башлады һәм Мизхәткә карап:

— Булды, туганым, рәхмәт, бар һавага чык,— диде.

Мизхәт, халыкны ярып чыккач, абына-сөртенә бәрәңге бакчасына

таба атлады. Ул еш-еш сулыш алды, колагы шаулады, гәүдәсе haман да үзенеке түгел иде. Абзар почмагына сөялеп шактый торгач, аның күзе кайбер нәрсәләрне аера башлады: бакчаның бәрәңге утыртылмыйча калдырылган урынында әле генә каезланган каеннар өелеп тора, ике нирга мунча бурап куелган һәм Рәмзи абыйсының балтасы почмакка чабылган килеш тора иде...

Мәетне юып, кәфенләп сай тартмага салгач, йөз мәртәбә тәһлил әйтеп, ясин укып хәерләр өләшенгәч, картларның тәкбире астында ишек алдына алып чыктылар. Әкрәм, шәфкать туташы белән Мөнәвәрә күпме генә тырышсалар да, улы белән хушлаша алмады, гәүдәсе кымшанмады, күзләрен берничә мәртәбә ачып йомды да йоклаган кебек ята бирде...

Тартманы ике урындык өстенә куйдылар.

— Зиратка бармаучылар, карап калыгыз,— диде картларның берсе һәм мәетнең баш түбәсеннән үк бәйләп куелган кәфенне чишеп, аның йөзен ачты.

Башларын түбән игән кешеләр Рәмзинең йөзенә соңгы мәртәбә карап үттеләр. Янәшәдә әнисе, хатыны, ике баласы, бүтән туганнары елашып басып торды. Кечкенә Рөстәм генә еламый, әтисенең хәрәкәтләнмәвенә, дәшмәвенә, көлмәвенә аптырагын хәлдә мөлдерәп аның йөзенә төбәлгән иде. Кешеләр карап бетергәч, мәрхүмне җеназа агачына салып өскә күтәрделәр дә акрын гына зиратка таба юл тоттылар. Арттан кара болыт булып халык иярде. Шул чак Рөстәмнең:

— Әтием, әтием, әтием! — дип ачыргаланып кычкыруы ишетелде. Аның тавышы үзәк өзгеч нечкә һәм ялварулы иде. Ул җеназа артыннан йөгереп куып җитүгә тузанлы юлга капланды һәм сынсыз булып катты. Хатын-кызлардан кемдер аны күтәреп, өйгә таба алып китте, сабый елый-елый һаман «әтием, әтием, әтием!» дип кычкырды, җиргә төшәргә теләп, аяк-куллары белән чәбәләнде...

Зират капкасы турына җиткәч, җеназаны чирәмгә куйдылар. Халык шул тирәгә җыелды. Моңа кадәр бөтенләй күренмәгән рәис Хөснуллинның юан түгәрәк гәүдәсе тәгәрәгәндәй алга килеп чыкты. Тар маңгае өстендәге җирән чәчләрен артка сыпырган арада янында торучы партком секретаре аңа кәгазь сузды. Кендек тишеген хәтерләтүче кечкенә күзләрен бөрештереп, Хөснуллин кәгазьдән укырга кереште:

— Иптәшләр! Рәхимсез үлем безнең колхозыбызның иң яхшы кадрларыннан берсе булган Рәмзи Әкмал улы Шаһиевне...

Шулчак партком секретаре аның колагына иелеп:

— Әкрәм улы...— диде.

Бүлдергәнгә ачуы чыгып Хөснуллин аңа борылды:

— Нәрсә?!

— Әкмал улы түгел, Әкрәм улы...

— Машинкада бастырырга иде, понимаешь! — дип мыгырданып алгач, Хөснуллин дәвам итте:

— Рәмзи Әкрәм улы Шаһиевне алып китте. Колхозның яңа төзелгән кайсы гына корылмасын карасак та, аңа Рәмзи Шаһиевнең фидакарь хезмәте кергән...

Нуриасма аның бер генә сүзен дә тыңламады, аңламады, аңларга да теләмәде. Ул Хөснуллинның түгәрәк йөзенә караган хәлдә ни кылырга белмичә аптырашта калды. Ә Хөснуллинның кызыл калын иреннәре туктаусыз хәрәкәтләнде, иреннәре белән бергә түгәрәк яңагы гына түгел, бөтен бите селкенеп торды. Кәтүк кебек эчкә баткан борыны гына селкенми иде. Рәмзинең үлемендә турыдан-туры гаепле кешенең аның мәете өстендә сүз сөйләргә батырчылык итүе Нуриасманы тынсыз-өнсез итте. Ярый, ул Рәмзинең җеназасына килсен дә ди. Ләкин бит ул башын иеп, кешеләргә күтәрелеп карарга оялып, читтә мескен булып басып кына торырга тиеш. Менә хәзер ул тотлыга-ялгыша укый торган сүзләрнең кабыгы гына Рәмзи рухына туры килә, ә аларның асылында бу җинаятьтән коры чыгарга теләү ята. Үзең үлеменә сәбәпче булган кешенең

изге рухын, җеназа мәрәсимен анын якыннары алдында, халык каршында үзенне аклау өчен файдалану кебек гөнаһны эшләү өчен ни дәрәҗәдә намуссыз булырга кирәк?! Монын шулай икәнлеге Хөснуллинның бирегә килүеннән үк аңлашыла иде. Чөнки ул колхозда күпме эшләп, гаеп итмәсеннәр, йөрәгемә ярамый, дигән сылтау белән бер генә кешенен дә җеназасына бармады. Анын бирегә килеп чыгыш ясавы — тагын бер җинаять иде, моны хәзер үк фаш итәргә кирәк иде. Нуриасма берәм-берәм кешеләрнен йөзләренә карады, алардан Хөснуллинга карата нәфрәт чаткылары эзләде, әмма андый нәрсә күрмәде. Аларның колагына килеп кергән сүзләр Рәмзи рухына туры киләләр, ә инде ул сүзләрне кем, нинди максат белән укуы кешеләр өчен барыбер иде. Алар Хөснуллинның Рәмзи рухын, шунын белән үзләрен дә мыскыллавына битараф иделәр. Нуриасма йөрәгенең ярсып тибә башлавын сизде. «Ничек болай була ала соң бу?!» — дип өзгәләнде анын күнеле. Һәм ул кешеләрне ера-ера Хөснуллинга якынлашты. «Тукта, оятсыз, җир бит!» — дип кычкырасы килде, тик туганынын соңгы туенда мондый ямьсез нәрсә эшләргә батырчылыгы җитмәде. Ул арада Хөснуллин тавышын ясалма калтыратып:

— Тыныч йокла, Рәмзи! — диде һәм анын сул кулы үзе дә сизмәстән костюм кесәсеннән кульяулыгын тартып чыгарды. Әле сүзе бетмәгән иде, ул аны кульяулыгын учлаган килеш тәгәлләде: — Синен якты истәлегең безнең хәтерләрдә мәңге сакланыр!

Хөснуллин кульяулыгы белән күзләрен каплап бер адым артка чикте... Нуриасма аңа җирәнеп карап торды. Кульяулыгы белән күпме генә сөрткәләсә дә, Хөснуллинның керфексез күзләрендә яшь тамчысы түгел, дым әсәре дә юк иде. Кульяулыгын кесәсенә тыгып, алан-йолан карап алган чакта анын карашы Нуриасманың тишәрдәй булып төбәлгән күзләре белән очрашты. Мона кадәр тыныч, салкын Хөснуллинның чыраена куе кызыллык йөгерде, ул урынында таптанып куйды, аннары карашын читкә яшерде. Нуриасма нәфрәтенә чыдый алмыйча әле аңа, әле кешеләргә карады. Гаделлек, кешелеклелек кануннары хөкем иткәндә, халык хәзер Хөснуллинны аяк астына салып таптарга тиеш иде кебек. Ни өчен соң халык түзә, хәтта моны сизми дә?! Иң коточкычы шушы түгелмени?! Шушы уйлардан башы каткан, йөрәге ачу-рәнҗеш белән ярсыган Нуриасма бүтәннәрнең ни сөйләгәнен аңламады да диярлек. Бары тик Рәмзинең гәүдәсе янына хатыны Мәдинәнең атлавын күргәч кенә ул газаплы уйларыннан аерыла алды. Мәдинәне бер ягыннан шәфкать туташы, икенче ягыннан кызы култыклаган иде. Менә алар җеназа янына килеп җиттеләр. Халык селкенергә дә базмыйча аларга төбәлде. Мәдинәнең таныру ы калмаган: күз төпләре, иреннәре күп-күмгәк, суырылган чыраенда кан әсәре калмаган, чәчләре тузган иде. Берни дә алып ата алмаслык авыр тынлыкта анын зәгыйфь, хәлсез тавышы бөгерьләрне телеп салды:

— Рәмзи... Рәмзи... — Ул, сүзен дәвам итә алмыйча, күз яшьләрен йотты. Үтә дә якын, җир йөзендәге берни белән дә чагыштырмаслык шушы изге исемне ике мәртәбә кабатлаганда, анын кичергән барлык фаҗигасе, йөрәгенә кара кан булып урнашкан мәңгелек кайгысы кешеләрне тетрәтте.

— Синең исемеңне... беркайчан да... — Мәдинәнең тавышы бөтенләй бетте, өзелде. Тик аңа каяндыр тагын көч иңде, тавышы беркем дә көтмәгәнчә янгырап куйды: — Беркайчан да!.. күләгә төшермә... Исемеңне, рухыңны изге итеп саклармын!..

Мәдинәнең тавышы өзелде, ул сулкылдап елап җибәрде...

Картларның берсе кузгалырга ишарә ясады. Мәрхүмне зират эченә алып кереп, күләгә урынга куйдылар. Картлар тезелешеп җеназа намазы укыгач, аны күтәреп алдылар һәм инде күптән, кара авызын ачып, үзенең мәңгелек хуҗасын көтүче кабергә юнәлделәр. Өч кеше кабер эченә төште. Өч сөлге белән тотып, Рәмзинең ак кәфенгә төрелгән мәетен гүргә иңдерә

башладылар. Шул чакта кызы үкереп елап җибәрде һәм әтисе артыннан ташланырга теләгәндәй кабергә омтылды. Аны иптәш кызлары эләктереп, читкә сөйрәделәр. Ул да булмады, Мәдинә кинәт җиргә чүкте, башы салынып төште. Шәфкать туташы, аның башын күтәреп, яңакларын чабаклый башлады, үзе туктаусыз: «Мәдинә, Мәдинә»! — дип дәште. Бераздан күзләрен ачты, тик ул берни дә күрми, аңламый кебек иде, иренең каберенә әллә ничә көрәк белән гөпер-гөпер балчык ыргытучыларга аптырагандай карап торды...

Менә кара балчык өеменнән башка берни дә калмады. Кабер ташын да урнаштырдылар, чардуганын да куйдылар. Картлар тәбәрак укыды, хәерләр өләшенде. Иң ахырда дүртесе кабернең дүрт почмагына чүгәләп салават әйтте. Күмү йоласының азагы шул иде.

Халык, авылның әле дүртенче дистәсен ваклый гына башлаган иң игелекле кешесен мәңгегә салкын гүр куенында калдырып, зираттан чыкты.

Юлдан акрын гына кайтып баручы кешеләрнең өстенә тузан бөркеп, Хөснуллин машинасы узды.

Картлар, өйгә кайтып, мәрхүмнең өчесен үткәрделәр.

Шуның белән эш тә бетте.

## 3

Нуриасманы авыл Советына дәштеләр. Аны ап-ак чырайлы, пеләш башлы, калын кысалы күзлек кигән ябык кына кеше каршылады, үзен тикшерүче дип таныштырды. Ул Гарифҗанның сәгать ничәләрдә, ничек урманга китүен сорашты, һәр сүзен язып барды. Нуриасма аның Бәриләргә кереп эчеп чыгуын, исерек булуын, аны председательнең урманга үзе әйдәкләп алып китүен сөйләп бирде. Аны тыңлаган саен, тикшерүченең маңгае вак җыерчыклар белән капланды, кулы язудан туктады. Ахырда ул күзлеген салып, ручкасын өстәлгә куйды һәм зәп-зәңгәр күзләрен Нуриасмага төбәде. Берничә секунд сынап карап торгач, болай диде:

— Әби, сез Идрисовның исерек булганлыгын төгәл раслый аласызмы?

— Төгәл дип... — Нуриасма ни әйтергә дә белмәде.— Ничек була соң ул төгәл раслау?

— Ну... әйтик, авызыннан аракы исе килгәнлеген.

— Мин урамның икенче ягында идем шул.

— Һемм... Алайса сез аның исереклеген каян белдегез?

— Исерекне айныктан аерырлык кына яшьтә инде мин,— диде Нуриасма төксе генә.

— Шулай да?

— Сөйләшүеннән, бөтен кыяфәтеннән...

— Кирамовада эчеп чыгуын расларлык дәлилләрегез бармы?

— Юк, нинди дәлилем булсын.

— Бәлки ул анда йомыш белән генә кереп чыккандыр, эчмәгәндер?

— Кыяр ашаргамы? Ул бит кыяр ашый-ашый чыкты.

— Кыяр ашау аның аракы эчүен раслаучы дәлил була алмый бит, әби. Кирамова, Идрисов айнык иде,ди, аңа бер грамм аракы эчермәдем, ди.

Тикшерүче зәңгәр тамырлы куллары белән ашыга-ашыга кәгазьләрен актарырга кереште һәм берсен тартып чыгарды.

— Больницадан бирелгән бу белешмәдә Идрисов айнык иде дип язылган.

Нуриасма шулчак нидер сизенә башлады.

— Үзебезнең район врачлары биргәндер бит? — диде ул сизенүен раслау өчен.

— Әйе, үзебезнекеләр.

Инде аңлашылды. Һәммәсе дә Хөснуллинга килеп тоташа иде. Врачлар аның кулында. Ул аларга колхозның түшкә-түшкә итен, чиләк-чиләк балын, капчык-капчык икмәген озата. Аптека мөдирләрен әйткән дә юк. Халыкка дип кайткан барлык кыйммәтле дарулар райкомның беренче секретаре белән Хөснуллинга китеп бара дип сөйлиләр. Алар ул даруларны туган-тумачаларына, дус-ишләренә аткаралар икән. Узган ел Хөснуллиннарга өй юышырга кергән хатыннар алардагы даруларның складтагы кебек өелеп торуына хәйран калып чыкканнар. Бу белешмәне алу аның өчен төкерек кенә. Гарифҗанны хастаханәгә илткәндә юкка гына ияреп бармаган инде ул. Зиратта Рәмзи рухын мәсхәрәләп, аның туганнарының күңелен йомшартырга, халык каршында игелек иясе булып күренергә теләсә, әшнәләре биргән ялган белешмә белән Хөснуллин хәзер исә үз җинаятен яшереп калмакчы була. Юк, ул ялгыз түгел! Халык җилкәсендә кәеф-сафа корып, җинаять өстенә җинаять кылып, үз башларын гына саклап яшәүчеләр менә шушы идарә йортыннан алып Мәскәүгә кадәр бер-берсе белән бәйләнгәннәр. Моны күреп торса да, соңарыбрак аңлады Нуриасма. Гомер буе фермада эшләп, буыннары кәкрәйгән Мосаллия үз гомеренә бер мәртәбә ындыр артындагы Бәкер санаториена да бара алмады. Йә, путевка юк, диделәр, йә, урыныңа кеше табып булмый, диделәр. Ә житәкчеләр үзләре елның теләсә кайсы вакытында хатыннары, хәтта балалары белән бергә Кара диңгез буена санаторийга очалар. Болар халыкның күз алдында эшләнә, боларны яшерә торган түгел. Әгәр бөтенесе бер булмасалар, ничек инде алар өчен генә андый җай бар да, колхозда бил бөккән кешеләргә юк? Берәүләр кол хәлендә, икенче берәүләр патша кебек. Гомер буе беркатлы булганга нәкъ әнә шул әйберләрне соңарып аңлаганга күрә дә Нуриасманың үз-үзен битәрләве аяусыз, тегеләргә карата нәфрәте чиксез иде... Шуңа күрә Хөснуллинның артын сөртергә кәгазьләр әзерләп йөртүче бу кешегә ул ачу белән карап торды. Тикшерүче әллә аның ни уйлавын чамалады, «син миңа алай ямьсез итеп карама» дип кисәткәндәй, ручкасы белән өстәлгә шак-шок сугарга кереште.

— Идрисовны аның белән урманга баручылар да эчмәгән иде диләр. Ничек сиңа гына исерек булып күренде икән ул?

— Нишләп миңа гына булсын? — диде Нуриасма эчендә кузгалган ярсуын көч-хәл белән тыеп.— Әнисе Хөснуллинның күз алдында сүкте аны. Эчкән өчен.

Тикшерүче тагын бер кәгазь алды.

— Хәдичә Идрисова үзенең менә бу аңлатмасында малаеның бер грамм да аракы капмаганлыгын әйтә.

Нуриасма көлеп куйгандай итте.

— Әнисе әйткәч, дөрестер инде алайса.

— Ә Идрисовлар белән сезнең арада ул-бу юкмы?

Тикшерүче, күзлеген киеп, ана кырыс карашын төбәде.

— Нинди ул-бу? — дип сорады Нуриасма, аңлап бетермичә.

— Ачу-мазар...

— Юк, юк, андый нәрсәнең булганы юк,— диде ул никтер ашыгакабалана.

Шуннан соң тикшерүче Нуриасма исеменнән язган аңлатманы укыды һәм аңа кул куярга кушып, алдына салды да ручка сузды. Тик Нуриасма кыймшанып та карамады.

— Кул куй, әби,— диде тикшерүче, ручканы аның борын төбенә үк китереп.

— Башта язып бетер, аннары куярмын,— диде Нуриасма тыныч булырга тырышып.

— Нәрсәсе килешмәде?

— Хөснуллинның Гарифҗанны мәҗбүри алып китүен ник язмадың?

Тикшерүче сикереп торып әрле-бирле йөренә башлады.

— Председательне бутау ник кирәк соң монда, әбекәччәем?! — диде ул нервыланып.

Нуриасма эченнән генә көлеп куйды. Әйдә, йөрен, түшәмгә сикер, тик барыбер син теләгәнчә булмаячак!

— Ә кемнәрне генә бутарга ярый? Син аерып күрсәт.

Тикшерүченең кашлары сикереп куйды. Орчык буе карчыктан мондый сүзләр көтмәгән иде, күрәсең.

— Син, әби, мине дөрес аңламадың,— диде тикшерүче, мөмкин кадәр йомшак булырга тырышып.— Бирелә бит сүз Идрисов хакында бара. Председательнең бернинди катнашы юк.

— Исерек Гарифҗанны урманга алып китсә дәме?

— Исерек булмаган ул! — Тикшерүче тавышын күтәргәнен сизми дә калды.

— Ә менә мин исерек дим. Исерек Гарифҗанны урманга алып китте дип яз. Хуҗа кушкач, шофер ни эшли ала? Гаепнең зурысы Хөснуллиннның үзендә.

— Хаталанасың, әби, хаталанасың!

— Юк, улым, Хөснуллинны ансат кына коткарам, дип син хаталанасың.

— Коткарырга аның җинаять эшләгәне юк...

— Мине син юләргә санама,— диде Нуриасма урыныннан торып.— Туганыбыз Рәмзинең каберендә миңа рәнҗеп ятуын теләмим. Район башлыкларына барып җитәрмен, кирәк булса, аннан да ары китәрмен — үз дигәнемне итми туктамам!

Ул ишеккә борылды, ләкин тикшерүче аны култыклап кабат утыртты. Аның йөзенә әллә сагаю, әллә курку билгеләре чыкты.

— Нигә башлыкларына барырга? — Ул ручкасын алды.— Әгәр үзеңә шулкадәр ышанасың икән — син кушканча язам. Тик яла ягу булып чыкмасын. Яла яккан өчен дә законда статья бар...

— Аллага шөкер, үз гомеремдә андый эш белән шөгыльләнгәнем юк.

Тикшерүче Нуриасма әйткәннәрне өстәп язды һәм, укып күрсәткәч, кул куйдырды.

— Ә Мәдинә? Аңардан сорадыңмы? — диде Нуриасма елтыраучы күзлек пыялалары аша тикшерүченең бәбәкләрен эзләп.

— Анысы инде безнең эш, әби! — Тикшерүче папкасын япты да елтыравык күненә учы белән шапылдатып сукты.— Тагын шунысы да бар: ул бит Идрисовка үчле. Син дә аның туганы.

— Алайса ник чакырттың?! — диде Нуриасма ачу белән.— Туган булгач, безнең сүзгә ышанмагач, чакыртмаска идең. Без башка җиргә дә бара белербез!

Ул саубуллашып-нитеп тормыйча чыгып китте.

* * *

Нуриасма чыгып китү белән тикшерүче Хөснуллин янына керде.

— Ни хәлләр бар? — диде рәис.

Тегесе күзлеген салып бик озак сөртте.

— Эш катлауланыр кебек бит әле, Мәҗит Харисович.

— Ни булды?

Ул Нуриасма белән булган сөйләшүне төкми-чәчми сөйләп бирде.

— Ул карчыкның киребеткән икәнлеге бөтен районга билгеле. Чакыртырга кирәкми иде аны.

— Шаһиевның хатыны үзе сорады бит.

Икесе дә шактый вакыт сүзсез тордылар. Хөснуллин ике кулы белән тәрәзә борысына таянды да, каядыр урамга караган килеш:

— Дөнья шул карчыкның аңлатмасына терәлеп калдымыни? — диде.

Тикшерүче аптыраган кыяфәт белән кулларын як-якка җәйде.
— Белмим инде. Тагын бит әле урманга барган теге ике кешегез бар. Идрисовның исереклеген дә, сезнен шунда бергә булуыгызны да яздылар.
Хөснуллин башын ялт борып аңа ачулы караш ташлады.
— Әйтергә идең. Мине бутамаска дип сөйләштек бит...
— Кат-кат әйттем. Аларны берәрсе котырткандыр. Берсен дә калдырмыйча язабыз дип, чата-кама килеп тордылар.
— Нишләргәдер кирәк. Мин бурычлы булып калмам...
— Берәү-икәү генә булса, аны ертып та атып булыр иде дә... Жалоба язарга мөмкиннәр. Әнә бит Шаһиевның хатыны, якыннары ишек төбеннән китми. Эшнең бүтән тикшерүчегә бирелүе дә бар. Катлаулы бу...
Хөснуллинның чырае күмер булды. Хәзергесе вакытта үзе хакында бер генә яман сүз дә чыгарырга ярамый иде аңа. Әле учет карточкасына язып бирелгән каты шелтә дә алынмаган. Район үзәгенә йорт салган өчен бирделәр аңа шелтәне. Дөресрәге, ул йортны саткан өчен. Ә нәрсә эшләргә тиеш иде соң ул? Район үзәгенә берәр эшкә күчергән булсалар, бүген шул йортта яшәр иде. Күчермәгәч, сатты шул. Ял көннәре белән дә, эш сәгате белән дә хисаплашмыйча көне-төне чапкан җитәкчегә шуны да күпсенделәр. Һәркөн уникешәр-уналтышар сәгать эшләден, рәхмәт, дип, аллә киләчәктә синең ул хезмәтеңә түләрләрме? Түләгән ди әнә. Әле бит тормышның башка ягы да бар. Син бүген монда, иртәгә кәҗә авылында. Кара көнеңә үз оянны булдыру мәслихәт. Менә ни өчен Мәҗит Харисович туган якларына йорт салмакчы иде.
Хөснуллин тәрәзәдән Мизхәтнең машинасы килеп туктаганны күрде.
— Әнә теге карчыкның малае да килеп җитте,— диде ул.— Саграк бул, аның бусы да әнисеннән ерак китмәгән.
— Ярар...
— Миңа хәзер үк Идрисовның әнисе кирәк. Дәштерерсең әле.
Шулай диде дә Хөснуллин үз бүлмәсенә ашыкты. Ул арада ишектә Мизхәт күренде.
— Мине сез чакырткан идегезме? — диде ул тупсадан узмыйча.
— Афзаловмы?
— Әйе.
Тикшерүче аның ябык, әмма тимердәй нык гәүдәсенә эчке көнләшү белән карап торды. Аның джинсы чалбарын, киң каешын, күкрәк кесәсенә эленгән күзлеген, шунда ук тыгылган блокнотын, авторучка ядәчен сизгер карашы белән капшап-капшап алды. Шуннан соң гына:
— Узыгыз, утырыгыз менә монда,— дип өстәл яныннан урын күрсәтте.
Үзе нәкъ Мизхәтнең каршына утырды да эшсезлектән нишләргә белмәгән кеше төсле ике кулын кара-каршы китереп бармакларын аралаштырды, аларны әле тиреләре агарырлык итеп кысты, әле тырпайтты. Мизхәт аның башының бик озын булуына, пеләш өлешенең ялтырап торуына игътибар итте. Аннары ул шунысын аермачык күрде: чигә тирәсеннән таралган тамырлары бүртеп-бүртеп тора, кайбер бүртмәчләрендә хәтта кан йөрешен дә чамаларга була иде.
— Сез Идрисовның күршесе дә, дусты да икәнсез,— диде ул, Мизхәткә түгел, ә үзенең тырпайган бармакларына карап.
— Әйе,— диде Мизхәт сак кына.
— Теге көнне ул урманга китәр алдыннан очрашкансыз, сөйләшкәнсез икән.
— Әйе, сөйләштек.
— Ул исерек-мазар булмагандыр бит? — диде тикшерүче болай гына, әһәмиятсез әйбер сорагандай гына итеп.
Мизхәт тикшерүченең нәрсә сораячагын монда килгәнче үк чамалаган, якынча җавабын да әзерләгән иде, билгеле. Тик хәзер, аның каршына баскач, каушап китте, керфекләрен аска төшереп, җавап бирә алмыйча торды. Әгәр Гарифҗанның исереклеген әйтсә, дустына бик начар булачак.

гын белгәнгә күрә, ул дөреслекне яшерергә ниятләде. Мизхәт керфекләрен күтәргәндә, тикшерүченең зәңгәр күзләре аңа төбәлеп хәрәкәтсез калганнар иде.

— Эчмәгән иде ул,— диде Мизхәт, алдашудан йөзенең уттай януын һәм бөтен тәненә тир бәреп чыгуын тоеп.

Тикшерүче кабаланып аның алдына кәгазь һәм ручка куйды.

— Языгыз. Кайчан, ничек күрдегез. Эчмәгәнлеген языгыз.

Ул яза башлады. Тикшерүче аның артына тәрәзә төбенә барып утырды. Мизхәт җөмлә төзи алмыйча җәфа чикте, тирләде, пешті, ялгышты, төзәтте. Арттан кеше карап утырганда бер кыен булса, дөрес булмаган нәрсәләрне язу үзе бер газап иде.

— Булды бугай,— диде ул артына борылып.

Тикшерүче аңлатманы тәрәзә төбеннән төшмичә генә алды да укый башлады. Мизхәт кәгазь кисәгенең шактый нык калтыравына игътибар итте һәм, бу кешенең йә нервылары тәртиптә түгелдер, йә бик эчәдер, дип уйлап куйды. Шул ук вакытта ул тикшерүченең уң як ирен почмагында хәйләкәр елмаюга охшаш нәрсә барлыкка килүен чамалады. Мизхәтнең язуыннан көлү идеме бу, әллә башка сәбәп бар идеме — анысын ул аера алмады. Тикшерүче аңлатманы кабат Мизхәтнең алдына салды.

— Әгәр сез аны айнык дип раслыйсыз икән, дәлилләрегез дә булырга тиеш.

Мизхәт аптырап аңа карады.

— Дәлил?

— Мин аның белән якыннан сөйләшеп тордым, бернинди дә аракы исе килми иде, дип языгыз.

Мизхәт ручканы кулына ала алмыйча утырды, чөнки бусы күрәләтә ялган иде. Тик хәзер моңардан баш тартып булмый, бу чыннан да Гарифҗанның айныклыгын раслый торган дәлилгә әвереләчәк иде.

— Курыкмагыз, курыкма,— диде тикшерүче, аның иңбашына җиңелчә генә кулы белән шапылдатып алып.— Экспертиза Идрисовның айнык булганлыгын раслаган бит.

Мизхәтнең өстеннән тау төшкәндәй булды һәм ул тикшерүче кушканча язып, кулын куйды.

— Миңа китәргә мөмкинме?

— Әлбәттә, мөмкин.

Хәзер теге хәйләкәр елмаю аның бөтен ирененә җәелгән, зәңгәр күзләре дә аңлаешсыз очкыннар чәчеп кысылганнар иде. Бу караш астында Мизхәт үзен алданган кеше кебек хис итте һәм шул авыр тойгы белән чыгып китте...

Хәдичә килүен күргә, тикшерүче аны утыртты да, тәмәке тартып керәм дип чыгып китте. Бераздан ишектә Хөснуллин күренде.

— Исәнме, Хәдичә апа,— диде ул аның янына чөймәшеп.

— Ару гына әле...

— Нәрсә, тикшерүче чакырдымыни? — диде Хөснуллин, берни белмәгәнгә салышып.

— Әле кичә генә чакырткан иде, тагын ни җитмәгәндер. Болай да башны кая куярга белгән юк...

— Нихәл итәсең инде, Хәдичә апа? Кайгы агач башыннан йөрми, бәндә башыннан йөри. Син артык бетеренмә. Гарифҗаның әйбәт кенә, мин врачлар белән сөйләшеп торам. Иң яхшы даруларны бирәләр, савыгып кайтыр, иншалла.

— И, Мәҗит апаем, кайтуын кайтыр. Аның бит әле азагы бар.

— Борчылма, Хәдичә апа, азагы да әйбәт булырга тиеш. Мин аны порукага алу турында эш йөртәм. Анысын үзең генә бел.

— Рәхмәт инде, апаем, бик зур рәхмәт. Туганың кебек күреп кайгыртасың инде...

— Монда четереклерәк бер нәрсә бар бит әле, Хәдичә апа...— Хөснуллин сүзен әйтеп бетермичә тукталып калды.

— Ни соң ул, апаем? — диде Хәдичә ана текәлеп.
— Беләсеңме нәрсә... экспертиза Гарифҗанны айнык дип тапты.— Ул мәгънәле итеп Хәдичәнең күзләренә карады. Хәдичә барысын да аңлыйм дигән мәгънәдә җиңелчә генә баш кагып куйды. Хөснуллин сүзен дәвам итте.— Ә менә берничә кеше Гарифҗан исерек иде дип аңлатма биргән.
— Әй, ходаем! — диде Хәдичә хафаланып.— Кемнәр соң алар?
— Урманга баручыларның икесе. Рәмзи хатыны. Хәер, алары синең эш түгел. Менә терәлеп торган күршең Нуриасма апа да Гарифҗан исерек иде дип чәтердәп тора ди.
— Нуриасмамы?!
— Әйе шул.
— Аннан булыр! Аннан була да ул!
— Син аның белән сөйләш, Хәдичә апа, күршең синең өстә кала. Ничек тә уртак тел тап. Гарифҗанның айнык булуы кирәк. Юкса, начар булыр аңа... Ә ул айнык булган тәкъдирдә, машинаның йә руленләге, йә тормозындагы берәр тимере өзелүе дә бар бит...
Хөснуллин чыгып киткәч, тикшерүче кереп, бер-ике юк кына сорау бирде дә Хәдичәне кайтарып җибәрде. Малаеның язмышы турында кайгырткан өчен ул председательгә күз яшьләре белән рәхмәтләр укый-укый чыгып китте.

### 4

Нуриасма тикшерүче яныннан бик авырлык белән генә кайтып житте. Авызы кипкән иде — чәй куярлык рәте булмады, башта ятып торды, йокымсыраган кебек тә итте, гәүдәсенә бераз хәл керсә дә, башы чуен кебек авыраеп калды. Чәй эчмичә җибәрмәс бу, дип уйлады ул һәм самовар куйды. Өстәл әзерләп йөргәндә, ишектә Хәдичә күренде. Аның йөзе борчулы, чәчәкле ак яулыгы астыннан маңгай, янак турларына тузгыган чәчләре чыгып тора иде. «Ишеткән»,— дип уйлады Нуриасма, күршесенең күзләренә туры карый алмады...
— Әйдә, түрдән үз, Хәдичә.— Ул аны өстәл артыннан чыгып каршы алды һәм ниндидер бер тетрәнү, яңагына китереп чапканны көткәндәй, аның беренче сүзен көтте.
— Мактап йөрисең икән, әле менә өстәл янына утырган гына идем. Әйдә, чәйләп алыйк,— диде, ягымлы булырга тырышып.
— Кичәле-бүгенле тамагымнан ризык үтми, күзем йокы күрми,— дип Хәдичә яулык очы белән күзләрен сөртте.
— Башыңа төшкәч, түзми кая барасың,— диде Нуриасма, инде болай да тәм-том белән тулы өстәлгә куярга суыткычтан әллә ничә төрле варенье, конфет ала-ала.— Әнә Рәмзи бүген кара җир астында ята...
— Әйтмә инде, әйтмә,— диде Хәдичә тагын күз яшьләрен сөртеп.— Шул техника балаларыбызның башына җитә инде. Гарифҗаным терелә алырмы инде...
Нуриасма икесенә дә куе итеп сөтле чәй ясады.
— Мизхәт бүген больницага барып кайтмакчы иде әле.
— Рәхмәт, рәхмәт, бигрәк бер-берсе өчен үлеп торалар инде. Үзебез дә начар яшәмәдек, аллага шөкер. Ул фермада эшләгән чакларны искә алсаң...
Хәдичәнең күзләре урынында түгел иде — Нуриасма моны ул килеп керүгә үк сизде. Юк, үткәннәрне искә алып утырырга гына кермәгән ул. Нуриасма көтте, ә Хәдичә чәйгә дә, ризыкка да үрелмичә әкрен генә сөйләшеп утыра бирде. Менә ул тамак кырды, зәңгәр шакмаклы клеенканың шакмагы буйлап бармагын йөртә-йөртә:
— Шактый кешене авыл Советына чакырганнар икән, сине дәшмәделәрме соң? — диде.

Клеенкага караса да, Хәдичәнең пычак очыдай үткән карашы күз читеннән генә елтырап китте.

— Чакыртмый калалармы соң, чакырттылар,— диде Нуриасма, әллә нәрсә юк кебек кенә итеп.

— Кулың калтырый димме?

— Бүген иртәдән бирле хәлем юк, әллә ни булды.

— Көне авыр, үземнең дә рәтем юк,— диде Хәдичә һаман клеенканы сыпырып.— Ниләр сораштырган булдылар соң?

Нуриасма урыныннан торып аның чынаягына үрелде.

— Чәең суынды, кайнарны ясыйм әле.

Хәдичә чынаягын кулы белән каплады.

— Юк, юк,— диде ул ашыга-ашыга.— Шушы килеш әйбәт.

— Синең бит салкын чәйне гомергә авызыңа алганың юк.

— Кайнары эчтә аның,— диде Хәдичә һәм авыр сулап куйды.

Икесе дә бер-берсенә карамыйча сүзсез тордылар. Тынлыкны Хәдичә бозды:

— Ниләр сорадылар соң?

Хәдичәнең җавап алмыйча чыкмаячагын Нуриасма аңлаган иде инде.

— Ниләр дип... ни күрдең — дөресен генә сөйләп бир, ди.

— Ни дидең соң? — Хәдичә карашын клеенкадан аңа күчерде.

Нуриасма аның йөзенә карамас өчен өстәлдәге әйберләрне гел кирәкмәгәнгә күчереп-күчереп куйды.

— Сөйләдем инде.

— Ни дип?

— Соң ничек булган, шулай сөйләдем.

Шунда Нуриасма үзенең дә бармагын нәкъ Хәдичә шикелле клеенка шакмагы өстеннән йөртүен күрде һәм, кулын кайнар нәрсәгә пешергәндәй, кинәт тартып алды. Әйтерсең лә аның бик җентекләп яшергән әйберсе күренеп китте.

— Минем Гарифҗан...— Хәдичә төкереген йоткандай туктап калды,— ни дидең соң?

— Күргәнчә инде, Хәдичә...

— Ничек күргәнчә?

— Үзең шунда идең лә. Миннән тәкрарлап сорап торасың юк.

Хәдичә чынаягын ачу белән этеп җибәрде, чәенең чайпалып клеенкага түгелүенә дә игътибар итмәстән:

— Их, Нуриасма, Нуриасма! — диде.

Аның һәр авазы кайнар күз яшьләре аша сыгылып чыкты, Нуриасманың йөзенә, әйтерсең, ут бөркелде.

— Мин бит синең ниләр сөйләгәнеңне ишетеп кердем! — Хәдичәнең зур булып ачылган күзләре зәһәр ялтырады.— Хак түгелдер дигән идем, шулкадәр дә ышанасым килмәгән иде... Инде аңладым...

Кинәт аның күкшел иреннәре хәтәр юкарып, алга таба кабардылар һәм ул Нуриасманың йөзенә төкергәндәй:

— Гарифҗанда ни үчең бар?! Гомер буе сиңа аш белән аткан балага ник син таш белән атасың?! — диде.

Гарифҗанны бу юл белән коткару ул Хөснуллиннар тегермәненә су кою икәнен, аларның халык җилкәсендә тагын да азыныбрак яши башлаячакларын Хәдичәгә аңлатып буламы соң?! Алар безне генә түгел, безнең балаларыбызны, оныкларыбызны да изәчәкләрен аңлатып буламы соң?!

Нуриасманың да йөрәге урыныннан купты, күңелендә әллә кайчангы рәнҗешләре белән хәзергеләре кушылды да өермә булып бөтерелде.

— Гарифҗан эчкән өчен хәзер мин гаеплеме?

— Син миңа җүләр сатма! — диде Хәдичә, каршысына очып килүче әйберне үткәрмәскә теләгәндәй, кул яссысын як-якка кызу-кызу селкеп.— Сиңа ни пычагыма аның эчүе, эчмәве? Күрми калсаң, ярамадымыни?!

— Сиңа яхшы атлы булам дип, дөреслекне яшерә алмыйм мин. Ачулансаң ачулан, үпкәләсәң үпкәлә.

— Дөреслек, имеш! — Хәдичә аллага ялваргандай карашын түшәмгә төбәп кулларын өскә күтәрде һәм шундук Нуриасмага иелде.— Гаделме соң ул синең дөреслегең? Иң якын күршеңне, малаеңның дустын төрмәгә утырта торган дөреслекнең азагын әйтимме: авыл бер эшче көчтән мәхрүм калачак! Шушылай синең кебек чалгы белән чапсак, авыл әллә кайчан беткән иде инде. Бер елны Хәсәннәр сугышкач, утыртабыз, клуб тәрәзәсен ватканнар, дип ду килделәр. Йөрдек тә, коткардык та. Утырткан булсалар, бүген өч алдынгы механизаторыбыз юк иде. Әйт, гаделме соң дөреслегең?

— Бер агач корыганга, бөтен урманны кисмиләр,— диде Нуриасма ачу белән.— Яшәп кара дөреслектән башка...

— Әйтер идем инде мин сиңа! — Хәдичә урындыгын алды да ыргыткандай шартлатып читкә куйды.— Авылны акыртып талаганда, кычыткан ашап, сыерыңның соңгы кашык сөтен ач-ялангач балаларыңның авызыннан өзеп, налог түләү өчен сатканда, кайда иде соң ул синең дөреслегең?! Әтиеңне төнлә нахакка алып киткәндә кайда иде?!

— Ул чаклар күптән үтте бит...

Хәдичә җикереп җибәрде:

— Үтмәде! — ул кулын сугардай булып аның борын төбендә селкеде.— Абзарыңнан сыерыңны җитәкләп алып чыгып киткән, бәрәңге бакчаңны кискән елларны оныттыңмыни? Колхозның акчасын капчыгы-капчыгы белән кара йөз шабашникларга бирел җибәргәнгә әле кайчан? Үзенең бөтен өере белән безнең канны эчеп симергән чабата кашлар ялгыз агачмы, урманмы? Шулмы синең дөреслегең?

— Бар ул, Хәдичә...

— Кайда соң ул, кайда, күрсәт!?

— Кешенең үзендә.

— Ә-ә-ә, үзендә икән! — дип сузды Хәдичә.— Үлемтек әйберләрс шикелле сандыкка бикләнгән, әйеме? Кеше күрмәгәндә генә алып барлаштырасың, көя төшмәскә нафталин сибәсең, әйеме?

Ул кисәк кенә Нуриасманың колагына иелде дә битенә кайнар сулышын бөркеп пышылдады:

— Ал син аңлатмаңны, кеше көлдермә!

Бүлмәдә тынлык урнашты. Хәдичә шулай иелгән килеш кымшанмыйча катып калды. Нуриасманың авыз тирәләрендә ачулы җыерчыклар күренде. Ул камфорка өстендә утырган фарфор чәйнекне кыйгайтып куйды, самовар чыжлый башлады. Хәдичә, авыз чите белән мыскыллы елмаеп, аның җавабын көтте. Нуриасма һаман аның төсле елмаеп:

— Ул риза түгел шул,— диде.

— Кем? — Хәдичәнең күзендә өмет чаткылары кабынды.

— Йөрәк,— диде Нуриасма тыныч кына.

Хәдичә ачудан башын артка чайкап җибәрде.

— Әйе, йөрәгең мина ачулы синең! — диде ул ярсуын тыя алмыйча.— Миңа кайгы килүе кирәк сиңа! Ә дөреслек дигәнең халык арасына чыкканда битко сөртә торган кершәнең генә!

— Ничек гөнаһтан курыкмыйсың, Хәдичә?! Син бит аллага ышана торган кеше!

Хәдичә аның бу сүзләрен гүя ишетмәде.

— Синең иптәшләре белән җылы якка очып китә алмыйча калган кара карганы күргәнең бармы? Кышкы салкында аннан да кызганыч җан иясе юк. Син шул карга хәлендә — япа-ялгыз. Мизхәтең булып Мизхәтең синең белән түгел: Гарифҗан бер грамм да аракы капмаган иде, дип язган.

Нуриасма урыныннан сикереп торуын сизмичә дә калды. Бу сүзләрдән аның тәннәре чымырдады. «Мизхәт миңа каршы... Мизхәт Хөснуллиннар белән...»

— Алдашасың, алдашасың! — дип кычкырды ул Хәдичәнең күзләреннән ялган эзләп.

Ләкин бер кулы белән моржа кучкарына таянган Хәдичәнең күзләрендә җиңү тантанасы балкый иде...

— Соң, миңа ышанмагач, авыл Советына бар,— диде ул мәсхәрәле елмаеп.

Нуриасманың ике битенә ялкын капты, тыны кысылды. Әлеге сүзләргә каршы куярлык аның бер генә дәлиле дә юк иде. Ул ашыга-кабалана камзулын киде, аягына чүәкләрен элде.

— Хәзер барам... тикшерүчегә барам...— дип сөйләнде ул үз-үзенә.

— Насырыңны корытма, Нуриасма,— диде Хәдичә никдидер әһәмиятсез генә әйбер әйткәндәй.— Синең аңлатмаң булды ни дә, булмады ни. Барыбер берни дә үзгәрмәячәк. Син бит берүзең.

— Алайса ник кыстап утырасың соң?

— Сынау өчен. Гомер буе яшәп, белмәгәнмен икән әле мин сине. Менә белдем инде, чын йөзең ачылды. Тыштан елмаеп, куеныңда таш йөрткәнсең икән. Мин сиңа мәңге дәшәчәк түгел!

Ул ишекне шартлатып ябып чыгып китте.

Нуриасма аякларын лаштыр-лоштыр сөйрәп көч-хәл белән караватына килеп җитте һәм ястыкка ауды, күзләрен йомды. Бөтен барлыгы теге сүзләрне кабатлады: «Мизхәт миңа каршы... Хөснуллиннар белән...» Аннары аның зиһенен бер сорау көйдерде: аңлапмы, аңламыйчамы? Бу сорауга нинди җавап бирелүгә карап, аларның тормышындагы бик зур, изге нәрсә бизмәнгә салыначак иде...

Хәдичә, урамны аркылы чыгып, өенең бусагасын атлап кергәнче Нуриасманы каргады. Алар мәңге килешә алмадылар. Моның төп сәбәпчесе Нуриасма иде. Ул гомере буе башкалардан аерылып торырга омтылды. Бөтен җирдә — фермада, урамда, җыелышта, мәҗлестә, һәр көн, һәр сәгать, һәр минут үзен күрсәтергә тырышты. Ул тырышкан саен, Хәдичәнең аңа котырып ачуы килде.

— Син әллә кая сикермә, барлык кешеләр төсле эшлә, ник тиреңнән чыгасың?! — дип аның йөзенә бәреп әйтә иде Хәдичә.— Бушка, бер таякка икәнен белмисеңмени?

Белергә теләмәде шул Нуриасма. Төннән төнгә фермада җене сыырылганчы эшләп аңа да бер таяк иде югыйсә.

Бер елны Хәдичә әнисе белән бер меңнән артык хезмәт көне эшләде. Алла боерса, быел тернәкләнеп китәбез икән, тамаклар туя икән, дип шатлануларының чиге булмады. Ә ел азагында, әйтергә дә оят, шулкадәр хезмәт көненнән тулар-тулмас бер капчык ашлык тиде. Бер еллык эшнең бәясе! Капчыкны идән уртасына утырттылар да үкереп еладылар. Өстәвенә ничәмә-ничә төрле налоглы, заемы! Бу гаделсезлектән, бу мәсхәрәдән ничек котылырга, кая качарага? Каршы әйтсәң, авылдан читкә чыгып китсәң — себер, төрмә. Авылда туасы булмаган. Тугансың икән, башыңны ташка орсаң да, сиңа бүтән тормыш юк. Кол кебек кәкрәйгәнче эшлә. Ул хәлләргә ни кылырга белмичә Хәдичәләр бәргәләнгәндә, Нуриасмалар эшләде дә эшләде. Әйтерсең, барысы да ал да гөл, шулай булырга тиеш, аңа Хәдичәләр дә, халык та, авыл да кирәкми, ул үзенә аерым зат иде. Фермада үзенең куна-төнә эшләве генә җитмәде, балаларын да алып килеп бил бөктерде. Бервакыт Хәдичә аның кулыннан сәнәген алып ыргытты.

— Кем өчен ертыласың, кемнәрнең табанын ялыйсың?! — дип кычкырды ул бөтен ферманы яңгыратып.— Бушка бит, бушка! Сизмисеңмени: иелгән саен, бил бөккән саен ныграк мыскыл итәләр, ныграк җәберлиләр!

— Ә нишләргә соң?!

— Тураеп басарга! — диде Хәдичә.— Без дә кешеләр, без дә яшәргә тиеш. Син җиде кат тиреңне тунаганда рәхмәт укып торасың, әле балаларыңныкын да тунатасың. Ә менә мин үзем дә туныйм! Миңа әшәкелек

кылалар икән, карап торыйммы?! Ә син чиста калмакчы булып кыланасың, макталасың килә.

Хәдичәләр фуражын да, печәнен дә, башкасын да әз булса да алып кайтырга тырыштылар. Халыкның күпчелеге шулай итте. Ю-ук, моны урлашу дип әйтергә мөмкинме икән? Юктыр. Бу бары тик бер нәрсә — исән калу өчен иде. Аларның исән калырга хаклары юк идемени?! Бар иде, хәзер дә бар, чөнки алар тиешлесен дә ала алмадылар. Ә башкасы? Еллар буе ял итмичә, авыруына-ниенә карамыйча, ачлы-туклы яшәү? Эшләү? Нуриасма исә, бозауларга печән бетсә, чалгы тотып үзе болынга китте. Авырса да, түшәктә ятмыйча эшләп йөри торгач, ике як үпкәсенә дә салкын тигерде. Аңа башкача ярамый, ул алдынгы, ул Хәдичәләргә үрнәк күрсәтә иде...

Колхозга алдап керткәннәр иде, дип уй йөртте Хәдичә, һаман алдап эшләттеләр, түзеп була алмаслык дәрәҗәдә бөтен яклап та кыстылар. Сулыш алудан башкага бернинди дә хокук калмады. Нуриасмалар халыкны алдаучылар һәм җәберләүчеләрнең сүзенә кул чаптылар, кара тир агызып бил бөктеләр. Гадел булмаган тәртипләргә риза булу, ярарлашу, халыкның кол хәлендә яшәве белән ризалашу дигән сүз түгелме соң? Өстә утыручыларга шул гына кирәк ләбаса, алар Нуриасмаларны күкләргә чөйделәр, маяк, ударник дигән исемнәр тактылар, мактау кәгазьләре бирделәр, президиумнарга утырттылар, газеталарда рәсемнәрен чыгардылар. Нуриасмалар тиле-тиле тигәнәк дигән саен чәчләре белән җир себерделәр. Бу бит, күрмәдеме әллә Хәдичә,— очсыз абруй артыннан куып, түрәләргә ярарлашу, үз иптәшләренә хыянәт итү иде. Чөнки Хәдичәләрне, Нуриасмалар кебек эшләмисез, дип гаепләделәр, битәрләделәр, еш кына хәлләрдә Хәдичәләргә бирәселәрне Нуриасмаларга бирделәр. Болар өчен аны Хәдичә беркайчан да кичермәячәк! Күпме генә күкләргә чөйсәләр дә, дөньяны Нуриасмалар үзгәртмәде. Әгәр дөнья ни кушсалар, шуны башкаручы Нуриасмадан гына торса, әгәр җай чыккан саен йөнны кирегә сыпыручы, гаделсезлек тәрәүләрен астан тәрләчә какшатучы Хәдичәләр булмаса, кем белә, бәлкем, авыл бүген дә теге буш таякка карап утырыр иде әле. Баштан ук бөтенесе бердәм булып тиешле якны каерсалар, авыл бүгенге кебек мөшкел хәлгә төшмәс иде. Ә Гарифҗаннарның нинди хокукы бар?! Аларга ни чәчәсен, ни төзисен, нинди терлек асрыйсын хәл итәргә кем хокук бирә?! Алар «әйе» диюче генә. Ә бит «әйе, ярар» дип тормыш бармый, «юк, алай түгел, болай ул» дисәң генә бара. Моны Хәдичә күптән аңлады, Нуриасмага исә ул кирәкмәде, аңа үз даны, үз исеме кадерле булды. Халык бит боларның берсен дә аңламый. Нуриасма пионерлар, комсомоллар белән очрашуларга йөри, сөйли, мактана, аңа шаккаталар, аны әйбәт диләр, ничек дөрес яшәгән, диләр. Нуриасма хаклы булып кала, ә Хәдичәләрнең ачы хакыйкате тормыш елгасы төбендә вакыт агымының мәңгелек ләме белән капланып кала. Иң коточкычы, иң аянычы әнә шул! Бу дөреслекне кемгә сөйләп, кемгә аңлатып була?! Менә кем ышана? Аның Гарифҗанны батырырга теләве дә үзен халык каршында пакь итеп күрсәтергә омтылудан гына түгелдер дип кем әйтә ала? Уйлый, уйлый да Хәдичә, «әтисе булса, Гарифҗан да болай булмас иде», дип ачына. Бигрәк аз яшәп калдылар шул алар Зәбир белән. Аны райбашкармада эшләгән җиреннән Күкелгә китереп рәис иттеләр. Бер ай дигәндә Хәдичәгә йортка керде. Үзе Чаллы якларыннан иде. Хатыны белән аерылганына өч ел, балалары булмаган. Гарифҗан тугач, Зәбирнең башы күккә тиде. Хәдичә әле Суфиясенә узган гына иде. Зәбирне райкомга чакырдылар. Чырае кара янып кайтып керде. Ике хатын белән яшәгән өчен партиядән чыгарабыз, җавапка тартабыз, дип котын алганнар мескенненең. Чыннан да, беренче хатыны белән загслы иде ул. Икенче мәртәбәсенә судка бирде — хатыны аерылырга тагын ризалашмады. Үтәр дигәннәр иде, үтмәде. Тагын райком, тагын бюро. «Барып сөйләшәм, ризалатам мин аны»,— дип киткән иде. Чаллыда йөрәге ярылып үлгән... Зәбирне җирләгәч, Хәдичә теге хатынны Чаллыдан эзләп табып, чәчен йолыкты, син генә үтердең, мәңге рәхәт күрмә, дип каргады. Аңа ник бу кадәр рәхимсез булды икән язмыш?!

## 5

Бүгенге идарә утырышы Хөснуллинның тәмам теңкәсен корытты. Аңа утырышның иртүк узуы кирәк иде, ә моңа исә күпләр каршы килде. Ут капмагандыр, кичкә калдырыйк, эш оештыра торган чак, урак өсте диючеләр шактый булса да, председатель сүзе өстен чыкты. Утырышта, гадәттәгечә, әллә ничә гариза, әллә ничә мәсьәлә каралды. Үзе өчен иң мөһим мәсьәләне (Хөснуллин утырышны шуның өчен генә җыйнады да) ул иң азакка калдырды. Юри бер генә тәнәфес тә ясамады. Арыган, талчыккан кешеләрне үзең теләгән юлга боруы бик ансат, алар теләсә нинди тәкъдимгә риза дип кул күтәрергә әзерләр, чөнки һәркайсы үзен көтеп торган мең төрле мәшәкать өчен көяләнеп утыра, моннан ничек тизрәк чыгып ычкыну хакында гына хыяллана. Иртәнге алтыда башланган утырыш тоташ ике сәгать барды. Инде Рәмзи хатыны Мәдинә мәсьәләсен куярга да була иде. Мәдинәнең аяк буыннары сызлый, ул инде күптәннән җиңел эш сорап йөрде. Хөснуллин аны ферма мөдире үк итәргә ниятләде. Чөнки Мәдинә аңа бу көннәрдә үз әти-әнисенә караганда да кирәгрәк, алай гына да түгел, аның тыңлаучан булуы кирәк иде. Дөрес, баш белгечләр — аларның һәркайсы белән Хөснуллин аерым-аерым сөйләште — әүвәл каршы килделәр, аннары рәиснең чигенмәсләген, сүз көрәштерүнең файдасыз икәнлеген күргәч, ризалаштылар. Каршы килүләре Мәдинә мөдирлекне булдыра алмас диюдән түгел иде. Бер яктан менә дигән сыер савучыны югалтасылары килмәсә, икенче яктан, хәзерге мөдир салгаларга яратуын исәпкә алмаганда, әйбәт житәкче иде. Әчкән саен Хөснуллин аның «эштән азат итүегезне сорыйм» дигән гаризасын яздыра. Утырышта катнашучыларга ул аның шундый дүрт гаризасын селкеп күрсәтте һәм ферма мөдирлегенә Мәдинәне тәкъдим итте. Элекке мөдирнең гадәтен белгәнгә күрә кайберәүләр, аның гаризаларына житди нәрсә итеп карамаска кирәк, диделәр, алны-ялны белми, тырыш, эшләсен, дип чыктылар. Икенче берәүләр Мәдинәне хупладылар, яшьтән үк сыер сава, тәҗрибәле, коллектив хөрмәт итә, куярга кирәк, диделәр. Өченче берәүләр: нишләп аларның икесенең берсе дә утырышта юк, Мәдинә риза булырмы соң? дип, мәсьәләне тагын да катлауландырып җибәрделәр. Мәдинәнең холкын белгәнгә күрә Хөснуллин аны бирегә юри чакыртмады. Үзен мөдир итүгә хәтта бер генә кешенең икеләнүен сизсә дә, шундук баш тартачак иде. Мәдинә риза, аның утырышта катнашуы мәҗбүри түгел, дип, колхоз рәисе үз тәкъдимен тавышка куйды һәм ул кабул ителде. Инде утырыш тәмам дип дәррәү кузгала башлаганнар иде дә Хөснуллин:

— Бер генә минутка, иптәшләр,— дип халыкны туктатты.— Сезгә мәгълүм, Рәмзинең иптәшләре бүген-иртәгә аның мунчасын эшләп бетерәләр. Үзе күп еллар идарә члены булып торды, хатыны да үрнәк савучы. Шуны искә алып, мунча эшләү чыгымнарын колхоз хисабына күтәрергә кирәк, дигән фикер бар иде. Ничек карыйсыз?

— Бик дөрес булыр! — диде баш бухгалтер рәис белән алдан килешенеп куйганча.

Башкаларның да хуплау сүзләре ишетелде. Тик профсоюз комитеты рәисе генә моңа каршы килде:

— Җирләү өчен матди ярдәм дә бүтәннәргә караганда ике мәртәбә артыграк бирелде,— диде ул.— Бусын да эшләсәк, башка колхозчыларда ризасызлык туачак...

— Рәмзи кебек кешеләр сирәк,— диде баш бухгалтер, аның сүзен бүлеп.

— Бик беләм, Рәмзи кебек кеше булмас та. Тик барыбер гадел түгел бу. Әнә Гөлгенә биш бала белән ятим калды. Өе кечкенә. Әйдәгез, аңа да өй салып бирик.

— Идарә риза булса, мин каршы түгел,— диде Хөснуллин.— Аңа да өй салыйк.

Бүлмәдә шау-шу купты. Тагын кемнәрнеңдер кемедер үлгән, аларга да йә тегесе, йә бусы кирәк, мондый юл белән барсак, колхозны шәхси хуҗалыкларга хезмәт күрсәтүче оешмага гына әверелдерергә туры киләчәк, диделәр. Хөснуллин шау-шуны туктатты да тәкъдимен тавышка куйды һәм беренче булып кулын күтәрде. Бу да үтте. Эшнең беренче яртысы хәл ителде, инде икенче яртысын башкарырга кирәк иде. Бүлмәсе бушауга, Хөснуллин шоферына Мәдинәне алып килергә кушты.

Мәдинә иртәнге савымнан кайтып чәй эчәргә генә утырган иде. Шофер рәиснең ник чакыруын әйтә алмады. Мунчаның инде түбәсен генә ябасы калган, төзүчеләр калай әзерлиләр иде. «Мөгаен эшләгән өчен акча түләргәдер»,— дип, ул саклык кенәгәсен кесәсенә тыкты.

Хөснуллин аны аягүрә басып каршы алды.

— Мәнә кичә фермада әйткәнемне мин үтәдем дә,— диде ул сизелерсизелмәс елмаеп.— Бүген идарә утырышы сине ферма мөдире итү турында карар чыгарды.

— Рәхмәт инде, Мәҗит Харисович. Мин һаман да куркам, көчем җитәрме — белмим...

— Ярдәм итәрбез. Ялгызың түгел, бергәләп эшлисе. Мунчагызны салу да, колхоздан алган материалларны да бушлай булыр.

Мәдинәнең йөзенә кызыллык йөгерде.

— Акчасын түләсәм, җиңелрәк булыр иде, халыктан кыен бит...

— Юк сүз сөйләмә! — диде Хөснуллин кулын селтәп.— Идарәнең карары шундый.— Ул бераз дәшми торды да кинәт ачулы тавыш белән:— Ә Гарифҗанны төрмәдә черетергә, нәселен корытырга кирәк! — дип кычкырды.— Шулаймы?!

Мәдинә коелды да төште. Ул председательнең ник болай диюен аңлый алмады, курку-шикләнүдән бөтен эчке әгъзалары суынып киткәндәй тоелды.

Хөснуллин аның каршына ук килде.

— Их, Мәдинә, Мәдинә! Синең урыңда булсам, шул егетне төрмәгә тыгарга маташучылар рәтенә басмас идем!

Аның тавышы хәзер ягымлы, йөзендә олы борчылу, кайгыртучанлык билгеләре уйный иде.

— Аны төрмәгә тыгарга... ни сөйлисез?!

— Исерек иде дип күрсәтмә биргәч, тагын ни кирәк?

Мәдинә үксеп елап җибәрде.

— Ничекләр алдыйм соң, Мәҗит Харисович?!

— Монда беркемне алдау юк.— Рәис баядан бирле бүлмәне ярып шылтыраган телефон трубкасын күтәреп кабат урынына куйды да сүзен дәвам итте.— Син үзеңне аның хатыны, балалары, авыру әнисе урынына куеп кара.

— Сез дә үзегезне минем урынга куеп карагыз,— диде Мәдинә өзгәләнеп.— Рәмзи рухы алдында мин ничек гөнаһ кылыйм ди?! Ул бит янәшәмдә генә, һәрвакыт янымда, мин хәтта аның җылысын, сулыш алуын тоям... Мин шул ялганга барсам, аның каршында җаныма зур гөнаһ алачакмын, аның рухын рәнҗетәчәкмен. Әти-әнинең, Мөхтәр абыйсының, башка туганнарының күзенә ничек карармын?!

— Ай-һай, Мәдинә, белмимүк.— Рәис башын чайкап торды.— Гарифҗаннарга китергән бәхетсезлекләр өчен Рәмзи сиңа рәнҗемәсме икән? Син бит аның нинди изге җанлы кеше икәнлеген беләсең. Игътибар беләнрәк тыңлап кара әле син аны. Ул бит гомере буе таш белән атканга аш белән атты...

Мәдинәнең ябык кечкенә гәүдәсе ничектер куырылып, бөрешеп калды, башы аска иелде. Аның чырае газаплы тартыша иде. Бу исә Хөснуллинга ышаныч өстәде һәм ул күптән уйлап куелган сүзләрен ашыгаашыга дәвам итте:

— Гарифҗан явыз ният белән эшләсә, бер хәл иде. Бу бит очраклылык, ялгышлык кына. Мөхтәрләр дә суынырлар, аңларлар. Ә болай

сез халыкның нәфрәтен генә казанырсыз. Дөньяда кичерә белүдән дә изгерәк нәрсә юк — минем принцибым шундый. Моны бөтен колхоз белә. Әллә кемнәр төрмәгә эләгәсе иде, мин аларны йолып калдым. Хәзер рәхмәт укыйлар, аллага табынгандай табыналар.— Хөснуллин шунда авыр итеп бер сулады да:— Кичер син аны, Мәдинә! — диде. Аларны да бәхетсез итмик! Сузарга ярамый: хәзер үк тикшерүче янына кер. Ачудан гына әйткән идем, диген. Һәм гомумән, эшне туктатуыгызны сорыйм, мин беркемне дә гаепләмим, дип гариза яз. Бу сиңа минем үтенечем. Аңла зинһар...

Мәдинә дәшмәде, башын игән килеш утыра бирде. Аңладымы ул аны? Аңлагандыр кебек. Әгәр бу фаҗигане уттай урак өстендә үзенә агачка барганда булганын район җитәкчеләре белсә, аны рәислектән алып атачакларын әйтергәме-юкмы икәнен Хөснуллин бик озак уйлады. Әгәр Мәдинә кискен каршы килсә, аның башка чарасы юк иде. Дәшмәү — ризалык билгесе дип, ул әйткән кадәресе белән чикләнде. Мәдинә күләгә шикелле тавышсыз-тынсыз гына чыгып китте.

Ул көнне аның күңелендә тикшерүче янына бармаслык көч табылды. Ә менә пошаманланып, мең төрле уйга төшеп үткәргән йокысыз төн аны сындырды. Бөтен барлыгы белән Мәдинә Хөснуллин сүзләренә карышса да, һаман аның ягына авыша баруын сизде. Чөнки ул әйткән нәрсә һәммәсен дә аклый, коткара, барысы өчен дә уңайлы иде. Шулай булуга карамастан, Мәдинәнең күңеле моны кабул итмәде, әмма күңеле кабул итмәсә дә, ул бирешә баруын, салкын акылының җиңә баруын тойды. Аны ниндидер чит көч, сизелми торган бер агым кебек, һаман үзе теләмәгән якка этә бирде. Инде торып фермага китәр вакыт җиткәндә генә ул әллә төшләнеп алды, әллә чын уяу хәлдә Рәмзинең тавышын ишетте: «Син бит инде барысын да хәл иттең, чуаркаем,— диде ул.— Үзең теләгәнчә эшлә...»

Тикшерүчегә барганда, Рәмзи рухыннан ул тагын бер мәртәбә елый-елый гафу сорады. Аның яныннан кайтканда мотоциклы белән канауга мәтәлә язды. Әрәмәлеккә туктап җиргә утырды, башын тезләренә салып тагын уйга батты. Һәм ул коты очып үзенең каядыр, ниндидер әйбәт булмаган нәрсәгә килеп капканлыгын аңлады. Ниндидер зур, изге нәрсә аяк астына салып тапталган, пычранган, инде соң, артка юл юк, ул хәзер үзе түгел, ниндидер ят, көчле агымның бер кисәге генә иде...

## 6

Мизхәт төшлектә үк Гарифҗан янына барып кайтырга ниятләгән иде дә, өлгермәде. Инде менә механизаторлар кичке ашка утыргач, ул ашап-нитеп тормады, хастаханәгә элдерде. Алар кузгалганчы, кайтып җитәргә кирәк. Биш чакрым ара сизелмәде. Ул аерым палатада ята иде.

Гарифҗанның башы колакларыннан ук марля белән чорналган, түбә тирәсеннән бер учма чәче тырпаеп чыккан, куллар, күкрәкләр дә марля эчендә, агарынган йөзен сакал-мыек баскан. Янында хатыны Хәлимә утыра.

— Хәлләрең ничек? — диде Мизхәт үзендә әллә нинди аңлаешсыз кыенсыну тоеп.

— Баш...— диде ул көч-хәл белән.— Баш...

Аның очлаеп калган борынына, авыз яннарына бәреп чыккан тир бөртекләрен Хәлимә мамык белән сөрткәләде. Гарифҗан үзенең чырае өстендә хәрәкәтләнгән мамыклы кулга курыккандай карап-карап торды да күзләрен йомды һәм хырхылдап сулыш ала башлады.

— Төнлә керфек тә какмаган иде,— диде Хәлимә пышылдап.

Мизхәт палатадан чыгып китте.

Ул басуга барып җиткәндә, комбайннар эшкә керешеп кенә маташалар иде. Мизхәтне Хөснуллин туктатты.

— Эшләр бер дә шәптән түгел бит әле, Мизхәт дус,— диде ул шаккатырып.

Дүрт ел эшләп аның бер генә мәртәбә дә Мизхәткә исеме белән дәшкәне юк иде. Кая таба бөгә соң әле председатель? Мизхәт таннан чыга, төнлә генә кайта, аның гаебе белән комбайннарның туктап торганы юк, тартмасыннан бөртек коелып йөрми. Нәрсә булыр?

— Сез ни турында? — диде Мизхәт йөзенә аптырау билгеләре чыгарып.

— Мин миһербанлылык хакында әйтәм.— Хөснуллин каядыр еракка күз ташлап алды.— Дустың үлем белән тартышып ятканда, бер дә әйбәт булмаган...

Мизхәт тәмам чыгырыннан чыкты.

— Мәҗит Харисович, турысын гына әйтегез: ни бар?!

— Гарифҗанны батыра торган анлатма биргәнсез дип ишеттем. Дөресме?

Мизхәт сабырын җуеп урынында таптанып куйды һәм тотлыга-тотлыга:

— Минме?! Ничек инде?! — диде.— Мин... мин... мин бернинди начар әйбер язмадым!

— Язмагансың икән, бик әйбәт,— диде Хөснуллин тыныч кына.— Тик әниең Нуриасма апа... Белмим, аңа ник кирәк булгандыр Гарифҗан исерек иде дип язу...— Рәис аптырап башын чайкады, сүз таба алмыйча туктап калды.

Мизхәт авызын ачты да катты. Аяк астындагы сары камылга караган килеш ул бөтен гәүдәсе белән акрын гына борылды һәм машинасына таба атлады. Арттан Хөснуллинның тавышы яңгырады:

— Бүген-иртәгә яңа машина кайтып җитә. Үзегезгә үзегез аяк чалмасагыз, яхшы булыр иде.

«УАЗ»ның кузгалып киткәне ишетелде. Председатель әйткән хәбәр башта аны аптырашка салса, хәзер ул бәйләнгән яраны чишеп, ертып җибәргәндәге шикелле әрнү белән алышынды. Ул әрнүнең чыганагы бер — үзен Гарифҗан алдында гаепле итеп тою иде. Әнисенең бүтәнчә язмаячагын Мизхәт белергә тиеш иде бит! Ләкин бу очракта!.. Бу очрак бөтенләй башка, Мизхәтнең җан дусты белән, аның язмышы белән бәйле ләбаса!

Шул уйлар, шул кичерешләр белән кичке сигезләр җиткәне сизелми дә калды. Бүген чык иртә төште, комбайннар туктадылар. Мизхәт, машинасын куйгач, ашыга-ашыга кайтты, иң элек Гарифҗанның хәлен әйтергә дип аларга керде. Сыер саварга чиләк, сөлге тоткан Хәдичә апа өйалды ишегеннән аңа каршы килеп чыкты. Ул исәнләшмәде, дәшмәде, Мизхәтне күрмәгәндәй, аңа ышкыла язып, баскычтан төште дә абзарга таба атлады. Аның артыннан Гарифҗанның кызы белән малае да йөгерешеп чыкты.

— Хәдичәтти! — диде Мизхәт аның артыннан иярел.

Хәдичә шып туктап аңа борылды да:

— Рәхмәт, апаем, кешенең кем икәнен авырлык килгәндә беләсең икән,— диде.

Аның күзләренә карарга куркыныч иде.

— Яңадан безнең ихатага аяк басасы булмагыз!

Шулай диде дә абзарга кереп китте. Гарифҗанның ике баласы Мизхәткә, нишләр икән бу дигәндәй, кызыксынып карап тордылар. Ул кызуланып капкадан чыкты, әмма үзләренә кайтырлык, әнисе белән очрашырлык кыюлык тапмады.

— Мизхәт үскәнем! — аңа таба Бәрия апасы килә иде.— Әллә авырып киттеңме, төсең качкан,— диде ул аның ике яңагын сыпырып.— И-и, салкын тигән сиңа, үскәнем. Әйдә, җылынып чык...

Мизхәт аңа берсүзсез иярде. Әгәр очрамаган булса да, Бәрия апасына керәчәк иде ул. Ач карынга ике рюмка эчкәч, күңелдәге әрнүләр,

аптырашлар, рәнҗешләр, ачулар ераккарак чигенгән шикелле булды. Мизхәтнең теле ачылды:

— Их, Бәрия апа, мине Хәдичәтти өенә кертмәде!..

— Барысы да җиңгәчәйдән! — диде Бәрия өзгәләнеп.— Ни начарлыгым тигәндер, мине дә бит... Тагын чакыртты теге кеше: эчерденме, юкмы, ди.

Бәрия үзе эчәргә кыстады, үзе туктаусыз сөйләнде:

— Аша әле, апаем, житеш коймагыннан да, башкасыннан да. Җиңгәчәй гомер буе мөгез чыгарды, бөтен халыкка яраган аңа ярамады. Шәрифҗан абыеңны да бит ул сөрелгән басудан ат арбасына өшегән чөгендер чүпләп алып кайткан өчен адәм хуры итте. Шул чөгендерен колхозга илтеп аудартып, идарәгә әләкләп йөрде. Шуннан соң читкә чыгып китте бит мескен Шәрифҗан. Ә кайда урлашмыйлар? Мин дөньяны шактый гиздем. Элек тә урлаштылар, хәзер дә урлашалар. Элек кайберәүләр генә иде, хәзер бөтен җирдә, бөтен кеше. Олтаныннан алып солтанына кадәр урлаша. Элек мескен халык исән калу өчен урлашса, хәзер түрәләр майларына чыдый алмыйча урлаша. Элек калаклап он булса, хәзер табаклап алтын. Имеш, җиңгәчәй генә әллә кем. Чабаталы фәрештә булмый ул! Миңа спекулянт дигән мөһерне дә иң әүвәл ул такты. Әйдә, тагын берне җибәр әле, апаем, тартынып утырма. Чакырып алып булмый, үзегез кермисез. Җиңги мине гомергә яратмады, халыкны талыйсың, дип бәйләнде...

Аны тыңлаган саен, Мизхәтне ачыну катыш үкенү били барды, гүя ул үзе дә Бәрия артыннан сүзен-сүзгә кабатлады. Мизхәткә әнисенең Шәрифҗан абыйсының авылдан чыгып китү тарихын сөйләгәне бар иде. Аны каракка әйләнер дип курыккан ул. Тормыш авыр, киендерерлек рәт юк иде, ди. Кешеләр урлашырга мәҗбүр булганнар, күпләрне төрмәгә дә утыртканнар. Әнисе идарәгә, авыл Советына барып, елап, ялварып, Шәрифҗан абыйсын хәрби училищега озаткан. Мизхәт уйларын дәвам итә алмады, чөнки Бәрия апасының сүзләре нәкъ колак төбендә яңгырап торды:

— Әйдә, авыр сулама, ашап-эчеп утыр әле, апаем. Ярый, спекулянт дисеннәр. Мин нинди начарлык кылган? Авыл халкына бер-ике чемодан әйбер алып кайтып сатканнан ни булган? Хәзер әнә дәүләт үзе шуны алга куя, бөтен ил ачыктан-ачык спекуляция белән шөгыльләнә. Менә шулай ул дөнья. Кем хаклы булып чыга соң инде? Ә җиңгәчәйгә, хет күз алды, хет күз арты, акыл кермәде, апаем. Ничек диләр әле... бөкрене...

Мизхәтнең куллары йодрыкланды, шартлатып өстәлгә сугасы килде, шулай да ул тыелып кала алды. Сикереп торды да:

— Җитте инде, Бәрия апа! — дип кычкырды һәм чыгып йөгерде.

Ул өйгә атылып килеп керде. Әнисе йон җегерли иде. Мизхәтнең борчулы йөзен күргәч, аның кабадан йон тартучы бармаклары хәрәкәтсез калды, орчыгы фырылдап әйләнүдән туктады.

— Ни булды, улым? — Нуриасма орчыгын читкә алып куйды.

— Әни, нигә син Гарифҗанны...— аның фикере өзелде, кирәкле сүзләр теленә килмәде.— Нигә... әйттең?

Сәгыйдулла ачуланган чакта ике каш арасыннан маңгай уртасына таба тирән җыерчык сузыла иде. Андый җыерчык Шәрифҗан белән Мизхәттә дә бар. Шуның тирәнлегенә карап, аларның йөрәгендә ниләр кайнаганын төгәл билгеләргә өйрәнде Нуриасма. Мизхәт нык ачулы иде. Ул әнисенә карамады, әле өстәл янына килде, әле тәрәзә каршына барды, әле үзенең киштәдәге китапларын кузгаткалап куйды. Нуриасма урыныннан кузгалмыйча гына аңа карап утырды.

— Башкаларга яраган бер синә генә ярамады. Гомергә шулай... Син генә үзеңә бер төрле...

Бу сүзләрне Мизхәт елап диярлек әйтте. Тик Нуриасма керфеген дә селкетмәде. Гүя аның үз уе, үз кайгысы шул кадәр зур, ул уй тавы

каршында Мизхәт әйткән әйбер тузан бөртегенә дә тормый иде. Ниһаять, ул авыр итеп сулады да жыр көйләгәндәй сузып:

— Мин дөрес яшәмәгәнмен икән алайса,— диде.— Мине яшәргә өйрәт әле, улым, әйдә өйрәт...

Мизхәт аякларын аерып тәрәзә каршына баскан килеш:

— Әни, Гарифҗан хакына! — диде.— Коткарырга кирәк аны! Бер генә мәртәбә...

— Нәрсә бер генә мәртәбә?! Йә, әйт, нәрсә?! — Нуриасма кычкырып җибәргүен үзе дә сизми калды.

Мизхәт ялт итеп борылды һәм әнисенең кырыс карашы белән очрашты, нишләптер эсселе-суыклы булып китте. Күзләрен тизрәк читкә алды, көчсезлеге өчен үз-үзенә ачуы килде. Күпме тырышса да, авызыннан сыңар сүз дә чыкмады, ул кызулап ишеккә юнәлде.

— Кая барасың?

— Клубка...

— Тукта, башлагач бетерик...

Мизхәт, туктаган килеш әнисенә таба атларга-атламаска белмичә, бер урында таптанып калды. Нуриасма тыштан үз уйларына чумып утырган төсле күренсә дә, малаенның бер генә хәрәкәтен дә күз карашыннан ычкындырмады. Ул бик җитди кыяфәттә акрын гына Мизхәтнең каршына килде.

— Улым, мин сине...— әнисе әллә ничек үзәк өзгеч моңсу итеп елмайды,— мин сине... бик авырлык белән үстердем. Тик син миңа каршы чыгарсың дигән уй беркайчан да күңелемә килмәгән иде...

Нуриасма туктап калды. Иң авырын, үзе кабул иткән карарны ул әле әйтә алмады. Алар икесе дә бер-берсенә рәнҗегәннәр, үпкәләгәннәр, әмма әнисен газаплауда улы үзен, улын газаплауда әнисе үзен гаепле саный һәм икесе дә бу интектергеч халәтнең тизрәк үтүен телиләр иде. Ләкин, үч иткәндәй, киеренкелек үтмәде, сүзсезлектән тилмерү, тынлык аны тагын да көчәйтте, түзеп тора алмаслык итте...

Ниһаять, Нуриасманың бер-берсенә чытырдатып кысылган иреннәре хәрәкәткә килде:

— Без әтиең белән гомер буе саклаган изге әйбергә тап төшердең син! — диде ул.

Мизхәт күзләрен тутырып аңа карады, әнисенең карашы рәхимсез иде. Ул үзенә бернинди кичерү юклыгын аңлады.

— Мин исән чакта безнең өйдә ялган була алмый. Син моны беләсең бит? — Нуриасма малаена сораулы карашын юнәлтте, ләкин Мизхәт башын читкә алды.— Менә шул: йә мин...— әнисенең калтыранган тавышы Мизхәтнең бәгырен кисеп бик нык акрынайды.— Йә... йә син... Ашап-эчәр урын да тапкансың...

Мизхәт, күзенә берни күренмәгән хәлдә, өйдән чыгып йөгерде. Кая бара — ул бу хакта уйлый алмады. Тамак төбен пешереп торучы кайнарлыкны бетерергә теләп йотты да йотты, ә ул бетмәде дә бетмәде. Әнисе аны өйдән куып чыгарды! Бу — башка сыймаслык хәл, бу хурлыкны күтәрергә көч җитәрлек түгел иде...

Мизхәт җил-җил атлап авылны чыкты, Ык яры буйлап әрәмәгә таба борылды. Инде караңгы төшкән икән, йолдызлар да калыккан икән, кызарып ай да күтәрелеп килә икән... Кая бара соң ул?! Әй, кая барса да барыбер түгелмени соң?! Әнисе, бердәнбер әнисе куып чыгаргач, аның кемгә кирәге бар хәзер?! Юк, кечкенәдән үк яратмады аны әнисе. Фәрит, Шәрифҗан абыйлары кайткач, алар белән сөйләшеп утырганда, Мизхәт үзендә көнләшү тойгысы уянуын сизә иде. Аларны әни какмаган да, сукмаган да, каты да бәрелмәгән, кылган шуклыклары, ялгышлары өчен тиргәмәгән дә. Мизхәткә генә әнисе баштан ук каты булды.

Ул әрәмәлеккә килеп җитте. Ыкның биек текә ярына малай чактагы кебек аякларын салындырып утырды. Астан акрын гына күтәрелүче дымлы һава салкынча булып тәнгә кагыла. Көне буе эссе кояш астында

утыз градуслы һаваның кайнарлыгын үзенә комсызланып йоткан елга суы әле җылы булса да, аның өстенә төнге салкынлык җәелә бара иде инде. Яр буендагы елак таллар, өянкеләр, колмак, бөрлегән сабакларына чорналып хәрәкәтсез утыручы шомырт, карлыган, балан, карама куаклары әле сүнеп бетмәгән алсу шәфәкъ яктысында, ай һәм йолдызлар астында сихри һәм серле булып күренәләр... Тегеяк яр буенда шопырдап балык чумды.

Юк, какты гына түгел, аны яратмады әнисе. Башка малайлар рәхәтләнеп велосипед, мопед, мотоцикл белән чапканда, Мизхәткә әнисе берни дә алмады. Акча юк димәде, бәндәгә табигать йөрер өчен ике аяк биргән, шулар белән йөрергә кирәк, диде. Ярый әле, Фәрит абыйсы кием-салымнан өзмәде, юкса кеше арасына чыгарлык өс-башка да тиенмәс иде. Колхозда алдынгы шофер булып эшләп, ничә ел чират көтеп, ул быелтыр көчкә «Урал» мотоциклы алу бәхетенә иреште. Ә аның яшьтәшләренең күбесе инде җиңел машинада элдерә.

Бәләкәйдән үк Мизхәтнең башы нужадан чыкмады. Әнисе фермадан кайтып кермәгәнлектән, барлык малайлар эшли торган эшләр өстенә ул идәнен дә юды, бәрәңгесен дә әрчеде, ашын да пешерде... Шуңа күрә ни кышын, ни җәен уенга аның вакыты калмады, ихатада эшләп йөргәндә ул кәшәкә сугучы, су коенып кайтучы, чаңгы-чана шуучы яшьтәшләренә кызыгып карап кала иде. Шулар өстенә әнисе аны үзе белән фермага йөртте, бергәләп бозауларга сөт эчерделәр, печән салдылар, асларын чистартып түктеләр. Бишенче класста укыганда ук әнисе Мизхәткә кечкенә чалгы саплап бирде, үзе белән бергә борчак, печән чабарга өйрәтте. Шуннан бирле аның кулыннан чалгы төшкәне юк. Үзе кебек малайшалай арасында башлап ат җигәргә өйрәнүче дә Мизхәт булды...

Авылның берсе артыннан икенчесе өстәлеп торган мәшәкатьләре вакыты белән кешене аңгырайтып, тупасландырып бетерәләр. Мизхәт моны үз җилкәсендә татыды. Сиңа туктап тын алырга вакыт юк, берсен эшләп, икенчесен куеп торышлы түгел: яз җиттеме — каз-үрдәгеңне бәпкә чыгарырга утырт, түбәләрендәге, баз өсләрендәге карны көрә, базыңа кар сал, ихатаңны чистарт, төяп түк, бакчаңны сөр, казы, тырмала, бәрәңгеңне, яшелчәңне утырт; көн саен бәпкә сакла, сарыкларыңның йоннарын ал кыркып; җәй житсә — бәрәңгеңне ута, китмәнлә, төбенә өй; утын хәстәрлә; печән чап, яңгырдан саклый-саклый киптер, машина йә трактор табып алып кайт, өеп куй; басуда үзеңә бүлеп бирелгән чөгендерне сирәклә, өч мәртәбә эшкәрт, чүпләп өй, балчыгыннан аралап кис, төяп җибәр; бәрәңгеңне казы, чүплә, ташы, чүпләп базыңа салып куй; шушылар өстенә ел саен йә койма, йә капка, йә түбә, яисә башкасын төргезергә кирәк — авыл Советы, райплан, лесник бусагасын тапта, язуын бирсәләр, клеймо суктыр, кис, алып кайт, пилорамага илтеп такта ит, койма кой; коймадан соң тишек өй түбәсе алыштырганны көтеп чиратта тора, аны рәтләүгә бәрәңге сала торган тыш базы ишелә — аңа имән тап, ишелгән балчыкны өскә чыгар, имәннәрне ярып тез, баз авызы яса, күм; инде чиратта өч ел буе кирпеч таба алмаганлыктан чыгарылмыйча ятучы өй миче, баганасы черегән урам капкасы, кызылга буясы өй түбәсе, матчасы сыгылган мал өе, күчәре сынган бәләкәй арба һәм башкалар, һәм башкалар. Шушылар өстенә көн саен иртәнге дүрттә торып сыер сау, сөтеңнең артканын дәүләткә тапшыр, сыер-сарыкларыңны капкалатып көтүгә ку, кош-кортларыңны ашат, куардаен йә тау битенә, йә елга буена ку, абзарда акырып яткан бозавыңа каян да булса үлән юллап алып кайтып сал, колхоз эшенә бар, кич кайткач, тагын мал-туар кара, кышын кар көрә, җәен көн саен яшелчәләргә, агачларга су сип, өй эчендәге тавык та чүпләп бетерә алмаслык эшләрне эшлә...

Шулар өстенә аның әнисе тагын әллә никадәр, аларның икесеннән башка беркем дә алынмый торган эшләр уйлап таба. Бер язны ике көн буе Ык яры буена тал утырттылар. Таллар үсеп киткәч, авыл Советы рәисе аларны район газетасына мактап язды. Тау битләрен басып китүче

шайтан таягын да әнисе белән Мизхәт чапты. Егет кешегә мондый эшләр белән йөрү бик кыен иде. Ул, әнисенә кычкырып әйтмәсә дә, эчтән моны бик авыр кичерде, гарьләнде. Кемнәрдер мактаса, кызлар, егетләр арасында аны үртәүчеләр, исәр дип көлүчеләр дә булды. Чөнки бу эшләр тормышның бүгенге колачы белән чагыштырганда бик вак, әһәмиятсез иде. Әмма әнисе шул вак әйберләрдән тәм тапты. Авылда берәрсе бәбиләсә, ул бәби ашы илтмичә калмады, язгыз карчык-корчыкларга сөт-катык кертте, кием-салым өләште. Мизхәтне бәләкәйдән үк карчык-корчыкларга утын ярырга, бәрәңге алырга, кар көрәргә, су ташырга йөртте. Болар барысы да читтән караганда изге әйберләр булып күренәләр, алар турында газеталарда да язып буладыр. Ләкин болар — тормышның өстендә ятучы кабыгы, тышчасы гына, ә Мизхәт зур нәрсәләр турында хыялланды.

Аның авыл хуҗалыгы институтына укырга керәсе, студент буласы килә иде. Ләкин шушы кадәр мәшәкатьләр уртасында әнисене ничек япа-ялгыз калдырмак кирәк? Читтән торып укырга да була лабаса. Ләкин тормыш аның фикерләренә әкренләп төзәтмәләр кертә башлады.

Иң элек шул билгеле булды: гел эш белән әвәрә килү аны иптәшләреннән аерган булып чыкты. Мәктәп стеналары эчендә юньләп сизелмәгән бу нәрсә колхозда эшли башлагач Мизхәтне хәйран калдырды. Аның иш егетләренең әллә нинди ул белмәгән уртак сүзләре, уртак мавыгулары, күрше авылларда йөри торган кызлары бар икән, ул кызлар турында беркем белми торган, үзаралай чышын-пышын килеп сөйләшә торган сүзләре бар икән...

Вакытлар үткән саен бетмәс-төкәнмәс мәшәкатьләрдән, әнисе уйлап чыгара торган эшләрдән тәмам арыды. Бер эшне тырыша-тырмаша эшләп бетереп, инде котылдым, инде бер генә көн булса да ял итәм, күңел ачам, китап укыйм дип өметләнеп торганда, икенчесе килеп чыга, анысы элеккесеннән дә ашыгычрак була, бусына тотынуга өченчесе, дүртенчесе сиздермичә чиратка баса. Кулдан балта-пычкы, кадак-чүкеч, чалгы-тырма, көрәк-сәнәк гомергә төшәсе, уч төбендәге сөялләрнең мәңге бетәсе юк. Моның очы да, кырые да булыр кебек түгел, авылда яшәгәндә булмаячак та иде. Чын, зур, мәдәниятле тормыш шәһәрдә иде. Урта мәктәпне бетереп, өч-дүрт ел колхозда эшләүгә Мизхәт ныклап торып әнә шушы фикергә килде. Институтка керү хыялы да тормышка аша алмады. Бер елны, Донецкига Фәрит абыйларына кунакка баргач, ул хәйран калды. Абыйлары әйтерсең оҗмахның түрендә яшиләр иде. Сигез сәгать эшлиләр дә ике көн рәхәтләнеп ял итәләр. Буш вакытында җаның теләсә кино кара, җаның теләсә танцыга, театрга, циркка бар. Фәрит абыйсы эшкә урнаштырырга да, фатир алырга да ярдәм итәм, тик әнине генә ризалат, диде. Әнисен авылдагы авыр тормыштан, мәшәкатьләрдән коткару өчен яхшы әмәл иде бу. Алар бергәләп авылга кайттылар. Шунда әниләренә үз планнарын әйттеләр. Ләкин ул тыңларга да теләмәде. «Шәһәрне макта, авылда тор, дигән сүзне белмисезме әллә? — диде.— Мин анда ярты елда аяк сузам, шушында тудым, шушында үләм, аяк-кулым йөрмәс, күзем күрмәс булып ятсам да, өемнән мәңге чыгасым юк»,— диде. Шулай итеп, китә алмады Мизхәт.

Инде болай булгач, өй салырга, нигезне яңартырга, ныгытырга карар кылдылар. Фәрит биш мең сум акча бирде, идән-түшәме, түбәлеге, бөтен нәрсәсе җитү бура сатып алдылар. Әмма өй салуны соңартырга туры килде.

Әгәр әнисе шул чакта Донецкига китәргә ризалашкан булса, Мизхәт әллә кайчан өйләнер, балалар үстерер, яшьтәшләреннән аерылып йөрмәс иде. Ә ул үзенең пары белән бәхетле булыр идеме соң? Ул бит Зөбәрҗәтне очратмаган булыр иде. Зөбәрҗәтне очрату, югалту, аерылу, янадан табу — бу кичерешләр бәхет идеме, әллә бәхетсезлекме, Мизхәт анысын әйтә алмый. Ләкин аларның шулай өйләнешмәс борын аеры-чөере килүен язмышка гына сылтап булмавын Мизхәт тә, әнисе дә, Зөбәрҗәт тә

яхшы аңлыйлар ич! Әле алда ни булыр — бусын беркем дә әйтә алмый, чөнки аларның язмыш йомгагы сүтелеп ташланган, әмма кабат яртылаш кына чорналган, очы очка ялганмаган килеш чәчелеп ята иде...

Аһ, ул Зөбәрҗәтнең авылга килеп төшкән көннәре! Яңа укытучы килгән дигән хәбәр яшен тизлеге белән таралды. Алабуга шәһәреннән, диделәр, чибәр икән, диделәр, акыллы икән, диделәр, бик әйбәт укыта икән, диделәр. Ә яшьләр, егете бармы икән, бик эре түгелме икән, ничә яшьтә икән, дип баш ваттылар. Бу сорауларга өч-дүрт көн беркем дә җавап бирә алмады, чөнки кыз фатирыннан беркая да чыкмады, беркем белән аралашмады. Кыз турында хәбәр чыганагы булырга тиешле фатир хуҗасы Миңлекамал карчык саңгырау иде. Мизхәт Зөбәрҗәт белән кибет ишегендә йөзгә-йөз очрашты. Кыз әйберләр алып чыга, Мизхәт кереп килә иде. Ул аңа:

— Исәнмесез,— диде һәм артка чигенеп юл бирде.

Кыз сизелер-сизелмәс кенә елмайды һәм туп-туры карап:

— Рәхмәт,— диде һәм биек үкчәле туфлиләре белән керт-керт китеп барды.

Сентябрь аеның кояшлы беренче якшәмбесе иде бу. Мизхәт өнсез булып катты да калды, аңа әллә ни булды, кызның ап-ак озын муены күз алдыннан китмәде. Ул аны бик якыннан, бер адым арадан күрде. Иңбашларына төшеп торучы күперенке кап-кара чәчләре уртасында ай сыман йөз, зәңгәр күлмәгенең кечкенә декольтесыннан күтәрелүче мәрмәрдәй ак һәм шома муен. Кызның күзләре казах кызларыныкы төсле кыйгач иде. Мизхәт аларның ни төсле икәнлеген дә хәтерли алмады, чөнки елмайганда алар бөтенләй диярлек кысылып беттеләр. Кап-кара каш-керфекләр, тулы иреннәр, почык борын... Бер карасаң, әллә нние дә юк кебек. Әмма кызның муены гына түгел, бөтен йөзенең балавыздай шома булуы аңа ниндидер серлелек өсти, ерак заманнардагы илаһи хатын-кыз затларын хәтерләтә иде. Мизхәт көне буе шушы тойгыдан арына алмады, машинада барганда әлеге кыз күз алдыннан китмәде. Шул көнне Зөбәрҗәт беренче мәртәбә культура йортына чыкты. Аңа барлык егет диярлек өмет баглады, чөнки авылда кызлар бармак белән генә санарлык иде. Һәр авылның үз дәртле хәтирәләре, Дон Жуаннары була. Иң элек алар чышын-пышын килделәр, күмәк һәм аерым-аерым кызны кармакка каптыру планнарын эшләделәр. Мизхәт андыйлар рәтенә керми иде, ул Зөбәрҗәткә сокланып карап торудан узмады, озатып куярга да батырчылык итмәде. Ул үз гомерендә ничә мәртәбә генә кызлар озаткандыр, тогәл әйтә алмый, ләкин алар барысы да диярлек уңышсыз тәгәлләнде. Кызлар янына килүгә әлеге Дон Жуаннарның теле телгә йокмыйча сайрый башласа, Мизхәт, киресенчә, теле аңкавына ябышкандай, юньләп сөйләшә алмас була, башы берни эшләми башлый, кызның һәр сүзе саен өстенә салкын су сипкәндәй бөкшәя иде.

Беренче көнне Зөбәрҗәтне озатырга озын Рафаэль китте. Ләкин икенче көнне көтү куганда аны Зөбәрҗәтнең өч сүз белән борып җибәрүе, Рафаэльнең үзләре очына сүгенә-сүгенә кайтуы бөтен авылга билгеле иде инде. Шул рәвешле аккош муенлы кыз көн саен бер егетне, башын кылыч белән чабып өзгәндәй, борып кайтара торган булды.

Ә Мизхәтне Зөбәрҗәт үзе озата кайтты. Әйе-әйе, үзе! Клубтан чыккач аның белән сөйләшә-сөйләшә атлады да китте.

— Хәзер мине егетләр озатып туйдылар, инде үзем егетләрне озата башлыйм,— диде ул көлеп.

Мизхәт аңа ияреп көлде. Алар таң атканчы «озатышып» йөрделәр. Башта ул Мизхәтне капка төпләренә кадәр, аннары Мизхәт аны озатты. Шулай йөри торгач, таң атты. Башка кызлар янына барса, теле көрмәлә торган Мизхәтне гомер буе Зөбәрҗәт белән бергә тәгәрәп үскән диярсең: рәхәтләнеп сөйләште, үзендә бернинди кыенсыну-тартыну сизмәде. Озатышып йөрүләр соңыннан яратышуга әйләнеп китте, алар бер-берсен күрми тора алмас булдылар. Әйтүенә караганда, Зөбәрҗәт егерме яшен-

дә бер егеткә тормышка чыккан булган икән. Ярты ел яшәгәч, ире хыянәт иткән, Зөбәрҗәт аның белән араны кырт кискән, ире акланырга, аңлашырга теләп күпме генә артыннан йөрсә дә, сынар сүз дә дәшмәгән, гафу итмәгән.

Танышуларына бер ел дигәндә эш инде бергә булу мәсьәләләренә барып терәлде. Төп фикерләре аларның туры килә иде: шәһәргә күчәргә. Зөбәрҗәт үзенең туган шәһәренә — Алабуга ягына тартты. Нәкъ шул көзне Мизхәт Донецкига барды, абыйсы белән кайтты, әнисе белән әлеге сөйләшү булды һәм ул Зөбәрҗәт файдасына хәл ителмәде. Мизхәт кистереп кенә бер карар кабул итә алмады. Өйне дә салырга насыйп булмады. Көз көне Мизхәтне армиягә алып җибәрделәр. Солдатка китү аның өчен бер яклап шатлык иде. Чөнки ул йөрәге авырту аркасында үзенең яшьтәшләреннән калды. Ныклап спорт белән шөгыльләнергә кереште, йөгерде, чаңгыда йөрде, бәкедә су керде. Икенче елны комиссия егетне сау-сәламәт дип тапты. Бу сөенечле хәл иде. Әмма ләкин саласы өйнең дә, Зөбәрҗәт белән булган мөнәсәбәтләрнең дә ярты юлда калуы аны бик нык борчыды. «Мин сине көтәрмен»,— диде Зөбәрҗәт аны озатканда.

Ике ел хәрби хезмәт әлеге борчуларны күңелдән чыгарып ук ташламаса да, күпмедер барыбер онытырды. Ике ел буе алар Зөбәрҗәт белән җылы мәхәббәт хатлары алыштылар. Ул хатларны бөтенесен бергә тезеп салсаң, кайнар мәхәббәт эчендә бәргәләнүче ачу-үпкәләр дә, шатлык-кайгылар да, киләчәккә корган планнар да ачык күренер иде. Ә шулай да бер житди үзгәреш булды Мизхәттә. Армиягә баруга ук ул өзелеп-өзелеп авылны сагына башлады. Һәр урамын, һәр тыкрыгын, һәр сукмагын, агачын, һәр өен, кешеләрен өзелеп-өзелеп сагынды, һәм нинди дер әйтеп бирә алмаслык бер кайнар, сагышлы моң белән әнисен кызганды, аның япа-ялгыз яшәвен күз алдына китереп, йөрәк өзелде. Баштагы мәлне сагындырадыр инде ул, дип Мизхәт үзен тынычландырырга тырышты, күзгә күренеп ябыкты, көйде. Ләкин сагыну бетмәде, киресенчә, көчәйгәннән-көчәя генә барды. Сагыну сахрасында ялгызы хәлсезләнеп яткан Мизхәтне авылдан килгән хатлар бер йотым салкын су кебек хәл кертеп җибәрәләр иде. Ниһаять, кайтыр көннәрне зарыгып көтәр чаклар житте. Хезмәте бетәргә өч ай калды дигәндә, Зөбәрҗәттән йөрәк ярырлык хат килеп төште. Хатта дүрт җөмлә иде: «Мин авылдан китәм. Безгә бергә кушылу мөмкин түгел. Берни дә аңлата алмыйм. Кичерә алсаң, кичер. Зөбәрҗәтең». Бу башка сыя торган нәрсә түгел иде. Мизхәт әлеге юләр җөмләләрне мең кат укыды, алар һәр хәрефенең бормасы, куелышы белән аның хәтеренә сеңделәр. Мондый хәл киноларда, китапларда гына була, дип уйлый иде Мизхәт. Ник ичмасам сәбәбен әйтмәгән?! Моны хат язышучы яшьтәшләре дә белмиләр иде. Әниләре янына Алабугага киткән, дип яздылар. Башыңны ташка орсаң да, берни аңлашылмый. Әле кайтырга өч ай вакыт бар, гел бер сорауга ялгызы җавап эзләнүче кеше өчен бу өч ай еллар кебек озак, бертөрле һәм мәңге бетмәс кебек иде...

Мизхәт су өстенә карап уйланды да уйланды. Уйлар әле үткәнгә, әле бүгенгегә йөгерде, хәзер аларны берничек тә туктату мөмкин түгел иде. Ә Ык тын иде, аның ярга ышкылганы да сизелми, күктәге йолдызлар да, ай да елгага кереп тулганнар, алар беркая да акмый, ә менә бу кызыл яр авыл белән бергә акрын гына шуыша кебек иде. Мизхәт башын тезләренә салды да берничә генә минутка күзләрен йомды. Әле уйлыйсы уйларның очы-кырые юк иде... Тикшерә, бизмәнгә сала башласаң, кемнең гаепле, кемнең гаепсез икәнлегенең очына чыкмалы түгел. Гарифҗан Рәмзинең һәм үзенең әти-әнисе, хатыны, балалары каршында гаепле. Хәснуллин белән Бәрия дә шулай. Әнисе Хәдичә апа, Гарифҗан, аның хатыны һәм балалары каршында гаепле кебек. Мизхәт гаиләнең иң изге нәрсәсен бозган өчен әнисе һәм мәрхүм әтисе каршында гаепле. Ныклабрак уйлый башласаң, бөтенесе алдында аерым-аерым да, бергә дә гаепле. Кем генә гаепсез соң? Кайда иң гадел хөкемчең? Әйе, әйе, әнисе хаклы! Хөкемче бер генә: Дөреслек!

* * *

Таң атканда Мизхәт Хөснуллиннарның капка төбенә килде. Капканы этеп-этеп карады, ул бикле иде. Бозау кадәр бурзай һау-һаулап өрергә керешге, чылбырын шалтырата-шалтырата ишек алдына аркылы сузылган чыбыкның әле бер, әле икенче башына ыргылды. Менә верандада, аннары болдырда һәм ишек алдында гөлт итеп утлар кабынды. Шуның артыннан ук болдырда пижамадан гына килеш Хөснуллин үзе күренде.

— Кем бар анда? — диде ул карлыккан тавыш белән.

— Мин әле бу, Мизхәт... дип җавап бирде егет капка өстеннән үрелеп.

— Афзалов?! Син нәрсә таң тишегеннән? Бер-бер хәл булдымы әллә?

Хөснуллин сөйләнә-сөйләнә капканы ачты, кул биреп күреште, Мизхәтнең борынына аракы, суган катыш әллә нинди авыр ис килеп бәрелде. Ул чак укшып җибәрмәде һәм үзе дә сизмәстән бер адым артка чигенде.

— Ни булды? — диде Хөснуллин, аны лычкылдык күзләре белән бораулап.

— Мин шуны белмәкче идем: кичә сез миңа ни өчен «үзегезгә аяк чалмасагыз, яхшы булыр иде» дидегез?

Хөснуллинның чырае үтүк бастырган кебек булды.

— Слушай, Афзалов! Эчкән булсаң, син буеңа сеңдер әле!

Ул салмак кына борылып кереп китмәкче булды, тик Мизхәт аның каршына басты. Рәис аңа астан өскә таба ачу белән карады.

— Син минем тәртәнең кыска икәнен беләсең. Яхшы чакта ычкын!

Ләкин Мизхәт кымшанып та карамады.

— Мин исерек тә түгел, сезгә бәйләнергә дә килмәдем. Минем бер генә нәрсәне беләсем килә: сез ни әйтергә теләдегез?

— Әгәр исерек тә түгел икәнсең, бәйләнергә дә килмәгәнсең икән, мондый сөйләшү өчен колхоз идарәсе дигән җир барын син белмисеңмени?

Мизхәт күз карашын түбән төшерде.

— Әйе, таң белән өегезгә килүем өчен гафу итегез, мин гаепле,— диде ул нindидер тонык тавыш белән.— Тик миңа хәзер үк белергә кирәк...

Хөснуллин аңа шактый вакыт сынап карап торды. Юк, исерек түгел иде Мизхәт. Ә күзләре бик сәер елтырый. Ни булган, нишләп бу вакыттан аяк өстендә ул? Йокы да туймаган, баш та авырткан килеш бу хакта уйлыйсы килми иде.

— Идарәгә килерсең...

— Юк, миңа хәзер кирәк. Яңадан бөтенләй кирәкмәячәк.

Ачуын басарга башка юл юк иде, Хөснуллин әйтте дә салды.

— Яңа машинаны сиңа бирергә мораль хакым юк минем. Вөҗданым кушмый. Ни әйтергә теләгәнемне аңладыңмы?

— Ни өчен хакыгыз юк?

— Беренчедән, мин үземне тыңлауларына күнеккән. Икенчедән, дустыңны пычратмау өчен әниең белән сөйләшергә теләмәгәч, минем сиңа моңа кадәр булган карашларым үзгәрде.

— Рәхмәт, аңладым,— диде Мизхәт бер якка чигенеп.— Фикерләрегез бик тиз үзгәргән икән...

Капканы эчке яктан ябып маташучы Хөснуллин аңа ялт итеп карады да:

— Әйе, тиз! — диде.— Ул бүген үк баштагысына да үзгәрә ала. Анысы синнән тора.

Болай ук туры әйтмәскә кирәк иде дә. Хөснуллин, нишләптер, тыелып кала алмады.

Мизхәт гаражга юнәлде...

Ул төнне Нуриасма да йокламады.

Мизхәт Ык буенда күзәткән йолдызларны, айны ул тәрәзә аша карап ятты. Улының тәүбә итүен, әни, мин ялгышканмын, диюен көткәндә, аның чыгып йөгерүе һәм кунарга да кайтмавы коточкыч хәл иде. Ярый ла, салган баштан әллә нәрсә эшләп ташламаса. Әгәр, чыннан да, шәһәргә китеп барса? Бүген ул сүзләрне Хәдичә юктан гына әйтмәгәндер, нидер ишеткәндер. Катырак кагылды, алай ук кирәк булмагандыр.

Мизхәт чыгып киткәч, ике мәртәбә автомеханик керде, ындыр табагыннан икмәк төшерергә кеше юк, тыңламас иде микән, диде. Нуриасма ни дип әйтергә дә белмәде, чыгып киткән иде, кайтса, әйтермен, диде. Ләкин ул кайтмады. Ана кеше уйларын ашыкмыйча-кабаланмыйча барларга, тәртипкә салырга теләде, әмма булдыра алмады. Уе кая гына йөгерә башласа да, йөрәк «син гаепле» дип аваз бирде. Әйе, улы алдында аның берничек тә җуеп бетерә алмаслык олы хатасы, гаебе бар һәм ул Зөбәрҗәт белән бәйле иде. Нуриасма үзенең бу гаебе турындагы уйларын еракkарак куарга тырышты. Ә аңа кадәр һәммәсе дә туры сукмактан бардымы икән? Әллә аңа кадәр дә абынулар булдымы?

... Сәгыйдулла үзенең инде аякка баса алмасын төшенгәч, Нуриасмага:

— Сиңа, карчыккаем, балаларга ана да, ата да булып калырга туры киләчәк,— диде.— Күңелең йомшак булса да, кулың каты булсын...

Нуриасма иренең васыятен тотарга тырышты. Акны — ак, караны кара дип әйтү — гаиләдә Сәгыйдулла исән чакта ук урнаштырылган изге нәрсә иде. Аны бозу иң зур гөнаһ саналды. Башкасы гафу ителергә дә мөмкин, әмма аны бозучыга иң каты җәза бирелде. Тик күп нәрсәдә чигенүчән, йомшак күңелле Нуриасма әлеге изге канунны үтәүдә ире үлгәч бигрәк тә катыланып китте, балаларының баш очында кылыч кебек янап торды. Ниндидер вак-төякләр булгандыр, әмма аның Фәрит белән Шәрифҗан тарафыннан бозылуын Нуриасма хәтерләми. Ә менә кече малае Мизхәт аны сискәндереп, куркытып куйгалады. Алтынчы класста укыганда ул бик төшенке күңел белән, кәефсез йөри башлады. Дәресләрен дә элекке кебек озаклап әзерләми, йорт эшләрен дә теләр-теләмәс кенә башкара. Әмма иң сәере шунда, Мизхәт уйнарга чыгудан бөтенләй туктады, иптәш малайлары да керми башладылар. Бер көнне Нуриасма аңардан:

— Әллә бер-бер хәл булдымы, улым? — дип сорады.

— Юк,— диде Мизхәт, укый торган китабыннан аерылып та тормастан.

Икенче көнне дә, өченче көнне дә сорап карады Нуриасма. Җавап шул ук булды. Нидер бар, тик малае аны яшерә. Бу әлеге канунны атлап чыгу иде.

— Улым, дөресен әйт: нидер бар бит?

— Юк...

Нуриасма аны диванга алып килеп утыртты.

— Әйт, нәрсә бар?

Мизхәт башын түбән игән хәлдә борынын тартып торды, бер сүз дә дәшмәде. Күзләренә туры карамакчы булып, Нуриасма аның башын күтәрде. Шунда Мизхәт түзә алмады, кычкырып елап җибәрде.

— Малайлар мине алдар таз дип үртиләр!..

— Синең алдашканың бармыни?

Сораштыра торгач, шул билгеле булды: Мизхәт район пионерлар слетында катнашкан һәм чыгыш ясаган иде. Бүтән чыгышлар белән аныкы да район газетасында басылды. Малайлар шуның өчен бәйләнәләр икән.

— Ә нәрсәсе дөрес түгел соң ул чыгышыңның?

— «Без шахмат түгәрәгенә дә теләп йөрибез» дигәне...

— Ник алай диден соң, улым?
— Райкомда эшләүче бер апа шулай дип өстәтте. Ә бездә шахмат түгәрәге бөтенләй эшләми.
— Эшләми дип әйттеңме соң?
— Әйттем дә. «Ул башкаларны ияртү өчен шулай кирәк, иртәгедән эшли башлар»,— диде.
— Сина чыгыштан баш тартасың калган, һич югы ул ялганнарны әйтмәскә идең.
Мизхәт яшьле күзләре белән аңа аптырап карап торды. Нуриасма аны кочаклап аркасыннан сөйде, чәчләреннән сыйпады.
— Улым, син инде хәзер зур үстең,— диде Нуриасма аның күз яшьләрен алъяпкыч итәге белән сөртеп.— Без синең белән болай килешик: мин дә, син дә, беркайчан да, беркайда да, беркемгә дә алдамаска. Ант иттекме?
— Ярар, әни,— диде Мизхәт.
— Белеп тор: әгәр шушы антны бозсаң, мин сиңа «улым» димәячәкмен. Мин бозсам, син «әни» димәссең. Гомер буе, мәңгегә шулай. Килештекме?
— Килештек.
Моның никадәр зур нәрсә икәнен ул чакта Мизхәт аңлап бетерә алдымы икән? Ничек кенә булмасын, мәктәп елларында аның әлеге килешүне бозуын хәтерләми Нуриасма. Ә менә армиягә киткәнче бер булды. Унынчыны бетереп, аның төзү бригадасында йөргән чагы. Бөтен халык кырылып бәрәңге ала. Бер көнне эштән кайткач, Мизхәт:
— Әнкәй, көннәр әйбәт торганда бәрәңгене алып бетерсәк, яхшы булыр иде,— диде.— Шушы арада безне Красный Бор ягына колхозга урман кисәргә җибәрәчәкләр.
— Эшегез беттемени? — диде Нуриасма.— Бозаулар торагын ремонтлыйбыз, дигән идең.
Мизхәт бераз сүзсез торды. Аннары:
— Урман кисәргә китүчеләргә Җәүдәт абый ял бирде,— диде.
Икенче көнне өйләгә кадәр бик күп бәрәңге алдылар. Төшке аштан соң Мизхәт тагын бакчага чыкты, ә Нуриасма ак балчыкка кушарга ат тизәгенә китте. Ике чиләген дә тутырып конюшнядан чыгып килгәндә, аңа төзү бригадиры Җәүдәт очрады.
— И Нуриасматти, терелдеңдәмени? — диде ул, исәнлек-саулык сорашкач.
Нуриасма аптырап, көянтә-чиләкләрен җиргә куйды.
— Ни сөйлисең, Җәүдәт энем, авырырга вакыт юк әле, бәрәңге алабыз.
Аның бу сүзләрен ишеткәч, Җәүдәтнең чыраен болыт каплагандай булды.
— Түшәк өстендә ята, диде бит Мизхәтең...— Җәүдәт кузгалып китте дә туктап артына борылды.— Мин каян кеше табарга белмим... Ике көнгә түзгән булсагыз да, бәрәңгегез җирдә калмас иде әле...
Аның рәнҗеп әйткән бу сүзләре өенә кайтып җиткәнче Нуриасманың колак төбендә янгырап тордылар. Ул чиләкләрен шарт итеп сарай алдына куйды, берсе авып китте — аңа да игътибар итмәде, ашыгып бакчага юнәлде. «Кара син аны астыртынны! Күрсәтим әле мин сиңа!» — диде ул эченнән кайнап. Мизхәт тирләп-пешеп бәрәңге казып ята иде. Нуриасма аның янына җил-җил килде дә көрәген кулыннан тартып алып, читкә ыргытты.
— Хәзер үк эшеңә бар! — диде ул ачуына буылып.
— Ни булды, әнкәй?!
— «Әнкәй» димә миңа! — Нуриасма елап та җибәрде.— Адәм хурлыгы! Ничек телең барды мине чирли дияргә?!
Мизхәт барысын да аңлап алды.
— Егерме сутый бәрәңгене ничек берүзеңә калдырыйм соң?!

Нуриасма калтыранган кулларын селти-селти аның каршына килде.

— Сиңа нәрсә өстенрәк?! — диде ул кулларын йодрыклап.— Бәрәңгеме?! Әйт, бәрәңгеме?! Иң изге нәрсәләрне менә бу балчыкка салып таптагач, ник кирәк ул бәрәңге?!

Нуриасма җирдә тәгәрәп яткан бәрәңгеләрне Мизхәткә таба тибептибеп җибәрде. Аннары өйгә кереп китте. Йөрәгенең ярсуын басар өчен салкын су белән дару эчте. Бераз тынычланганнан соң, бакчага чыкты. Мизхәт чиләккә бәрәңге чүпләп йөри иде.

— Мин нәрсә әйттем? — диде Нуриасма килеп житү белән.

Мизхәт әнисенең гадәтен белгәнгә күрә авыр сулап гәүдәсен турайтты һәм ялварып аңа карады.

— Әнкәй...

— Хәзер үк эшеңә кит! — диде Нуриасма һәр сүзен теш арасыннан сыгып чыгарып.

Мизхәт тагын бер мәртәбә авыр сулады да башын игән хәлдә ихатага таба атлады. Нуриасма бәрәңге чүпләргә кереште, үзе астан күз кырые белән генә Мизхәтне күзәтте. Малаеның салынган иңбашларын, иелгән гәүдәсен күрү аңа тагын котелмәгән тәэсир ясады, ул үзенә шул кадәр әшәке, каты бәгырьле булып тоелды. Ләкин нишләргә иде соң? Ипи валчыгын таптарга җөрьәт иткән кеше бөтен басуы белән игенне дә таптый; энә урлаган кеше дөя дә урлый; алдау юлына бер адым атлаган кеше икенчесен, өченчесен дә атлый. Сүздә торырга кирәк, әмма болай түгел, башкачарак итәсе булгандыр. Тик инде эш узган, дуамал йөрәге ничек кушкан, ул шулай эшләгән иде. Аның ятим, әтисез иканлеген, күңеле китеклеген уйлыйсы булгандыр. Иптәшләре арасында болай да кимсенәдер, ә ул аны әнә ничек рәнҗетте. Менә бит ата юклыгы! Бәлкем әтисе бер мәртәбә сүгенер, яисә яңагына менеп төшәр дә — шуның белән эш тә бетәр иде. Нуриасма алай итә алмый шул! Бәрәңге чүпләүдән туктап, ул инде бакча капкасыннан чыгып баручы Мизхәткә төбәлде. Нуриасма аның артына борылып каравын теләде. Карасын гына, ул аңа «кил» дип кул изиячәк. Тик малае туктамады. «Рәнҗеттең, рәнҗеттең!» — дип типте йөрәге кайнар кукрәгендә. Ул берничә минуттан үзен тирги-тирги бакча түреннән ишек алдына төште. Ничек булса да баласының рәнҗешен киметәсе килде, ничек икәнен үзе дә белмәде. Әгәр: «Бар, казы»,— дисәң? Әллә: «Кайтуыңа ни пешерим?» — дияргәме? Ләкин бу: «Син хаклы, мин кызып киткәнлектән генә шулай кыландым»,— дию гатиң булмасмы? Сарайда Мизхәтнең балтасы юклыгын күргәч, Нуриасма җиңел сулап куйды: эшенә киткән, боларның берсе дә кирәкми иде инде... Бераздан ул үзен-үзе тынычландырды, мәлҗерәп төшсәң, берничә дә ирешең булмый, бер генә мәртәбә чиген, йомшаклык күрсәт, аннары инде артка тәгәрәвеңне көт тә тор, теләгәнә ирешермен димә...

Нуриасма әнә шулай яшәде. Йомшаклык күрсәтсә дә, «мәмкә» дип үзен тиргәде, катырак кыланса да, «таш бәгырь» дип үзен сүкте. Әле моңа кадәр улының тәртипле, вөҗданлы булуына, ул теләгәнчә яшәвенә куанып туймый иде Нуриасма. Дөрес, ул моны Мизхәткә сиздермәскә тырышты, аны беркайчан да мактарга ашыкмады.

Ә менә бүген... Аның тәрбияле улы башкалар кебек ялган күрсәтмә язган. Үз-үзен катылыкта, бәгырьсезлектә гаепләүләре гел юкка булган икән. Киресенчә, катылык җитмәгән! Дилбегәне әзрәк бушат кына — хәзерге яшьләр ни кыланганын онытa. Карале, шәһәрдә нишлиләр! Яшьләрнең өер-өер булып, урам тулып эшсез йөргәне кайчан күренгәне бар?! Әллә аларның да әти-әниләре Нуриасма үзенең улы каршында олы гаеп эшләгән шикелле, нидидер ярамаган нәрсә кылганнармы? Әх, ул гаебен үзе исән чакта йолып бетерә алса иде Нуриасма! Ә бит Зөбәрҗәт авылга килмәсә, бәлкем, болар берсе дә булмас иде. Турысын әйткәндә, Нуриасма кызны үзе дә яратты. Авыл халкы да үз итте аны. Ләкин Мизхәт белән дуслыклары кочәя барган саен Зөбәрҗәт турында гайбәтләр дә ишәя башлады. Иң беренчесе кызның шәһәр баласы булуына.

артык нәзберек-пөхтәлегенә, берүзе бер төсле аерылып торуына бәйле иде. Авыл бу кадәр чисталыкны, бу кадәр пөхтәлекне күтәрә алмый. Аның яңгыры-сазы, бураны-кары, тузан-туфрагы бар. Әгәр син үтә пөхтә йөрергә ниятләсәң, үзеңне караудан бушый алмыйсың, бүтән эшкә вакытың калмый. Нуриасма үзе пөхтәлекне яратты, тик бу йокыны кисү бәрабәренә эшләнде. Хәзерге яшьләр мондый корбанга бара алыр микән? Ай-һай! Шулай итеп, халыкта аның турында үзен генә карый икән, өйдә кыл да кыймылдатмый икән, дигән сүзләр таралды. Авылда тормаячакмын, үзебезнең Алабугага китәм, Мизхәтне дә алып китәм, дигәннәре дә өстәлде. Җитмәсә, ул ирдә булган, аерылып кайткан икән... Нуриасмага ефәк кебек улыңны ир якасы иснәгән хатын-кыз белән йөретмә, аздырып, ияртеп алып чыгып китәр, диючеләр күбәйде. Башта Нуриасма аларга игътибар итмәгән иде, тора-бара бу сүзләр утлы күмер булып йөрәген өттеләр. Чыннан да, улы аның өчен бик кадерле иде шул! Атасыз килеш нинди авырлыклар белән үстер, кеше ит тә, бөтенесе чәлпәрәмә килсен, имеш. Чыннан да, ияртеп алып чыгып китсә? Әллә азмы андый очраклар? Мизхәт бит үзе дә шәһәр ягына карап кына тора. Авыл кешесе шәһәрдә кем инде ул? Мескен чәүкә ул. Шәһәрдә үскән кеше дә авылда шул ук чутта. Ул үз гомерендә бер нәрсәгә жаны-тәне белән инанды: бәндә жирдән аерылса, нәсел агачы корый, кавем-кабилә үлә. Авыл гына һәммәсен саклый, хәтерли. Ә шәһәрнең хәтере юк. Авыл һәр нәселнең жиде бабасына кадәр белә, кайсының кайчан туганын, ничек гомер иткәнен, кемнәргә күпме яхшылык эшләгәнен, кемнәргә күпме яманлык кылганын, гадәт-холкы нинди булганын, нинди чирдән үлгәнен, зиратның кайсы төшенә күмелгәнен хәтерли. Авыл кешесе туганны туган, күршене күрше, олыны олы, кечене кече итә, урамнан үтеп баручыга, танышмы-түгелме, сәлам биреп китә. Авыл бер гаилә, ә гаиләдә кемнең ничек сулыш алуына, нәрсә ашап-эчүенә, ни киенүенә кадәр билгеле. Шәһәрдә боларның берсе дә юк, була да алмый, шәһәр адәм баласының йөрәген дә, хәтерен дә үтерә. Анда кешенең күзе нәрсәгә төшә? Таш йортларга, аның эчендәге лаклы жиһазларга, алтын-көмеш йөгертелгән савыт-сабага, затлы келәмнәргә һәм кием-салымына, машиналарга... Йөрәкнең тамыр очлары — күзләр, колаклар, авыз-борын, аяк-куллар — һәммәсе жайсыз әйберләргә, тәмле ризыкларга барып тоташа. Йөрәк бөтен кайнарлыгын шуларга сарыф итеп, шәһәр кешесе жаныннан мәхрүм кала. Мин жанлы дип уйлый ул. Юк! Һәркем «әйбер, әйбер» дип чаба, кабалана бәндә. Ата-ананың — балага, баланың — ата-анага, ирнең — хатынга, хатынның иргә йөрәк жылысы калмый, туган белән туган, дус белән дус аралашырга вакыт тапмый. Кеше үзенең кавемен, денен, туган телен, жырын-моңын оныта...

Инде авылда яшәп тә, шәһәр жиле кагылган — жирдән кендеге өзелергә торган бәндәләр ишәйгәннән-ишәя. Шәһәр алдаучан. Ул Нуриасманың да өч баласын тартып алды. Сугыш елларында ул үзе ачлыктан-ялангачлыктан качып шәһәргә сыенырга мәжбүр булды, шунда тормышны анларга өйрәнде. Тик кешенең аң-зиһенен арттырса да, шәһәр аның хәтерен жуя, йөрәген үтерә торган булып чыкты шул... Дүрт баласының берсен генә булса да шәһәргә бирмәскә хакы бардыр бит аның?! Зәбәржәт шәһәрне каера икән, китә бирсен, ул шәһәрдә үскән. Бу хакта ул Мизхәт белән дә сүз кузгатып карады.

— Улым, болай гына шаяртасызмы, чынлапмы?

— Чынлап, әни. Ошый ул миңа.

— Авылда бит муеннан сазга батып, көне-төне тартсаң гына тормышны алып барып була.

Бусына Мизхәт дәшмәде.

— Бер дигән кыз кеше дә таба алыр иден.

— Тормышта төрле хәлләр булырга мөмкин бит, әнкәй...

Сөйләшү шуның белән тәмамланды. Кычкырышмадылар, бәрелешмәделәр, әмма Нуриасманың күңеленә олы шом төште. Менә кадәр

авыл кешеләре әйтә килгән, ул юньләп игътибарга алмаган нәрсәләрне беренче мәртәбә бөтен чынлыгы белән тойды Нуриасма. Әлеге шом көнләп-сәгатьләп үсә, канын агулый барды. Инде бүтәннәр эндәшмәсә дә, ул үзе шул хакта башлап авыз ачты, кинәш көтте. Ә киңәш, сүз берләшкәндәй, бер генә төрле булды: малаенны аерып ал, булыр-булмас кеше калдыгы белән гомерен бәйләтмә! Нуриасма аларның арасына тыкшынуның һич тә ярый торган нәрсә түгеллеген бик яхшы белә. Ләкин бит алар бер-берсен бәхетле итә алмаячаклар, чөнки, кайсы гына яктан карасаң да (берсе — шәһәр, икенчесе — авыл, берсе — егет, икенчесе — хатын), бер-берсенә тиң түгел иделәр. Шушыны аларга ничек төшендерергә? Инде Донецкига китү турында сүз беткәч, бура сатып алгач, Нуриасма тынычланган иде. Мизхәт ныклап авылда төпләнергә уйлый, дип куанды ул. Тик бу куаныч та озакка бармады. Беркөн Бәрия кереп, Нуриасмага көтелмәгән яңалык әйтте:

— И җиңгәчәй, сине кызганганга гына кердем, өй салгач, Мизхәт теге нәмәстәкәе белән чыгып китәргә җыена икән ләбаса!

— Кемнән ишеттен? — диде Нуриасма сулышы кабып.

— Укытучылар арасында шундый сүз йөри, мин авылда барыбер яши алмыйм, үзем монда яшәсәм дә, йөрәгем барыбер шәһәрдә, дип әйткән ди.

Шул рәвешле малайны коткару уе үскәннән-үсә барды. Ниһаять, ул Мизхәткә бер көнне болай диде:

— Улым, өй салгач, сине Зөбәрҗәт белән чыгып китәсең икән, диләр.

Мизхәт бераз сүзсез утырды, аннары үтә моңсу итеп әнисенә туп-туры карады да:

— Ышанма, әнкәй, гайбәт ул,— диде.

Ләкин Нуриасманың күңеле барыбер тынычлана алмады. Сорауның иң авыр өлеше һаман да җавапсыз калды.

— Ә Зөбәрҗәт? — диде ул тынычлыкны бозып һәм шым булып, берниндн хәрәкәтсез калып җавап көтте. Хәтта тын алудан да туктады, йөрәге генә күкрәк читлеген җимерердәй булып дөп-дөп типте.

— Зөбәрҗәт нәрсә? — диде Мизхәт.— Ул риза булса, син каршы килмәсәң?..

— Нәрсәгә каршы килмәсәм?

— Бергә булыр идек...

Йә хода! Нуриасма шулкадәр теләмәгән иде бу сүзләрне, шулкадәр курыккан иде нәкъ әнә шул җаваптан! Димәк, Мизхәт инде һич икеләнүсез Зөбәрҗәткә өйләнергә тели. Ни эшләргә соң, нишләр кылырга? Нуриасма әнә шул сорауга җавап таба алмаудан гаҗиз булды. Ичмасам ни Сәгыйдулласы юк, ни Фәрит белән Шәрифҗан читтә. Сеңлесе Кифая кайткач, аның белән дә киңәш-табыш итте итүен. Тик ул да аларны аерырга кирәклектән башка әйбер әйтә алмады. Анысы инде котылгысыз, ничек икәне генә мәгълүм түгел иде.

Башы катып, ни кылырга белми йөргәндә, Мизхәтнең солдатка алынуы Нуриасманы бу уйлардан коткарды. Бер яктан ялгызы калуына борчылса, икенче яктан күпмедер сөенде: ике ел вакыт шактый, шул чорда Зөбәрҗәт йә авылдан китеп барыр, яисә башка ни дә булса килеп чыгар. Ләкин ике елда Зөбәрҗәт беркая да китмәде, бүтән нәрсә дә булмады. Тагын хафага төште Нуриасма. Инде халыкта: Мизхәт армиядән авылга кайтып тормый икән, Зөбәрҗәт белән Алабугага китәләр икән, Мизхәт шунда тозелә торган заводка эшкә керә икән, дигән хәбәрләр йөри башлады.

Ахырда Нуриасма түзмәде, бер көнне Зөбәрҗәтне мәктәптән кайтышлый очратып өенә алып керде. Кыстый-кыстый чәй эчәргә утыртты, алдына кайнар өчпочмак куйды. Зөбәрҗәт оялды, кып-кызыл булды. Аларның очрашканда хәл-әхвәл сорашып үтеп китүләре булса да, егет әнисенең кыстый-кыстый өенә алып керүе бик тә сәер иде.

— Мизхәт ниләр яза соң, кызым? — диде Нуриасма ягымлы гына.

— Солдатның ни булсын инде, Нуриасма апа.— Зөбәрҗәт тагын кып-кызыл булды.— Әйбәт кенә хезмәт итәм, тиздән кайтам. Шул инде...

Нуриасма кызны оялтуына үзе дә кыенсынып куйды. Ләкин план инде күптән әзер, мең кат уйланган, чигенү мөмкин түгел иде.

— Сине Алабугага китәсең дип сөйлиләр...

— Китәм дип... Шәһәр бераз сагындыра инде...

— Ә Мизхәт белән ниятегез ничегрәк соң?

— Белмим инде...— диде Зөбәрҗәт карашын аска төбәп.

Бер тын сүзсез утырдылар. Аннары Нуриасма кызның уң кулын үзенең кытыршы кулларына алды, ялварулы карашын күзләренә төбәп:

— Кызым, зинһар өчен мине ятим итмә син,— диде, үзе туктаусыз аның кулын сыпырды.— Сез икегез ике кеше, сез ике дөнья өчен яратылгансыз. Зинһар алып китмә аны! Калдыра күр... Мин сиңа гомерем буе рәхмәт укырмын...

Зөбәрҗәтнең куллары калтыранып куйды, күзләренә мөлдерәп яшь тулды, иреннәре дерелдәде. Ул акрын гына торды да:

— Нуриасма апа... зинһар борчылмагыз... Хушыгыз! — диде һәм күз яшен көчкә тыеп, чыгып йөгерде.

Шушы сөйләшүдән соң өч-дүрт көн үтүгә, Зөбәрҗәт авылдан киткән, диделәр. Сәбәбен беркем дә белмәде. Нуриасма, теләгенә ирешсә дә (ул моңа Зөбәрҗәткә әйткән сүзләре сәбәпче икәнлегенә шикләнми иде), нишләптер шатлана алмады. Зөбәрҗәтнең яшь белән мөлдерәп тулган күзләре аны кая барса, нишләсә дә, эзәрлекләделәр. Куркып уянулар бетсә дә, йөрәгенә таш булып ниндидер авыр нәрсә утырды... Мизхәтнең авылга кайтасына инде ышаныч артты, әмма, нишләптер, ул шатланакуана алмады, үзен җинаятьче кебек хис итте. Йөрәктәге таш һаман ныграк баса барды, аны әледән-әле борчырга тотынды. Һәм бу юкка гына булып чыкмады.

Мизхәт, армиядән кайткач, колхозда шофер булып эшли башлады, өйне дә кузгаттылар. Мизхәт көнне-төнне онытып чапты, ябыкты, ләкин үз дигәнен итте — өйне бер дигән итеп җиткерде. Барысы да гадәти, әйбәт кебек иде. Әмма Нуриасма Мизхәтнең ничектер боеклыгын, җаны үз урынында түгеллеген тоеп-сизеп йөрде. Аның үҗәтләнеп тырышуы да ачу белән эшләү кебек иде. Күзеннән нур, шатлык качты баланың. Нуриасма моңа Зөбәрҗәт сәбәпче икәнне сизенә иде. Эченнән ютты, үтәр, диде, вакыт барысын да төзәтә, диде. Ул арада Мизхәт янында китапханәче Әминә бөтерелә башлады. Әминә яхшы кыз иде, авылныкы, ышанычлы, төпле нәселдән иде. Шуңа күрә моңа Нуриасма куанып туймады. Ул китаплар алып аларга килеп утыргалады, алар Нуриасма белән бик тиз уртак тел таптылар. Әминә килсә, Мизхәт үзе дә яктырып китә, алар шаяртышып, төртмә сүз сөйләшеп утыралар. Ул Әминәне клубтан да озатып куйгалый башлады. Моны бик тиз ишеттерделәр.

Октябрь айларында Нуриасма өйләнү турында җайлап кына сүз кузгатты.

— Кемгә? — диде Мизхәт аптырап.

— Соң... Әминә белән бик пар килгәнсез бит инде, улым,— диде Нуриасма елмаеп.

Мизхәт авыр сулады, кашлары җыерылды, йөзе кап-кара булды.

— Өйләнер идем мин... Әминә бик яхшы кыз...— диде һәм туктап калды.

— Соң?

Мизхәт тагын бик озак дәшми торды. Ул җавап бирмәсә дә, Нуриасма инде сизенгән иде.

— Зөбәрҗәтмени?

— Оныта алмыйм мин аны, әнкәй! — өзгәләнеп шулай диде Мизхәт.— Үтерсәң дә, оныта алмыйм... Күз алдымнан гел китми... Көчәя генә...

Мизхәт ишеген дә япмыйча чыгып китте. Нуриасманың йөрәге өзелеп төшкәндәй булды. «Йә аллам, мин бит бала гомеренә кергәнмен!» дигән хәтәр уй аның йөрәген өттереп, куырып алды. Ник кирәк булган миңа алар арасына тыкшыну?! Йөрәге баштук каршы иде, ләбаса! Ә ул, кеше коткысына бирелеп, Зөбәрҗәтне ничек тә булса Мизхәттән кисеп ташларга теләде. Үз баланны үзең бәхетсез итү шушы буладыр инде. Нуриасма ашаудан, йокыдан калды, ни уйларга да белмәде. Ул хәзер теләсә нинди шартка — аларның шәһәргә чыгып китүенә, үзенең ялгыз калуына да риза, тик балакае гына бәхетле булсын иде. Кеше гомерен кеше яшәми, бала гомерен ана яшәми, шулай булгач, кем үз ихтыярын башкага көчләп тага — аңардан да әшәкерәк җинаятьченең булуы мөмкинме?! Нуриасма гомере буе шушы әшәкелекне эшләмәсәм иде, дип яшәде, әмма, үч иткәндәй, гел шуңа барып абынды. Кайсы төштә дилбегәне бушатырга, ә кайда үзең теләгән якка борырга? Нуриасма өчен күпме яшәп шуны сиземләүдән дә катлаулырак әйбер булмады. Чөнки бу җигелгән ат түгел, бу тормыш, бередә мең мәртәбә четереклерәк, әрфия кебек ертылырга гына тора иде. Үзеңчә бик изге ният белән тотынасың, ә киресенчә килә дә чыга... Аннары үз-үзеңне эт итеп каргыйсың, ялгышыңны төзәтү өчен утка-суга төшәсең, тик чәлпәрәмә килгән күңел тәрәзәсен, күпме генә оста ябыштырсаң да, аның җөйләре йөрәктә мәңгегә кала...

Бәлкем әле Зөбәрҗәт кияүгә чыкмагандыр, ялгыздыр, дип өметләнде ул. Бәлкем Мизхәткә һәммәсен энәсеннән җебенә кадәр сөйләп бирергәдер? Өстәл янына утыргач, ул әллә ничә мәртәбә шул хакта авыз ачмакчы булды, тик батырчылыгы җитмәде. Ул үз-үзен күрә алмады һәм, әгәр әйтсә, әлеге тойгының ана карата Мизхәттә уянуыннан курыкты.

Теге сөйләшүдән соң Мизхәт Әминә белән аралашудан туктады. Күп көннәрне кич чыкмады, китап укыды да китап укыды. Әминә үзе дә килмәде.

— Нәрсә булды, улым, нишләп дуслыгыгыз бетте? — дип сорады беркөн Нуриасма.

— Кешене ник юкка алдарга, әнкәй? — диде Мизхәт.

— Ничек алдау?

— Егет белән кыз йөри икән, аның азагы билгеле... Әминә дә, син дә, авыл халкы да шуңа өметләнә. Мин берегезне дә алдарга теләмим...

Мизхәт хаклы иде. Нуриасма ары бәргәләнде, бире бәргәләнде, әмма үзенең гаебен әйтерлек көч тапмады. Ахырда ул бер карарга килде: Алабугага барып кайтырга! Март башы иде. Миңлекамал карчыктан җайлап кына Зөбәрҗәтнең адресын алды, Мизхәткә: «Чаллыга Кифая апаларга барып кайтам»,— диде. Ике тавык суйды, бераз чәкчәк пешерде, кипкән җиләк белән как алды. Бөтенесен яхшылап сумкасына тутырды да, йөрәген учлап, сәфәргә чыкты.

Беренче көнне ул Кифаяларда кунды. Төне буе сөйләшеп чыктылар, киңәш-табыш иттеләр. Икенче көнне Алабугага юл тотты. Аның уйлавынча, ял көнне Зөбәрҗәт өйдә булырга тиеш иде. Әгәр ул карышып маташса, әти-әниләре белән дә сөйләшеп карарга булды. Автобус шәһәргә якынлашкан саен, ничек барып керермен, ни дип әйтермен, әти-әнисе ничек каршылар, дигән уйлар борчый башлады аны. Ләкин иң куркытканы — Зөбәрҗәтнең күзләренә карау иде. Теге чакта үз өендә: «Син кит, тимә аңа, ятим итмә мине»,— дигән чактагы аның күз карашын Нуриасманың гомергә онытасы юк...

Бәхетенә, Зөбәрҗәт өйдә булып чыкты. Ул кер юып маташкан җиреннән бүленеп ишекне ачты һәм гаҗәпләнүдән әле Нуриасманың йөзенә, әле аякларына карады.

— Исәнме, кызым...

— Исәнме, Нуриасма апа,— диде Зөбәрҗәт.— Бусага аша күрешмик, әйдә, узыгыз...

Нуриасма эчкә үткәч, ул порошоклы суда алсуланган кулларын Нуриасмага сузды... Борынгы өстәл-урындыклар, шкафлар куелган зур гына фатирда ул берүзе генә булып чыкты. Әти-әниләре шәһәр читенә дачага киткәннәр икән.

Зөбәрҗәт өстәл әзерләде. Нуриасма күчтәнәчләрен бирде, озаклап ашап-эчеп утырдылар. Нуриасма аның эше, әти-әниләре турында сорашты. Зөбәрҗәт мактап, авыл хәлләре белән кызыксынды. Икесенең дә иң кирәклесен әйтергә батырчылыгы җитмәде. Бер сәгать чамасы утыргач, Нуриасма:

— Миңа кузгалырга да вакыт җитә торгандыр, кызым,— диде.

— Нишләп инде, бер килгәч куныр китәрсең, Нуриасма апа, кич әниләр дә кайта, сөйләшеп утырырбыз,— диде Зөбәрҗәт аны кыстап.

— Юк, кызым, мин озакка түгел, сине күрим дип кенә килдем...

Бу сүзләр Зөбәрҗәтне әллә нишләтеп җибәрде.

— Мине күрергә? — диде ул, ни елмаерга, ни җитди булырга белмичә.

Нуриасма карашын идәнгә төбәде.

— Теге чакта... Мин юләрне кичерә алсаң, кичер син, кызым.

— Ни сөйлисең, Нуриасма апа? — диде Зөбәрҗәт.— Мин инде аны әллә кайчан оныттым...

Ул елмайды, әмма бу табигый елмаю түгел, көчәнеп, көн саен бәгырен яндырган утын яшерергә теләп елмаю иде. Нуриасма моны сизде, эченнән генә әле Мизхәтне онытмаган булса кирәк, дип сөенеп куйды һәм бу аңа күпмедер кыюлык өстәде.

— Кайт син, кызым...

Зөбәрҗәт берни аңламаган күзләрен аңа төбәде.

— Карт башым белән йөз сиксән чакрым юл үтеп, шуны әйтергә килдем мин сиңа...

Зөбәрҗәт өчен бу сүзләрне ишетү чиксез рәхәт, ләззәтле булса да, аларның мәгънәсе томанлы иде. Авылга чакырамы ул, әллә өйләренәме? Нишләп Мизхәт үзе түгел, әнисе чакыра? Керфекләрен түбән төшереп, ул шушы сорауга җавап эзләде, җавапны хәзер үк табарга кирәк иде, башны ныграк ваткан саен билгесезлек артты гына. Дәшми дә торып булмый иде. Һәм аның күңел түрендәге иң кайнар хисләрен белдерүче, баштан ук чыгармыйча яшереп торган иң кадерле сүзе, читлектән иреккә очкан кош кебек, теленнән ычкынды:

— Ә Мизхәт?..

— Ул сине оныта алмый, кызым...

Нуриасма куркып Зөбәрҗәткә карады. Ни дияр ул?

— Мизхәт мине беркайчан да гафу итмәячәк, Нуриасма апа.

Нуриасма авыр сулап куйды.

— Итәр, кызым...

Димәк, Зөбәрҗәтнең ник киткәнен әнисе Мизхәткә сөйләмәгән. Димәк, ул һаман да берни дә белми, аны гаепли...

Алар икесе дә тын калдылар. Зөбәрҗәт адымнарын санагандай акрын гына атлап әле тәрәзә каршына барды, әле өстәл янына килде. Ахырда ул тәрәзәгә карап туктады һәм:

— Нуриасма апа, син кайчан сөйлисең соң аңа? — дип сорады.

— Син кайткач,— диде Нуриасма.— Шуңынчы булдыра алмыйм... Әгәр миңа ышансаң, кайт... Кайтырсыңмы?..

Зөбәрҗәт аның соравын җавапсыз калдырды, һаман тәрәзәдән күзен алмады. Нуриасма аның иңбашларының, кулларының сизелер-сизелмәс дерелдәвен чамалады.

— Ярый, кызым, рәхмәт, мин кузгалыйм әле,— диде Нуриасма урыныннан торып.

Зөбәрҗәт сискәнеп китте, аңа таба борылды. Аның күзләре мөлдерәп яшь белән тулган иде. Ул аларны кул аркасы белән генә сыпырып алды да:

— Хәзер әз генә кучтәнәч тыгам,— дип кухняга йөгерде.

Бераздан ул бөтен гөбәдия, полиэтилен капчыкка салынган шоколадлы конфет алып чыкты. Чәй эчкәндә гөбәдияне үзе пешергәнлеген ул әйткән иде инде. Нуриасма кучтәнәчләрдән баш тартты.

— Мин бит синең янга килгәнне Мизхәткә әйтмәдем,— диде ул пышылдап.

— Ә кем сиңа әйтергә куша? Әйтмәссең, Нуриасма апа.

Зөбәрҗәтнең бу сүзләреннән алар икесе дә көлеп җибәрделәр һәм кучтәнәчләр сумкага кереп тә утырды. Кул биреп күрешкән чакта Нуриасма үзен борчыган нәрсәгә җавап эзләп Зөбәрҗәткә карады, ләкин ул яшь белән чыланган керфекләрен аска төшерде. Күз яшьләрен күрсәтмәскә теләве идеме, әллә күңелендәгеН яшерергә теләве идеме, әллә кыенсынудан гына шулай эшләдеме — анысы Нуриасмага караңгы иде. Ни генә булса да, аның йөрәген баскан авыр таш әз генә читкәрәк шуышкандай булды. Зөбәрҗәт исән, әле кияүгә чыкмаган, Нуриасмага да кинә тотмый кебек, димәк, әле өмет сүнмәгән дигән сүз иде...

Кайткан көнне кич ул бик яхшылап өстәл әзерләде. Гөбәдияне урта бер җиргә утыртты. Мизхәт эштән кайткач, өстәл тулы сый-нигъмәткә баш чайкап карап торды. Ул гадәттәгечә эчәргә сөтен эзләде, ләкин литрлы банка күренмәде.

— Әнкәй, сөт кайда? — диде ул.

— Бүген бергәләп утырып чәй эчик әле, улым,— диде Нуриасма.— Кучтәнәчләрдән авыз итмәсәң, ярамас.

Мизхәт карышмады. Ул Кифая апасы җибәргән сырны телеп алып ипи белән ашый башлады. Нуриасма аның алдына гөбәдияне этебрәк куйды. Әмма Мизхәт гөбәдиягә үрелеп тә карамады, колбасага күчте, аннары сыр кисәргә кереште. Нуриасма түзмәде, сырны да, колбасаны да өстәлдән алып суыткычка куйды.

— Кичкелеккә итле-майлы ризыкны күп ашамыйлар, ашказанына авыр булыр,— диде ул.

Мизхәт авызына капкан ипиен чәйнәүдән туктап, аптырашта калды. Бер дә әнисенең ашауга бәйләнгәне юк иде һәм бу аны гаҗәпләндерде. Чәен ашык-пошык йотты да урыныннан кузгала башлады. Нуриасма үзе дә сизми калды — елап җибәрде.

— Ни булды, әнкәй? — диде Мизхәт чиктән тыш гаҗәпләнеп.

Әнисенең елаганын күптән күргәне юк иде инде аның.

— Син минем кайтуымны теләмәгәнсең,— диде ул чын күңелдән кимсенеп, рәнҗеп.

— Нишләп алай дисең, әнкәй?!

— Көткән булсаң, алып кайткан кучтәнәчләрне ашар идең.

— Үзең алып куйдың, хәзер мине гаепләсең...— диде Мизхәт ни уйларга да белмичә гаҗиз булып.

— Ә ник гөбәдиясен авыз итмисең? — диде Нуриасма тавышын күтәреп.

— Минем аның ише баллы әйберләргә ис китмәгәнен беләсең бит...

— Әнкәй алып кайтканны мин исем китмәсә дә, кабар идем,— диде Нуриасма һаман да күз яшьләре аша.

— Ярар, ашыйм алайса,— диде Мизхәт һәм, өстәл янына кабат утырып, бер телем гөбәдия алды. «Кеше картайган саен бала-чагага әйләнә бара дигән сүз әллә хак инде,— дип уйлады ул гөбәдияне кабып.— Әнинең күңеле нечкәргәннән-нечкәрә бара. Ялгыш әз генә кагылырга да ярамый...»

Мизхәтнең гөбәдияне кабу белән чәйнәргә ашыкмыйча авызында тотып торуын күргәч, Нуриасма тынсыз-өнсез калды. «Валлаһи, сизде, Зөбәрҗәт кулларының җылысын сизде!» Ул, күңелендә уянган яшерен шатлыгын сиздермәс өчен, улына юри ачу белән карады. Шушы гөбәдия белән Зөбәрҗәт рухы кабат кайтсын, улының канына, җанына керсен иде, дип теләде ул.

— Әнкәй, нигә миңа алай елмаеп карыйсың?
Мизхәтнең бу сүзләре аны урындыгыннан сикертеп торгызды.
— Елмаеп?! Елмайган ди! Елмаерсың синең белән!
Ул йөзенә юри кырыслык чыгарып, өстәл җыештыра башлады...
Мизхәт берни дә белмәде, сизенмәде.
Март үтте, апрель үтте, май үтте, Нуриасма ни уйларга да белмәде. Зөбәрҗәт нинди карарга килде икән? Хат язарга да кыенсынды, билгесезлектә яшәү дә бәгырьне киптерде...
Июнь җитте, сабантуй җитте. Мәйданга чыкканда, Нуриасмага Маһинур очрап:
— И малай, ишеттеңме әле, Мизхәт белән йөргән теге укытучы кыз кунакка килгән,— диде.
Нуриасма тигез җирдә сөртенеп куйды... Йә алла, теләге кабул гына булсын!
Мәйданда Зөбәрҗәт укытучылар белән аңа каршы якта басып тора иде. Мизхәт вак шакмаклы күлмәген, ак чалбардан, беләгенә кызыл бәйләп, мәйдан уртасында уеннар оештырып йөри. Нуриасма күрәшне дә, уеннарын да юньләп карамады, астан гына, яшерен генә Зөбәрҗәтне күзәтте, аннан күзен алмады, йөрәге киләчәктә булачак олы шатлыкны тоюдан ашкынып типте. Зөбәрҗәт тә аңа карап-карап алган шикелле тоелды Нуриасмага... Бу көнне кич ул Мизхәтнең өстенә кигән киемнәрен аңа сиздерми генә әнә күзеннән үткәргәндәй карады. Тап-топ тигән, җыерылган булмасын, туфлясы ялтырап торсын, Зөбәрҗәтне кызыктырырлык булсын...
И тормыш! Бүген ана айга, йолдызларга карап, Мизхәт кайтмаганга ут йотып ята. Ә ул төнне ул бер генә нәрсә теләде: Мизхәт өйгә озаграк кайтмасын иде, Зөбәрҗәт белән аңлашсыннар, килешсеннәр, иртәнгә кадәр йөрсеннәр иде, дип теләде, ул кайтканчы узган һәр минутны, һәр сәгатьне керфек тә какмыйча эчке куаныч белән санап озатты. Һәм аның теләге кабул булды: Мизхәт таң аткач кына кайтты. Нуриасма икенче көнне дә, аннан соң да улыннан берни дә сорашмады. Аның кыяфәтеннән йөзенә, күзләренә җан керүдән ул барысын да аңлады. Сабантуйдан соң китеп барган Зөбәрҗәтнең ун-унбиш көннән кабат килгәнлеге, кабат Миңлекамал карчыкка фатирга кергәнлеге, колхоз пионер лагеренда эшли башлаганлыгы ишетелде... Мизхәт көн саен кич мотоцикл белән аның янына лагерьга бара башлады. Беркөн Нуриасма түзмәде, аңардан:
— Улым, Зөбәрҗәт теге чакта ник бездән киткәнен әйттеме соң? — дип сорады.
Мизхәт җилкә сикертеп куйды:
— Хәзергә сөйли алмыйм, ялгыштым, ди.
Нуриасма, аның бу сүзләрен ишеткәч, Зөбәрҗәткә мең-мең рәхмәтләр укыды...

* * *

Таң атты. Инде төне буе килмәгән йокы хәзер килмәс дип, Нуриасма самовар куйды. Бәлкем ул Зөбәрҗәт янына киткәндер? Китсә, анда нишләп төне буе торсын? Мотоциклы да өйдә бит. Әле Зөбәрҗәт белән араларының да ничек икәнен улкадәр белми Нуриасма. Әллә төнге сменага алып киттеләрме икән? Ул чәй эчте, көтүләр куды — Мизхәте күренмәде. Төнге сменада булса, кайтып керер иде. Ә кайтмаса? Аның нишләсен каян беләсең: куып диярлек чыгаргач, кайтырмы ул, юкмы? Берәр юләрлек эшләмәсен тагын дип тә борчылганда Нуриасма. Җанына урын таба алмыйча әле урамга чыкты, әле бакчага чыгып, эшләп карады, әле өенә керде. Сәгать ун да, унбер дә тулды, колхозның төшке аш вакыты да үтте — малае юк иде...

Соңгы үр... Шуны менүгә авыл күренәчәк. Үрдә автобус акрынайды, ул акрынайган саен Фәритнең йөрәге кызурак типте. Авыл каршыда гына, үр артында гына... Автобусның түбәсендәге ачыклыктан һәм тәрәзәләрдән өреп, юл буе тәннәрне рәхәтләндергән җиләслек, тизлек акрынайгач, кинәт юкка чыкты. Аның урынына юл буенда лепердәшеп утыручы каеннарның сагызлы җылысы кояш, үлән, чәчәк исләре белән кушылып, автобус эченә бөркелде, борыннарны кытыклап, башларны әйләндереп җибәрде, каен себеркесе пешерелгән коры мунчадагы кебек эссе тыгыз һава «кайтып җиттегезме, балакайларым!» дигәндәй маңгайларга, битләргә, муеннарга сарылды... Их, никадәр таныш, никадәр татлы бу исләр, бу җил-җиләснең аз гына кагылышы!.. Туган як җиле генә күңелне шулай ашкындыра, моңландыра ала, бүтән беркайда да мондагы кичерешләр кабатлана алмый, кабатлана алмый шул!

Ниһаять, автобус үргә менеп җитте. Фәрит үзе дә сизмәстән утыргычтан күтәрелеп куйды, бугаз төене, су йоткандагы шикелле, хәрәкәтләнә башлады... Нишләп бу кадәр йөрәккә якын икән соң син, туган җир?! Һәммәсе дә ялтыравыксыз, тәртипсез бит югыйсә: агач өйләрең дә, яшел бәрәңге бакчаларың да, кәкре-бөкре урамнарың да. Ыгың да тигез ярлар уртасыннан төз генә акмый: кемдер чүлмәк белән аударып җибәргән төсле — авылның бер ягына дугайланып җәелгән, тәртипсез таралган да, җиләк болынына җиткәч, ярларына кергән, сул яктагы Тимергали күленә тоташмакчы булып якынайган, шомырт, карлыган, балан, гөлҗимеш, камырлык куакларыннан күпереп утыручы Әби әрәмәсенә иркәләнеп-терәләп үткән, аннары уңга борылып Чия тавына сугылган, аны әллә никадәр кимереп, биек кызыл яр ясагач, тагын тын гына агып киткән. Болар барысы да, аксыл иген басулары да, күктән агып килүче мамык болытлар да, кояш та — һәммәсе дә авылга сыенган, авылга төбәлгән...

Без дә шулай. Синнән ераклашкан саен якыная гына барабыз, ахры, туган җир! Һәр түмгәгең, һәр борылышың, һәр сукмагың күз алдында. Әйтерсең лә синнән чыгып киткәндә ике арадагыниндидер бер тамыр урталай өзелгән дә шуның очлары кабат ялгану өчен еллар үткән саен бер-берсенә ныграк тартылалар... Бу тойгы авылдан бик еракка, чит җирләрдә яшәүчеләргә генә таныш. Татарча җыр гына ишет — сагыш сөреме күзләрне, борыннарны, тамак төпләрен әчеттерә башлый. Гүя синең йөрәгең түрендә сизелер-сизелмәс кенә булып һәрвакыт моң чишмәсе тибә. Аның сизгерлеген сөйләп аңлата торган түгел. Фәрит кайчан гына кайтса да, авылны күрүгә үк, ул чишмәнең челтери башлавын тоя, аның рәхәт дымы бөтен тәненә тарала, һәр күзәнәген били, сүз әйтергә теле әйләнми, елап та, елмаеп та булмый...

— Костюмың төшкән.

Колак төбендә генә пышылдап әйтелгән бу сүзләр Фәритне сискәндереп җибәрде. Ул үзенең уң ягында тәрәзәгә терәлеп утыручы хатынына ялт итеп карады. Иренең аптыраш тулы күзләре Нәсимәне ирексездән елмаерга мәҗбүр итте. Фәриткә аның ап-ак түгәрәк йөзе, чем-кара күзләре, юка кызыл иреннәре генә түгел, таза муены да, шәмәхә чәчәкле күлмәгенең киң уентыгыннан күренеп торучы шома күкрәк авызы да елмая кебек тоелды.

— Костюмың төшкән,— диде Нәсимә сул якка ияк кагып.

Фәрит башын шунда борды. Әле бая гына тез өстендәге костюмы утыргычларга үтү өчен уртада калдырылган аралыкта ята иде. Ул аны житез генә алып, тузанын да кагып тормастан, тез өстенә салды һәм карашын кабат алга төбәде. Авыл инде шактый якынайган булса да, баягы татлы ашкыну юкка чыккан иде. Фәрит күз чите белән генә Нәсимәгә карады. Тәрәзәдән тоташ агым булып артка таба каеннар йөгерә, аларның кәүсә өлешләре ап-ак, өсләре ямь-яшел, әлеге агымны

тулаем диярлек Нәсимәнең балкып торучы ак түгәрәк йөзе каплап бара... Ник һаман Фәриткә карап елмая соң әле ул? Аның хатынына ачуы килде. Костюмыңны да тотып кайта алмыйсың диюеме? Фәрит, бу халәттән котылырга теләп, карашын авылга күчерде. Ләкин нидер булды, йөрәк шатлыктан сикермәде, киресенчә, күңелен ниндидер аңлаешсыз авыр тойгы басты. Ул, аны селкеп төшерергә теләгәндәй, урыныннан күтәрелеп-күтәрелеп куйды, чал кергән куе кара чәчләрен кулы белән артка сыпырды, тез өстендәге костюмын рәтләштерде. Тик таныш йортлар, таулар, әрәмәләр күзләргә терәлеп туктап калдылар, күңелгә үтеп керә алмадылар. Бер ел буе көтеп алынган иң бәхетле мизгелләр иде бит бу... Егерме елдан артык Донбасс шахталарында күмер тузаны эчкән елларында, кунакка кайткан саен, аның шушы үрдән күтәрелеп авылны күрүгә, күзләреннән мөлдерәп яшь чыга иде. Алар балачактан сакланып калган күз яшьләре иде бугай, чөнки шуннан да татлырак берни дә юк иде. Авылга җиткәнче, аның таныш урамнарын үтеп, туган өенең газиз бусагасын атлап кергәнче, Фәрит тын гына, сүзсез генә ул яшьләрне йота да йота, авыз эчендәге бераз тозлы, кайнар һәм татлы сыдән кубып теле нидер сөйләмәкче булып селкенә, тик тавышы чыкмый, еш-еш сулыш алганы гына ишетелә... Нишләп юкка чыкты соң әле ул татлы мизгелләр, йөрәкнең иң түрендә кала торган бәхетле минутлар?! Ни булды соң? Барысы да әйбәт кебек, югыйсә. Тиздән әниләре белән, уллары Марат белән күрешерләр. Мизхәт әле эштәдер, ул кич кайтыр. Күпме шатлык, куаныч көтә. Ә менә йөрәкне салкын хафалану китерде дә кысты, җибәрергә уйлап та карамый. Күңел сизенә, диләр, бер-бер хәл булса? Марат әллә тагын ныклап авырып китте микән? Ике кызлары Донецкида калды. Анда да бәла-каза килеп чыгуы бар. Аның күңелсез уйларын Нәсимә бүлдерде:

— Юкка телеграмма бирмәдек,— диде ул, Фәриткә үпкәләгәндәй.— Автобустан төшүгә Марат белән әни басып торса, нинди күңелле булыр иде...

Фәрит дәшмәде, хатынына «бу хакта килешкән идек бит инде» дигән мәгънәдә карап кына куйды. Хатын-кыз — хатын-кыз шул. Сөйләшеп-киңәшеп бер уртак фикергә киләсең, ә күпмедер вакыттан соң шуның өчен үк ир-атны гаепли, алай кирәк түгел иде ди, син шулай-шулай дигәнгә генә ризалашкан идем, ди. Авылга кайтачаклары хакында алар башта телеграмма сукмакчы булганнар иде, аннары кире уйладылар. Нигә дип әнисенең дә, Марат белән Мизхәтнең дә күңелләрен алдан ук алгысытырга? Фәлән вакытта кайтабыз дисәң, күп чакта нидер килеп чыгучан: әйтерсең, язмыш дигән нәрсә юри үзен сиздерә, миннән узмагыз дигәндәй, тәзәтмә кертә. Син уйласаң алтыга, ходай кисә яртыга, дип юкка гына әйтмәгәннәрдер. Шуңа күрә Фәрит хатынының теләгенә каршы килде, кинәт кенә кайтып төшәбез, шулай әйбәтрәк булыр, диде. Нәсимә моны ахырда үзе дә хуплады. Марат төн йокламый көтәр, бала күңелен ник телгәләргә? Хатларына караганда борчылырлык берни дә булмаса да, Фәрит тә, Нәсимә дә, бер-берсенә әйтмичә, эчтән сызалар, көяләнәләр иде. Чөнки авылдан килгән хатлар аларның икесен дә тынычландыру рухында иделәр. Дүрт яшенә кадәр ун-унбиш сүз әйтә алмаган, башы чирдән чыкмаган Марат, узган ел авылда калдырып киткәч, сихәтләнгән дә, сөйләшә дә башлаган.

Чын түгел иде бу сүзләр. Фәритнең йөрәге чәнчеште, ул тиз генә валидол капты. Моны күреп, Нәсимә авыр сулап куйды. Йөрәк авыртуның моңа кадәр нәрсә икәнен ул белмәде. Марат аркасында күргән хәсрәт-борчылулардан бу. Ә малай Фәрит өчен дә, Нәсимә өчен дә җан кебек кадерле иде. Хәер, кемнең баласы кадерле түгел? Ләкин Марат аеруча кадерле иде. Чөнки Нәсимә ике кыз тапты, ә Фәрит тилмереп малай көтте. Нәсимә иренең күңелендә, аңа сиздермәсә дә нинди уй ятуын тоеп, күреп йөрде. Малайлы кешеләргә кунакка-мазарга барсалар да, телевизордан балаларга бәйле тапшыру карася да, иренең йөзенә

кимсенүгә охшаш шәүлә чыга иде. Шул чакларда Нәсимә үзен битәрли, гомер буе иренең күңелен яралаган рәхимсез кеше итеп тоя. Кыскасы, икесенең дә кәефләре төшә, телләр тешләнә иде...

Бервакыт йокларга яткач, Нәсимә шыпырт кына:

— Фәрит, әйдә бер малай алып кайтабыз! — диде.

Фәрит аптыраудан бер сүз дә әйтә алмады.

— Беләсеңме, миңа Валя бүген бер серен ачты.

Валя Нәсимә белән эшләүче хатын иде. Иң шаккаттыргычы шунда, Валя башта малай, аннары кыз, аннан малай, аннары тагын кыз тапты. Нәсимәгә шуның серен ачкан бит. Имеш, дүрт елга бер мәртәбә хатын-кызның каны алышына. Шул чакта, һичшиксез, малай туа. Кәгазь-каләм тотып, хисаплап карасалар, Нәсимәнең хәзер нәкъ шул чоры икән. Фәрит моңа ышанмады. Хатын-кыз хыялы ниләр генә уйлап тапмый! Нәсимәгә утыз алты яшь, ул кырыкның өстендә, ник бер бала алып кайтмаска? Күрше Хәдичәтти әйтмешли, фәрештәнең әмин дигән чагына туры килдеме, әллә хатыннарның сүзләрендә бераз хаклык бар идеме, туды бит малай! Әле нинди генә малай! Өч ай дигәндә Маратка Донецкида сокланмаган кеше калмады. Әнисенеке кебек ап-ак, түп-түгәрәк йөзле, Фәритнеке төсле кап-кара сызылып киткән кашлы, озын керфекле, зур шомырт күзле иде ул. Нәсимәнең әнисе Гыйльменур Мәскәүдән килеп төшеп, малайга күз ташлау белән егылып китә язды.

— Балалар, бу пәйгамбәр нәселеннәндер, мондый чибәр баланың безнең нәселдә булганы юк! — диде.

Бу сүзләр бәхетле ата-ананың йөрәгенә сары май булып ятты.

— Күз тимәсен, теләсә кемгә күрсәтмәгез, чиргә олгашуы бар,— диде әбисе.

Әллә тагы аның сүзләре рас килде, әбисе китеп озак та тормады, Марат буылып ютәлли башлады, температурасы кырыкка җитте, авызына ризык капмады, тиргә батып су эчендә ятты. Врачлар салкын тигән диделәр, стофилоккок диделәр, балага туктаусыз укол кададылар. Нәсимә дә айга якын хастаханәдә ятып чыкты. Фәрит тә шушы юлдан кайтмады. Әнисе бала янында, ул өйдә йокысыз төннәр уздырдылар.

Инде рәтләнеп кенә килә дигәндә, Маратның бөтен йөзе, тәне шешеп, ямьсез таплар белән капланды, ул кәнс-тәнс акырды. Врачлар аллергия диделәр, салкыннан бик нык саклагыз, астмага әверелә күрмәсен, диделәр. Фәрит тә, Нәсимә дә утка-суга төштеләр. Бөтен тормышлары шушы баланы саклау, аякка бастыру мәшәкатенә кайтып калды. Өстәл өсләре теге яки бу авыру һәм аны дәвалау турындагы китаплар белән тулды. Сервант-шкафлар, аптека киштәләрен хәтерләтеп, укол белән кертә торган, эчә, сөртә, тәнгә сылый, ягa торган дарулар, горчичниклар, мамыклар белән тулды. Маратның авыртынып ыңгырашулары, ник мине болай газаплыйсыз дигәндәй, акыллы күзләре белән аларның икесенә дә тилмереп карап торулары йөрәкне телем-телем телгәләде. Әгәр үз гомерене бирү бәрабәренә баланы шул газаплардан коткару ихтималы булса, алар икесе дә шуны берни уйламастан, хәтта куана-куана ризалашырлар иде. Бала авыруын кичерүдән дә зуррак газап бармы икән ата-ана өчен?! Ә үлсә? Кеше — уйлый торган җан иясе. Фәрит тә уйлады. Купме генә читкә куарга теләсә дә, ул уй килде, минең иң эчке, иң тирән чоңгылында урын алып, корбанына ташланырга аны сагалап торган ерткыч җанвар кебек, сабыр гына көтеп утыра башлады. Марат үлсә, Фәритнең йөрәге бу кайгыны күтәрә алмаячак иде. Өч яше тулганчы бала нинди генә авырулар белән авырмагандыр да, ничә үлемнән калмагандыр. Авырый дисәң дә, аның бит чирдән котылып, ачылып киткән, уйнаган-көлгән чаклары да булды. Аның үзләрен «ах» иттергән көнне Фәрит тә, Нәсимә дә мәңге онытмаслар. Беренче балалары туганчы ук Фәрит, һичшиксез, малай булачак дип, уенчык машина алып куйган иде. Ышаныч акланмады — икенчесе дә кыз булды. Алар икесе дә бу машинаны юньләп кулларына алмадылар, алсалар да әрҗәсенә курчак,

чүпрәк-чапрак төяп уйнадылар. Ә Марат шул машинаны кулына тотуы булды, «двын-двын-двын-двын», «в-в-в-в-в-в-в» дип, идәннән этеп алып китүе булды. Ике кызның күпме уйнап, бер генә мәртәбә дә «двын-двын» дип машина тавышы чыгарганнары юк иде. Малай кешенең хикмәтен Фәрит шунда гына чынлап торып аңлады. Әле бит ул беркая да чыкмаган, ясследә дә, бакчада да булмаган, аның гомумән машина тавышы чыгарып уйнаган беркемне дә күргәне юк иде. Фәрит малаен кочаклап алды, аның йомшак кулларын, табаннарын, сыйракларын, ботларын кат-кат үпте, үзе күңеленнән киләчәккә әллә нинди өметләр баглады, баланың сәламәтләнү ягына таба тәпи басканын күреп сөенде...

Нәсимә, декрет ялы беткәч, үз хисабына түләүсез ял алды. Ул да беткәч, Маратны яслегә бирделәр. Ләкин ул анда бер атна да йөри алмады — салкын тидерде, больницага салдылар. Терелгәч тагын яслегә йөртә башладылар — ул тагын больница юлы белән төгәлләнде.

Маратның теле дә ачылырга ашыкмады. Барлык теләкләрен, ихтыяҗларын ул ике авазны бергә кушып белдерүдән узмады: «Уъ-ә! Әъ-у! Әъ-у! Уъ-ә!» Шушыңа барысы да сыйган, шуннан барысын да аңларга кирәк иде. Ашарга-эчәргә кирәк булса, ул авызын очлайтып, иреннәрен бөреп куыш ясады да чәнчә бармагы белән шул тишеккә төртеп: «Әъ-у! Уъ-ә!» — диде. Марат әллә ничек кинәт, көтмәгәндә авырый башлый иде. Кичтән бер дигән була, уйнап-көлеп тә йөри, инде бөтенесе шатланалар, куаналар, ә төн уртасында йә ут эчендә яна, йә сулыш ала алмый, йә үзен-үзе куркытып, үрле-кырлы сикерә. Ахырда врачлар узган ел: «Урын, һава алыштырып карагыз, мөмкин булса, авылга кайтарыгыз»,— диделәр. Уйлаштылар-уйлаштылар да, дүрт яшьлек Маратны Фәритнең туган авылы Күкеледә әнисе янында калдырып киттеләр. Бу — йөрәкне өзеп калдыруга тиң булды.

Донецкига кайткач, алар тере мәет кебек йөрделәр. Өйдә кулларына эш йокмады. Нәсимә, йокы бүлмәсенә кереп, башта Маратның фоторәсемен үбә-үбә елады, ә Фәрит аның елаганын ишетмәс өчен, авылдан алып килгән ундүрт телле тальянын уйнады. Шул рәвешле бер ай вакыт үтте. «Әллә кайтып китикме?» — дип авылга язган хатларына Фәритнең әнисе Мизхәттән: «Борчылмагыз, Маратның хәле әйбәтләнә, үсә, күңелен алгысытып йөрмәгез»,— дигән җавап килде.

Ут эчендә бер ел гомер үтте.

Менә хәзер аларны авылда ни көтә?

*Ахыры киләсе санда*

# Рафаил

## Мизгел

Мизгелләрнең ялын эләктердем...
Ите беләнКупты яллары,
Шул мизгелләр инде гомеремнен
Каннар аша туган таңнары.
Мизгелләрнең ялын эләктердем...
Сыртларында минем йөрәктер,
Мизгелләрне иярләгән кеше
Гасыр саен берәү кирәктер!
Мизгелләрнең ялын эләктердем...
Кушаяклап типте мизгелләр,
Дага кадаклары кадалудан
Тетконенеп беткән күңелләр.
Дөньяның бер күгәрегe белән
Чәрдәкләнгән чакта хисләрем,
Туган якның бөек мизгелләрен —
Умырзаяларын иснәдем.
Мизгелләрнең ямен эләктердем...
Мизгел — тәүге язгы күкрәүдер,
Яшәүләрем — кызлар, иркәләнеп,
Шашкан чакта туган тетрәүдер.
Шул мизгелләр хуҗа тормышыма,
Мин үзем дә мизгел ялында.
Атлантидаларны терелтерлек,
Помпейларның көлен эретерлек,
Бар дөньямны хаҗга йөретерлек
Мизгел чәбәләнә җанымда!

## Урамда

Мин Мәскәүне айкап кайттым бүген,
Уйлар корымына буялып.
Хәер биреп йөрдем, башкаланың
Хәер өстәвенә оялып.
Мәскәү озынлыгы — базар монда,
Үлчә аркылыга, йә буйга.

Рафаил (ГАЗИЗОВ) — *шагыйрь, 1948 елда туган, берничә китап авторы. Проза әсәрләре дә яза. Мамадыш районының Кече Кирмән авылында яши.*

Бәяләргә карап офтанасың:
Да, Марфа да, диеп, утызда.
Нәкъ егерме тугыз, дип әйтсә дә
Сессиядә Гайдар кайчакны,
Мәскәү хәтерләтә бар дөньяны
Чишендереп кайткан качакны.
Нәрсә кирәк? Ирен буявымы,
Ят бер гыйфрит сыйган шешәме?
Гыйшык чөйгән кызның тезләреме? —
Йә, тугара башла кесәңне.

Үзеңне дә сатып җибәрерләр
Абайламый, җайсыз торганда,
Башкаланың даны чүпрәк булып
Сатылырга чыккан урамга.
Урам маңгаена дага итеп
Кадакланган шактый исемне —
Челтәрләнгән калай савытсыман —
Чүплекләргә тарих күчерде.
Хакыйкатьнең очсыз ямаулыгы
Сагыш сеңгән мәрмәр такталар,
Күпме җинаятьнең җәннәтедер
Халык өчен бикле капкалар.

Иренмәгән һәр эт аяк чөйгәч
Кайнарланып бүрткән тарихтан,
Чабаталы, сәрхүш чорлар карый,
Иман мунчасына зарыккан.
Һәйкәл өсләрендә һәйкәл монда,
Ишарәсе бер үк милләттән,
Илбасарлар башкаларның рухын
Һәйкәлләре белән имгәткән.
Метроларга төшеп сулыш алам
Мәрмәр заллар ага күземнән,
Шушы купшы заллар йоткан байлык
Минем авыздан да өзелгән.
Тагын чыгам шәһәр урамына,
Монда ваклап Мәскәү сатыла,
Унбиш бәя торган Мәскәү данын
Ыштан итеп алам хатынга.

## Бүлмә

Язлар кунак булып килә монда,
Җылынырга минем йөрәктә,
Толымнары кебек хәлсезләнеп
Ак куллары ята күкрәктә.
Язлар китә кәгазь көймә сыман,
Йөрәк китә язга ияреп,
Җаным — буш бер бүлмә, бар дөньяның
Сагышларын шыплап өярлек.
Кайчак җәйләр килеп керә миңа,
Гүя бик күптәнге танышлар,
Җәйләр — чынлы болын, йөгерек колын,
Серкә очыручы арышлар.

Җәйләр төн күк шуа кочагымнан,
Яна яшен суккан мендәрләр,
Җанны сискәндерә күкрәү булып
Кайтавазга күчкән тетрәүләр.
Күзләр керә ишегемне ватып,
Җанбасар күк керә, бур булып,
Күп сөйләшеп тормый кочып ала,
Ханны гарык иткән хур булып.
Китә күзләр, күңел тәрәзәсен
Бәреп ватып тышка сикерә,
Гармун тартып исерек сагыш керә,
Әллә җырлый, әллә үкерә.
Кышлар килә миңа, чәбәләнеп
Бураннары эри кочакта.
Өләүкәгә урмәләгән кызны
Күреп торган бабай сыман, кышлар
Ах! дип кенә кала шул чакта.
Китә кышлар, бураннары кала,
Тыңламаган, шашкан кыз булып,
Бураннарда калам — кышкы буран
Күмгән арба сыман онытылып.

## Гомеркәем

Көннәремне сезгә бүләк иттем,
Ә төннәрем калды йөрәктә,
Аннан йөрәкне дә корбан иттем,
Көле тузгып ята күкрәктә.
Күзләремне сезгә бүләк иттем,
Сезгә кирәгрәк санадым,
Елның дүрт фасылын сезгә биреп,
Бишенчесе булып калганмын.
Шигырьләрем — сезгә, чире — миңа,
Шатлык — сезгә, кайгы — минеке,
Гайбәтләрнең котырганы — миңа,
Хакыйкатьнең агы — сезнеке.
Зәңгәр күкләр — сезгә, ә яшенле,
Актарылган күкләр — миңадыр,
Кояшлары — сезгә, котыплары —
Миңа булды, шуңа туңамдыр.
Йосыф вә Зөләйха, Таһир-Зөһрә
Мәхәббәте сезгә бирелгән.
Минем гомер — йолкыш сагыш кына,
Китап битләренә күмелгән.
Кайчак гомер, сукбай өтер булып,
Шул битләрдә йөргән буталып.
Хәзер инде зират каенында
Байгыш сыман утыра офтанып.
Гомеркәем тормыш гармунының
Ертык күрегә күк гырылдый,
Тормыш ата казы кочагында
Калган сабый сыман чырылдый.
Гомеркәем — шигырь тулпарының
Шартлап атылып чыккан күзедер,
Бәхетеннән дөнья тетрәнерлек
Бөек фаҗиганең үзедер.

## Борис Пастернак каберендә

Язгы бозны, шикәр кебек бозны
Кетердәтеп вата табаннар,
Заман бозын җаннарыннан коеп,
Атлый монда килә алганнар.
Зират сукмагына хәтер ава,
Зират сукмаклары пыяла,
Шушы сукмакларның күкрәгендә
Иман богаулары уала.
Хәтта буран килгән башын иеп,
Беркем карны көрәп куймаган,
Каберләрне кадерләрлек заман
Үле туган, йәки тумаган.
Ак ташына, салкын ак ташына
Таянды да гасыр туктады,
Ишетмәдем: гасыр бугазыннан
Ыңгырашу чыкты... чыкмады.
Бөтен дөнья күрә бу каберне
Һәм Пастернак күрә дөньяны,
Вакыт соңга калып аның исемен
Хак буяулар белән буяды.
Кеше көчсез вакыт хөкеменнән,
Ә көчлеләр гасыр иярли.
Борис Пастернакның кабер ташы
Гасырларны тотар җибәрми.
Яңа гасыр, зыялырак гасыр,
Үткән гасыр өчен оялып,
Пастернакның сөйгән кызы булып
Бүләк итәр әле кулъяулык.
Шундый биек кабер, бөек бәгырь,
Һәйкәл кирәк түгел андыйга,
Сүнгән, үлгән, корымланган намус
Монда килеп җанын кабыза.

## Кемдер шакылдата

Гасырлардан киләм, йөрәгемдә
Мәхәббәтләр уйган үткелләр,
Бу җанымда Йосыфтан да калган,
Таһирдан да алган төсмерләр.
Гасыр уртасыннан атлап киләм,
Мәҗнүн дә мин, Мәҗнүн түгел дә,
Берүземә меңләп Ләйлә кирәк,
Шундый дәрья яши күңелдә.
Тарих уртасыннан атлап киләм.
Кануннары ава алдыма.
Камчы гына түгел, гасыр үзе
Сулышымнан гөлтләп кабына.

Гасыр уртасыннан атлап киләм.
Сәхипҗамал кала кул болгап,
Габделҗаббар Кандалыйлар кала,
Сәхипҗамалына хат сырлап.
Галиябану килә тальян тотып,
Тыңламакчы, ахры, үз көен,
Гасыр күкрәгенә җирләде ул —
Безнең йөрәкләргә Хәлилен.
Бу йөрәгем оҗмах тәмугыдыр,
Анда фаҗигаләр саклана...
Яңа Таһир, яңа Зөһрә микән?
Кемдер шакылдата капкага.

# Фәрит Габдрәхим

## Кораб ясый татар

*Ил корабын җил сөрә!..*

Дәрдемәнд

### I

Уналтынчы гасыр... вәхши гасыр...
Батырылган татар корабы.
Җаныбызга богау салганнарга
Җәзанны бир, Ходам, ярабби!

Русиянең шыксыз корабында
Хаким чиркәү — даң-доң! — чаң кага.
«Такмыйсыңмы, тәре, гололобый?!» —
Татар каны ага... кан ага...

Үрчеттеләр, майлы калҗа биреп,
Мөртәт Шаһгалиләр нәселен.
Шаһгалинең оныклары уяу:
Богау өзсәң — башлар яньчелде.

### II

Инкыйлаби егерменче гасыр.—
Мәхшәр купты Рәсәй-корабта.
Үз корабын төземәкче татар...
Акты кабат, акты кара кан.

Өлкән туган: «Люблю!» — диде азак,
Бер каюта бирде... читлектәй:
«Ясасалар кораб — эшләр харап...
Татарга шул читлек бик җиткән».

Канлы әләм чөеп, «СССР» дип,
Үзгәрттеләр кораб исемен.
Тик барыбер богау өзелмәде,
Үзгәрмәде кораб җисеме.

### III

Дөнья корабыннан аерылып,
Сәфәр чыктык яңа кыйблага.
Офыктагы җәннәт гел читенде,
Күп явызлык, ахры, кылганга.

---

Фәрит ГАБДРӘХИМ — *Уфада яшәүче татар шагыйре. Башкорт телендә китаплары дөнья күрде.*

Җилкән ертык. Кораб төбе тишек.
Дәрья ярсу. Алда — шарлама.
Кораб ясый татар. «Җитте, брат!
Татар белән кабат шаярма!»

Бәйсез татар!
Үз корабың төзеп,
Китәрсең син кәрван артыннан.
Сукмә Горбачевны! Кой син аңа
Йөрәгеңдә һәйкәл — алтыннан.

## Сабан кой!

«Тимер тапкан тилмермәс»,— ди халкым.
Ә көн иткән татар тилмереп
Бетергәннәр Казан ханлыгында
Тимерлекнең барсын җимереп.

Татар кылычыннан, ук очыннан
Койган җәллад богау-зынҗырлар.
«Заманалар авыр, залимнәр күп»...—
Шулчак, ахры, туган бу җырлар.

Богауларың өзеп аттың, халкым.
Кайтты кабат, кайтты Сабантуй!
Ошбу богаулардан койма кылыч,
Ошбу богаулардан сабан кой!

Тапшыр аны Иван Иванычка,
Авыру җаны тәмам терелсен:
«Русское поле!» диеп җырлый-җырлый,
Мәскәү тирәсендә җир сөрсен!

## Эш аты

Мәскәү — башлы! Юккамыни
Бүлгән безне урталай.
Аерган да төп халыктан,
Япкан күрше утарга.

Кимсенүдән, алданудан
Үксергәме гарьләнеп:
Туып-үскән җиребездә
Килмешәккә әйләндек.

«Туган телем!» — дисең... Их, син —
Башкортстан татары!
Ни пычагыма сиңа тел?!
Син бит эш аты бары.

Кешни беләсең ләбаса,
Янгырат тирә-ягың!
Авызлыклы йөгән, тышау...
Сиңа ни кирәк тагын?!

Эш аз дисәң, Алла сугар,
Телеңә тилчә чыгар.
Син тезләнеп тарткан йөккә
Чыдаса татар чыдар.

Нәшрият кирәк?! Ха-ха-ха!
Менә сиңа тамаша!
Утар хуҗасымыни син?!
Син — эш аты, алаша!..

Сыртың чыбыркы телиме:
Куш аяклап тибәсең.
Сындыра күрмә Мәскәүнең
Черек утар киртәсен.

# Салават Рәхмәтулла

## Ага сулар

Башкаемны учларыма кысып,
Бата-бата тирән уйларга,
Күзләремне тутырып карап торам
Borгаланып аккан суларга.

Сулар юлы, гомер юлы сыман,
Башлана да жырлап-чылтырап,
Күкрәк көче белән жир актара,
Һичбер кемнән тормый юл сорап.

Чирәм яра, таулар булса — тишә,
Ташлар булса — кисә: юл сала.
Елга булып, диңгезгә юл ала,
Чыккан чакта чишмә булса да.

Ярларына сыймый шаулап ага,
Диңгез шиңәр сыман — туктаса.
(Үзе диңгез булыр иде, ярлар
Чытырдатып кысып тотмаса...)

Аккан сулар — узган гомер сыман...
Бата-бата төпсез уйларга,
Күзләремне тутырып карап калдым
Боргаланып аккан суларга.

...Их, боралмам гомерем агышларын,
Боралсам да сулар агышын...
Боргаланып аккан сулар сыман,
Бу дөньядан узып барышым...

## Көрәшчеләр

Картәтием атаклы көрәшче булган.
Ул сабантуйларда гел беренче урынны алган.

Хәйләләрсез, саф татарча көрәш —
Көрәшләрнең сыйфат билгесе:
Бер кысыла мәйдан, бер языла —
Кемдә калыр батыр сөлгесе?..

Егетләрнең сөлек кебекләрен
Берәм-берәм батыр егачак.
Батырдан да батыр пәһлеванга
Иң соңыннан... Садыйк чыгачак...

---

Салават РӘХМӘТУЛЛА (1942) — *Эстәрлетамакта (Башкортстан) яшәүче милләттәшебез. «Әйтелмәгән әйтер сүзләрем», «Күперләр», «Яңгыр, яу-яу!» һ. б. шигырь китаплары авторы.*

Һәм ул — чыккан! —
Беркем күрмәгәндер
Көрәшченең аңа тиндәшен:
Бер «һһ!» иткән дә ул —
Җирдән аерып,
Җилкә аша чөйгән көндәшен!..

...Картәтием чалымнары, диләр,
Йөрешемдә, холкым, буйларда...
Күңелкәем — җырга-моңга тулы,
Көрәшмәдем сабантуйларда.

Телдән-телгә, чордан-чорга күчкән
Картәтием даны — зур, беләм.
Сабантуйларда тик көрәшмәдем,
Мин бәйгегә кердем... җыр белән.

Хәйләләрсез, саф татарча микән
Бәйгеләрнең сыйфат билгесе?
Эх...
Аяк чалган мөтәшагыйрьләрнең
Кулларында... шагыйрь сөлгесе...

Тамырларда җинүчеләр каны!
Мең ялганны бер хак егачак:
Бер кысылыр йөрәк, бер язылыр —
Шагыйрь барыбер өскә чыгачак!

## Татар галәме?..

Кораб арты — кораб:
Космонавтлар
Галәм гизә (инде ни заман!)
Галәм гизгән корабларда нигә
Татарларга урын юк һаман?!

«Гел киендереп тә, гел ашатып
Һәм эчереп торыр,— диләрме?! —
Татар — хәтәр: галәм уртасында
Бәйсез дәүләт корыр...» — диләрме?!

## Колхозчы монологы

«Беренче»без — орден-медаль алды!
Ә зам-завлар — затлы бүләкләр! —
План тула иде!..
Безгә һәрчак
Була иде «кайнар теләкләр!»

Данлау була иде күккә чөеп:
«Сез — ышаныч илгә, сез — терәк!»
...Без — ышаныч һаман, без — терәк шул!
Шуңа сез — юк, без — бар: без — кирәк!..

# Укучыма бер сүз

«Хәбәрдарлык заманасы» диеп
Беркатлылар булмыйк һаман да.

Әй, укучым!
Йөрәкләрне ачып,
Бер сөйләшик икәү калганда.

Әле — жылы Апрель жиле исә!
Давыллары (мәгълүм!) искәннәр.
Хакыйкатьне әйткән өчен генә
Шагыйрьләрнең башын кисканнәр.

Мин бәхетле бүген: тугры сүзем
Йөрәгенә житә туп-туры.
Араларыбызда урала бит
Сволочьлар, каһәр суккыры...

Почмаклардан күзәтәләр безне
Һәм алалар әле язып та.
Алда — елмаялар!..
(Артыбызда
Йөриләрдер базлар казып та...)

Давыллары иссә, шулар безне
Мөнбәрләргә менеп «фаш итәр»:
Син укыган шигырьләрем өчен
Иң беренче... минем баш китәр...

**Рюноскэ Акөтәгава**

# ЧЫТЫРМАНЛЫКТА

НОВЕЛЛА

*Рюноскэ Акөтәгава (1892 — 1927) — япон әдәбиятының классигы. Бу талант иясенең бары тик үзе генә ачкан иҗади алымнары дөнья әдәбиятының алтын фондына кергән. Аның берсеннән-берсе кызыклы новеллаларын бөтен континентларда да яратып укыйлар. Рюноскэ яшәгән, иҗат иткән чордан ерагая барган саен аның әсәрләре заманчарак була бара һәм һаман укучыларны үзенә күбрәк тарта.*

*Япониянең ел саен бер яшь язучыга бирелә торган иң югары премиясе Акөтәгава исемен йөртә.*

*Гомере Коняш чыгышы иленең катлаулы үсеш чорына туры килгән Рюноскэ Акөтәгава авыр кичерешләр чолганышында яши. Тормыш белән араны өзәргә кирәклеге аның кайбер әсәрләрендә сизелгәләп китә. «Аллаларның бердәнбер бәхетсезлеге — алар үз-үзләрен үтерә алмыйлар» — ди ул.*

*1927 елның 4 июлендә, таң атып килгәндә ул агу эчә. Бу вакытта аңа нибары 36 яшь була...*

*Рюноскэ Акөтәгаваның журналда тәкъдим ителә торган «Чытырманлыкта» исемле новелласы дөнья әдәбиятындагы уникаль әсәрләрнең берсе санала.*

## Суд вәкиле сорау алганда утын кисүче сөйләгәннәрдән

Әйе. Мин тап булдым мәеткә. Гадәтемчә, иртән-иртүк, агач кисәргә дип ераккарак, таулар эргәсенәрәк барган идем. Кайда дип?.. Ямасинога китә торган юлдан аз гына читтәрәк. Анда бамбук белән ылыслы куаклар аралашып үскән, чытырманлы, бик аулак урын.

Мәетнең өстендәге киеме сыек зәңгәр төстәге суйкан, башында шәһәрнекеләр генә кия торган кәпәч иде. Чалкан яткан иде, шунысын да әйтим: тәнендә бары тик бер генә яра бар, нәкъ күкрәк турысында, янәшәдәге коры бамбук яфракларына кызыл буяу сиптерелгән кебек иде. Юк, каны агудан туктаган иде, ярасы йомылган булгандыр. Ә-ә, онытып торам икән, минем аяк тавышыннан да курыкмыйча, яра өстендә кан эчеп бер шөпшә утыра иде.

Кылычы, корал ише әйбере дисезме? Юк, андый нәрсә күренмәде. Мәет янында бау гына аунап ята иде. Аннары... Ә, әйе, баудан кала бер кырыйдарак тарак бар иде. Мәет янында шул ике генә әйбер күрдем. Ул төштәге үлән дә, коелган яфраклар да бик нык тапталган иде, күрәсең ул болай гына бирешергә теләмәгәндер. Аты юк идеме? Андый ешкынлыкка нинди ат керә алсын инде. Ат юлы ерактарак, куаклык артында.

## Суд вәкиленә мосафир монах сөйләве

Мәрхүмне мин кичәгенәк очраткан идем. Кичә... төш вакыты иде. Чама белән, төш вакытлары булыр. Кайдамы? Сәкиямадан Ямасинога бара торган юл өстендә. Ул атка атланган бер ханым белән Сәкиямага таба юл тота иде. Ханым киң читле эшләпә кигән, бөркәнчек аша чыраен күрмәдем. Ефәк күлмәге сары чәчәкле иде. Аты җирән төстә, ялы кыркылган. Буе? Озын буйлы иде шикелле. Мин бит монах, ул мәсьәләдә бик үк тирән йөзмим. Ир кешенеме? Әйе, бил каешына кылыч тагылган, аркасына җәя белән ук та аскан иде. Хәзергедәй күз алдымда, лакланган кара садагыннан егермеләп ук тырпаеп тора иде. Аның җирдәге тормышы шулай өзелер дип башыма да китермәдем. Уйласаң, адәм баласының гомере чык тамчысыдай бер мизгеллек кенә. И-ии, сүзләр белән генә аңлатырлыкмыни, нинди кайгы...

## Суд вәкиле сорау алганда җантимер сөйләгәннән

Мин кулга төшергән бәндәме? Атаклы юлбасар Тадземару булыр ул. Авадугата күперенә ат өстеннән егылып төшкән дә ыңгырашып ята — шунда каптырып алдым мин аны. Кайчан дисезме? Кичә кич белән, кояш баеган мәлдә. Әлегрәк тә мин аны чак эләктерми калган идем. Ул чакта да аның киеме шул ук зәңгәр суйкан, билендә кылыч иде. Ә бу юлы, күреп торасыз, җәя белән уклары да бар. Шулаймыни?! Димәк, кораллар үтерелгән ир кешенеке? Бу очракта инде җан кыючының Тадземару икәненә шикләнмәскә була. Күн белән тышланган җәя, лакланган кара садак, карчыга каурые куелган унҗиде ук — болар барысы да, димәк, үтерелгән адәмнең шәхси әйберләре. Әйе, аты да сез әйткәнчә, җирән төстә, ялы кыркылган.

Тәкъдирдә шулай язган күрәсең, Тадземаруны әйтәм, җирән айгыр аны сыртыннан кагып төшергән. Мин килеп җиткәндә ат күпер төбендә үлән чемченә, артыннан озын тезгене сөйрәлеп бара иде.

Ә бу Тадземару, шәһәр башкисәрләреннән аермалы буларак, хатынкыз күрсә болай гына ычкындырмый. Хәтерлисез микән, узган елны Акиторибэ гыйбадәтханәсе артындагы тауда бер хатынны кызы белән бергә үтереп ташлаганнар иде. Аны да шушы Тадземару мөртәт эшләгән диделәр. Менә тагын җирән атта барган хатын... Ирне үтергән икән, хатын кая киткән? Беркем белми. Сез гафу итегез инде, әшегезгә катыша дип уйламагыз, моны тикшереп ачыкларга кирәк иң.

## Суд вәкиле сорау алганда карчык сөйләгәннәр

Әйе, бу үтерелгән кеше минем кызымның ире иде. Вакастан самурай ул. Аңа егерме алты яшь. Исеме Канадзава Такэхиро. Юк, үчле кешесе булмас, бик йомшак холыклы иде. Минем кызыммы? Масаго исемле. Унтугыз яшь. Кыю-чаялыгы ягыннан ирләргә алыштыргысыз иде. Такэхирога кадәр бер дә яраткан егете булмады. Карасу төнле, сул як күз почмагында миңе бар, озынча йөзле.

Кичә Такэхиро кызым белән бергә Вакаска китте. Нинди гөнаһларыбыз өчен мондый бәла төште микән безнең башка? Кайда минем кызым, кайларда? Киявемнең язмышы белән инде әрнеп булса да килешәм, ә кызым хакындагы борчу һаман йөрәгемне сызлатып тора. Карчык кешенең сүзен тыңласагыз иде. Алла хакына дип сорыйм, бөтен урманболынны актарып чыгыгыз, зинһар, табып бирегез миңа кызымны! Тадземару дисезме әле, нинди әшәке бәндә ул! Киявемне генә түгел, кызымны да... (*Сүз әйтә алмыйча хәле китеп җылый*).

Мин үтердем ул адәмне. Әмма хатынына кул салмадым. Кая китеп олаккан ул? Әйтә алмыйм. Туктагыз әле! Күпме генә изаласагыз да белмәгәнемне беләм дип әйтә алмаячакмын. Хәзер инде, шулай килеп чыккан икән, мин тамчы да курыкмыйм, берни дә яшермәячәкмен дә.

Мин ул ир белән хатынны кичә төш авышып барганда очраттым. Җил исеп куюга ханымның бөркәнчеге ачылып китте дә... йөзе бер мизгелгә генә балкып алды. Миңа ул алиһә булып күренде. Мин шунда ук бу ханымны яулап алырга карар кылдым, ирен үтереп булса да.

Сезгә бу куркыныч тоеладыр? Ир кешене чәнчелдерү — гадәти нәрсә. Хатын-кыз хакына ирләрне һәрчак үтерәләр. Әмма мин билемә тагылган кылычым белән намуслы үтерәм, ә менә сез, кылычка тотына алмыйсыз! Сез власть, акча, матур ялган белән үтерәсез. Дөрес, мондый чакта кан чыкмый, ирләр исән дә кала кебек, ләкин алар барыбер тере мәеткә әвереләләр. (*Кинаяле көлү*).

Ирен теге дөньяга озатмыйча гына хатынын яулап алу мине канәгатьләндерми, дип һич тә әйтергә теләмим. Бу очракта да мин әлеге чибәркәйне кан чыгармыйча гына алырга теләгән идем. Әлбәттә, мондый шаяруны юл өстендә эшләмиләр. Моның өчен хатын белән ирне куаклыкка алып керергә кирәк иде.

Моның әллә ни кыенлыгы чыкмады. Тегеләргә юлдаш сыйфатында иярдем дә, сөйләнеп барган булам. Имеш, каршыдагы тауда борынгы курган бар, шуны казып, әллә нихәтле кылыч, көзге кебек әйберләр тапканмын. Бөтен хәзинәне тау итәгендәге урман ешкынлыгына кем дә таба алмаслык итеп күмгәнмен. Кызыксынган кешегә арзан гына бәягә сатып та җибәрүем бар, имеш. Минем мавыктыргыч сөйләвемә ир адәм әкрен-әкрен генә бирешә башлады. Шуны онытмагыз! Бу тормышта иң куркыныч нәрсә — нәфсеңне тыя алмау, комсызлык! Ярты сәгать тә үтмәде, тегеләр атны бордылар. Минем арттан ияреп, тау сукмагына төштеләр.

Агачлыкка җиткәч, мин хәзинәнең эчкәрәк, куе ешкынлыкка күмелгәнен, шунда кереп карарга кирәклеген әйттем. Нәфсесе кузгалган ир каршы килеп тормады. Хатыны, атыннан төшмичә генә, шул урында көтеп торырга булды. Дөрес эшләде, чытырманлыкка атны алып керерлек түгел иде. Бөтенесе дә, мин уйлаганча, майлаган кебек бара. Ханымны үзен генә калдырып без куаклык эченә кереп киттек.

Алга атлаган саен, бамбук агачлары ылыслы агачлар белән аралашып, ешкынлык отыры куера, караңгылана барды. Ниятеңне тормышка ашыру өчен моннан да кулай урынны каян табасың. Чытырманлы ботакларны аралый-аралый, хәзинәнең тегендәрәк, юан агач төбенә күмелгәнен сөйләп барам. Теге адәм, әсәренеп, миннән алгарак чыгып, ашыга башлады. Шулчак, капылт кына ыргылып, тегене сугып ектым да... аны агач кәүсәсенә бәйләп кую минем өчен секундлык эш иде. Баумы? Нинди юлбасар баусыз йөри инде, ә! Әлбәттә, тавыш чыгармас өчен, коелган бамбук яфракларын авызына төйдем. Шуннан соң нинди мәшәкать чыгара алсын инде ул.

Ирне шулайрак хәл кылганнан соң, хатыны янына әйләнеп кайттым. Барып карарга кирәк, ирегезгә кинәт кенә нидер булды, чире тота башлады бугай дидем.

Ханым, киң читле эшләпәсен салып, атыннан төште. Мин аның кулыннан тотып ешкынлыкка алып кереп киттем. Теге урынга җитүгә ул агачка бәйләнгән ирен күреп алды да куеныннан хәнҗәр тартып чыгарды. Минем әле беркайчан да мондый кыю-тәвәккәл хатын-кызны күргәнем юк иде. Абайламый калсам, эчемне актарып ташлыйсы иде. Ул

беренче селтәнүгә үк читкә тайпылып өлгердем. Юкка гына мин Тадземару булып йөримме! — кылычны кынысыннан алып тормыйча гына ханҗәрен бәреп төшердем. Нинди генә гаярь булмасын — коралсыз хатын-кыз көчсез инде ул. Шулай итеп, мин иренең җанын кыймыйча гына хатынны үземә буйсындырдым.

Ирен соңыннан да үтерергә теләгем юк иде. Ләкин мин күз яшенә манылып яткан хатынны калдырып бу урыннан тизрәк ычкыныйм дигәндә, ул җиңемә асылынды да, тыны-көне бетеп кычкыра башлады: «Йә сез үләсез, йә ирем... Икегезнең берегез үләргә тиеш!.. Ике ирнең дә күз алдында мәсхәрәләнү — үлемнән дә хәтәррәк... Сезнең берегез үләргә тиеш... Кем исән кала, мин шуңа барам». Бу очракта инде мин аның ирен үтермичә кала алмый идем.

Нинди явыз, әшәке бәндә, дип уйлыйсыз инде сез минем турыда. Әгәр сез ханымның шул мәлдәге чыраен күрсәгез, алай уйламас идегез. Шулай... Аның утлы күзләрен күрсәгез иде. Күз карашың тоюга, баскан урынымда яшен бәрсә дә, барыбер аны үземнең хатыным итәм, дип уйладым. Юк, бу, сез уйлаганча, хайвани теләк түгел иде. Әгәр мине женси хис кенә котырткан булса, ул ханымны читкә тибәр идем дә китеп барган булыр идем. Ул чакта инде аның иренә дә үз каны белән минем кылычымны кайнарлату кирәк булмас иде. Ләкин ул мизгелдә, күләгәле урман ешкынлыгында, ханымның йөзенә текәлеп карагач, мин аның ирен үтермичә кала алмавымны аңладым.

Әмма мин аны ерткычларча үтерергә теләмәдем. Иң әвәл бавын чишеп, кулларын ычкындырдым. Кылычка кылыч киләчәкбез, дидем.

Сез агач төбеннән тапкан бау нәкъ әнә шул, мин ташлап калдырган бау булыр. Баудан бушанган ир, чыраен ямьшәйтеп, җәһәт кенә үрелеп кылычын алды да, һичбер сүз әйтмәстән, ярсып миңа ташланды. Бу сугышның нәрсә белән беткәнен инде сөйләп торасы юк. Егерме өченче селтәнүдә минем кылыч аның күкрәген үтәли тишеп чыкты. Егерме өченче селтәнүдә — зинһар онытмагыз моны! Хәзергә кадәр гаҗәпләнүдән гаҗизмен: дөньяда бердәнбер шул адәм кылычын минем кылыч йөзенә егерме тапкыр тидерә алды. (*Сөенечле елмаю*).

Канлы кылычы белән гәрселдәп егылуга мин артыма борылып карадым. Күз алдына китерә аласызмы, ханым беркайда да юк иде. Агач араларыннан эзләргә тотындым, коелган бамбук яфраклары өстендә дә берниндй эз юк, туктап тыңлаңып карыйм, үлем белән тартышкан ирнең бугаз гыргылдыгыннан кала берни ишетелми.

Әллә соң без сугыша башлагач, ханым ярдәмгә кешеләр чакырырга дип юлга таба йөгергәнме? Болай торсам, капкынга эләгәсемне аңлап, тиз генә үлән арасыннан теге ирнең кылычын, җәя белән укларын алдым да бая килгән сукмакка чыктым. Аланлыкта ханымның аты берни булмагандай үлән уртлый иде. Соңыннан ниләр булганын сөйләсәм, бушка тегермән тарту булыр иде. Ачыктан-ачык барын да сөйләп бирдем. Иң каты җәзага тарта аласыз мине. Кайчан да булса башымның колга очында кадалып торачагын мин күптән белә идем.

## Киемидза гыйбадәтханәсенә тәүбә итәр өчен килгән ханымның сөйләвеннән

Көчләгәннән соң зәңгәр киемле адәм, агачка бәйләнгән иремә таба борылып, мыскыллы көлә башлады. Иремә ничеккенәләр авыр булгандыр шул чакта! Ничек кенә бәргәләнмәсен, чорналган бау аның тәненә тирәнгәрәк бата барды. Мин, үз-үземне белештермәстән, аңа таба тартылдым. Әмма теге явыз миңа ачу белән тибеп, читкә алып ташлады. Шул мизгелдә иремнең күзләрендә әллә нинди очкын ялтырап

алды. Әллә нинди... аңлатып булмый торган... Әле хәзер дә, аның күз карашын искә төшерсәм, бөтен тәнем калтырый башлый. Сүз әйтерлек чарасы булмаганга, бәгырь авазын күз карашына салган инде ул. Ул караштa ачу да, газап чигү дә түгел, ул караштa миңа карата чиксез җирәнү хисе көйри иде. Теге адәмнең тибүеннән дә түгел, ә иремнең шул коточкыч карашыннан мин, үз-үземне белештермичә, кычкырып җибәрдем дә һушымнан яздым.

Аңыма килгәндә зәңгәр киемле адәм юк иде инде. Агач кәүсәсенә бәйләнгән ирем һаман да үз урынында иде. Яфраклар өстеннән көч-хәл белән күтәрелдем дә иремнең йөзенә сынап карадым. Күзләрендә һаман шул — өшеткеч җирәнү хисе. Ул чагында нинди тойгылар кичергәнемне нечкәләр аңлатыйм...

Оялу да, әрнү дә, ярсыну да барысы бергә буталды. Чайкала-чайкала ирем катына килдем:

«Ишетәсезме! Бу хәлдән соң мин сезнең белән бергә кала алмыйм. Мин үләргә тиеш. Әмма сез дә, сез дә исән калмаячаксыз. Сез минем мәсхәрәләнүемнең шаһиты булдыгыз. Моннан соң мин сезне исән калдыра алмыйм».

Бик авыр булса да мин аңа шулай дип әйттем. Ул сүзләрдән соң да иремнең чирканулы карашы үзгәрмәде. Күкрәгемне бәреп чыгарга җитешкән дулкынлануымны басарга тырышып, иремнең кылычын эзли башладым. Теге юлбасар алган ахрысы, кылыч кына түгел, җәя белән уклар да юкка чыккан иде. Бәхеткә, аяк астында аунап яткан хәнҗәргә тап булдым. Хәнҗәрне ике куллап кысып тоттым да иремә якын килеп: «Хәзер мин сезнең тормышыгызга чик куям, аннары үземнекенә», — дидем.

Ирем көчкә генә иреннәрен кыймылдатты. Төелгән бамбук яфраклары аша сүзе аңлашылмады. Әмма мин аның иреннәре кыймылдавыннан нәрсә әйтергә теләгәнен аңлап алдым. Һаман да җирәнеп, мине күралмыйча ул нибары бер сүз әйтте: «Үтер». Җүләрсенгән бер халәттә мин аның йөрәк турына хәнҗәремне сабына кадәр батырдым.

Аннан соң мин тагын аңымны җуйдым бугай. Һушыма килгәч, тирәягыма карадым, ирем һаман шулай, бәйләнгән килеш, тик сулыш алуы гына сизелми. Куе ылыс ботаклары арасыннан ап-ак чыраена баеп барган кояш нуры төшкән. Үксеп җылавымны тыярга тырышып мин аның бавын чиштем. Аннары... Аннары ни булды соң әле? Сөйләргә телем бармый. Үз-үземә кул салырга ихтыяр көчем җитмәде. Хәнҗәрне бугазыма китереп карадым, тау астындагы күлгә ташланырга дип килдем — булмады. Исән калдым, әмма моның белән һич тә горурлана алмыйм. Бәлки шәфкатьле, миһербанлы Каннон алиһә минем кебек беркемгә кирәксез заттан йөзен чөергәндер. Ни эшләргә соң миңа, ирен үтергән, юлбасардан мәсхәрәләнгән хатынга нишләргә соң? Нишлим, йә?! (*Кинәт өметен өзеп үкси башлый.*)

## Үтерелгән ирнең рухы күрәзәче аша ни сөйли

Үз эшен кылып канәгатьләнгән юлбасар, хатыным янәшәсенә утырды да, төрлечә юмалап, юата башлады. Минем авызга яфрак тутырылган, гәүдәм агачка бәйләнгән, шуңа күрә хатыныма күз белән генә ым кагам. «Ышанма син аңа! Аның бар әйткәне — ялган.» Мин аңа аңлатырга телим, ләкин хатыным яфрак өстендә тезләренә карап утыра бирә, бер дә минем якка күтәрелеп карамый. Юлбасарның сүзләрен бик игътибар белән тыңлап утырамы? Көнләшүдән мин үз-үземне чәйнәп ташларга җитәм. Юлбасар исә үз максатына ирешү өчен

сүзләрне майлагандай тезә генә. Болай тапланган килеш ирен белән яшәү кыен булачак. Аның белән калганчы миңа хатын булырга ризалашу кулайрак түгелме. Тупас кылануы да, имеш, бер күрүдә гашыйк булудан икән... әнә бит ул сүздә нинди тәвәккәллеккә барып җитте.

Ниһаять, хатыным миңа күтәрелеп карады. Йә, Ходай! Болай ук та чибәр итеп минем аны беркайчан да күргәнем юк иде әле. Нәрсә диде соң шул чакта юлбасарга чибәр хатыным? Мин инде хәзер теге дөньяда гизәм, әмма хатынымның җавабын искә төшергән саен җанымны үрсәләнү телеп ала. Хатыным шулчак болай диде: «Кая телисез, шунда алып китегез». (*Озак тынлык.*)

Гаебе ул гына түгел иде. Шул җавап өчен генә мин, чиксез караңгылык дөньясын колачлаганда, бу кадәр үк әрнемәс идем. Онытырлыкмыни: хатыным, саташкан кыяфәт белән, кулын биреп юлбасар артыннан иярде, агачлар арасыннан чыгып барганда кинәт үлек кебек агарды да, миңа таба төртеп күрсәтеп: «Үтерегез аны! Ул исән чакта мин сезнең белән була алмыйм!» — дип, акылдан язган сыман, кычкыра башлады. «Үтерегез аны!» — бу сүзләрнең рәхимсез давылы хәзер дә мине төпсез караңгылык дөньясына куалый. Кайчан да булса шушындый чирканыч сүзләрне кеше булып кеше әйтергә мөмкинме? Кайчан да булса... (*Гарьлектән шаркылдап көлү яңгырый.*)

Хатынымның бу сүзләреннән хәтта юлбасарның йөзе агарып чыкты. Җиңенә асылынып хатыным отыры кычкыра: «Үтерегез аны! Үтерегез!» Юлбасар «әйе» дип тә, «юк» дип тә әйтмәде, сынап бер карады да, капылт типкәләп, хатынымны яфраклар өстенә ыргытты, кулларын күкрәгенә кушырып минем тарафка борылды: «Бу хатын белән нишләргә? Чәнчелдеримме, әллә гафу итәргәме? Баш селкеп җавап бирегез». Үтерергәме? Шушы сүзләре өчен генә дә юлбасарны гафу итәргә әзер идем мин. (*Тагын озакка тын калу.*)

Мин икеләнеп торган арада хатыным кычкыра-кычкыра куаклар арасына ташланды. Юлбасар шул мәлдә үк аның артыннан омтылып караса да кул очыннан да эләктерә алмады. Боларның барын да мин саташкан чакта томанлы гына күрдем шикелле.

Хатыным югалганнан соң, юлбасар минем кылычымны алып, бәйләнгән бауны кисте. Китәр алдыннан үзалдына: «Хәзер инде үзем турында кайгыртырга кирәк»,— дип мыгырданганы хәтердә.

Ул киткәч, бөтен тирә-юнь тып-тын булып калды. Тирә-юнь дип, янәшәдә генә кемнеңдер үксегәне ишетелә ич. Баулардан арынам да игътибарымны туплыйм. Үзем үксим икән ләбаса! (*Өченче тапкыр озаклап тын тору.*)

Оеган гәүдәмне агач кәүсәсеннән көчкә аерып алдым. Яфрак арасыннан хатыным калдырып киткән хәнҗәр ялтыравына күзем төште. Күтәреп алдым да бер селтәнүдә күкрәгемә кададым. Кан ташкынының тамакка тыгылуын сизсәм дә тәндә бернинди авырту тоймадым. Күкрәгем суына башлагач, тирә-юньгә тагы да тирәнрәк тынычлык иңде. Илаһи тынлык иде ул! Куаклыкта ник бер кош аваз салсын. Агач кәүсәләрендә баеп барган кояшның сагышлы нурлары гына көйри. Шәфәкъ нуры... Бераздан ул нурлар да сүнде. Агач ябалдашлары да эреп югалды. Чалкан төшкән гәүдәмне йомшак тынлык көчып алды.

Менә шул чакта кемдер шым гына минем янга килде. Кем икәнен күрергә телим, әмма урманны куе караңгылык баскан иде. Әлеге кемдер күзгә күренмәс кулы белән хәнҗәрне күкрәгемнән сак кына суырып алды. Шунда ук минем авыз эче кан йомгагы белән тулды. Аннары мин теге дөньяның мәңгелек караңгылыгына кушылдым.

Марсель ГАЛИЕВ *тәрҗемәсе.*

*Шигырь булса — бар, булмаса — юк! Бу инде хакыйкать. Моннан байтак еллар элек Арча укытучылар әзерләү мәктәбендә һәйбәт кенә шигырьләр яза торган Рифә Сабирҗанова дигән тупырдап торган бер кыз бала бар иде. Кыз балаларның һәрберсендә булганча, ул югалып торды. Баксаң, инде югары уку йортын бетергән, ул гына да түгел, аспирантура да тәмамлап йөри икән. Алынган юнәлеше дә заманча — Гаяз Исхакый иҗаты. Инде бу кадәр мәртәбәле, олы эшкә алынган кешедән шигырь соралмый да сыман. Тагын да шул ук хакыйкатькә кайтабыз:*

*Шигырь булса — бар, булмаса — юк!*

*Ә ул бар. Шуңа күрә дә Рифәгә мин булганын югалтмыйча, киң күңелле булып, үзенә бирелгәнне шигырь сөючеләргә җиткерүен телим. Халкыбызның күз карасы булган өлкән әдәби журналыбызда сүз алуына, хәерле сәгатьтә, дим. Амин.*

Мөдәррис ӘГЪЛӘМ.

# Рифә Рахман

## Керфекле тәрәзәләр

**1. * * ***

Бер теләксез оча сыман кошлар бүген,
Киләксезгә кар ява күк болытлардан.
Тәрәзәгә керфек терткән күзләремнән
Эре яшьләр тәгәриләр тиктомалдан.

Очасымы килә, белмим, кошлар кебек,
Ак кар булып ятасымы килә җиргә?
Минем дөнья сезнеке күк киң түгел шул,
Сыеп беткән менә шушы тәрәзәгә.

Сыеп беткән менә шушы тәрәзәгә...
Кешеләрдән качып, сезгә торам карап.
Карашларым сезне куып җиткән саен
Күченәсез, очасыз шул ераккарак.

Сыеп беткән менә шушы тәрәзәгә
Уйлар уем, уймак тәнем, шигырем дә...
Тәрәзәдән эреп төшкән көн күзләре
Китә алмый кунып калган керфегемә.

**2. Чишелмәгән шигем**

Ничә тәүлек керфек какмый чыгам,
Төн йокысы бирми бер шигем.
Шигем шиңмәсен, дип, чынга ашсын,
Келәсен дә элми ишегем.

Ничә тәүлек тәгам капканым юк,
Касәләр дә юкса өстәлдә.
Кулларымнан әйбер коелса да,
Шигем торган саен өстәлә.

Бер жыр оча кунар урын тапмый,
Тел очына килә гел һаман.
Мин чыгарган җыр да түгел ләса,
Никтер исемең белән буталам.

Ничә тәүлек йокы бирми инде,
Сөя ахры, дигән бу шигем.
Килә-китсә, керми үтмәсен, дип,
Келәсен дә элми ишегем.

3. Көнне кичектерү

Бу төн үлмәс төсле һичбер.
Аңа Хода
Озын гомер юллагандыр туган чакта.
Тәрәзәләрдә утлар сүнә, утлар янар...
Төн китмәгән миннән, ничек бу таң атар?

Кадакландым тәрәзәнең янагына,
Пәйгамбәр күк, тошкән башны салдым кыңгыр.
Терел кабат, терелт көнне, дигән төсле,
Баш очында бөтерелә богаусыз җыр.

Тәрәзләре сүнгән йортлар нинди уйда,
Тәрәзләре янган йортлар нинди гамьдә?
Пәйгамбәр күк күтәрелсә иде тәнем...
Пәйгамбәр күк инсаң иде бу галәмгә.

4. Көчләү

Көйсез күзләремнән күчкән көйләр
Тынгы табып, сиңа кайтмаса,
Җырымда да сине көнләделәр,
Урладылар, диеп алдашма.

Беләсең лә, сиңа борчу салмый,
Җырың ашкан төнне чыгалмам:
Ишегемне ачып кертермен дә,
Мендәремә ятмый чыгармам.

Күрмәгәндәй үтәр күзләреннән
Көйсез көен кыйсам, тынармын:
Сүрүендә синең сурәт сүнгән
Мендәремне тешләп еларммын.

Үрсәләнеп чәчләремне сүтәр,
Сагынуга шунсыз чыдамам:
Күзләреннән купкан шигыреңне
Мендәремә ятмый чыгармам.

5. Өркү

Ни булды соң? Йокмый, йокмый
Керфегемә керфегем...
Йокымны дәшеп, тәрәзгә
Капланган сумала төн.

Юкәрен алган юкә күк,
Ялангач мин, йокысыз —
Кара төн кайткан тәрәздән
Өркегән ялгызак кыз.

Ни булды соң? Йокмый, йокмый
Керфегемә керфегем...
Юкәләрен алган юкә күк
Өркетә сумала төн.

6. * * *

Күрим, дисәң, пәрдәләрем ачык,
Дәшим, дисәң, үзем шунда гына.
Вәгъдәсеннән узып көткән кыз шул...
Белми узасыңдыр ни уйларга.

И син кара,
И син, усал болыт!
Пәрдә тартмый мин бит сине көтәм.
Моңаерга әзер күзләрем бар...
Серләреңне йөртер, сүтеп китсәң.

Бер сәбәп юк, сәбәп моңаерга,
Уйланырга, керфегемне төртеп.
И син, болыт,
Елап яумасаң да,
Хушлаша күр,
Сагыш җиле кертеп.

7. * * *

Ни дип әле: сагын мине, диеп киттең?
Ни дип әле сөенергә тиеш гел син?
Соңгы комы агып беткән сәгать көтәр,
Ә мин менә һич тә сине көтмим, көтмим!

Ни дип әле: мине уйлап, елый күрмә,
Татлы гына булсын, дидең, синең өмет?!
Мин бит — өзәр усал җилләр көтеп арып,
Өрәңгедә кипкән соңгы яфрак түгел!

Ни дип әле: сагын мине, диеп киттең?
Сагынырга тиеш түгел ник үзең дә?
Минем уйдан өркеп калган кем йөрәге
Япан кырлар аша төндә миңа йөгерә?..

**8.** * * *

Күзләремә кунган төс — син,
Күз агыма кунган төс.
Сагышын салган чагында
Сарысын калдырган көз.

Күзләремә кунган төс — син,
Күз алмама тулган төс.
Шул сагыш карап торсынга,
Кара тап калдырган көз.

Җибәр, дисен, күзләреңнән,
(Хәлемне белү кая?!)
Китәсең килсә, кайгымның
Карасын кыеп кара,
Карасын кыеп кара...

**9.** Соңгы шигырь

Мин язмам да дигән идем кабат,
Уйламый да соңгы шигырь яздым сиңа.
Җырламадым, мәхәббәткә мәдхияне
Ак кәгазьгә агыздым, дип, язгы суда.

Син укырсың аны, морзе әлифбасын
Аңлый алмый газапланган бала сыман.
Мин берьюллык шигырь язып киттем сиңа,
Язгы сулар туңдырса да, борылмам.

Кызганмадым.
Тәнен камчы телгәләгән
Төсле чаж-чож килде дәфтәр бите,—
Соры асфальт буйлап торур аякларым
Сиңа соңгы үпкә шигырен язып китте:
«Кит-тем. Кит-тем...»

**10.** Ялгызак сагыш

Елларымның чираты юк, исәбе юк.
Үтә генә, җәйләр-кышлар сырлый-сырлый.
Очып китәр тузганак күк ап-ак — көзнең
Хушлашканда тәрәзәгә кунган тыны.

Үтә гомер, җәйләр-кышлар алмашынып.
Үтә үзе киткән көзләр исәбендә.
«Утызда да кыз!» — дип суккан сәгатемнең
Тавышыннан үзем куйдым исәнгерәп.

Сыгылмасам, сарылмасам иде... (ничек?)
Үземнән дә еламсырак кәүсәләргә.
Утлы алма сузар төсле кызыл көзем
Әче миләш ташлап качкан касәләргә.

## Жорҗи Амаду

# ГАБРИЭЛАНЫҢ ГЫЙШКЫ

*Әллә сабый бала булып кала,*
*әллә халык кызы булып бара —*
*анысын кем белә...*

*Бер генә халык та фәкать үз язучылары иҗат иткән әсәрләрне уку белән чикләнми. Нинди генә телдә язылса да, арада иң камил повесть яки роман бүтән телләргә дә тәрҗемә ителә. Бу өлкәдә азмы-күпме хезмәт куючы кеше буларак, мин үзем бөек гуманистларга баш иям һәм кайсыберләренең (Л. Толстой, В. Шишков, А. Толстой, Э. Войнич) китапларын туган телебезгә тәрҗемәләүдә көчемне кызганмыйча эшлим. Бүгенге көндә, миңа калса, дөньяда иң олуг гуманист әдипләр — Г. Гарсиа Маркес, Ж. Амаду һәм Ч. Айтматов.*

*Бразилиянең мәшһүр әдибе, егермедән артык роман авторы, академик, үз илендә һәм дөнья күләмендә зур бүләкләргә лаек булган, шул исәптән Халыкара Ленин премиясе лауреаты Жорҗи Амаду 1912 елны Баийада туа. Халык тормышын ул бизәмичә-нитмичә тасвирлый, хакимият тарафыннан кыерсытылган фәкыйрь-фөкарәне, гелбирә-фәхишәләрне кызганып кына калмый, бәлки аларның яхшы сыйфатларын ачып сала, кешелекле якларын күрсәтә, аларны тасвирлаганда буяуларны мул сала.*

*Язучының иҗатында аеруча зур уңышка ирешкән, хиссияткә гаҗәеп дәрәҗәдә бай романы — «Габриэланың гыйшкы» дигән әсәре. Автор үзе нурлы китабым дип бәяләгән әлеге әсәрдә гарәп егете Нәсиб белән искиткеч дәртле мулатка (берсе ак тәнле, икенчесе кара тәнле ата-анадан туган, көяшта нык янган сыман каратут тәнле) Габриэла арасындагы мәхәббәт хәлләрен зур осталык белән сурәтли.*

*Үзе чибәр, үзе яшь, үзе көчле булганга ярата кыз бар хуҗасын. Әмма аның өендә кол яки җария хәлендә бикләнеп, аңа гына карап гомер кичерергә һич риза түгел мулатка. Ул ирекне һәммә нәрсәдән артыграк саный, аның дәрте ташып тора, ул иреккә омтыла, азатлыкны яулап ала. Хәтта әле мәхбүс итеп кошчыкны да асрарга теләми — читлек аның өчен үлем белән бер. Әйе, иректә яшәүгә ни җитә!*

*Җир шарында бүген Латин Америкасы әдәбияты бәйге тота. Безнең укучы да аның һич югы иң-иң гүзәлләрен үзебезнең ана телебездә укырга тиеш, ул моңа лаек, дигән фикер мине Колумбия язучысы Г. Гарсиа Маркесның «Ялгызлык» дигән романын һәм Бразилия язучысы Ж. Амадуның арада бер камил әсәрен татарча язып чыгарга мәҗбүр итте.*

*Жорҗи Амаду 1954 елны Казанга да килеп китә. Кыска гына вакыт эчендә ул язучылар, сәнгатькәрләр белән аралашып, татар дөньясына, мәдәниятенә күз салып, Академия театрында спектакль карарга да өлгерә.*

*Мәһабәт гәүдәле, куе кара чәчле, каратут матур йөзле, бөтен дөньяга мәшһүр әдипне Казанда әле дә яратып искә алалар.*

*1958 елны язылып, оригиналда, ягъни португал телендә 60—70 басмада дөнья күргән, бик күп телләргә тәрҗемә ителгән әлеге романны татар укучысы да, ниһаять, үз ана телебездә укыячак. Хәзергә шуннан бер өзек тәкъдим итәбез.*

**Кыям МИҢЛЕБАЕВ.**

# Нәсибнең пешекче яллавы яки мәхәббәтнең бормалы юллары

Базарда инде чатырларны сүтеп, товарларны алып китеп яталар иде. Нәсиб, базар аша узып, тимер юл корылмалары арасыннан атлады. Конкиста калкулыгы итәгендә — «Коллар базары». Качаклар килеп өерләре белән урнаша һәм берәрсенең килеп эшкә яллаганын көтеп ята торган урынны кемдер әнә шулай атаган...

Нәсиб качакларны караштырып йөрде. Карты-яше өмет белән аңа күзләрен төбәгән. Хатыннар азрак күренә, аларның да итәкләренә чытырдап бала-чагасы ябышкан. Эзли торгач, ул кырык-илле яшьләрдәге озын буйлы, таза гына хатынны күреп алды.

— Ирем юлда үлеп калды шул, сеньор...

— Аш-суга осталыгың бармы соң?

— Мактанырлыгым юк шул, сеньор...

Йа раббем, каян табарга инде бу пешекчене? Карт кызларга тау хәтле акча түли алмый ич инде. Үч иткәндәй, бар тулы халык бит әле: бүген кеше үтерәләр, иртәгә күмәләр... Җитмәсә үзе дә иртә-көндез Коэльо кунакханәсендә тукланырга, аның тәмсез ашларын ашарга мәҗбүр бит әле. Пешекчене Аракажадан китертсәсе, юлын-фәләнен түлисе булыр, ахры. Нәсиб картаеп эштән чыккан бер карчык алдына килеп туктады. Таякка таянып йөри икән үзе. Ильеуска ничекләр генә килеп җиткәндер инде, бер ходай белә, тик инде Нәсибнең өенә барып та җитә алмастыр — юлда җан бирер төсле... Берәр эшкә яраудан битәр, үзен карарга кеше кирәк моның. Кипкән, бетәшкән, тәмам кешелектән чыккан, бичара... Күпме хәсрәт бу дөньяда!

Шул чагында икенче хатын-кыз якынлашты, өсте-башы телгәләнеп беткән, пычрак каткан йөзенә карап яшьме, картмы икәнен әйтерлек түгел, тузаннан керләнеп беткән чәче тузгыган, үзе яланаяк. Аның кулында кружка белән су булып, карчыкның дерелдәгән кулына тоттырды. Карчык сусаган булгандыр, шундук эчәргә ябышты.

— Алланың рәхмәте яусын үзеңә.

— Исең китмәсен лә, әбекәй...— Тавышына караганда, бу япь-яшь кыз булырга тиеш, Нәсиб килгәндә җырлаучы шул үзе түгел микән әле...

Полковник Мелк яллаган кешеләре белән тимер юл вагоннарына ышыкланды, иңенә гармун асканы гына, туктап, кул болгап саубуллашты. Чәчби дә аңа кулын болгады, аннары карчыкның кулыннан буш кружканы алды да китмәкче булды. Ләкин бөкшәйгән карчыкка хәйран булып карап торган Нәсиб кинәт кенә:

— Әбиеңме бу синең? — дип сорап куйды.

— Юк, сеньор.— Чәчби тукталды, тешләрен җемелдәтеп көлеп җибәрде, һәм Нәсиб аның чыннан да япь-яшь икәнен абайлады.— Без аны дүрт-биш көн элек кенә юлда очраттык.

— Кемнәр инде ул без дигәнең?

— Әнә ич...— Чәчби, бер төркем качаклар ягына ымлап, чишмә челтерәгән тавышлар чыгарып көлеп җибәрде.— Без барыбыз да бер якныкылар, шуңа бергә килдек. Корылык һәммә нәрсәне һәлак итте, һичбер дым өсәре калдырмады, агачларны корытып бетерде. Юлда без, үзебез шикелле, корылыктан качып килүчеләрне тагын очраттык.

— Синең туган-тумачаң бардыр инде?

— Юк шул, сеньор. Җир йөзендә беркемем калмады. Абзый тиешле кешем бар иде, юлда килгәндә Җеремоабога җитә алмады, мескенем, җан бирде. Чахотка...— Ниндидер көлке сүз әйткәндәй, янә дә көлеп җибәрде.

— Бая син җырламагансыңдыр бит?

— Мин, сеньор. Арабызда гармунчы бер егет бар иде, ул плантаци-

ягә ялланды, бу якларда баерга исәбе... Җырлаганда авырлык онытыла бит ул...

Чәчби кружка тоткан кулын биленә таянып басып тора иде. Нәсиб аны тузан катламы үтәли күрергә маташты. Болай нык булырга тиеш тә бит...

— Нәрсә эшли беләсең инде?

— Аз-маз барын да булдырам, сеньор.

— Кер юа беләсеңме?

— Кем белмәсен икән? — дип гаҗәпләнде теге.— Суы белән сабыны гына булсын.

— Аш-су ягына ничегрәк?

— Мин бер байда пешекче булып эшләгән идем...— Шулай диде дә, ниндидер күңелле хәл исенә төшкәндәй, янә челтерәп алды.

Әллә әнә шул сәбәпле-сәбәпсезгә көлүен күреп, әллә бүтәнгәме, әмма Нәсиб аны кулай тапмады. Сертанда ачлыкка интеккәннән соң, эшкә ялланасы килеп, сиңаниләр сайрамас. Йә, нәрсә пешерә белсен инде бу? Тозлаган итне табага салып кыздыра аладыр яки фасоль пешерә аладыр — бар белгәне шул булыр. Аңа бераз өлкәнрәк яшьтәге, бераз җитдирәк, чиста-пөхтә, Филомена шикелле уңган-булган хатын кулайрак булыр иде. Иң әүвәл, аш-су ягына кулы ята торган, тәм-томның ни икәнен таный торган, барга илтү өчен тәмле-томлыны хәстәрли алырдай булсын иде.

Ә Чәчби исә, аңа төбәп караган көе, нидер көтеп торуын белде. Нәсиб ни дип җавап бирергә дә аптырады, кулын гына селтәде.

— Ярый, хуш.

Борылып китте инде югыйсә Нәсиб, тик шул чакны үз артыннан:

— Чибәр дә соң! — дигән искиткеч мөлаем тавыш ишетте.

Нәсиб туктап калды. Нишләптер ул үзен чибәр дигәннәрен хәтерләми, бәләкәй вакытында әнисе әйтә торган иде дә бит әйтүен... Аптырарсың да шул.

— Туктале.

Кабат караштыра башлады. Әллә булмаса үзен сынап карарга микән?

— Аш-суга осталыгым бар, дисең инде алайса?

— Алып карагыз, сеньор, шунда күрерсез.

Һәй, ашка-суга кулы бармаса, һич югы өйне җыештырыр, өс-башны юыштырыр.

— Хакың күпме?

— Хакны, сеньор, аны сез куясыз инде. Теләгәнегезне түләрсез.

— Башта карыйк әле, нәрсә эшли беләсең икән. Хакың күпме торганны шуннан соң хәл итәрбез. Ярыймы?

— Ярар, сеньор, сез дигәнчә булыр.

— Алайса, ал төенчегеңне.

Чәчби янә ап-ак тешләрен елтыратып көлеп җибәрде. Нәсиб арыган иде, ялгыштым бугай, дип уйлады. Сертан кызын кызгануы аркасында өенә бер бәла өстерәп алып кайта бугай. Хәзер инде үкенүдән файда юк. Ичмаса кер юа белсәче...

Бәләкәй генә төенчектә кызның юклы-барлы әйберләре иде. Нәсиб ашыкмыйча гына кайту ягына юлланды, кызый аңардан биш-алты адым арттарак атлады. Тимер юлны чыккач та, Нәсиб артына борылып:

— Исемең ничек соң? — дип сорады.

— Габриэла булабыз, сеньор.

Нәсиб аны Лидейре-де-сан-Себастьян урамындагы өенә алып кайтты. Ачкыч белән ишекне ачыйм дигәндә генә, ачык тәрәзәсеннән күрше карчыгы дона Арминда күренде, ул дер-дер калтырана иде.

— Сеньор Нәсиб, нинди эш инде бу?! Намуслы, диндар хатын булып күренгән иде ләбаса, ходайның бирмеш көнендә чиркәүгә килер иде. Шуңа күрә дә мин...— Габриэланы күреп, сүзен әйтеп бетерә алмады.

— Асрау яллалдым әле. Аш пешерер, кер юар.
Дона Арминда, хезмәтченең буен-сынын үлчәгән-бәяләгәндәй, аны баштанаяк күздән кичерде. Аннары ярдәм кулы сузар булды:
— Кызым, берәр нәрсә кирәк булса, тавыш бирерсең. Күрше хакы — тәңре хакы, ярдәмем тими калмас. Бүген кич кенә өйдә була алмам. Деадороларда бүген сеанс буласы, картым мәрхүм белән сөйләшәсем бар... Синьязиньяның да күренүе бик ихтимал...— Аның күзе әле Габриэлага, әле Нәсибкә йөгерде.— Кыз бала яллладыгызмыни? Филомена кебек кортка кирәкмимени инде? — дип, мәгънәле генә итеп көлеп җибәрде.
— Башкасын таба алмадым шул:
— Нәрсә димәкче идем әле... Бу хәлнең килеп чыгасын мин алдан ук белдем. Шулай беркөн урамда теш табибын очраттым. Шул көнне үк сеанс та булды, бер атна элек кенә әле. Доктор Осмундога күз салуым булды, ирем мәрхүмнең: «Аны күрүеңә ышанма, мөет инде ул»,— дигәнен ишеттем. Мәрхүм шаяртып әйтә, дип торам. Картымның алдан хәбәр итүенә менә бүген инандым.
Ул арада Нәсиб ишеген ачып, өенә керде. Дона Арминда Габриэлага табан борылды.
— Берәр нәрсә кирәк икән, үземә тавыш бирмичә калма. Иртәгә сөйләшербез әле. Ярдәмем тимичә калмас: Нәсиб миңа үз улым шикелле. Минем Шиконың хуҗасы ул...
Нәсиб Габриэлага элек Филомена яшәгән, ишегалдына чыга торган бүлмәне күрсәтте,ниләр эшләргә тиеш буласын аңлатты: өй җыештырасы, кер юасы, аңа аш пешерәсе икән. Барда сату өчен тәмлетомлыны, кабым-төшемне гел телгә дә алмады, әүвәл кулыннан нинди эш килгәнен күрергә ниятләде. Утыз тугызлы Шико базардан алып кайткач азык-төлек куя торган чоланны күрсәтте. Үзе тизрәк киту ягын карады: кечкенә якта барына халык килеп тулачак, аның әле тамагына да капканы юк. Габриэла кунак бүлмәсендә тәрәзәдән күзен шар ачып кичке диңгезне күзәтте, аның мондый дәрьяны беренче күрүе иде. Хушлашканда хуҗа аңа:
— Һәйбәтләп юын, синә үзеңне рәткә китерергә кирәк,— диде. (...)
Үр менеп тыны беткән хәлдә ачкыч белән ишеген ачканда, Нәсиб залда ут янганын абайлады, әллә караклар керде микән, дип шикләнә калды. Ихтимал, яңа хезмәтче сүндерергә онытkандыр, дип тә уйлады.
Акрын гына керсә, ни күрсен — Габриэла урындыкка утырган көе йоклап киткән, озын чәчләре иңнәренә таралып төшкән, юып тараганнан соң чем-кара төскә кергән, бөдрәләнеп киткән. Өстендә — төенчегеннән алып кигән, бераз өшәнгән булса да пөхтә күлмәк, итәгенең ертыгыннан каратутлы, дарчин төсендәге тәне күренә, сулу алганда күкрәге бер күтәрелә, бер төшә, иреннәре елмая иде.
— Сөбханалла! — Нәсиб, үз күзләренә үзе ышанмыйча, туктап калды.
Ул сокланудан гаҗиз иде. Юл тузаны шундый гүзәллекне күрсәтмичә торган микәнни? Урындыкта утырган көе йокыга талган Габриэланың барлык кыяфәте — салынып төшкән йомры беләге, йокы аралаш елмайган каратутлы йөзкәе картинага язып куярлык матур иде. Ничәләрдә булыр икән бу? Тәне белән — яшь-җилкенчәк, бите белән — сабый кыз бала. Гарәп соклануын яшерә алмыйча:
— Бу чаклы да булыр икән! — дип үзалдына пышылдап куйды.
Аның тавышы кызның колагына керде булса кирәк, Габриэла кабаланып күзен ачты, ләкин үзе шундук елмайды да — аның белән бергә зал да елмайган сыман булды. Кыз урыныннан кубып,күлмәген рәтләде һәм шул чагында сабыр, ап-якты ай нурына охшап калды.
— Ятып йоклыйсың бар иде...— Нәсиб шуннан гайре сүз әйтергә үзендә көч тапмады.
— Сеньор миңа берни әйтмәде шул...

— Ниткән сеньор ди ул?

— Сез... Керләр юдым, өйне җыештырдым да сезне көтеп утырганда йоклап киткәнмен...— Тоньяк-көнчыгыш халкына хас булганча, ул бераз көйләбрәк сөйли иде. Әллә чәченнән, әллә инде баш чүмеченнән кәнәфер исләре бөркелә.

— Чыннан да, аш-суга осталыгың бар дисеңмени?

Электр лампочкасының нурлары Габриэланың чәче белән уйнады, аның күз карашы түбәнгә төбәлгән иде, уң аягы биеп китәргә иткәндәй идәндә шуып йөрде.

— Бар, сеньор, бар. Байларда асрау булган идем, шунда өйрәндем. Аш-су миңа җан рәхәте...— Габриэла елмаеп куйды, һәммә нәрсә елмайды, ул арада урындыкка утырып өлгергән гарәп тә елмаймыйча булдыра алмады.

— Чынлап та аш-суга кулың ята икән, мин сиңа һәйбәт хезмәт хакы билгеләрмен. Аена иллешәр мильрейс алырсың. Башкаларга егермене, күп дигәндә утызны түлиләр. Үзеңә генә читенгә килсә, ярдәмгә берәр кыз алырсың. Филомена кортка һич риза булмады. Эштән үлмәм әле, бернинди ярдәмчегә мохтаҗлыгым юк, ди торган иде.

— Миңа да...

— Хезмәт хакы шулай җитәрме соң?

— Үзегез күпме түләсәгез, шул җитәр...

— Нилләр белгәнеңне иртәгә күрербез. Иртәнге якта хезмәтче малайны җибәрермен. Барда гына ашыйм мин... Ә хәзер...

Янә дә нинди әмер булыр икән дип, Габриэла елмаеп басып тора бирде. Якты нур аның чәчендә уйный, кәнәфер исләре бөркелә иде.

— Хәзер бар, йокла, вакыт соң инде.

Габриэла, арт санын чак кына чайкап, ишеккә юнәлде. Нәсиб аның төз аякларына, итәк ертыгыннан күренгән дарчиндай карасу ботына сокланып карап калды. Кыз аңа табан борылды да:

— Алайса, тыныч йокылар, сеньор...— диде һәм караңгы коридорга кереп югалды.

Нәсиб аның пышылдап кына: «Чибәрем...» — дип өстәгәнен ишеткән төсле булды, урыныннан торып, аны кире дәшә язганнан калды. Юктыр, ул сүзне коллар базарында гына ишеткәндер. Чакырып куркытуың бар, шундый самими кыяфәтле кызыйның гыйффәтле булуы да ихтимал бит әле... Ашыгып ярамас. Нәсиб пинжәген салып, урындык башына элде, күлмәген салып ташлады. Бүлмәгә кәнәфер исе таралган иде. Иртәгә ул аңа ситсы күлмәк белән артсыз башмак алып кайтып бүләк итәрдер. (...)

Барында халык кими төшкәч, Нәсиб иртәнге ашны ашарга дип Шиконы кайтарып җибәрде.

— Юл уңаенда миңа да ашарга ала килерсең,— диде.

Иртәнге аш вакытында бар бушап кала. Нәсиб шул арада кассаны тикшереп, керемен-чыгымын исәпли. Аннары акрынлап халык җыела башлый. Иң алдан Тонико Бастос килә дә, «аш сеңдерү» сылтавы белән кашаса (шикәр камышыннан ясалган аракы) белән өче сыра эчә. Бүген һәркемнең телендә кичә шәһит киткән гашыйкларны күмү генә булды, аннары Тонико төнлә белән кабареда Нәсиб киткәннән соң нилләр булып алганын сайрады. Полковник Рибейриньо эчеп исергән икән дә өстерәп өенә кайтарып куярга туры килгән үзен, баскычтан төшкәндә өч мәртәбә коскан да өстен-башын пычратып бетергән икән.

— Рибейриньо баш-аягы белән гашыйк инде...

— Мундиньо Фалкан нишли соң?

— Бик иртә китте ул. Егетләр, минем монда катнашым юк, үзегез чамалагыз, дигән була. Моны ишеткәч, мин дә...

— Һөҗүмгә ташландыгызмы?

— Дөресрәге, уенга катнашырга исәбем.

— Анабела үзе чиертәме соң?

— Ни дип әйтим икән? Бөтенләй үк читкә какмый сыман.

— Ире нишли?

— Полковник яклы анысы. Рибейриньоның гадәт-холыкларын яхшы өйрәнгән. Мине якын да җибәрми. Хатыны полковникка елмайсын, аның белән танцевать итсен, аңа сарылсын, косканда җайлырак булсын өчен башын тотып торсын — һич каршылыгы юк. Мин якын бара башласам — килә дә керә икебезнең арага. Профессиональ альфонс[1] инде, һич тә бүтән түгел.

— Эшне бозарсыз дип шүрли булыр.

— Безгә калганы да җитәр. Полковник хакын түләсен дә, мин ял көннәрен алырмын. Ире дә әрсезләнүдән ахыры бер туктар әле. Минем бу яклардагы сәяси лидер улы икәнемне ишеттергәннәрдер инде, ара бозасы килмәс.

Шико ашарга алып килде. Нәсиб буфет яныннан чыгып бер өстәл янына җайлап кына урнашты, муенына тастымал бәйләде.

— Ниндирәк пешекче икәнен күрик әле...

Тонико:

— Яңасымы? — дип кызыксынды.

Шико иренеп кенә:

— Моныңише каратутлы чибәрне гомеремдә дә күргәнем юк иде,— дип теленә салынды.

— Сез бит миңа аны албасты сыман, дигән идегез. Оят та юк икән үзегездә, дустыгызга дөресен әйтмисез!

Нәсиб савыт-савыт ашларны тезеп куйды. Тавык кабиделы[2], кыздырылган тозлы ит, дөге, фасоль һәм телем-телем бананның исенә исереп:

— О-о! — дип соклануын белдерде.

Тонико малайдан сораштыруын белде:

— Дөрестән дә чибәрмени?

— Бик тә инде менә...

Тонико тәлинкәләргә иелеп:

— Шуны, пешерә белми, дисезме? Бу чаклы да ялганчы төрек булырсыз икән. Авыз суларын китерә ләбаса...

Нәсиб:

— Монда икебезгә дә җитәрлек, бераз авыз итегез ичмасам,— дип, аны да табын янына чакырды.

Бико Фино сыра шешәсен ачып, өстәлгә китереп куйды.

Нәсиб:

— Хәзер нишли соң? — дип Шикодан сораштырды.

— Әни белән сөйләшә калды. Сөйләвен минем әни сөйли инде, ул тыңлый да көлә генә. Аның көлүен күрсәгез, сеньор Тонико, акылдан язарсыз.

Ул арада Нәсиб ризыктан җитешеп:

— О-о! — дип кабаттан кычкырып җибәрде.— Сеньор Тонико, оҗмах сые лабаса! Ходайның биргәненә шөкер, хөрмәт күрәселәрем бар икән әле.

— Табында да, түшәктәдәме, ә, төрек?

Нәсиб шартлаганчы ашады да, Тониконы озаткач, гадәтенчә, агачлар күләгәсенә чыгып, шезлонгка сузылды. Узган атнадагы Баийа газетасын алып, сигара кабызды, мыегын сыйпаштырды. Иртәнге моңсулыгыннан арынган, дөньядан разый иде Нәсиб. Беравыктан абзасының кибетенә кереп, арзанлырак кына бер күлмәк, өйдә өстерәргә башмак

---

[1] Альфонс — Франциядә хатыннар тапкан малга яшәүче фәхеш ир-атны А. Дюманың «Мосье Альфонс» дигән комедиясенең персонажы исеме белән шулай атаганнар.

[2] Кабидела — кошның эчен-башын каны белән бергә томалап пешергән ризык.

сатып алыр. Пешекче белән әйбәтләп сөйләшергә кирәк булыр: бар өчен кабым-төшемне, тәмле-томлыны хәстәрләсен. Тузанга батып беткән, сәләмә киемле пешекче аш-суга шулай оста булыр дип, тузан катламы астыннан шул чаклы нәфис, шул кадәр гүзәл сылукай килеп чыгар дип кемнең башына килсен... Нәсиб тынычланып йокыга талды. Диңгез җиле аның мыегын назлап сыйпаштырды. (...)

Нәсибнең бик тә эчәселәре килә иде, су эчәргә дип кухняга юнәлде. Шул чагында абзасының кибетеннән Габриэлага атап алган күлмәк белән өйдә кияр өчен артсыз башмак салынган пакет күзенә чалынды. Нишләргә? Иртәгә үз кулына тапшырыргамы, әллә инде хәзер ишеге төбенә илтеп куяргамы? Иртән уянып китәр дә рождество күчтәнәчләрен сөенер. Нәсибнең авызы ерылды, төенчекне култык астына кыстырып, голт-голт итеп су эчте: банкет вакытында официантларга булышып йөргәндә күбрәк эчелгән иде шул, күбрәк...

Күктәге ай ишегалдында үсеп утырган җимеш агачларын яктырта иде. Хезмәтче бүлмәсенең ишеге ачык — эссе булгандыр инде, эсседәндер. Филомена караклардан куркып ачкычын борып куяр — бар байлыгы булган әүлия сынын шул рәвешле саклар иде. Ай яктысы бүлмәнең эченә үк үтеп керә икән ләбаса. Нәсиб тә керде — пакетны Габриэланың аяк очына куярга ниятләде. Иртән уянып киткәч, шаккатсын әле. Ә инде иртәгә кич, боерган булса...

Күзе караңгыга ияләште. Ай яктысы караватка төшә, Габриэланың ботын яктырта иде. Нәсиб, дер калтырап, шуңа текәлгән көе катып калды. Бу төнне ул Ризолета кочагында уздырырга өметләнгән иде, зур шәһәрдән килгән фәхишәнең үтә зур осталык белән назлавын татырга дип кабарега ашкынган иде — өметләре акланмады, дәрте басылмады. Менә хәзер инде Габриэланың каратутлы тәнен, караваттан салынган аягын күреп тора, ямаулы одеял астында яткан гәүдәсен тоташы белән гүя күз алдына китерә, ә инде кәнәфер исләре тәмам башын әйләндерә...

Габриэла төшләнеп кенә бераз кыймылдады. Нәсиб бусаганы атлап керде дә, кызга кагылырга базмыйча, кулын сузган килеш идән уртасында тораташтай катып калды. Ашыгасы түгел. Пешекчесез калсаң, мондый уңганны каян табарсың тагы?! Пакетны караваткырыена куярга да чыгарга. Иртәгә өенә иртәрәк кайтыр да ышанычын яулап алырга тырышыр, кыз аныкы гына булыр.

Төенчекне куйган чакны аның кулы дерелдәп китте. Габриэла дерт итеп уянып, күзен ачты, нидер әйтмәкче булды, тик инде үзенә төбәп карап торган хуҗасын күреп алды, тәнен капларга дип одеялын алырга сузылды, әмма одеялы ни рәвешледер идәнгә шуып төшкән иде. Кыз, оялчан елмаеп, калкынды да караватына торып утырды. Ай яктысына эләккән күкрәген томалап-нитеп маташмады. Хуҗасы тотлыга-тотлыга:

— Менә үзеңә бүләк алып кайткан идем. Аяк очына куеп калдырмакчы булган идем. Әле генә кердем...— дип сөйләнде.

Кыз елмаеп куйды: курыкмавын аңлата идеме бу елмаю, хуҗасына кыюлык өсти идеме — белмәссең. Сабый да сабый, бу да сабый: ботлары, күкрәкләре ап-ачык булуга да карамастан, гүя ул бөтенләй гөнаһсыз баладай, берни белмәгәндәй, тартынмады-нитмәде, төенчеккә сузылды.

— Рәхмәт яусын үзегезгә, сеньор, сезне Ходай тәгалә үзе сакласын.

Кыз пакетның бавын чишкән арада Нәсиб күзе белән ашарга җитешеп аны караштырды. Менә Габриэла күлмәкне күкрәгенә кысты да кулы белән сыйпарга тотынды.

— Бигрәк килешле инде...

Кыз башмакны караган арада Нәсибнең тыны кысылды.

— Сеньор бигрәк юмарт инде...

Нәсибнең түзәр хәле калмады — тыннары кысылды, күзаллары томаланды, кәнәфер исләреннән башкае әйләнде. Габриэла, әйбәтрәк

күренсен дип, күлмәкне читкәрәк сузды, янә ачык күкрәге пәйда булды.

— Бик күркәм... Әүвәл сезне көттем, иртәгәниләр пешерергә икәнен әйтерсез дигән идем. Сез кайтмыйсыз да кайтмыйсыз, шуннан яткан идем менә...

Нәсиб көч-хәл белән:

— Эшем күп булды шул,— дия алды.

— Бичаракаем... Арыгансыздыр инде? — дип, кыз күлмәкне төреп, башмакны идәнгә куйды.

— Кая, үзем элеп куйыйм,— дип, Нәсиб аның кулына орынды.

Габриэла:

— Нинди салкын кулыгыз...— дип көлеп җибәрде.

Нәсибнең бүтән түзәр әмәле калмады, беләгеннән эләктереп алды, икенче кулы ай яктысында аермачык күренеп торган күкрәгенә үрелде. Габриэла аны үзенә тартты.

— Чибәркәем...

Кәнәфер исләре бөтен бүлмәгә таралды. Габриэланың тәненнән эссе бөркелде, Нәсибнең бөтен гәүдәсен ботереп кенә алды, тәнен көйдерде, ай яктысы түшәккә сеңде. Үбешкән-сөешкән арада Габриэланың пышылдаган тавышы ишетелеп-ишетелеп алды:

— Чибәркәем...

## Чәченә чәчкә кадаган Габриэла

Ильеус мәйданнарындагы түтәлләрдә төрле гөлләр гөрләп чәчәк ата, анда роза да, алтын чәчәк тә, дәлия-георгин да, тырнак гөл дә бар. Яшел аланнарда кып-кызыл тамчылар булып «сәгать унбер» чәчәгенең таҗ яфракчыклары балкып утыра. Урман ешлыгында, Мальядо зонасында, Уньан һәм Конкиста әрәмәлекләренең дымлы җирендә әкияттәге төсле күке яше чәчәк ата. Ләкин шәһәрдә чәчәкләрнең хуш исләре дә, урман-бакчалардан килгән исләр дә өстенлек итми. Ильеуста кипкән какао орлыгының исе хөкем сөрә. Складларда какаоны капчыкларга үлчәп тутырган җирдән дә, порттан да, экспорт фирмалары урнашкан биналардан да галәмәт көчле ис тарала, читтән килүчеләрнең бу истән башлары әйләнә, ә шәһәр кешеләре ияләшеп беткән инде, сизмиләр дә. Какао исе шәһәр өстендә генә түгел, бәлки елга өстендә дә, диңгез өстендә дә йөзә-айкала иде.

Плантацияләрдә какао өлгергән чак. Пейзажда сары төснең төрле төсмерләре өстенлек ала башлады, хәтта әле һава да алтынсу төскә кергәндәй тоелды. Уңыш җыяр чаклар якынлашып килә, ә уңыш быел галәмәт бай, искиткеч мул булырга тиеш иде.

Габриэла тәмле-томлы салып олы бер поднос әзерләде, икенчесенә, тагын да зуррагына — акараже, абара, тәрәч балыгы белән пешергән пирожки-мазар, куырмасын-монысын тутырды. Негр малае Туиска, тәмәке төпчегән суыра-суыра, аңа барда ишеткәннәрен, үзенә кызык тоелган җыен вак-төяк хәбәрләрне сөйләде: әйтик, Мундиньо Фалканның ботинкасы унау икән; пляжда футбол ярышы буласы икән; мануфактур кибетеннән әйбер чәлдергәннәр икән; озакламый «Зур Балкан циркы» киләсе икән дә ул циркта фил, жираф, дөя, арысланнар, юлбарыслар бар икән. Габриэла аны елмаеп тыңлап торды, цирк аны да кызыксындырды.

— Киләмени? — дип сорады.

— Адым саен игълан элгәннәр.

— Бервакытны безгә дә килгәннәр иде. Җиңги белән мин дә барган идем. Шунда берәү утны йотты...

Туисканың үз исәбе икән әле: цирк килгәч, ул дөя менеп шәһәр буйлап йөрүче клоунны озата барачак икән. Аз-маз булышкан өчен

Туисканың маңгаена клоун акбур белән билге ясый да, шуннан соң аны кичке сеанска бушлай кертәләр. Әгәр дә мәгәр манежны хәстәрләргә булыша икән, ул чагында циркта малаең үз кеше булып китә дә вакытлыча гуталиндыр, щеткадыр салган тартмасын ташлап ук тора.

— Бер мәлне үзләре белән алып та китмәкче булганнар иде әле. Директор үзе дәште...

— Униформист булыпмы?

Туиска үпкәли язды:

— Юк ла инде. Артист булып.

— Син нишләргә тиеш идең инде?

Туисканың кара чырае балкып китте:

— Маймыллар белән номер күрсәткәндә ярдәмче буладыр идем. Аннары тагын биер дә идем әле... Әнки аркасында гына калдым...— диде. Чыннан да, негр хатыны Раймунда ревматизм белән газаплана, шуңа чит кешеләрнең керләрен юа алмый, дөнья көтү ике улына төшә: берсе — Фило, автобуста шофер, икенчесе менә Туиска, алтын куллы малай.

— Бии дә беләсеңмени әле?

— Күргәнең юкмыни? Биеп күрсәтимме?

Туиска шундук биергә дә тотынды, тумыштан биер өчен генә яратылган диярсең: аяклары әллә нишләр кыландырып бетерә, гәүдәсе ифрат җиңел йөри, ул арада учын учка сугып көй чыгара иде. Аңа карап торды, торды да Габриэла да тыелып кала алмады: ул да биюне үлеп ярата иде. Подностыр, кәстрүлдер ише нәрсәләрен ташлады да, итәген чеметеп кенә тотып, биюгә бирелде. Хәзер инде кояшлы якты ишегалдында икәү — негр малае белән мулат кызы бии иде. Габриэла бию дип бар дөньясын онытты. Туиска, кисәк кенә биюдән туктап, кәстрүл төбен кага башлады. Габриэла бөтерелүен белде — итәге җилфердәде, беләкләре ипле генә күтәрелде-төште, бөтен гәүдәсе җай гына чайкалды, янбашлары дерелдәде, йөзе нурланып балкыды...

— Йа рабби, подносларым!..

Икәүләшеп җәһәт кенә ризык-тәгамне җыйдылар да, Туиска подносларны башына утыртып, бию көенә сызгырына-сызгырына, китеп барды. Габриэла бию дип үләргә әзер иде, тиз генә туктый алмады, фәкать кухня ягыннан нәрсәдер чыжылдаганны ишетеп кенә, өйгә йөгерде.

Шиконың иртәнге чәйгә кайтканын ишеткәч, Габриэла үзе әзерләгән аш-суны алып, аягына туфлиен элде дә чыгарга юлланды. Шико ашаган арада ул Нәсибенә ризык илтә, барда аз-маз булышкалый иде. Әмма бусага төбеннән әйләнеп керде дә түтәлдән роза чәчкәсен өзеп алды, аны колак артына чәченә кадады, чәчкәнең бәрхет яфракчыклары кызның битен назлады.

Әлеге модага аны итекче Челипе өйрәтте, ул абзый руханиларны каргарга тотынса — яман каты сүгенә, хатын-кыз алдында исә итагатьле испан дворянинына әйләнә иде. Бу моданың дөньяда бер затлы мода икәнен әйтте:

— Севильяда сеньориталар чәчләренә кызыл роза кадап йөриләр,— диде.

Ильеуста күптән яши инде ул, аяк киемен игә китерә, үзе һаман португал сүзләренә испан сүзләрен катнаштырып сөйли иде. Элегрәк Нәсибнең барына әллә нигә бер генә керер иде: эше күп — иярдер, йөгәндер көйли, камчы үрә, ботинкага, итеккә үкчә суга, буш вакытында кызыл тышлы брошюралар укый, «Папелариа Модело»га кереп бәхәс кубара иде. Якшәмбе көннәрендә генә барга сугылып, триктрак яисә шашка уйный, яхшы уйнаучыга санала иде. Хәзер исә ходайның бирмеш

---

[1] Аперитив — аш үтсен өчен иртән шәраб эчеп кую.

көнендә иртәнге ашка чаклы, аперитив1 сәгатендә Нәсиб янына сугылмыйча калмый торган булып китте. Габриэла килгәнне күреп, чал бөдрә чәчен тузгытып башын селкә, яшь егеттәй, җем-җем итеп торган ак тешләрен күрсәтеп, көлеп җибәрә...

Бер ул гына түгел, бүтәннәр дә барга көн саен йөри башлады. «Везувий»ның эшләре ал да гөл. Габриэла хәстәрләгән тәм-том, кабымтөшем беренче көннәрдән үк аперитив сөючеләрнең теленә керде, андыйларның күбесе порттагы барлардан Нәсибкә агылды, һәм «Алтынсу»ның хуҗасы Плинио Арасны хәвефкә төшерде. Нью Гало, Тонико Бастос, капитан чиратлашып Нәсиб белән бергә иртәнге ашны ашыйлар иде, алар кая гына барсалар да Габриэланың искиткеч уңганлыгын мактап туя алмадылар. Аның кулы тигән акараже, тапалган итне, кысла боты белән катнаштырып, аның өстенә йомырка сытып, банан яфрагына төреп кыздырган тәбә ашы, ит белән ясалган әчкелтем пирожкилар чәчмә һәм дә тезмә әсәрләрдә макталды; укытучы Жозуэ бу нигъмәтләргә багышлап дүртьюллыклар язды: колбаса — кашаса кебегрәк рифмалар уйлап чыгарды. Ильеус яныннан пароходта узучы дусты, Алагоас штаты сенаторы хөрмәтенә үз өендә мәҗлес үткәрергә исәп иткәч, Мундинью Фалкан да Нәсибтән бер генә көнгә Габриэланы сорап торды. Халык барга аперитив эчәргә, покер уйнарга, аппетитны китерердәй борычлап ясалган акараждан, төрәч балыгы белән катлама-пирожкидан авыз итәргә, сыйланырга йөри иде. Халык торган саен күбрәк йөрде. Габриэланың ашка-суга осталыгын ишетеп, танышбелешләренә ияреп килүчеләр дә аз булмады. Кайсыберләре ашаргаэчәргә ашыкмады, озаклап утырды. Бу хәл, Габриэла үз хуҗасына иртәнге ашны үзе китерә башлагач, гадәткә керде.

Габриэла барга килеп кергәч, өйләнә-тирәдә соклану авазлары ишетелә: аның салмак кына йөрүләре, түбәнгә төбәлгән күзләре һәммә кешене сокландыра, ә инде аның иреннәренә кунган елмаю барда утыручыларның йөзләрен яктыртып җибәрә иде. Килеп кергәч тә Габриэла өстәлләр янында утыручыларга сәлам бирә, үзе туп-туры буфет янына уза, савытларын шунда куя. Элгәре бу вакытта халык гел булмый иде диярлек, килгәне бере тизрәк тамагын туйдырып китү ягын карый иде. Хәзер исә аперитив сәгатен озайтып, вакытны, гомумән, Габриэланың килүенә карап билгели торган булдылар. Ул килеп кергәч, элек алганны эчеп бетерәләр дә яңадан башлап җибәрәләр.

— Яле, Бико, сал әле бер рюмка «әтәч койрыгы»н[1].

— Миңа ике вермут.

— Әйдә тагын берне уйныйбыз,— дип, күн стакан эчендә сөяк-ашыкларны болгатып алалар да өстәлгә чәчеп җибәрәләр.— Берәмберәм оч король...

Нәсибнең ашы суынып төмен югалтмасын өчен халыкны тизрәк җибәрергә тырышып, Габриэла өстәлләр арасында булышып йөри. Аның башмагы цемент идәнне шуган кебегрәк гизә, купшы чәчен тасма белән кысып бәйләгән, нәфис битенә иннек-фәлән тимәгән. Өстәлләр арасыннан ул биегән төсле иттереп йөри. Кемдер аңа назлы сүзләр әйтә, кемдер ялынып-ялварып карап тора. Габриэла һәммәсенә елмая, холкы-табигате белән сабый баладан ерак китмәгән, тик инде янбашының чайкалып-биеп торуы гына кызның өлгереп җиткәнлеген ачык күрсәтә. Аның монда булуы гүя барны җанга якынрак, кунакчылрак иттереп җибәрә, һәммә нәрсә җанлана торган иде.

Нәсиб аның килгәнен мәйданга аяк басуы белән үк күреп ала. Кара чәченә роза чәчкәсе кадаган Габриэланы күргәч тә, гарәпнең рәхәтлектән күзләре кысыла. Ашарына китерә бит ул аның, тәмле ашлар, ә

---

[1] «Әтәч койрыгы» — бразилия аперитивы — кашаса кушкан вермут.

Нәсибнең бу сәгатьтә карыны бик нык ачыккан була, барда сату өчен әзерләнгән тәмле ризыкларны ашап бетерүдән көчкә тыелып кала ул. Ә инде Габриэла килеп керүгә, өстәл янында утыручылар аперитивны яңабаштан сорап ала. Нәсибнең кесәсенә акча күбрәк кирә, җитмәсә әле Габриэланы көпә-көндез күрү бәхетенә ирешә, үткән төнне исенә төшерә, киләсе төнне күз алдына китерә иде.

Нәсиб кешегә сиздермичә генә кызны капшый-тоткалый; Габриэлага рәхәт, ул чырык-чырык көлә генә.

Ул арада капитан:

— Кил әле, күр әле без уйнаганны, син минем шәкертем ләбаса,— дип кызны үз янына чакыра.

Барда юньләп кеше юк чакларда ул аңа триктрак уенының серен өйрәтеп маташкан иде, шуннан бирле кызны үзенең шәкерте дип атый. Габриэла башын чайкап көлә генә: «ишәк» дигән уеннан гайре аның бернәрсәгә дә сәләте юк иде. Шулай да уен озаккарак сузылса, капитан, һичшиксез, Габриэланы көтеп ала, соңгы тапкырларын ашык-сөяк ташлаганда үз янында булуын таләп итә:

— Монда кил, син бәхет китерәсең,— дип теленә салына.

Ә кайчагында Габриэла итекче Фелипега, Ньо Галога яисә докторга бәхет китерә иде. Андый чакны доктор кызның беләген чәбәкләп ала:

— Рәхмәт яусын, кызым, алла бирсә, тагын да чибәрләнә төшәрсең әле,— ди.

Капитан, үзенең укытучы икәнен дә исеннән чыгарып:

— Тагын да? Шуннан да артык кая инде тагын?! — дип аңа каршы төшә.

Ньо Гало дәшми-тынмый Габриэланы күзәтеп кенә утыра. Итекче Фелипе кызның чәчендәге розаны мактарга тотына:

— Ah, mis clinte anos![1] — ди.— Нишләп әле аның әнә шул роза чәчкәсенә, колак яфрагына, яшел күзләренә багышлап сонет язмыйсың? — дип Жозуэга бәйләнә.

Укытучы исә:

— Монда сонет белән генә котыла алмыйсың, мәдхия яки баллада язам әле,— дип аклана.

Алар һәммәсе дә сәгать беренче яртыны суккач та кузгалалар. Бико Фино шакшы куллары белән алар юмартланып калдырган чәйлекне комсызланып җыештыра. Сәгать сукканчы утырганнары теләр-теләмәс кенә кузгалышалар. Бар бушап кала. Нәсиб тамак туйдырырга утыра. Габриэла аның ашарына китергәләп, өстәл тирәсендә йөри, сыра шешәсен ачып, аның эчәренә сала. Нәсиб ара-тирә кикергәләп — исәнлек бу — ризыкны мактаса, Габриэланың каратутлы йөзкәе нурланып-балкып китә. Аннары ул савыт-сабаны җыештыра. Ул арада Шико әйләнеп килә. Бико Фино ашарга китеп бара. Габриэла барның мәйданга караган ягына шезлонг чыгарып куя да: «Хуш, Нәсибем!» — дип, кайтып китә. Гарәп «Сан Феликс» дигән сигараны көйрәтеп җибәрә, узган атнада чыккан Баийа газеталарын кулына ала да Габриэла чиркәү тыкрыгына борылганчы артыннан карап озатып кала: аның салмак кына артын тирбәлдереп, биегәндәй иплә йөрүләренә сокланып туя алмый, тик инде ул чагында розасы булмый. Нәсиб аның розасын шезлонгтан табып ала — кыз иелгән чакны төшеп калганмы бу роза, әллә югыйсә үз кулы белән чәченнән алып, шунда калдырганмы — алла белсен. Кызыл роза чәчкәсеннән кәнәфер исләре бөркелә — бу инде Габриэланың үз искәе. (...)

[1] Ah, кая китте егерме яшьлек чагым! (испанчаны бозып әйтә).

Таулы якта яши торган, кыргыйланып беткән ата мәче иде ул. Йоны пычранып, укмашып каткан, бер колагы ертылган иде. Әйләнә-тирәдәге ана мәчеләргә һич тынгылык бирми, ата мәчеләр белән сугышканда һәрвакыт җиңеп чыга, кыяфәте белән гел бандит инде менә. Таулы якта аның кермәгән-урлашмаган кухнясы юктыр, шуңа күрә хуҗа ханымнар да, хезмәтче кызлар да аны яраса әллә нишләтерләр иде, тик ул чамасыз сак кылана һәм житез иде. Әнә шул бандитның ышанычын Габриэла ни рәвешле казангандыр инде, ияреп йөрсен өчен, итәгенә ятып йокласын өчен ниләр генә эшләгәндер инде? Әллә бәлкем, теге калдык-постык эзләнеп иснәнеп килгәндә акырып-бакырып кумагандыр, идән щеткасы белән кизәнмәгәндер. Габриэла аңа сеңерле калҗалар, балык койрыклары, тавыкның эчен-бавырын ташлый иде. Мәче аңа ияләшеп китте, көннәрен гуява күләгәсендә йоклап уздыра торган булды, төнен бераз ит кунды, чистарына төште. Ул кич җитүгә сәйранга чыгып чаба — бөтен әйләнә-тирәне, түбәләрне йөреп чыга, үз эшендә һич ару-талуны белмәс иде.

Габриэла бардан кайтып ашарга утыргач та, мәче аның аягына килеп мырлый-мырлый сырпаланырга тотына. Калҗа элексә — тәмләп кенә ашап җибәрә, әгәр инде Габриэла башыннан сыйпаса, корсагын кашыса — бөтенләй эреп китә, мырларга ук тотына.

Дона Арминда бу хәлне могҗиза дип кабул итә. Шул чаклы кыргыйланган мәчене ияләштереп булыр дип, кулдан ризык алыр дип, үзен сыйпатыр дип, итәккә ятып йоклар дип башына да китермәгән икән. Габриэла үзен күкрәгенә кысып, йөнтәс танавына битен якын китерсә, мәче күзен кысык кына калдырып йома да акрын гына мыраулаган була, тырмаштырган була. Дона Арминда карашынча, моны бер генә нәрсә белән аңлатып була — Габриэла ачылып җитмәгән арадашчы медиум, ул үзеннән бик тә көчле флюид-нурлар агылганын да аңламый, ә инде шушы тупас алмазны сеансларда шомартсаң, аннан теге доньябелән аралашу өчен бер дигән күрәзәче килеп чыгар иде. Габриэланың флюидлары булмыйча тагын нинди нәрсә кулга ияләштерә алсын ди шундый да кыргый җанварны?

Тол хатын оекка баш сабарга, хезмәтче кыз мәчене иркәләргә ишек төбенә икәүләшеп килеп утырган саен дона Арминда үзенең дәлилләрен китерергә тотына:

— Кызым, сиңа киләчәк сеанска бармый калырга ярамый. Узганында да Диодоро сораштырды үзеңне: «Бүген нигә килмәде? Медиумга искиткеч бай бит ул, аның артында утырган чакны аңладым» — дигән була. Текмә-тек шулай диде. Мач килеп торуын әйт әле син, үзем дә шулайрак уйлаган идем ләбаса. Диодоро, үзе яшь кенә булса да, андый нәрсәләрне әйбәт белә. Әрвахлар белән аралашканы, аларга әмерләр биргәне әллә каян күренә. Менә син дә күрәзәче булып китәрсең...

— Миңа кирәкми ул... Кирәкми, дона Арминда. Ни эшкә ди ул миңа? Үлгәннәргә тимәгәнең хәерле, тыныч кына йокласыннар шунда... — Габриэла мәченең корсагын кашыган иде, тегесе тагын да кәефләрәк мыраударга тотынды.

— Кызым, бер дә акылга сыя торган эш түгел әле киреләнүең. Әрвахың болай гына сиңа акыл өйрәтә алмый лабаса, шуңа гомер юлыңны сукыр килеш үтәрсең. Әрвах бит безнең өчен сукырга юл күрсәтүче белән бер. Безгә бит ул юл күрсәтә, каршылыкларны уратып узарга булыша...

— Минем алда юк ул каршылык, дона Арминда.

— Андамыни хикмәт, ул бит киңәш тә бирә. Шушы арада гына дона Ампаро бик авыр бәбиләде. Чыгасы гына килми бит малайның. Нишләргә дә белмим, тәмам аптырадым. Сеньор Милтон инде табиб чакырт-

макчы булган иде. Шунда миңа кем ярдәм итте дисең? Ирем мәрхүм: ул бит гел миңа тагылып йөри, бер минут та ялгызымны калдырмый. Тегендә бит,— тол хатын бармагын күккә төбәде,— һәммә нәрсә, хәтта медицина да мәгълүм. Колагыма пышылдавы булды — шулай эшләвем булды. Тупылдап торган малай туды.

— Әйбәт эш инде кендек әбисе булу. Сабыйларга туарга булышасыз...

— Менә хәзер син киңәшкә мохтаҗ, аны сиңа кем бирә?

— Мин киңәшкә мохтаҗмыни әле, дона Арминда? Белмидер идем...

— Бер дә акылың юк шул, кызым. Болай диюемә үпкәләмә, шыр дивана икәнсең ләбаса. Ходай биргән байлыктан файдалана белмисең.

— Нәрсә сөйлисездер, төшенә алмыйм, дона Арминда. Һәммә нәрсәмне киям ич инде. Сеньор Нәсиб бүләк иткән туфлине дә киям әле. Барга шуны киеп йөрим. Хәер, туфли ипсез ул киеп йөрергә, мин үзем артсыз башмак яратам, бик уңай.

—Туфли сөйләп утыраммыни мин сиңа, дивана кызый? Әллә инде күзең чыкканмы сеньор Нәсибнең үзеңә гашыйк икәнен күрмәскә! Бөтенләй тугарылды бичара, боегып йөри, өйгә дә иртә кайта...

Габриэла мәчене күкрәгенә кыса төште, көлеп җибәрде:

— Сеньор Нәсиб асыл кеше, аңардан һич куркасым юк. Мине куып җибәрергә уйламый, ә мин аның күңелен күрергә тырышам.

Шул чаклы сукырлыкка тап булгач, дона Арминда хәтта бармагын чәнчеп алды.

— Ой, бармагым! Бу чаклы да шыр тиле булырсың икән булсаң да. Сеньор Нәсиб бит сиңа җаның теләгән нәрсәне алып бирә ала. Бай ләбаса ул! Ефәк сорасаң — ефәген, ярдәмгә бер кыз сорасаң — икене, акча дисең икән — җаның теләгән хәтле бирәчәк.

— Миңа бит берни кирәкми... Нишлим мин акча белән?

— Әллә син гомереӊ буена шулай матур булырмын дисеңме? Чибәрлегеңнән хәзер файдаланып калсаң каласың, калмасаң юк. Нәсибтән берни сорамыйсыңдыр әле, әйеме?

— Юк, сезнең белән кинога барганда бераз акча сорыйм. Тагын нәрсә сорыйм инде?

Дона Арминда тәмам чыгырыннан чыкты, чукмарга кигезгән оегын атып бәрде: мәче, коты алынып, хәйләкәр күзләрен карчыкка төбәде.

— Нәрсә сорасаң да, кызым, җаның теләгәнне алып бирәчәк! — Ул пышылдауга күчте.— Әгәренки көен тапсаң, өйләнер дә әле үзеңә.

— Нишләп миңа өйләнсен ди ул, дона Арминда? Нишләп өйләнсен ди? Сеньор Нәсиб рәтлерәк, баерак гаиләдән, юньлерәк кыз алырга тиеш. Нигә дип мине алсын икән?

— Әллә югыйсә синең сеньора буласың, үз өеңдә әмерләр биреп, һәйбәт киенеп, ирең белән култыклашып йөрисең, кеше арасына керәсең килмиме?

— Ул чагында миңа көннәр буена аягыма туфли киеп йөрергә туры килер иде... Анысына риза түгел... Ә болай сеньор Нәсибкә үзем бик чыгар идем чыгуын.— Аш-су хәстәрләр идем үзенә, аз-маз кул арасына керер идем...— Габриэла елмая-елмая сөйләде, мәче белән шаярды, аның юеш салкын танавына борынын төртте.— Нәрсә лыгырдап торам соң әле! Сеньор Нәсибнең миннән башка да мәшәкате баштан ашкан. Минем шикеллегә нишләп өйләнсен ди әле? Мине бит ул кыз көе күрмәде... Ул акылдан язса да мине алырга тиеш түгел... Хыялланмыйм да...

— Сүземә колак салыр идең ичмаса, кызым. Теләгең генә булсын, акыл белән эш кенә ит: кирәк икән — бирел, кирәк түгел икән — ризалашма, канын кыздыр, тәмам аздыр. Ул болай да хафага калган. Шико әйтә, ни ди, судья синең өчен өй тотарга риза икән, ди. Аннары Нью Галоның кемгәдер әйткән сүзләрен ишеткән: сеньор Нәсиб гел аптыраштa, ди.

— Кирәге юк...— Габриэланың йөзеннән елмаю качты.— Ошамый ул судьягыз миңа. Карт пәри шикелле.

Дона Арминда:

— Әнә тагын берәү килә...— дип ымлады.

Урам буйлап ашыкмыйча гына полковник Мануэл Ягуар килә иде. Болар турысына җиткәч, ул туктады, башыннан эшләпәсен салып, чуар кульяулыгы белән маңгаен сөртте.

— Хәерле кич,— диде.

Тол хатын аңа:

— Хәерле кич, полковник,— дип җавап кайтарды.

— Нәсибнең йорты шушыдыр бит? Әлеге кызны күреп абайладым,— дип сөйләнә-сөйләнә, Габриэлага ымлады.— Бала-чагаларны Ильеуска күчерергә иде исәп, шуңа хезмәтче эзләп йөрүем әле... Берәр юньлерәк хатын-кызны белмисездер бит?

— Нишләтергә, полковник?

— Нишләтергә дип... Аш пешертергә инде...

— Андыйны бу тирәләрдә таба алмассыз шул.

— Нәсиб сиңа күпме түли соң?

Габриэла аңа хәйләсез-нисез күзләрен күтәреп карады:

— Алтмыш мильрейс, сеньор...

— Ул да аз түгел анысы, аз түгел.

Тынып калдылар. Фазендейро читкә карап тик торды. Шулчак дона Арминда кул эшен алды да, саубуллашып, өенә ашыкты. Анда ишек аркылы боларның сөйләшкәнен тыңларга бик җайлы иде. Полковник канәгать калды, елмаеп, кызга сүз кушты:

— Дөресен генә әйткәндә, пешекче кирәкми дә миңа. Бала-чага күченгәч, плантациядән берәрсен алып кайтырмын әле аш пешерергә. Җәлләдем үзеңне, шушындый каратут йөзле чибәркәй әрәм ята бит кухняда, дидем.

— Нишләп, полковник?

— Кулың яргаланып бетә. Хәзер инде үзеңнән тора. Телисең икән, һәммә нәрсәң булыр: бер дигән өй, хезмәтче кыз, кибеттән җаның теләгәнне алырсың, кәстрүл-мәстрүлеңне ташлыйсың. Күңелемә хуш килдең, кызыкай.

Габриэла урыныннан кузгалды, аның чыраенда рәхмәтле елмаю чагыла иде.

— Йә, ни диярсең?

— Бигайбә, сеньор, мин риза була алмыйм. Бертөрле дә начарлык уйламагыз, миңа монда да яхшы, бернинди мохтаҗлыгым юк. Миңа китәргә рөхсәт итегез, сеньор полковник...

Ишегалды түрендәге тәбәнәк дивар өстендә дона Арминданың башы күренде. Ул Габриэланы дөшеп алды:

— Мач килеп торуын әйт әле син аның! Әйттемме мин сиңа? Бусы да сине өйле итмәкче.

— Бер дә ошамады ул миңа... Ачка интегеп үлсәм дә...

— Дөрес әйттемме? Теләгең булса...

— Ә минем теләгем юк.

Габриэла үзенең бөтен киемнәрен — ситсы күлмәкләрен, артсыз башмакларын, колак алкаларын, беләзеген, брошка-мазарын ярата иде; аягына кысан туфлиен генә килештерми иде. Үзенең ишегалдын, кухня белән плитәсен, үзе йоклый торган бәләкәй генә бүлмәсен бик тә ярата иде; барга йөрүдән үзенә бер ләззәт ала — анда хәйран кызыклы яшьләр, әйтик, укытучы Жозуэ, сеньор Тонико, сеньор Арилар белән күрешә-аралаша, өлкән яшьтәге әдәпле әфәнделәр белән, әйтик, сеньор Фелипе, доктор, капитан белән очраша иде, негр малае Туиска белән дуслашып алды, мәчене иялəштерде.

Сеньор Нәсиб аның күңеленә хуш килә: үзе чибәр, үзе яшь, үзе таза ир-атның йонтәс күкрәгенә башыңны куеп, янбашында аның саллы

ботының авырлыгын тоеп ятулары бигрәкләр рәхәт иде. Мыегы белән Габриэланың баш чүмечен кытыклый да бөтен тәннәрен кымырҗытып җибәрә. Ир-ат куенында йоклавы рәхәтен рәхәт тә бит, әйле булам дип, кием-салымга, тамак-мазарга алданып кына карт-коры янында ятуның кызыгы юктыр. Кызыгырлык булсын шул ул, сеньор Нәсиб шикелле, үзе яшь, үзе чибәр, үзе таза булсын.

Дона Арминданы да әйтер идем инде! Спиритизм дип йөри-йөри тәмам хыялыйга әйләнгән, башына әллә ниләр килә башлаган. Сеньор Нәсиб өйләнә, имеш тә, Габриэланы хатынлыкка ала, имеш... Әмма хыяллану дигән нәрсә бар бит әле, әнә шул рәхәт бирә. Сеньор Нәсиб белән култыклашып урамнарда йөрсәң... Кинога кереп, янәшә утырсаң, башыңны аның мамык мендәр шикелле йомшак иңбашына куйсаң... Бәйрәмнәрдә аның белән танцевать итсәң... Бармагыңда аның балдагын йөртсәң... (...)

## Габриэла белән читлектәге кошкай

Кошчыкны күргәч тә, Габриэла:

— И—и нинди матур! — дип кычкырып җибәрде.

Нәсиб читлекне урындыкка куйган иде, кошчык бәргәләнергә тотынды.

— Сиңа бу... Ялгызыңа ямансудыр югыйсә.

Шулай диде дә утырды. Габриэла аның аягы янына идәнгә чүмәште, йөнтәс дәү кулын алып, учын үпте. Бу хәл Нәсибнең нигәдер әтиләре җирен, Сирия тауларын хәтеренә төшерде, нигә икәнен ул үзе дә әйтә алмас иде. Аннары Габриэла башын аның тезенә салды. Нәсиб аның чәчен сыйпады. Кошчык ул арада тынычланып өлгерде, тавышын күрсәтте.

— Берьюлы ике бүләк... Бу чаклы да акыллы булырсың икән, җаный!

— Ничек ике?

— Берсе — кошчык, икенчесе — үзең алып кайтып бирүең. Һәркөнне бигрәкләр соңга калып кайтасың лабаса...

Нәрсә, Нәсиб шундый да ярны югалтыр микәнни? «Хатын-кызның тугрылыгы ахыры бер сына ул, сынмый калмый». Нью Гало, тәсе уңа, димәкче булгандыр әле. Нәсибнең үзәкләре әрнүе кыяфәтенә чыкты, Габриэла башын күтәргән арада моны абайлап алды.

— Нәсибем, син нишләптер миңа моңсу күренәсең әле. Бер дә мондый түгел идең бит. Күркәм күңел белән, елмаеп-көлеп йөри идең, хәзер гел пошаманга калдың. Нәрсәдән ул алай, Нәсиб?

Ни дисен инде ир-егет сөеклесенә? Гел үз янымда калдыруның чарасын, сине саклау ысулын белмимен, димәс ич инде. Шулай да гарәп аңлашу өчен форсатны ычкындырмаска булды.

— Сиңа әйтер сүзем бар иде шул.

— Әйт соң, хуҗам...

— Миңа ошамый торган, мине борчый торган бер нәрсә бар шул.

Габриэла шөбһәгә төште:

— Берәр ашны начар пешердемме, йә булмаса керեңне начар юдыммы?

— Юк, юк, башка мәсьәлә.

— Нәрсә соң?

— Синең барга йөрүең. Бик ошап бетми шул миңа.

Габриэла күзен зур итеп ачты:

— Сиңа булышырга, ашыңны кайнар чагында ашатырга тырышудан гына йөрим ләбаса. Башка бер эшем дә юк анда.

— Мин беләм дә бит... Мин белгән белән генәмени...

— Әhә, төшендем. Анысын уйлап җиткермәгәнмен... Барга кереп йөрүем ошамыйдыр инде... Пешекче башы белән барга керә, диләрдер... Уйлап җиткермәгәнмен...

Нәсиб бу фикерне җүпләп:

— Шулай шул... Кайсыбер кеше моңа илтифат та итми, ә бит моңа каршы төшүчеләр дә бар,— диде.

Габриэланың күзләренә сагыш иңде. Кошчыкның җыры җанны ашады, йөрәкне телгәләде. Бу чаклы да сагышлы булыр икән Габриэланың күзләре!

— Аларга минем нинди зыяным тигән?

Нигә инде сөеклеңне шулай газапларга, нишләп инде дөп-дөресен әйтеп бирмәскә, сөю хисен ачып салмаска, көнчелек корты күңелен ашаганны әйтмәскә, аңа кайчаннан бирле күңеленнән әйтеп йөргән *бибием* дигән назлы сүзен хәзер кычкырып кабатламаска?

— Иртәгедән алайса кара ишектән үтеп кенә ашарыңа калдырып чыгармын. Залга да узмамын, тыштагы өстәлләргә дә якын бармамын.

Әфарин. Димәк, Нәсиб аны көн үзәгендә элеккечә үк күрәчәк, үз янында икәнен тоячак, аның кулына, аягына, түшенә орыначак. Ихтимал, бу әле кем җитте шуның тәкъдименә, түмле сүзенә кире җавап булып та аңлашылыр...

— Яратып йөрисеңме соң син барга?

Габриэла ияк какты. Буш вакыты булса, барга чаклы юлны урап кайта, анда да hәммә нәрсә күңеленә хуш килә. Шәhәр буйлап савытлар күтәреп барган чакны, өстәл араларыннан узган чакны ир-атның үзенә ымсынып карап калганын абайлый, пышылдаганын ишетә. Әмма аны карт-корының күз карашы кызыксындырмый, полковникларның үзенә өй алып бирергә теләк белдерүләре күңелен hич үсендерми. Ир-атның шулай сокланып каравы, сәлам бирүләре, кочарга ымсынулары гына ошаса ошый торгандыр. Әнә шул дәртле хәләте, гүя, төнгелеккә барып тоташа — Нәсиб куенында яткан чакны Габриэла барда үзе күргән чибәррәк ир-егетне хәтеренә төшереп ята. Сеньор Тонико да була анда, сеньор Жозуэ да, сеньор Ари да, сеньор Эпаминондас та, кибеттә кассир булып эшләүче егет тә... Бу гауганы шуларның берәрсе чыгармагандыр лабаса? Юк, булмастыр. Игътибардан мәхрүм калган берәр карт пәридер әле, мәгаен!

— Ярар ла, электәге шикелле үк кил. Ләкин моннан соң өстәл араларында йөрмәссең, буфет янында гына торырсың.

Димәк, аңа сокланып карый алачаклар икән әле, елмаячаклар икән әле, бер-ике сүз әйтер өчен янына да киләчәкләр икән әле...

Нәсиб кисәктән генә:

— Барга китим,— диде.

— Бик иртә бит әле...

— Миңа гомумән дә кайтырга ярамый иде.

Габриэла аның аякларын кысып кочаклаган да hич китәргә ирек бирми генә бит. Нәсиб аны төнлә белән генә назлый, көпә-көндез якын барганы булмады. Торыйм дисә, рәхмәт төшкере, җибәрми генә бит!

— Әйдә минем монда... Тиз бул...

Нәсиб мулат кызын үзе белән ияртеп алып китте. Беренче мәртәбә үзенең йокы бүлмәсендә, үз караватына яткызып тунасын әле. Хезмәтчесе, пешекчесе итеп түгел, бәлки хатыны шикелле иттереп... Габриэла ике кулы белән аның башын кысып тотып, күзләреннән үпкәч, Нәсиб гомерендә беренче мәртәбә:

— Әйт әле, мине бик яратасыңмы? — дип сорар булды.

Габриэла көлеп җибәрде, hәм аның көлүе кошлар җырлаганга, сандугач сайраганга охшап яңгырады.

— Чибәркәем... Бик-бик яратам... Алай гына микән әле...

Тукта, нишләп соң әле Нәсиб аны кайгыга салды, нишләп дөресен әйтеп бирмәде?

— Берәү дә сине барга килмәсен дип әйтмәде. Минем үз сүзем ул. Моңсулануым да шуннан килә. Барысы да сиңа җыен тузга язмаган сүз әйтә, шаяртып маташа, кулыңны тота, шунда ук барның идәненә генә бәреп екмыйлар лабаса...

Габриэлага бу сүзләр мәзәк тоелды, һәм ул рәхәтләнеп көлеп җибәрде.

— Исең киткән икән... Мин бит аларга әйләнеп тә карамыйм...

— Чынлапмы?

Габриэла аның башын күкрәгенә кысты. Шул чагында Нәсиб үз телендә, гарәпчә иң-иң назлы сөю сүзләрен әйтер булды:

— Бибием... Моннан ары мин сиңа шулай диярмен, синең урының шушы булыр, бибием, шушында йокларсың, бибием... Гәрчә аш-су эшен башкарсаң да, моннан ары пешекче түгел синең исемең, син шушы йортның хуҗабикәсе. Якты кояш нуры да син, айның яме дә син, кошлар сайравы да син. Исемең синең — Биби...

— Биби, нәрсә, чит телдәге исеммени? Мине шулай ата алайса, үз телеңдә ешрак сөйлә, көен яратам шул телнең...

Нәсибне озаткач та, Габриэла читлек каршысына утырды. Менә нинди әйбәт кеше бит: мине көнләшә, дип сөенде. Көлә-көлә, читлеккә бармагын тыккан иде — кошчыкның коты алынды, талпынып куйды тегә. Көлми ничек түзәрсең, Нәсиб хәтле Нәсиб көнләшкәч... Ә менә Габриэла үзе һич көнләшми: хуҗа кеше, теләге булса, башка хатын янына да бара ала. Сизә иде ич инде, баштарак нәкъ шулай булды: аның белән дә ятты, башкалар янында да булгалады. Ләкин Габриэла көнләшмәде. Тели икән, китә бирсен икенче берәү янына, бөтенләйгә үк түгел, бер кичкә генә. Ә менә Нәсибнең көнләшүе мәзәк инде. Жозуэ аның белгеннән тоткан икән, шундый чибәр, шундый җитди сеньор Тонико Нәсиб күрмәгәндә генә моның баш чүмеченнән үбәргә талпынган икән, әгәр сеньор Эпаминондас очрашмакчы булып сүз кушкан икән, сеньор Ари конфет ташый һәм аны иягеннән генә тоткалый икән инде, аннан гына дөнья җимерелмәгәндер ич әле... Нәсиб кочагында чакта Габриэла хыялында һәр көнне берәрсе белән дә ятып карады лабаса, аннары тагын элеккеләре — үзе генә белгән ир-ат белән дә яткандай хис итте, фәкать абзасын гына якын җибәрмәде. Әле берсен назлый-сөешә, әле икенчесен... Күбрәк теге Бебиньо дигән малай белән дә сеньор Тонико белән була. Хыялланудан да татлы ни бар икән?

Барга барулары, ир-ат арасында чуалулары нинди рәхәт! Дөньяда яшәве үзе бер бәхет лабаса. Кояшта кызыну, салкын ваннада юынуны ярата ул; гуява чәйнәү, манго ашау, борыч кимерүнең дә һич кимен куймый; урамнарны урау, җырлау, бер егетнең куенында үзен икенче берәү белән дип хис итүне дә булдыра.

Биби дигән исем бик ошап китте әле аңа. Алыптай гәүдәле Нәсибтән һич көтмәгән иде ул моны. Ә бит үзе шундый мизгелдә дә чит телдә сөйләде, көнләшеп сөйләде... Мәзәк тә инде! Юк, Нәсибне һич рәнҗетергә ярамый, әйбәт кеше ич ул. Хәзер инде бераз саграк эш итәр, күңеленә әрнү салмаска тырышыр. Ләкин өйдә генә бикләнеп, тәрәзәгә дә килмичә, урамга да чыкмыйча тормас ич инде. Елмаймый-көлми, сөйләшми-нитми генә йөрмәс ич инде. Ир-атның тавышын, еш-еш сулавын бер дә ишетмичә, күзенең елтыравын күрмичә яшәмәс ич инде. «Сорама да, юк та, Нәсиб, алай булдыра алмыйм».

Кошчык читлеге эчендә бөрголәнә дә суккалана. Күпмедән бирле мәхбүс икән инде? Әллә ни күп түгелдер, күнегеп тә өлгермәгән. Хәер, бикләнеп яшәүгә кем генә күнегә алыр икән? Габриэла кош-кортны ярата болай үзе — этләр, мәчеләр, тавык-чебешләр белән дуслыгы да бар шикелле. Плантациядә эшләгән чакны аның тутый кошы бар иде, шул сөйләшә торган иде. Ачка үлде бит, әй, абзасыннан алда дөнья куйды... Бу кошчыкны бер дә менә читлектә асрыйсы килми. Кызганыч. Нәсибкә әйтсә, үпкәләр, рәнҗер. Рәнҗемәскә... Габриэлага ялгызына

ямансу булмасын дип, җырчы кошны алып кайтып бүләк иткәч... Әмма софраның да җыры моңсу, Нәсиб тә моңсу. Аны рәнҗетү килешмәс, бераз саграк булу кирәктер. Аны рәнҗетмәс өчен, кошчык үзе читлегеннән чыкты да очып китте, дияргәдер.

Габриэла ишегалдына чыкты, читлекне ачып җибәрде. Мәче йоклап ята иде. Кошчык гуявага очып менеп кунды. Габриэлага җыру җырлады. Бу чаклы да яңгыратып, күңелле итеп җырлар икән җырласа да! Габриэла елмаеп куйды. (...)

# Туй

Өстенә күк күлмәк, аягына кысан туфли кигән, керфекләрен түбән төшереп, оялчан гына елмайган Габриэлага һәркем кызыгырлык иде. Кунак бүлмәсенә ул Тонико белән култыклашып килеп керде, нотариус олуг бәйрәмнәрдәгечә ыспай киенгән иде. Ладейре-де-сан-Себастьян урамындагы Нәсиб йорты шыгрым тулды. Чакырылганнары да, чакырылмаганнары да килде — туйдан тукмак каламы соң! Нәсиб үзенең ниятен әйткәч тә Габриэланы дона Арминда өенә озатты: ярәшкән егет белән кызга бер өйдә куну килешми икән ләбаса.

Габриэла моңа сәерсенеп:

— Нигә инде? Барыбер түгелмени? — диде.

Түгел шул менә. Хәзер бит ул Нәсибнең ярәшкән кызы, хатыны булыр, бүгеннән үк олуг хөрмәтенә лаек. Өйләнешергә ризалыгын сорагач, Габриэла уйга калды:

— Нигә инде, сеньор Нәсиб? Кирәкмәс иде инде...

— Нәрсә, риза түгелмени?

— Ризасын риза да бит... Кирәкмәс иде. Мин бит сезне болай да яратам.

Нәсиб хәзердән үк хезмәтчеләр яллады: берсе өйне җыештырыр, икенчесе, яшь-яшь кыз бала, аш-су һөнәренә өйрәнер. Ресторанда эшләргә тагын карыйсы булыр әле. Буяучылар яллап, өенең буявын яңарттырды, өр-яңа мебель кайтартты. Ярәшкән кызына бирнә булдырды — җиңгәсе ярдәме белән күлмәген-фәләнен, эчке киемнәрен, туфлиен-оегын сатып алды. Абзасы белән җиңгәсе башта гына сәерсенделәр дә, тора-бара бик ягымлы булып киттеләр. Ярәшкән кызны утырмага да чакырдылар. Нәсиб кенә ризалык бирмәде: хәстәрләү эшләрен үзе генә башкарып чыга алмаячак иде. Ә менә дона Арминда белән ике арадагы дивар бик тәбәнәк булу сәбәпле, Габриэла итәген күтәрә дә сикереп чыга — тау кәҗәсе диярсең. Шул рәвешле Нәсибе янына йокларга йөрде. Апасы белән җизнәсе Нәсибкә авыз ачарга да ирек бирмәделәр, аның өйләнүенә теш-тырнаклары белән каршы килделәр. Итабунада яшәүче Эшкәриләр исә бүләк итеп бака кабырчыкларыннан эшләнгән искиткеч матур абажур җибәрделәр.

Өстенә карасу-зәңгәр костюм, аягына ялтыравык туфли кигән, мыегын гайрәтле иттереп бөтереп җибәргән, күкрәгенә кәнәфер чәчәге кадаган Нәсибне күрәселәре килеп ничаклы халык җыелган. Габриэла аска гына карап елмая иде. Судья игълан итте: утыз өч яшендәге коммерсант, Феррадасада туып, Итабунада кенәгәгә теркәлгән Нәсиб Эшкәри Сәгадәт белән егерме бер яшендәге, өй эшләрен башкаручы, Ильеуста туып, шунда ук кенәгәгә теркәлгән Габриэла да Силва никахлашалар, диде.

Нәсибнең йорты шыгрым тулы — ир-ат күбрәк, хатын-кыз азрак: Тониконың хатыны язылышкан чагында шаһит буларак чакырылган иде, ул бар да, аның каенсеңлесе аксыл чәчле Жеруза килгән; капитанның киң күңелле, искиткеч гади хатыны килде; кыз туган Рейслар әнә бертуктаусыз елмаешалар; Жоан Фулженсионың алты бала тәрбияләп

тә бирешмәгән хатыны килде. Бүтәннәренең киләсе килмәде — хезмәтче кызга өйләнәләр димени!

Өстәл өсләрендә ризык-нигъмәт, шәрабның да төрлесе. Кунаклар чамасыз күп булып, өйгә генә сыеп бетә алмаганнары тротуарны тутырды. Ильеуста мондый кызыклы-җанлы туйның булганы юк иде әле. Плинио Араса булып, ул да конкуренция дип тормаган, шампан күтәреп килгән иде. Чиркәүгә барып никахлашсалар, ямь өстенә ямь буласы иде дә бит. Нәсиб мөселман динендә икән ләбаса; хәер, Ильеуста яши-яши аллаһе тәгаләдән дә, Мөхәммәт галәйһис-сәламнән дә читләшкән, тик инде Гайсә пәйгамбәргә дә, Иеговага да якынлашмаган иде. Шулай да поп Базилио килеп, Габриэлага фатихасын бирде:

— Иерихоннан килгән роза гөлкәем чәчәк атып, нәсел калдырсын,— диде.

Нәсибкә исә бармак янады:

— Теләсәгез нишләгез, балаларыгызны чукындырмыйча калмыйм...— диде.

— Ризамын, сеньор падре...

Кич якынлашып, эңгер-меңгер җиткәч, урамнан берәү:

— Күрегез, күр, җир казу машиналары кайткан! — дип сөрән салмаса, туй мәҗлесе, ихтимал, кара төнгәчә сузылган булыр иде.

Барча халык урамга агылды. Риодан кайтып төшкән Мундиньо Фалкан да туйга килде, Габриэлага ул кызыл розалар китерде, Нәсибкә көмеш портсигар бүләк итте. Аннары урамга чыкты да үз-үзеннән канәгать булып елмайды: дүрт җир казу машинасын сөйрәп ике буксир килә иде. Шулчак өч мәртәбә «ура» кычкырдылар да кияүләр белән саубуллаша башладылар. Иң әүвәл Мундиньо Фалкан, доктор һәм капитан саубуллашты.

Бәйрәм тамашасы портка күчте. Кияүләр янында бары тик туташ-ханымнар, Жозуэ белән итекче Фелипе генә беравык юандылар. Мондый шау-шулы көнне Глория булып ул да тәрәзә каршында утыру белән чикләнмәде, урамга атылып чыкты. Дона Арминда да, яшьләргә тыныч йокы теләп, чыгып киткәннән соң мәхшәр тулы, буш тәлинкәләр—шешәләр тулы өйдә икәүдән-икәү калгач, Нәсиб телгә килде:

— Бибием...— диде.

— Сеньор Нәсиб...

— Нишләп әле сеньор? Мин бит синең хуҗаң түгел, ирең.

Габриэла балкып елмайды, аягыннан туфлиен салып атты, яланаяк килеш өйне җыештыра башлады. Нәсиб аны беләгеннән эләктереп алды да кинә белән:

— Алай ярамый, бибием,— диде.

— Нәрсә ярамый?

— Сеньорага яланаяк йөрү килешми.

Габриэла шөбһәгә төште:

— Яланаяк йөрү килешмимени?

— Килешми шул.

— Нигә инде?

— Син ярыйсы гына бай сеньора хәзер, халык сиңа хөрмәт белән карый.


— Юк инде, сеньор Нәсиб, мин үзем булып, Габриэла булып калу ягында.

— Мин сине тәрбияләргә алынам.— Шулай дип Нәсиб аны күтәреп алды да караватка илтеп салды.

Габриэла фәкать:

— Чибәркәем...— дип әйтергә өлгерде...

# БӨТЕНДӨНЬЯ ТАТАРЛАРЫ КОНГРЕССЫ



Инде хәбәр ителгәнчә, быел Казанда без моңарчы хыялга да сыйдыра алмаган мөһим вакыйга — Бөтендөнья татарлары конгрессы булып узды. Кунакларны каршылау һәм озату көннәрен дә кертеп исәпләгәндә, бу тантана 17—23 июньнәргә туры килде. Гаҗәеп бу форумга БДБ илләреннән, АКШ, Төркия, Финляндия, Алмания, Австралия, Канада, Япония, Кытай кебек ерактагы чит илләрдән 1200 ләп кунак җыелды.

Мондый зур җыелышның зарурлыгы, Татарстан Республика Президенты Минтимер Шәймиев аңлатуынча: «... иҗтимагый үсештә милли фактор үзен һаман саен ныграк сиздерә барудан, чын мөстәкыйльлеккә омтылу заман таләбе булып әверелүдән килеп чыкты».

Конгрессның төп максаты — милли мәсьәләләрне хәл итү өчен төрле төбәкләрдә яшәүчеләрне барлау, бергә туплау һәм уртак бурычларны чишүдә төп принципларны билгеләү иде. Кунаклар, эшкә керешкәнче үк, Татарстан башкаласында бер-бер артлы күпсанлы әдәби-мәдәни чараларда катнаштылар: тюркология, экология конференцияләре, М. Солтангалиев тууга 100 ел тулу кичәсе, «Казан утлары» журналының 70 еллык юбилее һәм башкалар.

Конгресс ачылачак көнне, 19 июньдә исә, иртәдән үк Казанның Ирек мәйданында уен-көлке, җыр-бию башланды. Мәйданга җөмһүриятнең танылган һәвәскәрләре, фольклор ансамбльләре җыелган иде. Аларның чыгышын һәммә кеше ифрат зур кызыксыну белән карады.

Иртәнге сәгать унда Конгресс Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт академия опера һәм балет театрында үз эшен башлап җибәрде. Анда катнашучыларны Татарстан Җөмһүрияте Премьер-министры Мөхәммәт Сабиров тәбрикләде.

—Төрле сәбәпләр, ачы язмышлар аркасында дөнья буйлап сибелгән милләттәшләребез бүген менә бергә җыелдылар,— диде ул.— Бу җыен Президентыбыз Указы нигезендә үткәрелә. Юлыбызда кыенлыклар күп булса да, киләчәккә ышанычыбыз зур...

М. Сабиров тантанада катнашучыларны чит илләрдән килгән атаклы милләттәшләребез белән таныштырып чыкты. Россия Федерациясе Президенты Б. Ельцинның котлавын игълан итте.

Бөтендөнья татар конгрессында Татарстан Президенты М. Шәймиев зур нотык белән чыкты. (Аның нотыгы журналыбызның сигезенче санында бирелде). Моннан тыш, утырышта тагын егермеләп кеше сөйләде. Алар арасында чит ил кунаклары да, галимнәр дә, икътисадчылар да, күрше җөмһүрият вәкилләре дә, дин әһелләре дә бар иде.

20 июньдә исә эш, һәр катнашучының һөнәренә вә осталыгына карап, аерым секцияләрдә дәвам итте. Кунаклар 15 түгәрәк өстәл янына чакырылдылар һәм аерым мәсьәләләр турында эшлекле сөйләшү алып бардылар, киләчәккә бурычлар билгеләделәр.

Эш араларында, кичләрен кунакларны төрледән-төрле мәдәни чаралар көтеп алды. Казан дәүләт консерваториясендәге концерт та, Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбле чыгышы да, «Шүрәле» балеты да, «Хуҗа Насертдин» спектакле дә, җөмһүриятебезнең сәнгать осталары концерты да, «Әлдермештән Әлмәндәр» спектакле дә, төрле төбәкләрдәге Сабан туйлары да, шәһри Болгарга сәяхәт тә кунаклар күңеленә хуш килгәндер.

Конгрессның әһәмиятен, ул башкарган эшләрне, ул башлап җибәргән бинигһая файдалы элемтәләрне сөйләп-аңлатып бетерү һич мөмкин түгел. Шулай да без укучыларыбызны «Түгәрәк өстәлләр янында» алып барылган 15 мәҗлес белән кыскача таныштырырга булдык. Уйлавыбызча, ул әңгәмәләр конгресс эшен һәрьяклап күзалларга азмы-күпме мөмкинлек бирер.

## Дипломатия һәм халыкара элемтәләр мәсьәләсе

Мәгълүм булганча, мондый вәкаләт элекке Татарстанга бөтенләй бирелмәгән иде. Шунлыктан бу юлда һәр нәрсә яңа һәм мәсьәләне чишү өчен әр-яңа юл ярырга туры килә. Баксаң, Татарстанның икътисади потенциалы күп кенә чит илләрдә зур кызыксыну уята икән. Бүген үк инде дистәләрчә чит илләр Татарстан белән төрле юнәлешләрдә элемтә булдырырга, Казанда үз вәкиллекләрен ачарга әзер торалар. Беренче чиратта — Россия.

«Дипломатия һәм Татарстанның халыкара элемтәләре» турындагы сөйләшүне вице-президент В. Лихачев алып барды. Василий Николаевич, моңарчы чит илләрдә эшләп, кайбер телләрне дә яхшы белгәнгә, үзен шактый тыныч тотты. Югыйсә, аңа сорауларның иң четерекләләре яуды. Халыкара хокук буенча юридик фәннәр докторы булуы да аңа ярдәмгә килгәндер. Сорауларның иң беренчесе шундый иде:

—Татарстанның үз дипломатларын әзерләү ни дәрәҗәдә тора?

Мондый сорауны И. Закиров (Пермь), А. Ибраһимов (Ульян) һәм башка милләттәшләр бирде.

В. Лихачев Татарстанның бу мәсьәлә буенча җитди эш алып баруын, Мәскәүдәге Халыкара элемтәләр институтында белгечләр әзерләнәчәген әйтте. Моннан тыш шул ук мәсьәләне чишүдә Казан университеты, авиация, химия-технология, финанс-экономика институтлары да җиң сызганып эшкә керешәчәкләр.

Танылган журналист һәм сәяси күзәтүче Фәрит Сәйфелмөлеков Татарстанның чит илләр белән бәйләнеш урнаштыруында Россиянең мөнәсәбәтен ачыкларга теләде.

—Россия белән мөнәсәбәтләрне җайга салу — безнең төп бурыч,— диде Лихачев. Без эшчәнлегебезне Татарстанның халыкара хокук субъекты булуыннан, милләтләрнең үзбилгеләнү хокукы булуыннан чыгып оештырабыз.

Әзербайҗан Милли Мәҗлесе вәкиле Максуд Мамедов утырышта үз җөмһүриятенә ярдәм сорады һәм шул ук вакытта, Татарстанның тышкы эшләр буенча алып барган сәясәтенә ярдәм йөзеннән, үз җөмһүриятендә Татарстан илчелеген беренче булып төзергә ярдәм итәчәген белдерде.

БДБның татарлар күп яши торган төбәкләрендәге милләттәшләр, анда оештырылган милли-мәдәни үзәкләрнең абруен күтәрүдә ярдәм-киңәш сорадылар. Бу җәһәттән дәүләтара килешүләр кирәк, ул чагында әлеге оешмалар татарлар өчен күбрәк һәм нәтиҗәлерәк хезмәт күрсәтә алачак.

Америка Кушма Штатларыннан килгән кунагыбыз Равил Салиәхмәт:

— Татарстанны тизрәк чит илләргә тулысынча танытырга кирәк! — дип ашыктырды.— Америкадан зур бизнесменнарны чакырыгыз! Чит ил капиталы өчен мөмкинлекләр ачыгыз! Шунсыз Татарстанны тиз генә танымаячаклар. Россия белән мөнәсәбәтләрегезне тизрәк ачыклап бетерегез! Законнарыгызны камилләштерегез! Шунсыз бизнесменнар сезгә игътибар итмәс. Бераүнең дә акчасын җилгә очырасы килми...

Төркиядән Садри Максудиның оныгы Г. Пултар, Польшадан Стефан Мостафа кебек кунаклар төрле илләрдә дуслык җәмгыятьләре төзергә, алар ярдәмендә, шул илләрнең рәсми оешмалары белән дә элемтәләр урнаштырырга кирәклеген әйттеләр. Америка Кушма Штатларыннан килгән Рифат Таби аеруча зур мәсьәләләр күтәрде. Алар Лихачев белән бик озак бәхәсләштеләр. Ахырдан В. Лихачев, күңелендәге канәгатьлек хисләрен кушып, болай диде:

— Мин бик шат: мөстәкыйльлеккә ирешү юлыбызда ялгыз түгел икәнбез. Барлык илләрдә диярлек үз һөнәрен профессиональ дәрәҗәдә белүче милләттәшләребез булуы — безгә зур таяныч. Рәхмәт сезгә!

## Татар мәдәнияте һәм әдәбиятының торышы, үсеш проблемалары

Бу «түгәрәк өстәл»не Татарстан җөмһүрияте мәдәният министры Марсель Таишев белән Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ринат Мөхәммәдиев алып барды.

Утырыш, алдан билгеләнгән бүлмәгә генә сыймыйча, язучыларыбызның Г. Тукай исемендәге клубына күчте. Кунаклар арасында бик мөхтәрәм каләмдәшләр-сәхнәдәшләр бар иде: Кырым әдибе Билал Мамбет, алман журналисты Фәрит Иделле, Төркия профессоры Надир Дәүләт, Фәрит Сәйфелмөлеков, чуваш Атнер Хузангай, Һади Такташ улы — ташкентлы Рафаил Такташ һәм башкалар.

Утырышта Марсель Таишев чыгыш ясады. Аның сүзләренә караганда, Татарстан мөстәкыйльлек юлына баскач, әдәби-мәдәни доньябызда эш җанлана төште. Яңа нәшриятлар, киностудия, театрлар ачылды. С. Габәши, С. Садыйкова, С. Хәким музейлары оешты. Әстерхан, Төмән, Ульян кебек шәһәрләрдә дә музейлар ачу буенча эшләр алып барыла. Әмма моңарчы «колач җәйгән» югалтуларыбызны болар белән генә тутыру мөмкин түгел. Тел бозылган, гадәтләр онытылган, милли сәнгатебезгә мәхәббәт суынган. Хәзер шул югалтуларны торгызу вә яңаларын булдыру мөмкинлеге туды. Вакыт җитте. Җиңнәрне сызганырга кирәк!..

Министр чыгышыннан соң күрше өлкәләрдә яшәүче милләттәшләрнең үтенечле чыгышлары яңгырады. Мәсәлән, Мордовиядән килгән кунак Камил Әхмәт андагы татарларга күрсәтелә торган мәдәни хезмәтнең бик түбән дәрәҗәдә икәнлеген бәян итте.

Өлкән әдибебез Әмирхан ага Еники милли әдәбиятыбызның барлык милләттәшләргә җиткерелү-җиткерелмәү мәсьәләсенә тукталды. Бу юлда хосусый милеккә һаман да юл ачылмавын ассызыклап үтте. Аңа куәт биргәндәй, Күкчәтаудан килгән делегат Хәким Муллабаев: «Безнең кибетләргә милли китаплар бик аз кайтарыла».— дип аваз салды.— «Китап-почта» дигән оешма безнең үтенечләргә игътибар итми, җавап хат та салмый. Татар гармуны да, милли киемнәр дә юк. Безгә нишләргә?»

Кыскасы, һәммә тарафта кызыксынучы эшлеклеләр кирәк!

Мөнбәргә Америкалы профессор Рифат Таби менгәч, мәшһүр язучы Ибраһим Сәлахов аңа зәңгәр ефәк чапан белән камчат бүрек бүләк итте. Рифат Таби, табигый ки, үз чыгышында җөмһүриятебезнең башка илләр тарафыннан тизрәк танылуына ирешүне алга сөрде. Шунсыз булмый.

Аннары Мәскәүдән Зөфәр Фәтхетдинов, Төркиядән Намык Кемаль бәй Зөябәк һәм башкалар чыгыш ясады.

Мәдәни мәҗлес тикшерелгән мәсьәләләр буенча карар кабул итте.

Җәмгыятьнең асылы аның хатын-кызга булган мөнәсәбәте белән билгеләнүен без бик яхшы беләбез. Бу төшенчә үзенә гаилә, милләт кебек төшенчәләрне дә иярттеп алып килә. Бөтендөнья татар конгрессының «Милләт. Гаилә һәм хатын-кыз» дигән «Түгәрәк өстәле» нәкъ менә шул мәсьәләләрне күтәрде дә инде. Бу утырышны «Сөембикә» журналының баш мөхәррире Роза ханым Туфитуллова алып барды.

Монда сүз, нигездә, буыннар арасындагы бәйләнеш, милли гореф-гадәтләрне саклау, телебезгә игътибар турында барды. Киңәшмәдә Казан авиация институты өлкән укытучысы Тәэминә Биктимерова, Америка Кушма Штатлары кунагы Шәмсия Апакай, Минзәләдән врач Асия Хәлимова кебек эшлекле кешеләр чыгыш ясады. Бәхәсләрдә мөхтәрәм язучыбыз Гомәр Бәширов та катнашты. Дин әһелләреннән Рәшидә остабикә Исхакова, Сәйдә Аппакова ислам дине кагыйдәләрен, татар балаларына иңдерергә кирәкле тәртип ысуллары турында искә төшерделәр. Зәкия ханым Рәсүлова татар зыялылары тормышына кагылышлы укыту ысулларына тукталды.

АКШтан килгән Шәмсия Апакай белән Нәркиз Агиш үз илләрендә, туган телләрен оныттырмас өчен, балалары белән хәтта юлда, машинада барганда да гел татарча гына сөйләшүләре хакында әйтеп уздылар. Төрек язучысы Г. Пултар (Садри Максудиның оныгы) аеруча дулкынландыргыч чыгыш ясады. Ул татар хатыннарының үз балаларында милли хисне саклап кала алуларына соклануын белдерде:

— Урысның шундый кырыс кануннарын җиңеп, үз милли аңыгызны, телебезне коткаргансыз! — диде.

Австралияле Фирдәвес Садри исә, каенанасы һәм каенсеңлесе Мөшәрәф укыта торган сыйныфлар эшчәнлеге турында сөйләде. «Без Татарстанны онытмабыз»,— диде.

Бөтентатар хатын-кызлар берләшмәсе (ассоциациясе) оештырылды. Бу оешма татар халкын бергә туплауга бөтен көчен куячак. «Түгәрәк өстәл»дә бу берләшмәнең Уставы һәм резолюциясе кабул ителде. Берләшмәнең идарә рәисе итеп «Сөембикә» журналы баш мөхәррире Роза Туфитуллова сайланды. Берләшмәнең тагын бер үзәге Хельсинкида да эшләячәк. Австралияле Фирдәвес Садри гаиләсе берләшмә фондына ун мең сум иганә кертте.

## Милли мәгариф системасын үстерү

«Түгәрәк өстәл»не Татарстан халык мәгарифе министры педагогия фәннәре докторы, профессор Васыйл Гайфуллин алып барды. Аның кереш сүзе бик тә гыйбрәтле булды. Министр үзенең чыгышында татар теленең әһәмиятенә, аның борын-борыннан ук дәүләт теле буларак, укыту-тәрбия даирәсендәге ролен ачыклауга иркенләп тукталды. Бүгенге көндә татар теленең арбуен кайтару, аның үсешен тәэмин итәргә кирәкле бурычларны билгеләде.

Бу очракта алфавитка кагылышлы фикерләрнең дә кузгалмый калуы мөмкин түгел иде, әлбәттә. Чөнки конгресска чит илләрдән килгән кунаклар безнең бүгенге кулланыштагы, кириллицага нигезләнеп төзелгән алфавиттан авыр файдаланалар. Үзара аралашу кыен. Өстәвенә, кириллица тәртибендә төзелгән алфавит татар теленең кайбер үзенчәлекләрен дә тиешенчә яңгырата алмый.

Төркиядән килгән профессор Надир Дәүләт үзенең чыгышында нәкъ менә шушы мәсьәләне күтәрде, кичекмәстән латин алфавитына нигезләнгән яңа алфавит булдырырга кирәклеген расларга тырышты.

Һәммәбезгә билгеле булганча, милли мәгарифтә тамырдан үзгәреш кертүне көтеп ятучы мөһим бурычлар биниһая күп. Шундыйларның берсен академик Миркасыйм Госманов телгә алды.

— Без, урта белемне мәҗбүри итеп белдердек тә, аның нәтиҗәсенә игътибар да итмәстән, һаман шул юлдан атларга тырышабыз. Нәтиҗәдә укучыларның табигый сәләтләре ачыла алмый кала, ә урта белем аттестаты балага һичнинди һөнәр дә бирми. Минемчә,— диде академик.— Без милли мәктәпләрнең төрледән-төрле булуына ирешик, үзәккә баланың сәләте алынсын. Ничә

еллык, нимдирәк һөнәр бирә торган уку йортын сайлавы баланың, ата-аналарның ихтыярына куелсын иде.

Мондый тормышчан фикер белән килешми мөмкин түгел, аңа күпләр кушылды. Татар иҗтимагый үзәгенең вице-президенты, филология фәннәре кандидаты Р. Ягъфәров, шул ук фикергә ялгап, инде югары уку йортларында да туган телдә укытуны хәл итәргә кирәклегенә басым ясады. Аның уенча, алда шундый перспектива күренеп тормаган очракта, бакчаларда да, мәктәпләрдә дә татарча укыту баланы ифрат кыен киләчәк алдында калдыра.

Татар теле укытучылары өзерләүгә тукталып, КДПИның проректоры, профессор Г. Габдуллин, Арча педучилищесыннан И. Сәгъдиев сөйләделәр.

Укытуда ана теленең әһәмиятен, зур мөмкинлекләрен искәреп, КАИ доценты Г. Зәбиров чыгыш ясады. Күпләр исә кадрлар, уку-укыту әсбапларының дәреслекләрнең җитешмәвенә һәм бу мәсьәләне тиз арада хәл итүнең зарурлыгына тукталдылар.

## Татар эшмәкәрләре (бизнесменнары) утырышы

Бу төр эшмәкәрләргә конгресс аеруча зур игътибар юнәлтте, чөнки җөмһүриятебезнең киләчәге, һичшиксез, аның җитештерү куәтенә, уңган, тырыш эш йортучеләренә бәйле булып калачак. Моңарчы Мәскәү күзенә, Мәскәү учына карап торып, ифрат та бай Татарстан икътисады тәмам бөлгенлеккә төшә язган иде. Әмма бу аяныч хәлдән безне мостәкыйльлек үзе генә коткара алмый. Бирелгән һәр мөмкинлектән тулысынча файдаланып, җиңнәрне сызганырга, җөмһүриятебезне, туган Татарстаныбызны мул вә матур итү өчен бик тырышып эшләү сорала.

Эшмәкәрләр мәҗлесен алып баручы Филзә Хәмидуллин (ул — Татарстанның премьер-министр урынбасары һәм Дәүләт икътисады комитеты рәисе):

—Безнең максат — Җир шарының төрле почмакларында яшәүче татар уңганнарын очраштырып таныштыру,— диде.— Шунсыз безгә Татарстандагы берсеннән-берсе катлаулы булган эшләрне ерып чыгарлык түгел. Базарларыбызга халыкка кирәкле малны тутыру, үз байлыгыбызны отышлы сату, башланган һәм ташланган зур-зур төзелешләребезне җиренә җиткерү, искереп, сафтан чыгу дәрәҗәсенә җиткән предприятиеләребезне файда-табыш китерерлек дәрәҗәгә күтәрү һәм башкалар, һәм башкалар... Әнә шулар турында ачыктаначык сөйләшсәк иде!

Мәҗлестә катнашучылар арасында Бөгелмә якларыннан Камчаткага китеп урнашкан гайяр җанлы зат Рәфгат Сәйфуллин бар иде. Ул — Камчаткадагы мөселман коммерция үзәге рәисе, универсаль коммерция компаниясе президенты икән. Камчатканың халыклары составыннан да яхшы хәбәрдар үзе. Камчаткада 8 меңләп татар яши, уңганнар, булганнар. Рәфгат әфәнде Япония, Сингапур, Тайваньда яшәүче татарлар белән дә тыгыз элемтә булдырган. Үз эшендә аңа ислам дине эшлеклеләре ярдәм итә икән. Шул ук мөмкинлекләргә таянып, ул Татарстан эшмәкәрләренә Көнчыгыш мәмләкәтләр белән файдалы хезмәттәшлек элемтәләре урнаштыруда ярдәм итәргә булды.

Шунысын да әйтергә кирәк: бу төр эшмәкәрләр тар диварларга, кыска өстәлләргә риза түгел, алар сөйләшүне саф һавада һәм әллә ни күпсанлы «күзколаклар» булмаган урында алып баруны хуп күрделәр.

Мәҗлестәшләр арасында шактый тәҗрибәле һәм замананың иң яңа төр һөнәрләренә таянып эш алып баручылар да юк түгел иде. Әйтик, Япониядән килгән Тәминдәр әфәнде Мөхит. Ул — ике зур фирма хуҗасы. Чит илләргә электроника җиһазлары, медицина аппаратлары һәм кер юу кулланмалары сата. Бәйләү машиналары да тәкъдим итә ала икән.

—Татарстанга кирәкле товарларны чыгару мөшәкатьләрен мин үз өстемә ала алам,— диде ул.— Әмма эшмәкәрлекне ышанычлы һәм файдалы итү өчен безгә халыкара күләмдә зур бер оешма кирәк. Минем уемча, мондый оешманың үзәге Казан каласында булуы хәерле.

Япониядә, Тәминдәр әфәндедән кала да, тагын дүрт-биш яшь татар эшмәкәре бар. Аларны кызыксындыру һәм уртак файдага эшләтү Татарстан эшмәкәрләренең бурычы булып кала.

Тәминдәр әфәнденең Үзәк оештыру фикерен Австралиядән килгән эшмәкәр Рөстәм Садри да хуплап чыкты. Бу әфәнде казанлыларга күптән таныш инде. Әмма әле аның да сизелерлек эшкә кереп китә алганы юк. «Татарстанның тышкы сәүдә кануннары эшләнмәгән,— ди ул.— Бу хәл нығытып торып сәүдә

эшләре ачып җибәрергә комачаулый. Халыкара югарылыкта кануннар булдырырга кирәк!»

Төркиядән килгән Фәрит әфәнде Бичури исә Татарстанга кирәкле предприятиеләр төзүне үз өстенә алырга әзер. Аның исәбенчә, мондый предприятиеләр Татарстан халкының ихтыяҗларын якын арада канәгатьләндерер иде.

Татарстан тормышын ныклы җирлеккә бастыру өчен иң әүвәл фәнни бер тикшеренү уздырмыйча да булмый. Эшне нидән башларга? Иң кирәкле чыгымнар күпме? Кемнәргә, нинди чыганакларга таянырга?.. Шуңа охшаш җитди мәсьәләләрне чишеп тотынмаганда, уңышка ирешүе икеле. Әмма мондый мәсьәләләрне хәл итәрдәй көчләр дә юк түгел. Бу фикерне Финляндиядән килгән Акиф әфәнде Али алга сөрде. Ул үзе — компьютерлар өчен программалар төзүче фирма башлыгы.

Бу утырышта күңелне шунысы дулкынландырды: кайда гына яшәмәсен, ни белән генә шөгыльләнмәсен, татар баласы үз туган туфрагында мул тормыш хөкем сөрүен ихластан тели икән.

## Яшьләр. Мәдәниятебезнең дәвамлылыгы мәсьәләләре

Яшьләр язмышына кагылышлы «түгәрәк өстәл» милли кыйммәтләрнең алдагы буыннарга да илтеп җиткерелүенә, кадерләп саклануына һәм үстерелүенә багышланган иде. Киңәшмәне «Дөнья» газетасы хезмәткәре Рим Гыйлфанов һәм Татарстанның яшьләр оешмалары советы рәисе Илдар Гыйльметдинов алып барды.

Киңәшмәдә Татарстанның бик күп төбәкләреннән, Башкортстаннан, Үзбәкстаннан, Санкт-Петербург, Мәскәү шәһәрләреннән, Ульян өлкәсеннән, Финляндиядән килгән кыз-егетләр катнашты. Казан университеты һәм пединституты студентлары аеруча күп иде.

Фикерләр бер мәсьәләдә уртаклык тапты кебек: татар телен үз хокуклары белән тулысынча коралландырырга, яңартырга, аңа әр-яңа үсеш мөмкинлекләре табарга! Тик шушы максатларга ирешү юлларын билгеләргә чират җиткәч, фикерләр шактый аерылды. Яшьләргә хас булганча, артык кайнарланып китүчеләр дә булды. Мәсәлән, КДУның татар филологиясе факультеты студенты Айдар Хәйретдинов, татар теле өйрәтүне мәҗбүри рәвештә кертергә, дип чыкты. Аның тагын бер кызыклы фикере бар: һәр елны татарлыкка иңдерү көннәре үткәрергә кирәк, ди ул. Шунсыз арабыздагы адәмнәрнең татармы-урысмы икәнлеген ачыклап бетерү һич мөмкин түгел. Ә безгә теләсә нинди дәһринең татар булып йөрүе кирәкми. Безнең милләт исемен күтәргән икән, чын мәгънәсендә татар булсын: телне дә, мәдәният-әдәбиятны да, гореф-гадәтләребезне дә ихластан танысын, белсен!..

КДУның тагын бер студенты Мөдәррис Каюмов татар балаларын, элекке еллар гадәтенчә, кызларга һәм малайларга бүлеп, аерым-аерым укыту мәсьәләсенә тукталды. Тыңлап утыручылар бу фикерне хуплап каршы да алдылар. Мөдәррис үз тәкъдимнәрен Татарстан законнарын караганда да искә алырга кирәклегенә басым ясады.

Яшьләр төрле мәсьәләләргә кагылдылар. Андреев, мәсәлән, татар әдәбияты классикасын яңадан, тулысынча басып чыгарырга кирәклегенә тукталды. Гаҗәп түгел. Яшьләребез, алфавитлар алмашынып торганга, классиканы белми диярлек.

Яшьләр «түгәрәк өстәле»нең кайбер кунаклары конгрессны танымау турында да сүз кузгаткаладылар. Аларга, ни сәбәптәндер, бу мәсьәләләр Милли Мәҗлес утырышларында каралырга тиеш кебек тоела икән. Төп сәбәпләрне, әлбәттә, алар аңлатып тормадылар.

Карап торганда, чыгышлар бик каршылыклы тоелса да, яшьләр мәсьәләләрен күтәргән «түгәрәк өстәл» бик кирәк фикерләр туплады һәм эшен нәтиҗәле төстә түгәрәкләп куйды.

## Татар телен үстерү

Бу хакта фикер алышырга җыелган галимнәр алдында аеруча катлаулы мәсьәләләр куелган иде. Телебезнең бүгенгесе, аның кулланыш даирәсен

үстерү, кадрлар туплау, алфавитны, имланы камилләштерү, тормыш-көнкүрештә, халыкара элемтәдә татар телен гамәлгә кертү... Ни генә юк!

Мәсьәләнең күпкырлы булуын чамалап, бу «түгәрәк өстәл»гә белгечләрнең дә төрледән-төрлесе килгән иде: телчеләр дә, кибернетиклар да, математиклар да, фәлсәфәчеләр һәм тарихчылар да. Кереш сүзне академик Мирфатих Зәкиев алды.

Җомһүриятебездә ике телне дәүләт теле дип игълан итү татар теленең абруен үз урынына куюда тагын бер катлаулылык тудырды. Аның икенчеллеге, мескенлеге кимемәде. Татар телен кулланыш ягыннан тергезү — безнең иң мөһим бурычыбыз,— диде ул.

Аның бу ихлас сүзләрен хупламый мөмкин түгел иде. Аны Казан университеты вәкилләре Ф. Сафиуллина, Р. Бохараев, Р. Якушев та күтәреп алдылар. Аларның теләк вә таләпләре түбәндәгедән гыйбарәт иде:

—Татар телен гамәлгә кертү буенча вәкаләтле комиссия төзелергә тиеш.

—Компьютерларның тормышта киң кулланылыш табуы татар теленең хәлен бигрәк тә кискенләштерде. Аны һәр тарафта куллану өчен бүген үк информацияне татар телендә булдыру системасын эшкәртергә кирәк.

—Татарстанда татар телендә эшләүче бердәм элемтә-информация коммуникацияләре төзү — кичектергесез мәсьәлә.

—Татарстанда дәүләт теле бер генә булырга тиеш. Җитәкчеләр исә ике телне дә белсен!

—Имла мәсьәләсен принципиаль хәл итү сәгате сукты. Латинга күчүне, шул ук вакытта гарәпчә өйрәнүне дә алга сөрергә кирәк.

Төркиядән, Мәрмәрә университетыннан килгән профессор Орхон Угыз болай диде:

—Заманында безнең мөхтәрәм президентыбыз Мостафа Кәмал Ататөрек латин әлифбасына күчүне бер төнлек эчендә хәл итте. Төрки халыкларының дөньякүләм мәйданга чыгуы бердәм латин графикасы булдыруга бәйле.

Төркиянең Измир университеты укытучысы Мостафа Өнәр:

—Иске классик телләрнең элемтәсе нык иде,— диде.— Казанда чыккан китапларны, гарәп хәрефләрендә булганнарын, рәхәтләнеп укый ала идек. Инде латин имласына күчә алсак, шул иркенлек кире кайтачак. Берләшик әле, туганнар! Ильминскийдан соң бәйләп тагылган ямьсез мирастан котылырга кирәк инде!

Бу «түгәрәк өстәл» дә катнашучылар татар телен латин графикасына күчерү буенча мөртәбәле резолюция кабул иттеләр. Анда дәүләт телен компьютерлаштыру, заманча чаралар булдыру, имланы гамәлгә кертү вакытлары һәм башка бик мөһим чаралар каралды.

## Матбугат һәм информация чаралары

Бу турыдагы әңгәмәне «Татарстан» телерадиокомпаниясенең ул чактагы рәисе Илгиз Хәйруллин белән матбугат һәм информация министры Шамил Хамматов алып бардылар.

Алга куелган бурычлар, киләчәккә планнар белән танышканнан соң кунакларыбыз, һич тә көттермичә, бер-бер артлы сүз ала башладылар. Мари республикасыннан килгән кунагыбыз Т. Галимов (врач кеше) үз төбәгендә алып барган милли эшләре белән таныштырды. Кызганычка каршы, мондагы күп кенә милләттәшләребез үз телен начар белә икән.

—Андый кардәшләребез өчен иң яхшысы — радио тыңлау, телевизор карау,— диде оратор.— Шунлыктан «Татарстан» телерадиокомпаниясе безгә өзер видеокассеталар җибәреп торсын иде! Аннары... бездә 1944 елдан бирле кырымтатар халкы да яши. Аларны да үз милли культура байлыклары белән таныштырып тору кирәк. Бездән башка бу хакта берәү дә кайгыртмас...

Пермь өлкәсенең Барда районында чыга торган «Таң» газетасы мөхәррире Гыйбрай Кәримов Татарстан тарафыннан китаплар юллау мәсьәләсенә кагылды. Ул якларда китап кәгазе арзанрак икән. Бергәләп тотынганда милли басмаларны арзангарак төшерергә дә мөмкин булачак.

Красноярск краеннан килгән Хәкимә Биюсева үз җирләрендә милли матбугат таратуның авырлыкларына тукталды. Аңа күп кенә законсыз каршылыкларга очрарга, шовинистик дошманнар алдында җавап тотарга туры килгән. Һәр эшне законлы рәвештә алып барырга кирәк, уңышка фәкать шул очракта гына ирешергә мөмкин икәнлегенә басым ясады ул.

Милли әдәбиятны, информация чараларын таратуда төрле каршылыклар очравы турында башкалар да сөйләде. Омскидан килгән кунак Разия ханым, Россия хуҗа булып алгач, беренче башланган милли тапшыруларның хәле кабат авырая башлавын хәбәр итте. Читтән килүчеләрнең бер теләге игътибарга лаек: татарча радио-телевидение тапшырулары алып барыр өчен кадрлар әзерләү мәсьәләсе күтәрелсен иде, диләр алар.

Бу җәһәттән Мәскәүдә дә эшләр шәптән тормый. Бирелә «Туган тел», «Болгар» кебек җәмгыятьләр, һәвәскәр театр студиясе оештырылган. Әмма алар арасында бердәмлек юк. Төгәл юллар билгеләнмәгән. Мәскәү кунагы Диләфрүз Хәйруллина:

— Без клубта ай саен бер спектакль куябыз, әмма радиотапшырулар, китап сәүдәсе юк дәрәҗәсендә,— диде.— Элек, җиденче яртыдан торып, радио тыңлый идек, хәзер шуны да бетерделәр. Безгә бигрәк тә татар китаплары кирәк. Китереп бирүчесе булса, үзебез сатар идек...

Әңгәмәдә катнашучылар Татарстанда чыгарыла торган вакытлы матбугатның алдыручыларга бик соң ирешүен дә телгә алдылар. Кайчак бу газета-журналларны кочагы-кочагы белән атнага, айга бер мәртәбә генә китереп ташлыйлар икән. Бу хакта, төптән уйланып, кискен чаралар күрергә кирәклеге хакында әйтелде. Алдагы елда бу мәсьәләләр тагын да катлауланачак. Үзләрен аерым дәүләтләр дип игълан иткән җөмһүриятләр анда яшәүче күпсанлы татарларны, гомумән, газета-журналларсыз калдыру алдында торалар. Бу турыда уйланырга да, кичекмәстән чаралар күрергә дә шартлар җитәрлек.

«Түгәрәк өстәл»не алып баручыларның берсе Татарстан китап нәшрияты директоры Харис Әшрәфҗанов татар китабын бастырудагы һәм аны таратудагы кыенлыкларга тукталды. Кызганычка каршы, безнең бу эш белән, ягъни татар китабын тарату-сату белән, аны җитәрлек дәрәҗәдә белмәгән кешеләр шөгыльләнә. Шуңа күрә эш авырайганнан-авырая бара, чөнки хәзер һәр адым базар мөнәсәбәтләренә бәйле. Чит өлкәләрдән килгән милләттәшләрнең бу эштә, ягъни татар китабын, матбугатын таратуда зур фидакарьлеге сорала.

«Түгәрәк өстәл»дә Казан университетының журналистика кафедрасы мөдире Флорид Әгъзамов та катнашты. Аның әйтүенчә, бездә кайчандыр өч йөзләп татарча газета-журналлар чыгарылган. Әмма аларның байлыгын өйрәнергә мөмкинлекләр юк. «Без һаман да шул баткаклыкта ятмабыз. Бу фәнне камилләштерергә һәм башка илләр дәрәҗәсенә ирешергә тиешбез!» — диде ул.

«Түгәрәк өстәл» махсус карар кабул итте. Анда:

— массакүләм информация чараларын, китап нәшрияты эшчәнлеген яхшырту өчен БДБ илләре белән Татарстан арасында килешү төзергә;

— сәясәт, икътисад һәм мәдәният, матбугат мәсьәләләре буенча Россия Федерациясе белән килешү булдырырга,— диелә.

Без менә шундый эшлекле сөйләшүләрнең нәтиҗәләренә өмет итеп калабыз. Татарстан язучылары өчен бу килешүләрнең кадере аеруча зур!

## Тарих һәм татар эмиграциясе

Без, татар халкы әлле кайларга чәчелгән, дибез. Бу сүзләрне хәрфән аңларга кирәкми. Чөнки татар халкы гел «чәчелеп» кенә тормаган, аның үзе биләгән җирләре дә бүгенге Татарстан җөмһүрияте мәйданыннан шактый киң. Тик без бу хакта сүз алып бармыйк әле! Бүген татар тарихы белән шөгыльләнүчеләрне мәсьәләнең башкасы — чит җирләрдә күпмеләп татар яшәве ныграк кызыксындыра. Заманаларның хәвефле булуы безгә моңарчы мондый тикшеренүләрне алып барырга мөмкинлек бирмәде, ярамый иде.

Әлеге олуг конгресс алдыннан да бу хәл үзгәрешсез калды. Әмма «Тарих һәм татар эмиграциясе» мәсьәләләренә кагылышлы «түгәрәк өстәл» янында сөйләшеп утырганда, Кыргызстаннан килгән галим Мөхмүт Юнысов үзенең шул юнәлештә алып барган эзләнүләре һәм аның нәтиҗәләре белән уртаклашты.

— Социолог буларак, фәкать үз тикшеренүләремә таянып кына шуны әйтә алам,— диде ул.— Минемчә, СССР әле бердәм ил чагында, чит-ят илләрдә 60 меңләп татар яши иде. Хәзер элекке республикалар үзләрен мөстәкыйль дәүләт дип белдерде. Тагын күпме татар чит илләрдә калды?!

Шул рәвешле, сүз үзеннән-үзе Татарстаннан читтәге татарлар язмышына барып тоташты. Арада шактый анык саннар әйтеп чыгыш ясаучылар да булды. Татар иҗтимагый үзәгенең президиумы әгъзасы Г. Фәйзрахманов:

—БДБ илләрендә бүленеп калган татарларның хәле яман,— диде.— Бер Төркмәнстан ягында гына да 80 меңгә якын татар бүген үк Татарстанга кайтырга тели. Тик, мәгълүм ки, безнең Югары Советта мондый эш белән шогыльләнүче махсус оешма юк. Минем ерак чит илләрдә яшәүче милләттәшләргә дә үтенечем бар: алар үз илләрендә Татарстан турында язып-язып чыксыннар, радиотелевидениеләреннән сөйләсеннәр иде. Татарстанны чит илләргә тизрәк танытуда бер чара булыр иде бу...

Моңа ялгап китеп, Австралиянең Аделаида шәһәрендәге татар җәмгыяте рәисе Сәгыйть ага Садри, кулларыннан килгәнчә, Татарстан суверенлыгын яклауларын аңлатты. Алар хәтта Б. Ельцинга махсус хат та язып салганнар икән. Садри әфәнде татарларны бердәм булырга чакырды, соңгы вакытта бирелгән форсаттан файдаланып калырга кирәклеген ассызыклап үтте.

Казан дәүләт университеты галиме Җ. Зәйнуллин исә мәсьәләнең яңа, куркынычлы бер ягына кагылды. Бүгенге яшьләр, вакытлы авырлыкларга буйсынырга теләмичә һәм башка илләрдәге конкурешнең чагыштырмача җиңеллеген белеп, тиз-тиз башка илләргә китеп калу юлына кызыгалар. «Ашыкмасыннар иде! — диде ул.— Мин Гарәбстандагы эмигрант кардәшләребезне күрдем. Аларның хәле һич тә мактанырлык түгел».

Румыниянең Констанца шәһәре университеты докторы Ә. Мамут Татарстанның чит илләрдә үз вәкилләрен булдыруны ашыктырырга кирәклекне аңлатты. «Әгәр, әйтик, Румыниядә Татарстанның консуллыгы ачылса, румын татарлары белән Казан татарлары арасындагы мөнәсәбәтләр тиз арада бик нык якынаеп китәр иде»,— диде ул.

Сүзгә йомгак ясагандай, «Донья» газетасының баш мөхәррире Римзил Вәлиев бу өлкәдә баш ватарлык проблемаларның күплегенә тукталды һәм татарларның эмиграция хәлен өйрәнүче бер үзәк кирәклеген телгә алды. Мондый фикер белән килешми мөмкин түгел.

## Милли кинематография

Татарның милли кинематографиясе әле «тәпи басарга» гына өйрәнә. Шунлыктан бу хакта җыелып сөйләргә теләүчеләр, мәсьәләне кай яклап башлап җибәрсәләр дә, ирекле иде. Мәгълүм булганча, Татарстан хөкүмәте 1991 елны, сәнгати һәм мультипликацион фильмнар төшерү өчен, «Татаркино» студиясе булдыруны алга бурыч итеп куйды.

Әлеге «түгәрәк өстәл»гә исә элекке СССРның төрле студияләрендә иҗат иткән милләттәшләр, мәшһүр киночылар җыелган иде: Булат Мансуров, Фәрит Дәүләтшин, Роза Хөснетдинова, Аделша Агишев, Дилшат Фәтхуллин... Әле килә алмый калганнарын да өстәсәң, үзе бер киностудия! Аларның күбесенең ата-баба җирен., туган Татарстанны беренче күрүләре.

Дөрес, безнең Казанның үзендә дә кино сәнгате осталары байтак. Соңгы елларга кадәр, бәхәсләр алып барылса да, Мәскәү рөхсәте булмаганлыктан, эш һаман сузыла килде. Әле хәзер дә казанлыларның кайберләре эшне зур сәнгати фильмнардан башлап җибәрүне хупламый. «Башта базасын, төшен булдырыйк!» — диләр алар. Әмма шул эштә зур тәҗрибә туплаган кунаклар башка фикердә. Аделша Агишев:

—Бөтен шартларның да булуын көтеп утыру — сәнгатьне тумас борын үтерү белән бер,— диде.— Хәзер үк фильмнар төшерә башларга кирәк! Нинди мөмкинлек бар, кем ярдәм итә ала — барысыннан да файдаланырга! Үзбәкстан, «Мосфильм» ярдәм итәргә мөмкин. Аннары, студия дигән нәрсә — бер бүлмә бит инде ул. Шуңа кереп утырган бер белгеч фильм төшерү өчен кирәк әйберләрне булдыра. Аның исеменнән куркып утырырга һич ярамый. Барлык шартлары булган студияләрдә дә түбән сыйфатлы, талантсыз фильмнар туып тора...Татарстан хөкүмәте бу эшне бик хуплый, шул ук вакытта нәтиҗәле иҗат көтә. Моңа кинематографистлар бик шат. Өстәвенә, эш башлану белән үк Казанга килеп иҗат итәргә теләк белдергән талантлы милләттәшләребез дә бар икән. Андыйлардан Шакуров, Абдулов кебек тамашачыларның сөекле актерларын атадылар. Сүз дә юк, бу әр-яңа тармакта тамашачы игътибарын җәлеп итәрдәй эш майтарганчы, әле шактый кыен мәсьәләләрне хәл итәргә туры килер. Әмма башлап йөрүчеләрнең дәртенә, фидакарьлегенә карагандa, һичшиксез, безнең үз кинематографиябез булыр, үз тарихыбызны, үз халкыбыз холкын чыгылдырган тулы канлы фильмнар экраннарга чыгар, дип өметләник.

Нинди эшкә генә тотынсаң да, аны кемгә тапшыру мәсьәләсе калкып чыга. Соңгы елларда исә безнең милли җомһүрият өстенә төшкән вазифалар күбесенчә читтән, үзәктән бирелгән һәм, күп очракта, хикмәтне төптән аңлап җитмичә, кушылган әмерләрне үтәүгә кайтып кала килде. Шунлыктан Бөтендөнья татарлары конгрессына җыелучыларны кадрлар хәле нык борчыганлыгы сизелде. Бурычлар күп — аларны үтәп чыгардай милли кадрлар кирәк!

Милләтне бүгенге кыенлыклардан аралап чыгарырдай белгечләр әзерләү, беренче чиратта, укытучыларның үзләрен булдыруга кайтып кала. Шуңа да әлеге җитди мәсьәлә турында сөйләшергә җыелган «түгәрәк өстәл»не Казан педагогия институты ректоры, Татарстан халык депутаты Рүзәл Юсупов җитәкләде.

Россия гуманитар университеты профессоры Әкъдәс ага Борһанов бу мәсьәләнең нечкә якларына тукталып үтте.

— Безгә, Россия гуманитар университеты мисалында, үз милли гуманитар университетыбызны булдыру кирәк! — диде ул.— Җомһүриятебездә мондый югары дәрәҗәдә Конгресс уздыру — зур нәрсә. Моны теләсә нинди халык та, теләсә нинди җомһүрият тә уздыра алмый. Милли кадрлар әзерләүне дә без шул ук югарылыкта, дәүләт эше дәрәҗәсенә күтәрергә һәм кичекмәстән хәл итәргә тиешбез. Моңарчы бездә гуманитар белем бирү юк дәрәҗәсендә кала килде. Ансыз Татарстан халыкара күләмдәге мөстәкыйльлеккә, аны барлык илләрнең дә тануына ирешә алмаячак.

Кадрларның кичекмәстән әзерләү кирәклеген бигрәк тә элекке СССРның төрле төбәкләрендә күпләп-күпләп оешып яшәүче татар вәкилләре хуплады. Пермь өлкәсенең Барда районы администрация башлыгы Сәлим әфәнде Назин, милли кадрларның беренчеләрен генә Казан әзерләсен, икенче буыннар үз туган якларында туган телдә укып чыгарга тиешләр, диде. Бу сүздә хаклык зур. Чөнки һәр оешмага татар кадры кирәк булган саен Казанга мөрәҗәгать итү, кадрны шундый ерак җиргә җибәреп укыту күп күләмдә өстәмә чыгымнарга да бәйле.

Кыскасы, бу өлкәдә дә бик күп мәсьәләләр күтәрелде һәм, бәхеткә, утырыштагы белгечләр милли кадрлар булдыруда баш җитмәслек киртәләрнең юклыгын билгеләделәр. Бары тик тырышырга, кул кушырып утырудан сакланырга кирәк. Шунысы мәгълүм: үзебез башлап йөрмәсәк, безгә әзергә бәзерне берәү дә китереп бирмәячәк.

## Татар халкының тарихы

Бу «түгәрәк өстәл»не җитәкләүче галимебез, Казан дәүләт университеты деканы, Татарстан Фәннәр Академиясенең член-корреспонденты, Индус Таһиров, әле конгрессның төп утырышында ук җитди чыгыш ясады.

— Без хәзер Җирдә татар булып яшәп калу-калмавыбызның гарантиясе турында сүз алып барабыз,— диде ул.— Бәйсез дәүләт булсак, без яшәрбез, киләчәк буыннар да яшәр!..

Аңлашыла ки, профессор бу уңайдан татар халкының тарихы гасырлар буе өйрәнелмәгәнлеккә ишарә ясады. Бигрәк тә тарихның бозып күрсәтелүе аянычлы. Бу утырышка Татарстанның күренекле тарихчылары, чит ил галимнәре җыелган иде. Һәр чыгышта тиз арада татар тарихын булдыруга, элек җибәрелгән хаталардан арынырга кирәклегенә басым ясап әйтелде.

## Мирас мәсьәләләре

Министрлар кабинетының утырышлар залында җыелган мөхтәрәм галимнәр, филология фәннәре докторы Флүн Мусин җитәкчелегендәге «түгәрәк өстәл»дә кыйммәтле мирасыбызның ни хәлдә икәнлеген анализладылар. Ике тапкыр алфавиты үзгәртелгәнлектән, татар халкы үзенең нинди зур мираска ия икәнлеген дә, аңардан файдалана алу мөмкинлеген дә белмичә яши.

Бәхеткә, әдәбиятыбыздагы һәм мәдәниятебездәге моңарчы сакланып калган байлыкларны барлауда сизелерлек ярдәм итәрдәй яңа журналыбыз чыга

башлады. «Мирас» исемле бу басма тиз арада укучыда зур кызыксыну да уятты. Аның кыю, бик җентекле язмалары, мирасыбызны лыклы җирлеккә бастыруда беренче адымнардан каралырга хаклы.

Әмма алдагы эшләр бер бу журнал сәхифәләренә генә сыеп бетәрлек түгел. Репрессияләнгән әдипләребезнең хезмәтләрен ничек барлап бетерергә дә аны укучыга, халыкка кай арада танытырга? Чит илләрдә яшәргә һәм иҗат итәргә мәҗбүр булган әдипләребез, галимнәребез хезмәтләрен нинди ысуллар белән туплап, җөмһүриятебезнең алтын фондына кертергә?

Утырышка катнашкан һәр илнең барлык галимнәре шул сораулар юнәлешендә чыгышлар ясадылар, уртак фикергә килделәр.

## Фәнебезнең торышы

Конгресс делегатлары һәм кунаклар арасында күренекле урынны БДБның төрле төбәкләреннән һәм күп кенә чит илләрдән килгән галимнәр алып тора иде. Аларның кайберләре фәнни лабораторияләрдә эшли, башкалары югары уку йортларында укыта. Алар, башлыча, Татарстандагы фәннең үсеш юлларын, потенциалын тикшерүгә багышланган «түгәрәк өстәл»не сайладылар. Утырышны Татарстан Фәннәр академиясе Президенты Мансур Хәсәнов алып барды.

Бу дәрәҗәдә барган сөйләшүләрнең һәр тармагына тукталу мөмкин түгел. Шуны гына әйтергә кирәк: утырыштагылар, үзләре кайдан гына килгән булсалар да — Нью-Йорк институтыннанмы, Төркия университетыннанмы, Мәскәүдәнме — теләкләр, омтылышлар уртак икәнлеге ачыкланды. Әле яңа гына оешып килүче татар фәннәр Академиясенә киңәш бирүчеләр дә, ярдәмгә әзер икәнлекләрен белдерүчеләр дә булды.

## Иске бистәләребез хәле

Мәгълүм ки, безнең Казаныбызның иң матур, архитектура ягыннан карaганда иң кадерле урамнары, йортлары, сарайлары шактый җимерек хәлдә. Аларның хозурлыгын кайтару исә зур чыгымнарга бәйле. Бүгенге җитешмәүчәнлек дәверендә бер генә шәһәр башлыгы да, калган мәшәкатьләргә күз йомып, бу биниһая авыр эшкә тотына алмый.

Казанны сагынып кайткан кардәшләрне шул мәшәкатьләребез белән дә таныштыру ниятеннән әнә шундый утырыш оештырылган иде. Аңа архитекторларыбыз озак кына әзерләнгәннәр. Планнар, өметләр, эшне башлап җибәрү өчен генә булса да кирәкле чыгымнар — барысы да исәпкә алынган иде.

Бу киңәшмәгә, кызганычка каршы, кеше азрак килде. Әллә ни зурдан кубып сөйләшергә мөмкинлек булмады. Архитекторлар берлеге рәисе Фәридә Зәбирова:

—Без алдан сөйләшүләр алып бардык,— дип аңлатты утырыштагыларга карап.— Тарихи бистәбезне саклап калырга, аның «тергезелүе»нә өлеш кертергә теләк белдерүчеләре дә бар кебек сизелгән иде. Чит илдә моңа бик оста кардәшләребез барлыгын тоеп торабыз. Инде менә сүлпәнлек килеп чыкты. Техник фәннәр кандидаты Фәрит Җамалиев та бу эшнең ифрат катлаулы булуына һәм шәһәр администрациясенең, тарихыбызга хөрмәт йөзеннән, бу татар бистәсен ничек тә «адәм рәтенә» китерергә тырышачагын аңлатты.

Әлбәттә, гомер эчендә беренче мәртәбә очрашып, «түгәрәк өстәл»ләргә бүленеп сөйләшүләрдә генә татар халкы алдына килеп баскан мең дә бер проблема һич тә хәл ителеп бетмәде. Бу утырышларда халыкка яхшырак булсын өчен җаның ярып бирергә әзер белгечләребез, эшмәкәрләребез, галимнәребез — кыскасы, фидакарь җаннарыбыз барлыгы ачыкланды. Бусы да бик яхшы. Зур эшләргә әле беренче ниятләр генә билгеләнде. Бөтен татар халкыннан таләп ителә торган олы эшләр — алда. Бу хакыйкатьне һәркем аңлап торды.

«Түгәрәк өстәлләр» янында сөйләшенгән сүзләр һәм киңәш-табышларның киләчәктә эшлекле адымнар булып гамәлгә ашуын көтик һәм үзебез дә актив катнашыйк, мөхтәрәм милләттәшләр!

Язманы **Кояш ТИМБИКОВА** әзерләде

# Васыйл Гайфуллин

педагогия фәннәре докторы, профессор,
Татарстан җөмһүриятенең халык мәгарифе министры.


## ТАТАР МӘКТӘБЕ: АЛДА НИЛӘР КӨТӘ?

Без моңарчы мәгарифтә гомуми-мәҗбүри урта белем булуга, һәркемнең урта мәктәп дәрәҗәсендә бушлай укый алуына горурланып йөрдек. Бер караганда, илдәге һәммә кешенең тигез белемле булуы әйбәт шикелле. Тик шушы изге максатның тормышка ашып җитү-җитмәве турында азрак уйлана идек. Чыннан да, һәркем бертигез белем аламы соң бездә? Укытуын укытабыз, әлбәттә. Әмма бу тоташ бертөрлелек, нигездә, уртакул белемле яшүсмерләр тәрбияләүгә, төссез белгечләр күбәюгә генә китереп чыгарды. Аеруча сәләтле шәхесләр шушы гомумилек эчендә югалып калдылар, күренмәс булдылар. Бүген исә талантларның юклыгы үзен нык сиздерә башлады. Баксаң, без мәгърифәт өлкәсендәге иң мөһим шартка — балаларның төрлесе төрле сәләткә ия икәнлегенә бөтенләй күз йомганбыз лабаса. Шул рәвешчә, җәмгыятебез уртакул укучыдан уртакул студент, аннан уртакул белгеч үрчетеп яткан.

Башка илләрдә күптән инде һәр шәхеснең тумыштан килә торган сәләтенә, теләгенә, максатларына таянып эш итәләр. Шушы беренчел сыйфатларга карап, анда уку йортларының да төрледән төрлеләре булдырылган. Җәмгыятькә кирәкле талантлы шәхесләрне ачыклау, аларга кирәкле шартлар тудыру, аларны күзәтеп-барлап тору башкача мөмкин дә түгел. Шушы бурычын үтәгәндә генә мәгърифәт кешенең башка ихтыяҗларына да җавап бирә ала. Бездә, кызганычка каршы, бу мәсьәлә еллар буенча чишелеш таба алмый торды.

Хәзер без әкренләп, уңышлы һәм бик үк отышлы булмаган тәҗрибәләр аша, барлык балаларны бер калыпка салып укыта торган мәктәпләрдән арына башладык. Юл башына шәхесне, аның табигый сәләтен куеп эш итәргә тырышабыз. Татарстан мәгариф министрлыгы хәзер тәмам өлгереп җиткән мәсьәләләрне дәүләт күләмендә, бөтенхалык күләмендә хәл итәргә омтыла. Министрлык 1995 елга кадәр ниятләп төзелгән план-программа булдырды. Аның «Талантлы балалар», «Экологик белем һәм тәрбия», «Хезмәт тәрбиясе», «Мәктәптән тыш тәрбия мәсьәләсе» кебек кызыклы бүлекләре бар. Программада тәрбиячеләрне һәм укытучыларны социаль яклау да, ата-аналарга мөнәсәбәт тә, укучыларга, инвалид балаларга ярдәм ысуллары да каралган.

Без министрлыкта тупланган яңа фикерләрне, закон төсен алсын өчен, махсус закон проекты итеп, хөкүмәткә тапшырдык. Төп максатыбыз — игътибарны халык мәгарифенең иң беренчел икәнлегенә юнәлтү. Чөнки һәр изге эшнең, нәтиҗәле эшнең башы мәгърифәтле эшмәкәрләргә барып тоташа. Шунсыз булмый. Бу хакыйкатьне тулысынча танымаган тәкъдирдә безне һаман зур югалтулар көтеп торачак. Сәләтле кешеләрне ачуда бөтен мөмкинлекләрдән файдаланырга кирәк: программалар ирегә, аерым укытулар, яшүсмерне чит илләргә җибәреп өйрәтүләр...

Без бу яңа талпынышларыбызда гомумхалык мәнфәгатен күздә тотабыз һәм, шуңа күрә, һәр тарафтан хуплау, ярдәм вә теләктәшлек көтәбез. Бәхеткә, омтылышларыбызны тормышка ашырырдай көчләр дә җитәрлек шикелле тоела. Тәвәккәл педагогларга, тәрбиячеләргә таянып без мәктәпләребезнең, бакча-ясләләрнең яңарыш дәверенә аяк басарга җыенабыз. Бу юнәлештәге эзләнүләр әле башланып кына килүгә карамастан, инде телгә алып сөйләрлек кайбер нәтиҗәләр дә бар кебек. Иң мөһиме — баланың шәхесенә игътибар артты. Шуңа таянып кайбер мәктәпләр укучыга махсус программа булдырды. Ифрат кызыклы бу алым министрлык тарафыннан да хуплана.

Соңгы ике-өч елда эзләнүчән педагоглар яңадан-яңа методик алымнарны сынап эшлиләр. Тәҗрибәләр җөмһүриятнең 250 ләп мәктәп һәм училищесында

алып барыла, төрле ысулларның саны кырыклап исәпләнә. Кайбер уку йортлары хәтта тәҗрибә үткәрү урыны булып санала. Алар, башлыча, Казан, Зеленодольск, Әлмәт, Бөгелмә кебек шәһәрләрдә урнашканнар. Андый уку йортларында университет, пединститут, милли мәктәпләр фәнни-тикшеренү институты күрсәтмәләре буенча да тәҗрибәләр үткәрелә. Безнең министрлык та читтә калмый, әлбәттә. Кайбер укытучылар, тәрбиячеләр исә бөтенләй күтелмәгән үз тәкъдимнәрен күтәреп чыгалар. Үз коллективларында ифрат кызыклы тикшеренүләр, күзәтүләр алып баралар, бик нәтиҗәле тәрбияви ысулларны тормышка ашырырга алыналар.

Бу җәһәттән, Казан, Чаллы, Зеленодольск, Бөгелмә, Әлмәт, Алабуга төбәкләрендәге кайбер мәктәпләрнең чын-чынлап тәҗрибә тирәлегенә әйләнүен әйтергә кирәк. Аксубай, Түбән Кама, Кукмара, Буа, Балык Бистәсе, Әгерҗе, Мамадыш, Октябрь районнарынын кайбер мәктәпләрендә дә уңышлы тәҗрибәләр бар. Аерым фәннәрне ассызыклап тирәннән өйрәнү буенча да тәҗрибәләр үткәрелә. Питрәч, Кама Тамагы, Арча районнарындагы педагоглар нәкъ менә шул юнәлештә эзләнүләр алып баралар. Махсус тармакларга юнәлдерелгән уку йортлары — мәктәпләр дә булдырылды. Аларда физика-математика, химия-биология, сәнгати-эстетик, педагогик, икътисадый юнәлешләр алга сөрелә. Мондый мәктәпләрнең саны хәзер 400 дән артып китте. Шуның яртысын авыл мәктәпләре тәшкил итә. Бу даирәдә утыз меңләп бала белем ала.

Мәгълүм ки, моннан берничә ел гына элек бездә лицей, гимназия, колледж кебек яңа төр уку йортлары да барлыкка килде. Андыйларны хәзер Казан, Чаллы кебек зур калаларда гына түгел, авылларда да табарга була. Бүгенге көндә җөмһүриятә унлап лицей, кырыкка якын гимназия һәм колледж бар. Моннан тыш Чаллыда муниципаль Шәхес үсеше үзәге ачылды. Аны КамАЗ акционерлык җәмгыяте үз карамагына алды. Алабугада ата-аналар берлеге хәйриясендә сәнгати-эстетик фәннәрне тирәннән өйрәнүче шәхси мәктәп эшли. Зәйдә исә инде менә ике ел татар теленә, тарихына һәм мәдәниятенә ныграк игътибар бирүне күздә тоткан якшәмбе мәктәбе булдырылды.

Яңа юлга аяк басуда безгә элекке тәҗрибәләр дә, югары квалификацияле педагоглар да, чит илләр үрнәге дә зур ярдәм булып тора. Һәм, әлбәттә, бу яңа төр уку йортларында үзләренә генә хас яңа алымнар, методик ачышлар, көтелмәгән табышлардан да кыю файдаланалар. Андыйлардан Казанның 11нче мәктәбендәге лицейны, Зеленодольскидагы укыту-тәрбия һәм Кама Аланындагы укыту-педагогика комплексларын мисал итеп китерергә мөмкин. Чагыштырып караганда, яңа төр уку йортларында белем бирү һәм тәрбия чаралары уңай якка шактый аерылып тора: фәнне үзләштерү тирәнәя, укучыларның дөньяга карашы киңәя, аларның сәләтеннән ныграк файдалану мөмкинлеге туа. Уку-укыту планнары да күзгә күренеп үзгәрәләр. Хәзер балалар кешене танып белү, психология, педагогика, дин тарихы, фәлсәфә, социология, логика, аралашу ысуллары кебек өр-яңа дәресләр тыңлый алалар. Чит телләрне өйрәнү дә башка җирлеккә күчерелә. Ул гимназияләрдә беренче-икенче сыйныфлардан ук кертелә башлый. Өстәвенә, ике чит тел өйрәнергә дә мөмкинлек тудырыла. Берсе көнбатыш илләр теле булса, икенчесе итеп гарәп, төрек яки фарсы кебек көнчыгыш халыклар телен сайларга мөмкин. Бу дәресләр интенсив ысул белән укыту алымына уңышлы таяналар. Яңа төр укытуга күчүче мәктәпләрне кайберләрендә (мәсәлән, Лаеш районында) фермерлык осталыгы, экономика, маркетинг (Казанның 39нчы мәктәбе) кебек тормыш-көнкүреш өчен аеруча кирәкле дәресләр дә кертелә. Бу юнәлештә эзләнүләр алып баручы мәктәпләргә Татарстан укытучыларның белемен камилләштерү институты да ярдәм итәргә әзер. Укучының сәләтен һәрьяклап ачуда кайбер мәктәпләрдә оештырылган факультатив дәресләр игътибарга лаек. Мондый сәгатьләрдә балалар риторика, сәхнә осталыгы, ритмика, аэробика, музыка, бию, җыр, рәсем сәнгате белән шөгыльләнәләр. Әлбәттә, мондый күпкырлы тәрбия алып бару өчен мәгариф челтәренең матди мөмкинлекләре җитенкерәми. Әмма эшне теләп оештыручылар ярдәм итәрдәй кешеләрне, хезмәт коллективларын да, спонсорларын да таба.

Казан университеты, авиация һәм химия-технология институтлары, мәсәлән, төрле түгәрәкләргә җитәкчеләр биреп, лекцияләр укып, кайбер мәктәпләргә ярдәм кулларын суздылар. Мәктәпләр белән вузларның үзара тыгыз, эшлекле мөнәсәбәттә торуы аеруча яхшы нәтиҗәләргә китерә.

Әйтик, Казанның 11нче мәктәбендә оештырылган педагогик лицейны тәмамлаучы ун бала — Казан педагогика институтының чит телләр факультетына, өчәве исә Истанбул университетына керделәр. Алар укуларын уңышлы дәвам иттерәләр. Зеленодольскидагы 3нче гимназияне тәмамлаучыларның барысы да

диярлек, инде өч ел рәттән, югары уку йортларына кергәндә, һичнинди авырлык та кичермиләр. Казандагы 131нче һәм Бөгелмәнең 6 нчы физика-математика мәктәпләрен тәмамлаучыларны да югары уку йортына керү имтиханнары һич куркытмый.

Кызганычка каршы, югары уку йортлары белән элемтәдә эшләү күп кенә мәктәпләргә житенкерәми шул әле. Алабуга пединституты, Казанның төзелеш, финанс-экономика, энергетика, ветеринария, авыл хуҗалыгы институтлары да бу мөһим чарага йөз белән борылып җитә алганнары юк. Югыйсә, мәктәпләр белән элемтәдә тору һәр институтның үз эшенә дә турыдан-туры уңай йогынты ясый бит.

Мәгарифтәге һәр яңалык ифрат авыр юл яра. Алдарак уңышлы якларны телгә алсам да, ачыктан-ачык шунысын да әйтергә кирәк ки, бу юнәлештәге сөенечләребез, көенечләргә караганда, бик аз әле. Күпчелек мәктәпләрдә яңалыкка ачык йөз күрсәтергә һич ашыкмыйлар. Хәтта тулы мөмкинлекләре булган районнарда да баланың сәләтенә киң колач бирердәй укыту алымнарын эзләмиләр. Актаныш, Баулы, Алексеевск, Чүпрәле, Мөслим, Саба, Яңа Чишмә, Әлмәт районнарында яңалыклар аеруча авыр кертелә. Чистай, Менделеев шәһәрләрендәге торгынлык безне тәмам аптырашка калдыра. Бу районнарның мәгариф житәкчеләре, мәктәп директорлары күзгә бәрелеп торучы, ифрат файдалы яңа ысулларны да күрмәмешкә салышалар.

Авыл мәктәпләренең хәле бигрәк тә зур игътибар таләп итә. Кайбер житәкчеләр монда нинди дер үзгәреш кертүне, балаларны дифференциаль ысул белән тәрбияләү-укытуны бөтенләй мөмкин түгел дип саный кебек. Әмма Кукмара районының Олы Сәрдек авылында оештырылган педагогик лицей мондый карашны тамырыннан юкка чыгара. Лаеш районындагы Столбище лицее да уңай мисал була ала. Бу лицейга, сынаулар аша үтеп чыкса, хәтта күрше район балаларын да кабул итәләр. Кызыксынучы житәкчеләргә Аксубай районындагы гимназия белән танышуның да зарары тимәс иде.

Сүз дә юк, яңа төр уку йортлары булдырганда, күп кенә чыгымнар тотарга туры килә. Укытучыларның атналык эше 15 сәгатькә калдырылды. Яңа төр белгечләр алырга, штаттагы хезмәткәрләр санын арттырырга мәҗбүр булдык. Шунысын да әйтергә тиешмен: әлегәчә бу яңа чыгымнарның үзен аклаганы юк. Киресенчә, тикшерүләр яңа төр уку йортларында да шактый кимчелекләрне табып тора. Мәсәлән, Казандагы 2 нче гимназиядә шундый хәл туды. Район мәгариф бүлеге ни карагандыр? Ялкау директорны әллә кайчан нигә алмаштырмаска иде?!

Кайбер урыннарда тиешле мөмкинлекләр дә тудырылмаган әле. Чаллыдагы педагогика лицее, мәсәлән, коллективның тырышлыгы нәтиҗәсендә генә уңышлы эшләп ята. Тиешле лабораторияләр, иҗат түгәрәге бүлмәләренең булмавы бу бик тырыш һәм кирәкле лицейга бөтен мөмкинлекләрен ачып салырга җай бирми. Мондый мисалларны, кызганычка каршы, күпләп китерергә була. Кайбер татар гимназияләре хәтта гадәти мәктәпләргә караганда да авыррак шартларда эшләргә дучар ителгән.

Тагын бер мөһим мәсьәлә бар әле. Яңа төр мәктәпләрдә программага, тормыш таләбе буенча, күпсанлы үзгә дәресләр өстәлә. Әмма алар гомуми белем бирүче фәннәргә хилафлык китерергә тиеш түгел. Бу шартта укытучы четерекле хәлдән чыгу юлын табарга тиеш иде. Киләчәгебез базар икътисадына бәйле икән, димәк, аның аяусыз законнары яшь буынга шушы уку дәресләренең киеренкелеге белән үк аңлашыла башларга тиеш. Яңа уку елыннан укыту-производство комбинатларының 9—11 сыйныфларына «Базар икътисады нигезләре» дигән курс та керә. Ничек кенә булмасын, киләчәктә һәр баланың табигый сәләте тулысынча ачылып житкерелергә һәм үстерелергә тиеш. Бу юнәлештә педагогларга тулы мөстәкыйльлек бирелә.

Дөрес, төрле укытучы бу мөстәкыйльлектән төрлечә файдалана. Кызганыч ки, кайбер тәҗрибәләр артык дәрәҗәдә «кыю» булып китте. Кайберәүләр, мода өчен, элек ирешелгәннәрне тулысынча җимереп ташлау юлына бастылар. Аның урынына исә, күңелләренә ни ошый, шуны урнаштырмакчылар. Янәсе, һәр укытучы үзенчә укытсын, кемгәдер иярү кирәкми дә, килешми дә, диләр алар. Шуны онытырга ярамый: педагогикада кемгәдер турыдан-туры ияру мөмкин дә түгел. К. Д. Ушинский әйткәнчә, тәрбия эшендәге тәҗрибә башка берәүгә тулысынча тапшырыла алмый, бары тик тәҗрибәнең асылын гына уртаклашып була; файдаланганда да, бары тик тәҗрибә турындагы үзгә фикерләрне генә истә тотарга мөмкин. Чөнки шартлар да, барыннан да бигрәк тәрбияләнүче балалар да, бөтенләй башка һәм алар бертөрле була да алмый.

Без яңалыкларны хуплыйбыз, тик һәр педагогик үз мөмкинлеген, осталыгын,

үз карамагындагы балаларның сәләтен тирәннән белеп эш итсен иде! Кайбер җитәкчеләр исә, кызганычка каршы, замана модасы артыннан кугандай, ашыгу-каударлану сиздерәләр. Кирәкле җирлекне әзерләми торып, яңа методикага күчәргә ашкыналар, әмма көтелгән нәтиҗә килеп чыкмый. Алдан ук хаталану ихтималын истә тотмыйлар, шунлыктан артка чигенергә урын да калмаган була. Элекке тәҗрибә пыран-заран китерелгән, ә яңасы уңышсызлыкка дучар ителгән. Балалар өчен шуннан да яманы юк инде. Мәктәпләрне бишкөнлек уку атнасына күчергәндә күп урыннарда әнә шуңа охшаш күңелсезлекләр килеп чыкты. Мәсьәләгә җитди карамау аркасында балаларның сәламәтлегенә дә зыян салынды, белемнәрне үзләштерүдә дә күзбуяучылыкка юл куелды. Чөнки кайбер сыйныфларга көненә сигезәр сәгатькә кадәр дәресләр кертелгән. Укучыга ял, спорт, күңел ачу өчен вакыт җитми башлаган... Уку программасын камилләштермичә тотынганлыктан күңелсезлекләр чыгу ихтималын чамаларга кирәк иде дә бит, эшкә иҗади мөнәсәбәтнең булмавы аркасында бөтен тискәре күренешләргә юл ачылган. Кайберәүләр хәтта уку сәгатен 40—35 минуткача кыскартканнар. Нәтиҗәдә, ел буена исәпләгәндә, 15—20 сәгать югалган булып чыга. Мондый юл белән ничек отасың инде?!

Һәр педагог, әгәр ул үз эшендә ниндидер яңалык кертергә уйлый икән, мәсьәләнең бөтен ягын кат-кат уйларга тиеш. Нәтиҗә уңай да, бик яман да булырга мөмкин — ул шуны онытмаса иде! Бигрәк тә яңа төр уку йортлары ачар алдыннан җиде кат үлчәп бер кат кисү кагыйдәсе истән чыкмасын иде. Мәктәп ишегенә яңа исем язылган такта кадаклап куюдан гына һичнинди файда да юк. Гимназия, лицей кебек уку йортлары өр-яңа программа таләп итә. Шуңа күрә дә андыйларны ачар алдыннан бик җентекле әзерлек эшләре сорала. Бүген эшләп килүче гимназия һәм лицейларның яңа җирлеккә басканын күрү өчен әле күп еллар кирәк булачак. Нәкъ шулар тәҗрибәсеннән чыгып әйтергә мөмкин: яңа типтагы уку йортларын бары тик бөтен шартлар белән тәэмин ителгән очракта гына ачарга кирәк. Тиешле программа, методик кулланмалар, әзерлекле педагоглар һәм укытучылар, матди-техник база — һәммәсе дә булсын! Татар гимназияләрен ачу өчен, өстәмә рәвештә, милли кадрлар, татар теле һәм әдәбияты буенча кулланмалар, Татарстанның географиясен, тарихын, мәдәниятен тирәннән белүче укытучылар кирәк. Шушы мөмкинлекләр юк икән, ишек-капка башындагы «гимназия», «лицей», «колледж» кебек сүзләр генә бер тиенлек тә яңалык бирмәячәк.

Яңа төр уку йортлары ачыла башлагач, кайберәүләр: «Әһә! Инде безнең балаларны югарыгы-түбәнге дәрәҗәләргә аерырга тотындыгызмыни?!» — дип, яман чаң суга башлады. Бу очракта кистереп әйтергә кирәк — монда балаларны тигезле-тигезсез баскычларга бүлү юк һәм булмаячак, бары тик һәр баланың үз сәләтен билгеләргә һәм, шуңа карап, аны дөрес тәрбияләргә омтылу гына алга сөрелә. Гимназиягә дә, лицейга да с ә л ә т е б у л г а н(!) һәр бала кабул ителә. Бу төр уку йортлары башка мәктәпләрдән алты ягы: сәләтле укучылары, талантлы педагоглары, яңа методикасы, укытуның күпкырлылыгы, программаның тирәнлеге һәм укучыларга киләчәк өчен төгәл юнәлеш бирүе белән аерыла.

Педагогикада төрле эзләнүләрне, тәҗрибәләрне кем, кайда, ничегрәк алып барырга тиеш соң? Заманның чиренә әйләнә башлаган яңалык артыннан куу галәмәте үзен һәрчак акламый бит ул. Шуңа күрә яңа тәҗрибәләрне бары тик эштә торгынлык, бер урында таптану сизелсә генә башлап җибәрү хәерле. Анда да бик җентекләп әзерләнгән җирлек кирәк. Эшне үзгәртә башлаганчы, яңалыкның ахыры кая барып чыгасын чамалау зарур. Үзгәреш ясарга җыенасың икән, мәктәбеңдәге мөмкинлекләрне күздән кичер, укучыларыңның сәләтен өйрән. Тәҗрибә үткәрүнең максатын безнең җөмһүриятtә түбәндәге мәсьәләләрдән чыгып билгеләргә кирәктер, мәгаен: тирәнәйтелгән уку курсын ачып җибәрү, бишкөнлек уку атнасы шартларында укыту-тәрбия чараларын оештыру, яңача укыту методикасын сынау, күмәк иҗади укыту методикасын өйрәнү, яңа төр уку йортларындагы эшләрне камилләштерү һәм башкалар.

Тәҗрибәләр алып бару өчен рөхсәтне кем бирә? Шулай сораучылар да бар. Әгәр сүз аерым бер укытучының эзләнүләре турында бара икән, аңа әллә кайларга барып, рөхсәт сорап йөрүнең кирәге юк. Бу эш педсовет рөхсәте белән генә алып барыла. Эшнең планы төзелә һәм коллективта тикшерелә. Аның барышы да гел тикшерелеп тора. Министрлыкның махсус приказында мәктәп башлап җибәргән яңа тәҗрибәнең Татарстан укытучыларының белемен камилләштерү институты тарафыннан да күзәтү астына алынырга тиешлеге әйтелә.

Мәктәп күләмендә тәҗрибә алып барылганда, эшнең киңәйтелгән планы район мәгариф бүлегенә тапшырыла. Моңа нинди дә юридик чара итеп карарга кирәкми. Бу — эшнең уңышын тәэмин итәргә тиешле шарт. Шул ук вакытта, мәктәпкә, тәҗрибә үткәрергә алынган педагогларга ярдәм дә, җаваплылыкны уртак итеп карау да.

Шулай да тәҗрибә үткәрергә алынган укытучы яки коллектив үзен чикләнмәгән хокукларга ия итеп тоймаска тиеш. Бу кисәтүне, зинһар, дөрес аңлый күрегез. Мин педагогикадагы яңалык кертүләрнең, төрле тәҗрибәләрнең ифрат та җаваплы эш булуына кабат басым ясарга гына телим. Алдан әзерләк күрү, барын да чамаларга тырышу кирәк.

Безгә кайчак тәҗрибә кылучыларны тыярга да туры килә. Берничә ел элек бер «новаторның» икенче мәктәпкә барып дәрес бирергә теләвен, ә аның урынына теге мәктәптәге «тәҗрибәче»нең монысына килергә теләвен ишеттек. «Максатыгыз нәрсә соң?» — дип сорадык. «Ник? Фәлән шәһәрдәге Фәләнев шулай иткән бит, миңа ярамыймы?» — ди бу. Кыскасы, бер тамаша кирәк булган моңа — шул гына. Бу төр «тамашалар»ның педагогик эзләнүләр, фәнни тәҗрибәләр белән һичнинди дә уртаклыгы юк. Чын ачышлар ясардай тәҗрибәче педагоглар адым саен очрамый, алар бармак белән санарлык кына. Бу хакыйкатьне һәркем яхшы аңларга тиеш. Җитәкчеләрдән исә аерым игътибар таләп ителә. Алар яңалык кертергә җыенучы укытучыны тикшерергә дә, аңа ярдәм кулы сузарга да тиеш. Эзләнүләр көткәнне бирми икән, вакытында бу уңышсыз тәҗрибәгә чик тә куелырга тиеш. Әлбәттә, мондый игътибарлылык җитәкчене борчулы шартларга куя. Шуны искә алып, без Казан пединститутында махсус әзерләк курслары булдырдык. Анда безнең мәгарифтә яңалык кертергә теләүче җитәкче кадрлар тәрбияләнәчәк.

Әлбәттә, соңгы берничә ел дәвамында гына алып барыла башлаган эшләребез, алда торган бурычлар белән чагыштырганда, ифрат дәрәҗәдә аз әле. Шулай да, эшкә җиң сызганып тотынган коллективларның тырышлыгына карасаң, күңелдә якты өмет чаткылары кабына. Шушы фидакарьлекне тагын да үстерү, ашкындыру, дәртләндерү — безнең төп бурычыбыз.

---

*Безнең календарь*

# ГАЛИ ХУҖИНЫҢ ТУУЫНА — 80 ЕЛ

Татар совет поэзиясендә күп еллар тырышып эшләгән һәм бай әдәби мирас калдырган Гали Хуҗи (Гали Хажи улы Хуҗиев) 1912 елның 17 октябрендә Татарстанның Апас районы, Карамасар авылында тимерче гаиләсендә туа. Авылда җидееллык мәктәпне тәмамлый, аннары Казан авыл хуҗалыгы институтына укырга керә. Ләкин бераздан, авыру сәбәпле, укуын ташларга мәҗбүр була. 1932—1941 елларда «Кызыл армеец» һәм «Яшь сталинчы» (хәзерге «Татарстан яшьләре») газеталарында эшли. Төп эшеннән аерылмыйча югары педагогик белем ала.

1942 елда ул үз теләге белән фронтка китә һәм җиңү көненә кадәр Беренче Украина фронтында татар телендә чыккан «Ватан намусы өчен» газетасының җаваплы секретаре булып эшли. Сугыштан соң журналистик эшчәнлеген дәвам итә: «Кызыл Татарстан» (хәзерге «Ватаным Татарстан») газетасында эшли. 1954—1962 елларда Татарстан Язучылар берлеге каршындагы яшь язучылар белән эшләү бүлегенә җитәкчелек итә. 1963 елдан — профессиональ язучы.

Гали Хуҗиның әсәрләре матбугатта утызынчы елларның беренче яртысында күренә башлый. Тәүге китабы «Шатлык» 1936 елда басылып чыга. Сугышка кадәр «Комсомолка» һәм «Хәсән күле» дигән поэмалар иҗат итә. Ә сугыш чорында ул патриотик темада актив эшли, биш поэма яза.

Сугыштан соң да героик үткәнгә һәм тарихи шәхесләргә багышлап күп әсәрләр тудыра. Утыз биш еллык иҗат дәверендә Г. Хуҗи дистәдән артык зур һәм кече күләмле поэма, баллада һәм шигъри цикллар иҗат итә. 1966 елда вафат булды.

# ХӨРМӘТЛЕ УКУЧЫЛАР!

Алдагы саннарыбызда гарәп һәм латин әлифбасын өйрәтүебез, уку күнекмәләре өчен әдәби һәм тарихи әсәрләребездән өзекләр бирүебез исегездәдер. Бу эшне дәвам итүне үтенгән хатлар редакциябезгә әле дә килеп тора.

Соңгы дәвердә мәдәни мирасыбызга игътибар арта, төрле дәүләтләр һәм халыклар белән бәйләнешләребез киңәя бара. Җәмәгатьчелек соңгы елларда татар язуын бүтән хәрефкә, күпләр латинга күчерүне куәтли. Бердән, шушы таләпләргә җавап рәвешендә, икенчедән, гарәп әлифбасында инде шактый күп язмалар басуыбызны хәтердә тотып, без моннан соң латин хәрефләрендә уку-язу күнекмәләрен бирүне дәвам итәргә булдык. Бу әлифбаны яхшы үзләштергән укучыларыбыз, бигрәк тә, яшь буын бай мәдәни, гыйльми казанышларга, камил технологиягә, компьютер техникасына ия көнбатыш дөньясы белән җиңелрәк аралаша һәм эш итә алыр, көнбатыш халыклары телләрендә укуга да әзерлеклерәк булыр дип өметләнәбез.

Кайсы авторларның нинди әсәрләрен яңалифчә укырга телисез? Сездән хатлар көтәбез, кадерле укучылар!

Ә хәзер атаклы шагыйребез Дәрдмәнднең берничә шигыре белән танышыйк.

## DƏRDMƏND

### BEZ

Ƣasьrlar kicte kitte... kicte jьllar!
Nəʙilər, padişalar sərde dəʙran....
Ƣəmerlərder, kycep kərʙan ʙə kərʙan,
kilep kicte çihandan qanca illər.

Synep, ʙəjran ʙulьp məƣmyr tijəklər,
Çir astьnda tezelde qu səjəklər.....
Isə çillər, kycə qomnar.... ʙetə ez...
Dəriƣ, məxzun kyꞑel, ʙez də ʙetəʙez!..

Məsafir kem, çihanƣa ʙastь ʙotnь,
Bijette aƶƣьrьp anь zamana....
Өjep cergən əmitne.... tөrtte utnь —
Çotьp utlarnь... kitte... jana.... jana....

## KORAB

Şaulьj diŋgez....
Çil erəder......
Çilkənen kirgən koraв!
Tən və kendez
Ul jezəder:
Jul вara, jat il qarap....

Cьqtь çillər,
Quptь dulqьn —
Il koraвьn çil serə!....
Qajsь jullar,
Nindi upqьn
Tarta вezne çan sorap?!

***

Gerləgən sular вaşьnda,
Tьnlagьz, şundan ytər,
Jersə sьqtap taŋ səxərlər
Moŋ sagьşlardan xijal.
I tugan ilneŋ havasь,
Rənçemim, zinhar kytər!
Rənçemim, zinhar kytər!
Ni gəzizrək, вu vatanmь?
Ah, tugan qəvmem gəziz;
Ul meqəddəs qan вelən ul
Izge setkə ni çitər?...
Set qalьr, vatan kitər,
Set qalьr, vatan kitər!

## МӘСКӘҮДӘ ОЧРАШУ

15 сентябрьдә Мәскәүдә Татарстан Республикасы Президенты М. Шәймиев белән Россия Федерациясе Президенты Б. Ельцин очрашты. Анда эре оборона предприятиеләрен халык хуҗалыгы өчен кирәкле продукция чыгарырлык итеп үзгәртеп кору һәм АлАЗ төзелешенә, агропромышленность комплексын үстерүгә кагылышлы кайбер икътисади мәсьәләләр тикшерелде. Күтәрелгән проблемалар буенча уртак тел табылды, хөкүмәт органнарына тиешле тәкъдимнәр һәм карарлар әзерләү буенча тиешле күрсәтмә бирелде.

Татарстан белән Россия арасында килешү төзүгә әзерлек мәсьәләләре дә игътибар үзәгендә булды. Фикер каршылыклары килеп чыгу сәбәпле, Татарстан Республикасы белән Россия Федерациясенең рәсми делегацияләре әлеге килешү текстын килештерү өчен эшне дәвам итәчәкләр.

## БЕЗНЕҢ ДЕЛЕГАЦИЯ ЛИТВАДА

Татарстан вице-президенты В. Лихачев, Премьер-министр урынбасары Ф. Хәмидуллин һәм Президент киңәшчесе Р. Хәкимов составындагы делегация Литва Республикасында рәсми визит белән булды. Делегацияне Литва Югары Советы Рәисе В. Ландсбергис кабул итте. Ике арада сәяси, икътисади һәм башка мәсьәләләр буенча төпле сөйләшү булды. Әңгәмә барышында ике дәүләтнең хезмәттәшлеген киңәйтү мөмкинлекләре, Литва белән Татарстан арасында мөнәсәбәтләр дәрәҗәсен тиешле килешү һәм башка актлар белән беркетү зарурлыгы әйтелде.

Татарстан делегациясе шулай ук Литва Республикасы Премьер-министры, вице-премьеры һәм хөкүмәтнең башка әгъзалары белән икътисади эшчәнлекнең ихтимал юнәлешләре, аерым алганда, нефтьне бергәләп эшкәртү, Литва флотын Татарстан ихтыяҗларында файдалану турында сөйләшүләр алып бардылар. Каунас һәм Казан шәһәрләрендә сәүдә вәкиллекләре ачарга килештеләр.

## ИГЕНЧЕЛӘР БӘЙРӘМ ИТТЕ

Татарстан быел үз тарихында беренче мәртәбә иң күп күләмдә ашлык җыеп алды. Бу җиңү — Татарстан мөстәкыйльлеген ныгытуда бик зур адым.

19 сентябрь көнне республиканың барлык районнарыннан, күрше республикалардан һәм чит илләрдән килгән күпсанлы кунакларны Лаеш районы «Җиңү» колхозы кырлары каршы алды. Җөмһүриятебездә инде онытылып бара торган бәйрәмнәрнең берсенә — «Татарстан кыры-92» бәйрәменә җыелды алар.

Бәйрәмгә Республика җитәкчеләре — Татарстан Президенты М. Шәймиев, Премьер-министр М. Сабиров, Югары Совет Рәисе Ф. Мөхәммәтшин, шулай ук район һәм шәһәр администрация башлыклары, министрлыклар, предприятие җитәкчеләре дә килгән иде. Кунаклар арасында күрше Мари-Эл республикасы Президенты В. Зотин да бар иде. Олы тантананың «Туган тел» көе белән башланып китүе һәммә кешенең күңеленә хуш килде.

Бәйрәм көн буе дәвам итте. Икмәк фронты батырларын Татарстан очучылары да котлады. Мәйдан уртасындагы келәмнең нәкъ үзәгенә алар зәңгәр болытлар арасыннан Татарстан байрагын алып төштеләр. Ямь өстенә ямь өстәп, җыр һәм бию ансамбле концерты күрсәтелде.

## КАҺАРМАН БАБАЛАРЫБЫЗГА — ҺӘЙКӘЛ!

Бөтентатар иҗтимагый үзәге, Мәдәният һәм сәнгать әһелләре берлеге 1552 елда Казанны чит ил басып алучыларыннан саклауда һәлак булганнарга куелачак һәйкәл проектына конкурс игълан иттеләр.

Конкурс йомгаклары буенча проект авторларын түбәндәгечә бүләкләү карала:

Беренче урынга — 10.000 сум.
Икенче урынга — 7.000 сум.
Өченче урынга — 3.000 сум.

Конкурска ярдәм итәргә теләүче спонсорлар табылса, бүләкләр зуррак та булырга мөмкин.

Конкурска эшләр 1993 елның 30 августына кадәр түбәндәге адрес буенча кабул ителә:

420111. Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27 йорт. БТИҮ. Телефоннар: 32—51—32.

## ГАЛИМНӘР КИҢӘШӘ

Күптомлы Татар энциклопедиясе кирәклеге һәркемгә мәгълүм. Ә менә моны чынга ашыру буенча нәрсәләр эшләнә соң?

Сентябрь аенда Татарстан Фәннәр Академиясендә энциклопедияне төзүче өлкән мөхәррирләрнең утырышы булды. Анда шәһәребез югары уку йортлары, фәнни тикшеренү институтлары галимнәре, Фәннәр Академиясе әгъзалары катнашты.

Утырышны Татарстан Фәннәр Академиясе президенты, академик М. Хәсәнов алып барды. Билгеләп үтелгәнчә, Татар энциклопедиясе сүзлегенең унатты бүлеге материал-

лары, аерым алганда: «Астрономия», «Биология», «Музыкаль мәдәният тарихы», «Фольклор» бүлекләре төзелгән инде. Әмма бу юнәлештә шактый хезмәт куясы бар әле. Сүзлек татар китап басмасы тарихында зур әһәмияткә ия булачак.

## «МИЗГЕЛ» ГАСЫРЛАРНЫ КОЛАЧЛЫЙ

Татарстан дәүләт кино үстерү фонды каршында эшләүче «Мизгел» киностудиясе быел берничә кинохикәя һәм киноповесть иҗат итте инде. Аларның берсе — халкыбызның гореф-гадәтләренә багышланганы «Каз өмәсе» дип атала. «Татарстан. Гасырлар һәм еллар» дигән фильм исә өч бүлектән тора. «Дус җанлы халык» — бусы Бөтентатар конгрессы турында.

Хәзер кино тасмаларында тагын берничә әсәр әзерләнә. Алар — «Казан утлары» журналына һәм татар китабының 270 еллыгына багышланган фильмнар булачак. Татар халкының бөек улы Мирсәет Солтангалиев турында да фильм эшләнә. Киләчәктә татар халкының бөек уллары турында башка киноновеллалар да иҗат итү күздә тотыла. Бу студия шулай ук татарча мультфильмнар да эшли.

Шулай итеп, татарча нәфис фильмнар төшерүгә акырынлап булса да әзерлек бара.

## АБРУЙЛЫ АНСАМБЛЬ — БАЛАЛАРГА

Сентябрь аенда Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбле коллективы Казан шәһәрендәге гимназия, мәктәпләрдә үзенең программаларын күрсәтте. Балалар өчен концертлар Ленин районының 3 нче музыка мәктәбендә һәм Киров районының 15 нче татар гимназиясендә башланып китте. Ансамбльнең алдагы чыгышлары Бауман районының 1 нче гимназиясендә, Ленин районының 85 нче мәктәбендә дәвам итте.

Ансамбль җырчылары Ф. Фәтхерахманов, Ф. Ялалова «Зәңгәр шәл» спектакленнән Булат — Мәйсәрә дуэтларын балалар һәм укытучылар күңеленә хуш килерлек итеп башкардылар. Ә бию группасы үзенең «Биш пар» биюен, талантлы яшь бию остасы А. Хәмитов башкорт биюен бүләк итте. Татарстанның халык артисткасы Н. Василова җырлары да туган якка мәхәббәт хисләре уятты. Ансамбль әнә шулай итеп яшь буынны тәрбияләүгә үз өлешен кертә.

## СИБЕЛГӘН ЯКТАШЛАР, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

Бөтентатар иҗтимагый үзәге быел төрле төбәкләрдән Казанга килеп тупланган милләттәшләребезнең якташлык җәмгыятьләрен төзү эшенә керешә. Пермь татарларының шундый җәмгыятен булдыру өчен оештыру комитеты төзелү турында милли матбугатта хәбәр ителгән иде инде. Октябрь аенда бу җәмгыятьнең оештыру конференциясе Казан театр училищесы бинасында узачак.

Чиратта — Әстерхан, Себер, Нижний Новгород, Пенза, Курган, Чиләбе һәм башка төбәкләрдән килгән кардәшләрнең якташлык җәмгыятьләрен төзү. Бу эштә ярдәм итәргә яки үзе дә катнашырга теләгән кешеләрнең Бөтентатар иҗтимагый үзәгенә хәбәр итүләре сорала. Телефон: 32—51—32.

## «КАЗАН УТЛАРЫ»: УКУЧЫЛАР КОНФЕРЕНЦИЯСЕ

Әдип халкы «тормыш пульсы»ын һәрвакыт кулда тотарга тиеш. Менә шуңа да алар рух, язарына азык эзләп халык арасына чыгалар.

Татарстан язучылар берлеге рәисе Р. Мөхәммәдиев, Г. Ахунов, М. Мәһдиев, А. Гыйләҗев, Р. Низамиев сентябрь аенда Әтнә районының «Искра» колхозында булдылар. Колхоз рәисе, авыл, иген хакында үзе дә китаплар язган Фәйзи ага Галиев аларны авыл хезмәтчәннәренең тормышы белән таныштырды.

Кичен авыл мәдәният йортында «Казан утлары» журналын укучылар конференциясе үткәрелде. Очрашу һәм кызыклы әңгәмә барышында язучылар күп кенә сорауларга җавап бирделәр.

## ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕНДӘ

* * *

Иҗат оешмабыз инициативасы белән, татарлар яшәгән байтак кына төбәкләрдә семинарлар үткәрелеп килenә. Август аенда шундый семинар Түбән Камада булып узды. Аңа шушы төбәктә яшәүче яшь иҗат көчләре җыйналган иде. Авторларның әсәрләрен тикшерүдә Язучылар берлегенең кабул итү комиссиясе рәисе Аяз Гыйләҗев, күренекле әдип Мөхәммәт Мәһдиев һәм әдәби консультант, шагыйрь Рөстәм Мингалим катнашты.

* * *

Күптән түгел «Татарстан хәбәрләре» газетасында аксакал әдибебез Әмирхан Еникинең Татарстан Республикасы Президенты М. Ш. Шәймиевкә ачык хаты басылган иде. Җөмһүриятебез башлыгы аны игътибарсыз калдырмады. Шул ук «Татарстан хәбәрләре» газетасының 6 август санында Президентыбызның Әмирхан ага Еникигә җавабы дөнья күрде. Мондый хат алмашу — демократик дәүләткә баруыбызны күрсәтеп торучы шулай ук бер күңелле факт.

* * *

Республикабызның Менделеев районында мәрхүм шагыйрь Егор Уткинның 60 еллыгы зур күләмдә билгеләп үтелде. Аның туган авылы Бөрешледә һәм район үзәгендә тантаналы кичәләр булып узды. Районның иҗади көчләре өчен Егор Уткин исемендәге бүләк тә билгеләнде. Ул бүләкләр елга бер мәртәбә бирелеп барылачак. Шагыйрь истәлеген билгеләүдә Казаннан килгән бер төркем әдипләр дә катнашты.

# БАБАЙЛАР ТУП ТИБӘ

Сез Башкортстанда туып һәм хәзерге көндә дә шунда яшәүче татар рәссаме Ринат Мидхәт улы Хәсәновның киндергә буяу белән ясаган рәсемен күрәсез. Анда авыл тормышы, көнкүреш халык иҗаты рухында сурәтләнгән. Картина күптән булып узган вакыйгаларны шулкадәр җанлы һәм тормышчан итеп күз алдына китереп бастыра ки, хәтта сизмәстән үзеңне дә шул чор кешесе итеп тоя башлыйсың. Вакыйга 1920 елларны хәтерләтә. Бу турыда буденовка башлыгы кигән ир кеше сыны һәм киндердәге башка, артык күзгә бәрелмәгән вак-төяк әйберләр дә сөйли кебек. Бабаларыбызның ул еллардагы гореф-гадәтләре һәм милли бизәкләр картинада бик ачык ярылып ята.

Хәзер картинаның сюжетын күздән кичерик. Менә татар авылы урамында хоккейга охшашлы уен сурәтләнгән. Күпләр өчен бу сәер булып тоелырга мөмкин. Татарларда борынгыда булган туп уенын, кайбер картлардан кала, күпләрнең белмәве бар. Хоккей татар халкының күптәннән килгән уенымы соң дигән сорау туарга мөмкин. Галимнәребезнең тикшеренүләренә һәм әби-бабаларыбызның сөйләүләренә таянып, без: әйе, хәзерге хоккейга охшаш уеннар элек татарларда да булган, дип әйтә алабыз. Әгәр дә без Р. Уразманованың быел Казанда басылып чыккан «Татар халкының йолалары һәм бәйрәмнәре» китабын актарып карасак, укмаштырып ясалган туп-сага куып уйнаганнары турында мәгълүмат алырбыз. Элеккеге Сембер өязе татарлары бу уенны — шәрәкә, мишәрләр — бүксә, ә керәшеннәр чүкәтә дип йөрткәннәр. Уен кагыйдәләре буенча тупны махсус әзерләнгән чокыр тирәли тезеп куелган йомыркаларга тидереп, аларны шул чокырга тәгәрәтеп төшерү шарт булган. Кайбер очракта, мәсәлән, Урал буенда, (Бәләбәй, Уфа өязләрендә) кәшәкә белән сугуы уңайлы булганга күрә, бер тупны икенче тупка бәреп уйнаганнар. Кем чокырга күбрәк йомырка тәгәрәтеп төшерә — шул кеше бүләккә йомырка алган. Халыкта хәтта: «Туплы уйнасалар, туклык була»,— дигән әйтем дә яшәгән.

Гадәттә, бу уен яз башында, кара җир чыгуга башланып, сабантуйлар белән бәйләнеп киткән. Уенны шулай ук җыен көннәренә чамалап, көзен уңыш җыеп алганнан соң да уйнаганнар. Ринат Хәсәнов картинасында уяну алды халәте рәсем сәнгате чаралары ярдәмендә бик дөрес тотып алынган. Киндердәге рәсемне табигать күренешләренә бик бай дип әйтеп булмый. Берничә агач, ерактагы урманчык һәм биек булмаган таулар, салкын кыштан соң әле зәңгәр төсен җыеп бетерә алмаган аксыл күк... Мондый төстәге күк безгә, игътибарыбызны башка нәрсәгә юнәлтмичә, картинадагы вакыйгаларны ныклап күздән кичерергә ярдәм итә. Табигать һәм авыл күренешләре дә, картинадагы персонажлар да безгә Урал буена урнашкан татар авылы һәм анда яшәүчеләрнең гадәти бер көне турында сөйли. Урал буе татар авылларына гына хас бизәкләр белән көязләнгән йортлар бик җентекләп төшерелгәннәр. Авыл манзарасының аерылмас бер кисәге булган кое да игътибарны үзенә тарта. Рәсемдә ул мәһабәт һәйкәлне хәтерләткән биек багана аша салынган сиртмә белән сурәтләнгән. Әмма һәрберсе үз эшләре белән мәшгуль булган авыл кешеләренең сыннары картина композициясендә төп урынны алып тора. Милли киемнәрен кигән балалар, картлар һәм хатын-кызлар авыл халкына гына хас шөгыльләре белән шулкадәр белеп һәм җентекләп иҗат ителгәннәр ки, хәтта аларга карап Урал буе татарларының үзенчәлекле милли киемнәре турында фикер йөртергә дә була. Уенчыларның һәвәсләнеп туплы уйнауларын һәм алгы планда гәпләшеп торучы ирләрнең торыш-кыяфәтләрен дә рәссам бик җанлы итеп биргән. Р. Хәсәновны персонажларның характерлары кызыксындырмый, ә аларны милли төсмерләүләр, кием-салымнары һәм гореф-гадәтләре аша чагылдыру рәссамның төп бурычы булып тора. Сез күргән күчермәдән аермалы буларак, рәссам кулы белән ясалган картина күпкә җанлырак, аның колориты да бик бай. Рәссам зәбәрҗәт-яшел, кызылсу-сары, коңгырт-сары һәм аларга капма-каршы булган ак төсмерле буяуларны куллана. Бу төсләр кушылмасы татар халык сәнгатенә, аеруча киеменә хас булып, Казан татарларында ул XIX гасырда чуар төсләр белән алыштырыла, ә Урал буе татарларында исә соңга калдәр сакланып кала. Р. Хәсәнов татар халкының көнкүрешенә бәйле гореф-гадәтләргә, рухи тамырларга киредән әйләнеп кайта. Бу очракта аның рәссамлык сәләтенә дөреслекне чагылдырырга ярдәм иткән фәнни әзерлеге дә өстәлә.


Гүзәл ВӘЛИЕВА-СӨЛӘЙМАНОВА.

**Тышлыкның дүртенче битендә:** танылган галим, тәнкыйтьче Азат Әхмәдуллин.

Ю. ФИЛИМОНОВ,
М. КОЗЛОВСКИЙ фотосурәтләре.

Бәясе 1 сум 80 тиен

Индекс 73210



КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)

Журнал включен во Всесоюзный каталог